ISSN 0206–4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

4.2012



# ИДЕЛЛЕ ТАРИХЫБЫЗ







*XX гасыр башында алынган фотосурәтләр.*
*Абдулла ДУБИН коллекциясеннән*

**Казан утлары**
**Qazan utlari**

2012

# 4
**(1074)**

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
*«ТАТМЕДИА»*
*ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рафикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Камил Кәримов, Ләбиб Лерон, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

*420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир—562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-93-16.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-39-63.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге—222-09-80.*
**Факс**—(843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

### ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. Соңгы карлар яуганда. *Хикәя.* ..... 5
Клара БУЛАТОВА. Үткәнемнең тамыр җебен эзлим. *Шигырьләр* ..... 12
Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы. *Роман-эссе.* ..... 15
Марис НӘЗИРОВ. Күп сынады язмыш ныклыгымны. *Шигырьләр.* ..... 61
Әхтәм ЗАРИПОВ. Галиябану туе. *Кыйсса* ..... 64

### САТИРИК ӘСӘРЛӘР КОНКУРСЫ

Марсель СӘЛИМ. Ышандырин. *Хикәя* ..... 122
Мөнир ВАФИН. Ялгыш кына. *Шигырьләр* ..... 125
Зиннур ХӨСНИЯР. Авыл малайлары... *Шигырьләр.* ..... 127
Нурислам АЙБУЛАТОВ. Комиссия. *Шигырь.* ..... 128
Илдус ДИНДАРОВ. Кырый урамда. *Шигырь.* ..... 129
Солтан МОРАТ. Такмаклар ..... 130
Хәмис ГАРИПОВ. И Казан... *Шигырь.* ..... 131
Бәдигыйзмнар ..... 131

### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Фәридә ХӘСӘНОВА. Флера Гыйззәтуллинаның шигъри дөньясы ..... 132
Рүзәл ЮСУПОВ. Ком сәгате дөрес йөри, сакау күке ялгышмый ..... 137
Рәниф ШӘРИПОВ. Рәмзиянең «Көмеш туны» ..... 142

### ФӘН

Гамир ГАРИФУЛЛИН. Нугайлар тарихыннан сәхифәләр. ..... 145
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы ..... 154
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ..... 156

### ХӘТЕР

Фәнис ЯРУЛЛИН. Хәтер төпләрендә утлы күмер ..... 159

### КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕ

Зиннур МАНСУРОВ. Иелгән башта таҗ тормас ..... 173

### ЮБИЛЕЙЛАР

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. Шигъри җанлы галим. ..... 181
ЙОЛДЫЗ. Ә хакыйкать һәрчак кирәк бит ул. *Шигырьләр* ..... 184
Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Кысага сыймас канат. *(Ләис Зөлкарнәйгә 50 яшь)* ..... 186

«Казан утлары» архивыннан ..... 120
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..... 190

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман-эссе Т. ГАЛИУЛЛИНА «Созвездие Магдеева» (прод.); повесть А. ЗАРИПОВА «Свадьба Галиябану»; рассказ Ф. ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ «Ожидание весны»; стихи К. БУЛАТОВОЙ, М. НАЗИРОВА, ЙОЛДЫЗ.
«Сенной базар»: Конкурс сатирических произведений.
«Наука»: статья Г. ГАРИФУЛЛИНА «Страницы из истории ногайцев»; Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень».
«Литературная критика»: Ф. ХАСАНОВА. «Поэтический мир Ф. Гиззатуллиной»; рецензии Р. ЮСУПОВА на книги К. Каримова «Песочные часы», «Картавая кукушка» и Р. ШАРИПОВА на книгу Р. Габдулхаковой «Серебряная шуба».
«Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Память»: дневниковые записи Ф. ЯРУЛЛИНА.
«Наши юбиляры»: статьи А. ЗАКИРЗЯНОВА, посвященная к 75-летию Н. Хисамова и Р. ЗАЙДУЛЛЫ, посвященная к 50-летию Л. Зулькарная.
З. МАНСУРОВ. «Мысли вслух».
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: культурный центр «Әкият» в городе Казани; писательница Альбина АБСАЛЯМОВА.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novel-essay by T. GALIULLIN «Magdeev's Constellation» (continuation); story by A. ZARIPOV «Galiyabanu's Wedding»; story by F. ZAMALETDINOVA «Waiting for Spring»; poems by K. BULATOVA, M. NAZIROV, YOLDYZ.
«Hay market»: Competition of satirical works.
«Science»: Article by G. GARIFULLIN «Pages from History of Nogai»; F. GARIPOVA. «History of our villages».
«Literary Criticism»: F. KHASANOVA. «F. GIZZATULLIN's poetic world»; reviews by R. YUSUPOV on books by K. Karimov «Hourglass», «Cartan cuckoo» and by R. SHARIPOV on book by R. Gabdulkhakova «Silver coat»;
«Pages of «Tatar encyclopedia».
«Memory»: diaries by F. YARULLIN.
«Our heroes of day»: article by A. ZAKIRZYANOV dedicated to 75th anniversary of N. Khisamov and R. ZAYDULLA dedicated to 50th anniversary of L. Zulkarnaya.
Z. MANSUROV. «Think aloud»:
From photo archives of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: cultural center «Akiyat» in the city of Kazan; writer Albina ABSALYAMOVA.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 02.04.2012, график буенча 02.04.2012.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ М–394. Тираж 4014.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ТУ 16-00337.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе иркле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2012 ел.



Фирүзә
Җамалетдинова

# СОҢГЫ КАРЛАР ЯУГАНДА

ХИКӘЯ

Ачык тәрәзәдән ялкау гына сибелеп кергән көмеш чәчкәләргә охшаш кар бөртекләре хатынның юка халат изүенә бәрелә, ялангач беләкләренә сарыла. Бөтен урам аклыкка күмелгән. Карлар инде башкача — яз рухын тоеп, яктырак җемелдәшәләр. Язның үзен сиздергән үтә дә рәхәт, аяз бер көнендә Рәфиләнең дә күңеленә бәйрәм рухы инде. Табигатькә бәйле тоемын югалтмыйча, ул тәрәзә янынннан кузгалып, бүлмә почмагына табан юнәлде һәм якын ук килеп шифоньер ишеген ачып җибәрде. Тонык төймә-күзләрен елтыратып торган иске язгы пәлтә, иркенлек тоеп, урыныннан кымшанып куйды. Рәфилә элгечтән алмый гына аңа шактый озак төбәлеп торды. «Искергән икән шул, — дип уйлады. — Бөтеркәләре дә күбәйгән...» Ничектер ул, бу мәлдә, гүя жансыз, кыршылган пәлтә басымы астында калды.

— Шушы пәлтә дә изә диген, ә... — дип сөйләнде. — Тфү-тфү, әйттем исә кайттым, кием дигән әйбернең ни рәвешле икәнен күрмәгән күзсезләр дә, аяк-кулсызлар да яши бит әле бу җир өстендә. Аллага шөкер бит әле, — диде ул аннан үз-үзенә каршы килеп. Пәлтәне элгечтән алып әйләндерә-әйләндерә карады да кире алган урынына урнаштырды.

— Шулай да театрга мондый иске-москы киеп йөрүчеләр юктыр инде хәзер. Тулай торак тирәсендә күренергә генә ярыйдыр бу пәлтә белән... Хәер, бик исе китеп тормый әле, утыз ел яшәгән оясында аны ни кисә дә таныйлар...

Ә менә театрга баруны нигәдер уена да керткәне юк иде шул быел. Бер атна элек бу хисне дә кузгатырлык сәбәп табылды. Эштән кайтып кына кергән иде, телефон шалтырады.

— Сеңлем, Зәки абыең машина җибәрә. Театрга җыенып ята идек бит әле без. Йортка күз-колак булмассыңмы дигән идек...

Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА — *язучы; «Тулымлы ай», «Догалы корт», «Еллар кәрваны» исемле китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Казанда яши.*

Телефонның аргы башындагы тавыш ягымлы ишетелсә дә, катгый һәм таләпчән иде. Апасы белән җизнәсе кай тарафка юл тотсалар да зур коттеджны гадәттә аңа гына ышандырып калдыралар шул... Бу юлы да ризалашты Рәфилә.

...Хан сараедай коттеджның иркен сулышлы бүлмәсендә ул апасының киенгәнен күзәтеп торды. Гаҗәеп бер тамаша итеп карап утырды. Менә алсу төскә буялып, өстенә энҗе бөртекләре сибелгән озын тырнаклар затлы шифоньер ишегенә үрелде. Менә аларның үрелүен үк яратып шифоньерның ишеге ачылып китте. Елык-елык килеп торган әллә ничә чәшке тун кукраешып йоннарын кабартты...

— Кайсын киим икән? — диде апасы назлы елмаеп. — Агы затлырак күренәдер, мөгаен... Син ни диярсең икән, сеңлем?

Ни дип җавап бирсен инде Рәфилә?

— Урамда туңдырган бүген. Кар да очыштыра... — дип сүзгә кушылды ул.

— Соңгы карлардыр инде, — диде апасы. — Ява дисәң дә дөрес булмас, пыяла кебек коелалар алар хәзер...

«Ай-һай, соңгылары микән?» — дип уйлады хатын эченнән генә, һәм чәшке туннар эленгән шифоньерга озак итеп төбәлеп торды. Ул киемнәрнең һәммәсе дә рухны биектә тотарлык илаһи көч өстәргә сәләтле иде. Кеше алдында үзеңне үзең җәлләмәүдән дә бөегрәк хис була аламы икән бу дөньяда?

Апасы кәч-кәч басып, яхшы киемнәреннән сулап туймаслык хушбуй исләре аңкытып, аяк астына күз дә ташламыйча чыгып китте. Ире янәшәсендә роза гөледәй гүзәл иде ул... Шул мәлдә Рәфиләнең күңелендә дә театрга барасы килү теләге баш калкытты. Янә иске пәлтәсе күз алдына килде. «Берәр җае чыкмый калмас әле, — диде ул, ышанычлы итеп. — Базарда пәлтә бетмәгәндер...»

Икенче көнне Рәфилә апасын «Вьетнам базары»на чакырды.

— Берәр пәлтә карар идек, апа, — диде. Телефон кинәт тынып калды. Бераздан авыр сулады. Аннан соң гына телгә килде.

— Җизнәңнең җәмгыятьтәге урыны бик зур бит, сеңлем... Хәерчеләр базарында мине берәрсе күрсә, аны унайсыз хәлгә куярмын күк... Түбән төшерергә ярамастыр җизнәңнең дәрәҗәсен...

Әллә нинди аңлаешсыз сүзләр сөйләде ул. Рәфилә байлар өчен шәһәрдә махсус кибетләр барлыгын белсә дә, апасы Вьетнам базарына барудан баш тартыр дип һич тә уйламаган иде. Менә кемнәр өчен тоталар икән ул базарларны! Җәмгыятькә кирәк икән лә алар. Әйтәм аны, диде ул үз-үзенә ачыш ясагандай, анда гел безнең ишеләр йөри. Күпчелеге хатын-кызлар — кимендә сигез сәгать эшләп, тәмам изелгән адәми затлар. Ә өйдәгесен дә кушсаң?! Анысын инде кем чутлаган? Арыганлыклары йөрешләреннән, салынып төшкән иңнәреннән үк күренеп тора. Алар өчен базарда үлчәве теләсә кемгә ярашлы кофталар сатыла. Оеклары да үлчәмсез. Башкасы да. Оек димәктән, тәмам затсыз инде алары, алып кайткан көнне үк тишелә дә чыга. Аннан ел әйләнә шул оекны ямыйсың. Череп беткәнче ямыйсың. Чөнки кул шуңа ияләшкән, күз шуңа күнгән була... Кеше изүдән тәм табалар диген, ә? Базар мөнәсәбәтләре имеш... Бәлки сәясәт мөнәсәбәтләредер?.. Тфү, тфү, әллә нәрсәләргә кереп киттем, кеше ишетмәсен тагын, — диде ул як-ягына каранып. Баядан бирле пип-пип кычкырып торган телефонын куйды да, Рәфилә кухня ягына атлады.

— Пәрәмәч пешереп алыйм, булмаса, өйгә бераз бәйрәм рухы таралсын, — диде ул базарга һәм дә театрга бару уеннан кире кайтып. — Берәр җае чыкмый калмас. Әлегәчә ялангач йөргән булмады ласа...

***

— Әни! — дип эндәште улы, компьютерыннан күзен алмыйча гына.
— Тагын нәрсә инде, — дип канәгатьсезлеген сиздереп елмайды ана, майда чыжлаган алсу йөзле пәрәмәчләрен әйләндерә-әйләндерә.
— Кил әле минем янга, әни!
— Башымны катырмасана!
Шул арада улы жил-жил атлап, сикереп дигәндәй якынайды да, кыскычтай куллары белән әнисен ике җилкә башыннан эләктереп, бүлмә түренә табан этеп китте.
— Күрсәтим әле, әни, менә бит нинди машина сайладым мин!
Раиф елт итеп кенә компьютеры каршына утырды, аннан төймәләргә җәһәт-җәһәт баскалады. Экранга кып-кызыл машина чәчрәп чыкты. Ул тыр-пыр килеп, әллә нинди биек йортлар арасыннан, тизлеген арттыра-арттыра алга очты.
— Шәпме, әни! Киттем мин... Пока...
— Каешыңны эләктерденме? Карап йөр, улым, — диде ана һәм елмая-елмая кысан бүлмәнең үзен һәрчак көтеп торган газ плитәсе куелган ягына юнәлде.
— Әни!
— Тагын нәрсә инде? Машина да машина имеш, — дип сөйләнде ана үзалдына. — Җәяү йөрмичә рәхәтләнеп.
— Әни дим! Кил әле минем янга!
— Әү, улым, аптыратма инде, зинһар, — дия-дия ана янә улы янына килеп басты.
Улы экранга төбәлгән карашларын мизгелгә дә аермыйча сөйләнде:
— Әни, күрәсеңме, монысы бик бай шәһәр була монын. Күрәсеңме мондагы байлыкны! Алтыннарны, долларларны... Капиталистларның да черегән байлары яши бу йортларда.
— Череп бетсеннәр лә, — диде ана тирән уфтанып. — Иртән илле тәңкә биргән идем юлыңа, шуның белән капиталистлар арасына барып кердеңме инде син, бәбекәем? Җәяү элдертә торган шәһәрләрне карарга иде, бәлки... Яки велосипедта йөри торганны... Яхшы илләрнең шундыйлары да бар диләр бит...
— Юк, юк, капитализмга җәяү бармыйлар инде әни. Велосипед белән дә барып житеп булмый анда.
Экранга бәйле шушы газиз затның җавабыннан канәгатьлек тоеп, ана янә ихластан елмаеп куйды. «Башы эшли малайның, — дип уйлады ул. — Димәк тарихтан имтиханын биргән. Шулайга охшап тора. Югыйсә «койрык» белән кайтып тәмам котны алды бит, чукынчык...»
— Җә, әни, ничек, шәп күренәме минем машинам? Ошыймы сиңа, ә?
Раифның авызы колак артына житкән, күзләре байгыш күзләредәй эреләнеп елтырый иде.
— Ошый, улым, ошый, — диде ана эчке рәхәтлек кичереп.
— Беләсеңме, әни, Илдарга туган көненә нәкъ менә шушындый машина алганнар, әтисе үзенә сайларга кушкан. Ә ул сайлаган. Менә шундыйны. Бүген институтка яңа машинасында килде... Тегесен туганнарына саткан... Мерседесын...
— Әйбәт булган, — диде ана исе китмичә генә. — Аның әтисе безнең оешманың директоры шул. Директор кешенең акчасы күп була аның. Әтиең белән минем кебек гади эшче түгел лә ул... Бик әйбәт булган...
— Нәрсәсе әйбәт? Аның машинасымы, минекеме?
— Синеке, әлбәттә.
«Синеке хәләл, улым, — диде ана эченнән генә. — Безгә хәрәм килешми

дә аннары. Килешкән кешеләр бар да соң! Аларга ул янгыр кебек сенә генә бара...»

Ана белән ул кинәт икесе берьюлы көлеп җибәрделәр. Аннан улы өстәде:

— Шулай диген. Беләсеңме, әни, аңа машинаны салонда эшләүче консультантлар үзләре сайлашкан. Йолдызлык буенча. Илдар Үгезбозау йолдызлыгында туган бит ул...

— Йолдызларның да тимергә катнашы бар микәнни, улым? — диде ана гаҗәпләнүен яшерә алмыйча.

— Бар, әни, бар! Үгезбозауларга «Volvo» машинасы алырга тәкъдим иткәннәр. Шушы машинада гына хәвеф-хәтәрсез йөри алачаксың, дигәннәр. Теге саткан Мерседесы белән шуңа төнлә күпердән очкан булган да инде ул. Больницада ятты күпме... Әни, минем дә туган көн житә бит, ә?

Ана компьютер дигән афәт эчендә тормыш итеп яткан улын кызганып тәрәзәгә төбәлде. Урамда ап-ак кар ява. «Соңгы карлар микән бу? Жылы карлар микән?» — дип үз-үзенә сорау бирде Рәфилә. Әллә нинди матур өметләр вәгъдә итеп килгән көн тагын узып киткән, язгы пыялада шәфәкъ алсуы уйнаклый иде.

— Бүген дә хезмәт хакын бирмәделәр, — дип сөйләнде ул үз-үзенә. Сүзләре уйларга ялганды: — Кризис та кризис дип тәмам желеккә төштеләр ләбаса. Көч түгеп тапкан хәләл ипиеннән мәхрүм итәләр. Бу хакта ул курка-курка булса да, житәкчесенә дә әйтеп карады югыйсә:

— Иписез ничек көн итмәк кирәк? — диде.

— Эшлисегез килмәсә, сезне беркем дә тотмый, дүрт ягыгыз кыйбла, иптәш Газизова, — дип теләр-теләмәс, иренеп кенә җавап бирде житәкче. Аннан алар бригадалары белән җыелышып суд органнарына мөрәҗәгать итеп, гаделлек эзләп карамакчы булдылар.

— Дөреслек фәкыйрьлеккә иш була алмый. Гаделлек тә бик еракта яши, анда барып житәр өчен юллар шактый урау хәзер, — дип теш арасыннан сүзләр сөзде директорга якынрак бер зат. Кыскасы, көндәлек мәгънәсез бер сөйләшү инде... Аның каравы, житәкчеләре үзе дә бу атнада өр-яңа машинада килде. Фаралары да шук мәче күзләредәй ялтырап тора... Бер төркем машина йөртүчеләр көне буена әллә нинди сиптергечләрдән сиптерә-сиптерә машина юдылар. Тәмам күзләр чагылырлык иттеләр...

— Әни, минем дә туган көн житә бит, — дип эндәште улы экрандагы дөньядан чыгып тормыйча гына.

— Житә дә узып та китә инде ул, улым. Былтыр туган көненә компьютер алдык бит менә. Әле кредиты да түләнеп бетмәгән. Әтиеңнең ярты ел жүнләп акча алганы юк.

Ана улы алдында зарланудан тыелып торырга уйлады. Сүзне башка юнәлешкә борды.

— Ә сиңа дигән машина компьютер эчендә үк булып чыкты бит әле, улым. Әнә ич, ничек шәп җилдерәсең! Рәхмәт яугыры!

Әйткән сүзләреннән Рәфилә үзе үк куркып, куырылып куйды. «Йа Ходаем! Быел институт бетерә бит инде бу бала. Кая барыр ул? Эше табылырмы? Үз көченә ышанган баланы кем көтә бүген? Укуы компьютердагы машина сыман бер мәгънәсез булса, нишләрсең? Чын машинаны әтисе кебек гомердә дә күрмәсә, ни хәл итәрсең... Тфү, тфү... Әйттем исә, кайттым... Берәр жүнен бирер әле Ходай...»

Җәмгыятьнең өзелгән жепләрен ялгамакчы булып хатын төрле-төрле уйларга батты.

— Шәп дисең инде, әни...

Улы компьютерына карашларын кадап янә сорау бирде:

— Ә бу шәһәр ошыймы соң сина, әни?

Ана ят калага төбәлде, кызыгып, гүя ул аңа фәрештәдәй өстән карап торды. Их, кереп кенә качып булсын иде дә соң шушы компьютер эченә! Әллә нинди тар урамнар, чуен күперләр, биек-биек жансыз йортларны юлның аргы очы суырып ала барды. Рестораннар, кафелар, Алып чабатасын каккан ком таулары, тагын әлләниләр күзгә чалынды. Улы кискен борылышларга кереп-кереп китте... һәм таш диварларга барып чәпәлде. Күз күрмәгән ят урамнар буйлап яшьлек ашкына иде...

Ни хикмәт, урамда бер жан иясе дә күренми, улының мондый ялгызлыгы ана өчен бик куркыныч тоелды. Ул арада машина үз юлына төште дә янә алга ыргылды. Баганасы да чыдам булып чыкты. Раиф әнисенең үз янында басып торуын да онытты. Аның дөньясы бары тик машина тәрәзәләре һәм юллардан гына гыйбарәт иде...

— Әллә ничек хәзерге яшьләр, — дип уйлады ана кухня ягына атлый-атлый. — Ниндидер үзгә бер тормыш белән яшиләр. Күз күрмәгән чит-ят илләр турында хыялланалар. Без яшь чакта туган ил берәү генә иде. Һәм ул бар иде. Бик тә кадерле иде. Хәер, әле дә шулай түгелме?.. Бу хакта китапларда язалар, сугыштан чулак булып кайткан бабасы да өзми-куймый сөйли торган иде, мәрхүм. Бала-чагасы да тынлый белгән инде. Хәзергеләрнең тыңлау сәләте дә юкка чыкканмыдыр... Менә улы белән дә еш кына бөтен сөйләшкәннәре ике-өч жөмләдән гыйбарәт.

— Кайттыңмы?

— Кайттым.

— Ашадыңмы?

— Ашадым.

— Институтта нинди яңалыклар бар? — дип сорый ана.

— Юк, — ди улы һәм курткасын да ычкындырып тормыйча компьютеры янына уза. Кабыза. Экранда яктылык күренгәч кенә киемен салып компьютеры каршысындагы урындык артына элә... һәм машина шәүләсенә ияреп, тып-тыныч күңел белән чит илләргә табан юл ала...

— Ничекләр тәртипкә өйрәтәсе икән соң бу баланы? — дип уйлый Рәфилә кайчакта. Апасы да:

— Тәмам итәк астыңнан чыгармадың инде улыңны, төн ул яшьләрнеке, беләсең килсә. Төнге клублар синең белән минем өчен түгел алар, — дип канына тоз сала.

— Ул клублары байлар өчен аның, — ди Рәфилә. Чөнки гомере буе да акчасыз яшәргә риза ул, тик газиз улкаен гына караңгы, билгесез төннәр тартып алмасын...

— Әйдә, уйный бирсеннәр компьютерларында, хыялларын үз күзләре белән күреп яши бирсеннәр, тик башларына гына зыян-зәхмәт кагылмасын... Кешеләр нишли икән соң мондый чакта? — дип уйлый ана. Эштә башкаларның да шул ук хәлләрне кабатлап сөйләүләрен ишеткәч, борчулардан янган йөрәге сүрелә төшә кебек...

***

Ә улы аның шул минутта тулай торакның кысан, тынчу бүлмәсеннән галәмнең алтынга күмелгән бер иленә барып житә дә дөнья баена әверелә. Юк, юк, патшасына! Менә монда катлы-катлы йортлар барысы да аныкы. Киң урамнар да аныкы гына. Машинасы да затлы. Рестораннары да. Акчасы да капчыклап. Мондый бәхетле һәм дә мондый рәхәт тормыш тагын кайда бар? Тик әнисе менә... Ачуны китерә шул әнисе. Көзгедәй юллардан жилдереп барган шәпкә тота да:

— Житте сиңа, малай! Дәресләреңне кара, — ди. Шул сүзләрдән көннең

бөтен кызыгы бетә, рәхәте китә. Илдар исенә төшә. Ана машинаның чып-чынын да алганнар бит әле. Ул өенә дә кайтмаган, институтка төнге клубтан гына да килгән бит әле... Ресторанга да үз машинасында йөри. Ресторан уйга килгәч, Раиф туктап калды. Ашказаны сулкылдап куйды. Бик нык тамагы ачкан икән ләбаса. Бүген институтта ашханәгә керергә өлгермәделәр шул.

— Әни, ашарга нәрсә бар анда? — дип эндәште ул компьютер экраныннан күзен алмыйча гына.

— Син, балакаем, бик зур шәһәрдә, бик затлы рестораннар тирәсендә йөрисең түгелме соң, шунда гына тамак ялгап ал инде бу юлы, — диде ана ихлас күңелдән улы дөньясына кучеп. Раиф айнып китте. Ачлык корты ашказанына ябышкан, ул аны сулкылдатып суыра иде. Егет экраннан аерылып аш өстәленә юнәлде.

— Аша, әнә, пәрәмәч пешердем, — диде ана өстәл өстендәге табакка ымлап. Аннан улы алдына чәй ясап куйды.

— Эч, улым, эч, — дип аркасыннан кагып алды.

— Кит әле, әни, — диде улы канәгатьсез генә борынын җыерып. Үзе капкан ризыгын тиз-тиз йотты. Ул шулай компьютеры янына ашыга иде...

***

Бу шәһәр дигәннәре авыл кешесенә һич килешми бугай, — дип уйлады Рәфилә. — Бер гаиләдә һәркем үз тормышы белән яшәсен әле... Үзе эштә. Ире дә эштә. Ул иртә таннан чыгып китә дә, бөтен тәрәзәләрдә утлар гөлтләп янып торганганда гына кайта. Кризис турында сөйләшергә дә кеше юк хәтта... Аның талчыккан кыяфәтендә һәм хәсрәтле карашында кризис дигән афәт болай да бөтен хасиятләре белән чагыла. Газаплы яшәештән арыган көннәрендә салгалаган чаклары да була. Моңа бераз эче поша инде әлбәттә. Әнә күрше хатынының ире көн дә исерек, тик бер тамчы исе китсә икән! «Эчсеннәр, ирләр эчмәсә, безгә зарплата бирмиләр бит, квартплатаны ничек түләмәкче буласың син? Бюджетны, аракы эчеп, ирләр генә тотып тора да аны», — ди. «Көйли, җайлый хатын-кыз тарта инде бу дөньяны, — дип уйлап куя Рәфилә. — Исерек ирен акларга да җай таба». Тик бер дә улына күрсәтәсе килми шул әтисенең «төшергән» чагын. Улы инде егет булды менә. Аллага шөкер, агулы суларга тартылмый. Тик ана да эшләп яшисе, шуны аңлый микән ул? Һичберкайчан бакчага булышырга алып барып булмый үзен.

— Минем вакытым юк, — дип кенә җибәрә. Хәер, ирексезләп эшләтү нигә инде? Вакыты юктыр, дип килешергә тырыша ана. Кояш йөзе күрмәгән, ак чырайлы улын табигатькә бик бәйлисе килсә дә, аның ябык иңнәренә авырлык төшерүдән үзе дә курка кебек...

***

Ана улы йоклаган якның чаршавын әкрен генә ачып җибәрде. Әнә иртә таннан уянып та килә инде ул.

— Чәй куй, әни, ашыгам, — диде улы яткан көенчә киерелә-киерелә.

Ул тиз-тиз юынып-киенеп өстәл янына килеп утырды. Тиз-тиз кайнар пәрәмәч белән чәй йотты. Аннан, тулы сумкасыннан бушатып, китап-дәфтәрләрен барлый башлады. Карават астындагыларын да тартып чыгарды хәтта. «Уку бик авыр эш инде, дип уйлады ана. — Ә мин анардан тагын әллә ниләр көтмәкче. Замана үзенә ничек кирәк тапса, шулай тәрбияли ич баланы... Мин ышанып тапшырган инде... Йә, тагын нишли алам соң?»

Шул мәлдә кемдер ишек какты. Рәфилә ишекне ачуга, иркен итеп елмаюдан алсу бит алмалары чокырланып торган гүзәл бер кызга тап

булды. «Иртә таңнан нишләп йөри икән бу бала?» дигәндәй, чибәркәйгә аптыраулы караш ташлады.

— Мин өй эчендәге милекне страховать итәргә килдем, апа, — диде туташ.

— Тулай торактагы милекнеме? — дип көлде Рәфилә. — Иске кухня шкафыннан кала ни булсын бирedә, сеңлем?

— Нигә, шкафны да страховать итәргә мөмкин. Янып китсә, яки урлап чыксалар, ягъни мәсәлән...

— Ничә тәңкәгә төшәчәк инде ул миңа? — дип кызыксынасы итте хатын.

— Сигез йөзгә генә, — диде кыз. Ул бик җитди иде.

Рәфилә аның күзенә төбәлгән көенчә, башын артка ташлап яңгыратып көлеп җибәрде.

— Мин аны дүрт сумга гына сатып алган идем шул... Моннан утыз ел элек, — дип куйды. — Урласалар ни, «котылдым» диярсең...

Кыз уңайсызланып кашын җыерды.

— Бөтен серегезне түгеп саласыз тагын апа, оялмыйсыз да үзегез... — диде ул тагын да җитдирәк итеп.

— Элек ояла идем мин, сеңлем. Хәзер оялмыйм инде. Дәүләт оялсын. Аракы эчмәдем, тәмәке тартмадым. Гомерем буена эшләдем дә эшләдем... Ат урынына тарттым мин бу дөньяны...

Кыз әйтер сүз тапмады. Кире борылды.

— Сез бай йортлар ягына барыгыз, — диде Рәфилә. — Тулай торакта кирәкле кешене таба алмассыз барыбер... Монда без барыбыз да бертөсле...

— Байларның иминлек компанияләре аерым шул, апа. Ә безгә план тутырырга кирәк, — диде кыз күңелсезләнеп һәм кисәк борылып, баскычлар янәшәсендәге лифт ягына юнәлде.

Ул арада тулы сумкасын аркасына асып, улы да ишек төбенә килеп басты. Кроссовкиларын кигәндә бер-ике авыз сүз алмашырга өлгерделәр.

— Трамвайга чыгасыңмы, улым?

— Автобуска.

— Урамда салкын бүген. Кар да очып тора. Җылырак киенергә иде.

— Соңгы карлар ул, әни... Салкын түгел алар, — диде улы, садәлек аша елмаеп.

— Әйе, соңгы карлардыр... Җылы карлар... Хәерле юл, улым. Хәзер мин дә кибеткә чыгып керим әле. Ипи беткән, сөт кирәк... Соңрак базарны да урап кайтырмын... Язгы пәлтә карыйсы иде...

Ул иске пәлтәсенә үрелгән арада улы күз алдыннан юк та булды. Ана лифт ишекләренең шалтыр-шолтыр ябылганын ишетте. Иминлек иленнән килгән теге яшь кызның бәллүр тавышы колагына чалынгандай тоелды. Ничектер, аңа кинәт ямансу булып китте. Әйтерсең, бәхеткә илтәсе бер яп-якты көн улын үзенә тартып алган иде. Бәхеткә булмыйча тагын... Киләчәк яшьләрнеке ич!

Рәфилә пәлтәсен кире элде дә, ишекне бикләп улы бүлмәсенә үтте. Аның караваты янына килеп урын-җирен сыйпады. Ана кеше генә тоя ала торган бәхеттән тулышып, улының җәймәләрен тигезләде. Ә ап-ак җәймәләр җып-җылы, ул җылылык аңа шулкадәр дә газиз иде...



Клара
Булатова

# ҮТКӘНЕМНЕҢ ТАМЫР ҖЕБЕН ЭЗЛИМ

***

**Ярсуын тыярга диңгездә буа юк,**
**Давылны җыярга кабык юк шулай ук.**
**Алай да ярларга бәрелгәч диңгез дә,**
**Ярсуы шиңә дә, яңадан чигенә.**

**Алай да каршында нык торган кыяга**
**Юлыккач, давыл да дучар бит тынарга.**
**Каршылык каршында тетелә барсы да,**
**Тик ярсу диңгезнең ярлары ашала.**

**Бәрелгән давылдан ягылган ярадан**
**Ныклыгы ватылган кыя да таркала.**
**Илләр дә, үзара каршылык туганда,**
**Җиңүгә ышанып чамасыз кылана.**

**Каршылык каршында ватыла барсы да –**
**Иминлек югала, бөтенлек югала.**

***

**Дистә еллар буе иңрәп эзлим,**
**Җеп очларын күрмим беркайда.**
**Кайда соң ул — минем туган җирем,**
**Кендек каным тамган җир кайда?**

**Юлдан табып кая китергәннәр?**
**Исеме дә шунда кушылган...**
**Ташландыклар түгел, табылдыклар**
**Булып үскән күпләр шушыннан.**

Клара БУЛАТОВА — *шагыйрә; «Язлар алда», «Һәрвакыт янымда», «Каурый канат — җил атым» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Татнефть» һәм Татарстан Язучылар берлегенең С.Сөләйманова исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Әлмәттә яши.*

Табылдыклар илгә кирәк булыр, —
Шул өндәве белән юатып,
Белем биргән, һөнәр биргән оя
Олы юлга калган озатып.

Олы юлда кеше кем булса да,
Нинди язмыш көтә бу көндә?
Үткәннәре илдә билгесезнең
Киләчәген белми беркем дә.

Үткәнемнең тамыр җебен эзлим,
Җеп очларын күрмим беркайда.
Кайда соң ул — минем туган җирем,
Кендек каным тамган җир кайда?

***

*М.Ц-га*

Диңгез кызы. Җирнең илсез кызы
Бик билгеле һәм бәхетсез кызы.
Шигърияттнең югалтулар үтеп
Күккә күтәрелгән бер йолдызы.
Шигърияттнең тирән төпләрендә
Әле ачылмаган исемнәр күп,
Бу фәкыйрең төпкә төшмәде дә,
Күтәрелмәде дә сезнең кебек.
Ә шулай да шагыйрәләр йөген
Гомер буе иңнәрендә йөртә.
Шагыйрьҗан дип атамый да үзен —
Тик шигырьләр язып гомер итә.
...Хәерчелек сыта аны талап,
Бөтергәләп фәкыйрь дөньяларда.
«Фәрештәләр һаман яланаяк,
Итекләрен шайтан урлаганга».
Син үзеңә-үзең кул салгансың,
Тәңре сине ничек кичергәндер.
Ә мин түзәм әле, бу дөньясын
Сөяр өчен көчем җитүдәндер.
Юк, үземне түгел,
Мин үземнән
Артыграк сөйдем кешеләрне.
Җырларым да, үземнекен түгел,
Күбрәк көйли алар кичергәнне.
Яшим юкса, синдәй юксыллыкта.
Көн туды исә һаман тиен санап.
«Итекләрен шайтан урлаганга,
Фәрештәләр һаман яланаяк».
Син башында егерменче йөзнең,
Ә мин менә егерме берендә.
Ике чор һәм ике халык кызы
Язмышларның уртак элмәгендә.

***

Апрельнең соңгы көннәре,
Тиздән май керә инде.
Быелгы майлар бу илгә
Ниләр китерер инде?

Табигать тә, җәмгыять тә
Һичнәрсәгә баш ими.
Җилкәләргә генә түгел,
Йөрәкләргә таш төйи.

**Һай, авыр ла бу дөньяда**
**Таш төялгән йөрәккә,**
**...Ташлар төеп тутыручы —**
**Якының булса бигрәк тә.**

**Айлар буе көнен, кичен**
**Борчылабыз, янабыз.**
**Гомер буе юк-бар өчен**
**Йөрәккә таш салабыз.**

## Ай, авыр, авырта

*(шаян җыр)*

**Һай, авыр, авыр, авырта,**
**Авырта йөрәккәем,**
**Нигә соң, әни, син миңа**
**«Яратма!» дип әйтмәдең?**
**Дөрес,син мине сакладың,**
**«Кичләрен йөрмә», — дидең.**
**Егетләр белән күрешеп**
**«Алдана күрмә!» — дидең.**
**Йөремсәк булып үсмәдем,**
**Йөрмәдем, алданмадым,**
**Алай да, сәгате суккач,**
**Яратмый калалмадым.**
**Ай, авыр, авыр, авырта,**
**Авырта йөрәккәем,**
**Нигә соң, әни, син миңа**
**«Яратма!» — дип әйтмәдең?**

***

**Апрельләр үтәр инде,**
**Җитәрләр майлары да...**
**Ялгызың ничек түзәрсең**
**Ямьле яз айларында?**

**Ямьле язлар үтәр инде,**
**Җитәрләр җәйләре дә...**
**...Егет көтү көтәр иде,**
**Зәй буе җәйләвендә.**

**Егет көтү көтәр иде,**
**Кыз сыер савар иде,**
**Егет кызын, кыз егетен —**
**Насыйбын табар иде.**

**...Язлары ел да яңара,**
**Җәйләр дә ел да кайта.**
**Тик кызлар, егетләр генә**
**Төрлесе төрле якта.**

**Авылда берсе калмаган,**
**Авылдан яшьләр китткән.**
**Җәйләүләр юкка чыкканга**
**Җәйләрнең яме беткән.**

***

**Берәүгә дә әйтми генә**
**Әле һаман фал ачам.**
**Ышанмаучан күңелемне**
**Ышандырып маташам.**

**— Дөрес менә, кайта бит! дим**
**Төймә төшсә алдыма.**
**Әгәр читкә тәгәрәсә:**
**— Көттерер, дим, аз гына...**

**Сине көткән кичләремдә**
**Фал дисбесе кулымда.**
**Йөрәгем ярылыр инде**
**Ул-бу булса юлыңда.**

Тәлгат
Галиуллин

# МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ ЙОЛДЫЗЛЫГЫ

РОМАН-ЭССЕ

**«Өч баһадир» һәм бер тәнкыйтьче турында риваять**

*Кешенең үз гомере буена тапкан иң зур табышы — Тугрылыклы дуслары.*

К.Насыйри.

Әле дә яхшы хәтерлим, 1994 елда татар матбугатында танылган фото остасы Мидхәт Шакиржановның ифрат кызыклы бер рәсеме пәйда булды. Рус былина каһарманнарына ошатыпмы, әллә бездә дә хөрмәткә лаеклы олы шәхесләр бихисап, дип, бәхәсләшепме төшерелгән рәсем берничә ел дәвамында Татарстан Язучылар берлегенең болын чаклы кабул итү бүлмәсенең диварында эленеп торды. Астына «Өч баһадир» дип язылган сурәттә XX гасырның икенче яртысы татар прозасының, бу сүзне авыз тутырып әйтәм, бөекләре төшерелгән иде: Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев һәм Мөхәммәт Мәһдиев. Бу истәлекле рәсем язучыларның альбомнарында, аерым алганда М.Мәһдиевнең «Кеше китә — жыры кала» (1996) җыентыгында да урын ала. Буйга дусларыннан калкурак, гәүдәгә тулырак М.Мәһдиев, нәкъ рус халык иҗаты узаманы Илья Муромец кебек, уң кулын маңгаена куеп, әдәби офыкны күзәтә. Язучылар берлегендә булганда шул фотога карап, сокланып, булган бит сүз сәнгатебезнең илаһи затлары дип уйланып кайтучы бер мин генә булмаганмындыр. Баһадирларыбыз үз вакыты белән берәм-берәм мәңгелеккә күчкәч, бу рәсемне кемдер ошатмыйча, дивардан алдыртты. Аның хәзер кая икәнлеге дә билгесез. Ник туганына үкенәсең килмәсә, керән кебек ачы, яхшы пычак кебек үткен телле Аяз әкә исән чакта кагылып кара иден бу рәсемгә. Үзе юкның — күзе юк, дигән шул халкыбыз.

Ни өчен нәкъ шул каләм ияләре сынга алынып, «өч баһадир» дип аталганнар соң дигән сөальнең тууы да табигый. «Талантлы язучылар» дип кенә котылыр иден, татар прозасы бер чорда да талантларга кытлык кичермәде, җитмәсә әле татар хатыннары башка милләтләргә Чыңгыз Айтматов кебек даһиларны бүләк итте. Үткән гасырның икенче яртысында гына да Г.Бәширов, Ф.Хөсни, М.Әмир, Ә.Еники, И.Гази, А.Расих, И.Салахов кебек өлкәннәр ышыгында Н.Фәттах, Х.Камалов, Р.Төхфәтуллин, Х.Сарьян, М.Хәбибуллин, Ә.Баянов

*Дәвамы. Башы 3нче санда*

кебек теләсә кайсы алга киткән әдәбиятның йөзенә кызыллык китермәслек сүз осталары күтәрелә. Соңгылар белән бер чорда яисә үкчәләренә басып килгән М.Әмирханов, З.Зәйнуллин, А.Хәлим, Ф.Бәйрамова, Ф.Садриев, М.Маликова, Р.Мөхәммәдиев, Ә.Гадел, М.Галиев, Ә.Гаффар, К.Кәримов, Ф.Яруллин, Р.Низами, Н.Әхмәдиев, З.Хөснияр, Р.Зәйдулла, Г.Гыйльманов, Р.Галиуллин һ.б. төрле буын сүз осталары хәзерге прозабызның горурлыгын тәшкил итәләр. Әдәбиятыбызны төптән тартып баручыларын гына саный китсәң дә, кул-аяк бармаклары житми, энже-мәрҗәннәрдәй жемелдәп үзләренә чакырып торган әсәрләрен уку рухыңны баета, татар халкының киләчәгенә өмет уята. Әле бит сүз сәнгатенең шигърият дигән илаһи төре, театр тоткан драматургиясе, вакыт-вакыт түрәләрне сискәндереп алган публицистикасы бар. Аларны да рәнжетәсе килми.

Шулай да рәсемгә өч язучыбыз дөрес сайлап алынган дип саныйм.

Әдәби очрашуларда, кичәләрдә аларны — өч дусны — Г.Ахунов, М.Мәһдиев, А.Гыйләжев — бергә еш күрергә мөмкин иде. Бу — табигый. Талант һәрвакыт үз ишенә тартыла. Алтмышынчы еллардан алып бу өч сүз остасы татар прозасының өлешчә драматургиясенең дә әйдәп баручы, йөзен билгеләүче язучылар буларак танылдылар. Ә инде И.Гази, М.Әмир, Г.Әпсәләмов, А.Расих, Ф.Хөсни кебек олы затларыбыз дөньяны ташлап киткәч, әдәбият дилбегәсе алар кулына күчә. Ижатлары да, үзләре дә бер-берсенә охшамаган, әмма уртак максат, рухи бөеклеккә омтылыш, милләт киләчәге өчен жан атып яшәү каләм ияләрен якынлаштыра.

Үткән гасырның икенче яртысында татар әдәбиятында барган үзгәреш-яңарышлар, рухи дөньябызның яңа кыйтгаларына үтеп керүләр, татар милләтен үзаңлы, кабатланмас үзенчәлекле, ямьле һәм мәгърур сыгылмалы телле, шуңарда мәңге яшәргә лаеклы халык буларак миллилекнең фәлсәфи расланышы нәкъ менә алар ижатында тулы гәүдәләнешен тапты. Социалистик реализм методы тантана иткән чорда тәнкыйди реализмны яңа югарылыкта «терелтүчеләр», жан өрүчеләр нәкъ менә шул каләмдәшләребез, бигрәк тә Аяз Гыйләжев белән Мөхәммәт Мәһдиев булды. Алар кальбеннән өзелеп төшкән роман-хикәяләр, бәян-драмалар, публицистик, тәнкыйди әсәрләр, истәлекләр вакыт узган саен яңа сыйфатлары, беренче танышуда күзгә бәрелеп тормаган гүзәллекләре, икенче, өченче мәгънәви тирәнлекләре белән ачыла баралар. Бу өч затны бер рәсемгә туплаган икенче сәбәп — аларның ихласи дуслыклары, дидек. Халкыбызның йөзек кашларыдай йөртелергә лаеклы ошбу шәхесләребез бер-берсенә таләпчән, ижатларына нисбәтән кырыс та була белгән аркадашлар иде. Ягъни әлеге якынлыкның нигезендә әдәбият үсеше өчен жаваплылык, рухи теләктәшлек ятса да, алар буш ләббәйкә яудыру дәрәжәсенә төшмичә, һәр яңа әсәргә (шул исәптән үз ижат жимешләренә нисбәтән дә) сыйфатына карап, бәя бирергә тырыштылар.

Миңа алар өчесе бергә туры килгән очракларда юлдаш булгаларга туры килде. Бу хакта язып чыкканым да булды. Гадәти, шул ук вакытта мәгънәле, дустанә һәм кинаяле сөйләшүләр, башкалар өчен сәеррәк тоелырга мөмкин төрттерүләр. Аларны якыннан белмәгән кеше берни аңламый. Менә алар, жилкәләрен «чәкештереп», мәжлестә утыралар.

— Гарифжан, бер пирог кисәген алып бирче, сиңа тарелка якын.

— Шаяртма, парин, анысы минем өчен артык зур. Хәзрәт малаена, Мәһдигә калдыр.

Мөхәммәт ишетеп ала.

— Егетләр, мин язучылар арасында иң аз ашаучы. Халык белә. Гариф, мине кочкан булып, пиджакка кулларыңны сылама әле, зинһар.

Аларны районга чакыралар. Дирижер Ахунов. Дусларына телефон аша ым сала.

— Сабага дәшәләр. Әллә чыгып, укучылар белән аралашып алабызмы?

— Шаһидә сине җибәрәме соң, Гарифҗан?

— Син, абзый, Нәкыяң белән сөйләш, Шаһидә апагызны көйләүне-җайлауны үз өстемә алам. Бер-ике көн салпы ягына салам кыстырсаң, юлга бер коньяк та төреп тыгар әле. Минем Шаһидә алай кысмырлардан түгел.

— Анысы ук булмас, парин, шыттырма!

— Аяз, «Яра» повестеңны сөреп чыктым. Мавыгып китеп, сәгать икедә генә ятылган. Яхшы әсәр язгансың, рәхмәт. Миңа «Өч аршын җир»ең күбрәк ошый. Монысына психологик эчтәлек җитеп бетмиме шунда, әллә мифологик фикерләүгә өстенлек бирәсеңме, өздереп әйтә алмыйм.

— Парин, син дә хаклысың, һәр елны бер үк дәрәҗәдәге әсәр биреп булмый икән. Мәһди каядыр ашыга. Язып бетерәсе әйбере бардыр әле. Һәр елны бер повесть, йә роман биреп бара. Берсеннән-берсе затлы әсәрләр.

— Син, Аяз, Мәһдине тоташ мәдхиягә чумдырып аздырма. Аңа да әйтәсе теләкләрем бар.

Үзара очрашканда төрттерү, үртәшү-көлешү, сүз белән чеметеп алу җитәрлек була иде. Ике яклы пычак кебек үткен телле А.Гыйләҗев:

— Мөхәммәт, дөресен әйт әле, синең әтиең, урыны оҗмах түрендә булсын, чыннан да мулла идеме?

Тегесе мәкерне аңламыйча:

— Ни өчен сорыйсың? Шикләнергә нигез бармы әллә?

— Бар шул, парин. Характерың йомшаграк. Мөәзин малаена охшабрак торасың.

— Мин сезнең белән генә шулай, кырыс таләпчәнлегем турында студентларымнан сора, — дигән җавап белән генә дусты Аяздан котылып булмасын чамалаган Мөхәммәт «ва банк» бара.

— Мин бит явызлыкка Караганда шахтасында өйрәнеп кайтмадым. Мин куркытылган нәсел баласы.

Шуннан соң инде икәүләшеп Ахуновка «күчәләр».

— Гариф, син ар телен беләсеңме? — ди Аяз әкә.

— Белмим. Миңа удмурт теле ни пычагыма кирәк.

— Әдәбиятларының классигы булып түрдә генә утырыр идең, — дип өсти Мөхәммәт.

— Килеш-килбәтең, йөреш-гадәтең белән син койган да куйган удмурт инде, — ди «Өч аршын җир» авторы.

— Ярый, күпсенмәгез. Бөек татар әдәбияты классигы булып йөрим әле, — ди Ахунов, сүзгә кесәгә кереп тормыйча.

Таныш-белешләре, якыннары күп булса да, ахыргача ачылып китә, серләрен уртаклаша торган дуслары күп түгел иде «өч баһадир»ның, талант талантка тартылу өстенә, әхлакый якынлык аларны берләштерә. Ә инде әдәби мәйданда алар рухына туры килмәгән, тартәгә тибә торган берәр зат килеп чыкса (мәсәлән, Ф.Мусин А.Гыйләҗев әсәрләренә берьяклырак бәя бирде), «тегене» урынына утыртуда бердәмлек үрнәге күрсәтә белделәр. М.Мәһдиевнең иҗат юнәлешен иң тирән аңлап, татар сүз сәнгатенә алып килгән яңачалыгын ачкан мәкаләләр А.Гыйләҗев («Сайланып чыккан сүзләр») һәм Г.Ахунов («Авыл пәйгамбәре») каләмнәреннән төште.

Прозабыз баһадирларын якынлаштырган, анысы инде үзләреннән тормаган, тагын бер тарихи сәбәп бар иде. Өчесе дә тоталитар режим камчысын, изүен татыган шәхесләр. Ачлыктан үлем хәленә җиткән гаиләсен саклап калу өчен бер күтәрәм бәрәнге урлап Гариф Ахунов төрмәдә утырып чыга. Үз башыннан узган хәлләрне тасвирлаган «Йөгез, бер дога» авторы кызлар култыклап йөрисе биш елын Караганда якларында уздыруга мәҗбүр ителә. Мөхәммәтне «сатлык җан» баласы исеме гомер буена диярлек эзәрлекли.

Миңа алар белән 1994 елның көзендә Питрәч районының Күн авылында еллык урып-җыюны тәмамлау бәйрәмендә катнашырга насыйп булды. Көннең бик яңгырлы, салкынча булуына карамастан, олуг затларыбыз белән аралашу үзе бер бәхет иде. Бу сәфәр турында «Өлкәннәр» исемле язмамны да бастырган идем. Шуннан соң унбиш елга якын вакыт узган булса да, кире кайтарып булмаслык ул көннәр һаман күз алдында. Ник дип әле шул очрашу-аралашу вакытында игътибарлырак булынмаган, яшәешебез кыйбласы, татар милләтенең кабатланмас үзенчәлекләре, әдәби барышыбызга, аның аерым шәхесләренә бәяләре турында сораштырмадым икән дип, үкенеп утырган чакларым аз булмады. Инде өчесе дә оҗмах кошлары. Мөхәммәт 1995 елда кинәт китеп барды. Кешенең гомере, халык җырындагыча әйтсәк, һай, бик кыска шул. Әнә, кара каргаларның 250 ел яшәгәннәре дә бар, диләр. Әле шул кыска гына тормыш аралыгында Ходай Тәгалә адәм баласына бихисап сынаулар җибәрә.

Мин бу шәхесләрнең өчесе белән дә, булсын «Казан утлары»ның редколлегия утырышында, булсын кабул итү коллегиясендә, гел аралашып, фикерләшеп яшәдем. Рәсми сөйләшүләр беткәч тә, гадәттә өч дус өйләренә ашыкмыйлар. Гариф абый кемгәдер телефоннан чылтырата, А.Гыйләҗев бүлмәдәге китапларның тышлыгын өйрәнә, Мөхәммәт бүреген угалап, кара кыска мутон тунының кесәсенә кулын тыгып, тәрәзәдән карап торган булып, баш мөхәррир Равил Фәйзуллиннан тәкъдим көтә.

— Абзыйлар, ашыкмагыз әле! Берәр чынаяк чәй эчеп алырбыз. Сөйләшеп тә бетермәдек кебек әле.

Бүлмә хуҗасының ымын көткән «абзыйлар» шул мизгелдә үк туарылып китеп, портфельләренә үреләләр. Тиз арада өстәл шоколад, чикләвек, су, коньяк ише тәгамнәр белән бизәлә.

Бүлмә хуҗасын кара ялтыравык өстәленең чиста калуы борчый, аңа тап төшеп, матурлыгы бозылмасын! Ник дисәң, редколлегия әгъзалары аңа газиз терсәкләрен терәп куеп, татар әдәбиятының сыйфатын, киләчәген билгелиләр. Һәркайсыбызның алдына чиста кәгазь, плакат, үткән елгы календарь ише әйберләр җәелә. Аз-маз капкалап, тамак кытыгын бастырып алганнан соң, китә протоколсыз аралашу, сөйләшү; фикер алышуның кинлеге галәм чикләренә дә сыймас дәрәҗәгә җитә.

Шул чорда вак-төяк күренгән сөйләшүләр, бер-берсенә теләкләр теләүләрдән алган тәэсирләр озак саклана, истәлек булып күңелдә яши. Шул мизгелдә әйтелгән фикерләр мәңгегә күңелдә калыр дип инансаң да, кеше хәтере бар нәрсәне саклый алмый шул. Язын мәңге яшелләнеп торырдай яфраклар көзен шыбырдап коелган шикелле, бик мәгънәле сүзләр, фикерләр төшеп кала икән.

Сүзне, гадәттә әүвәл рәсми кеше буларак, сонрак «йогып» калган гадәт буенча, «мин болайрак уйлыйм», дип Гариф абый башлап җибәрә, Мөхәммәт белән мин дәвам иттерәбез, аннан инде дилбегәне кулына алып, авызыннан саесканны Аяз абый очыра, сүзне «Өч аршын җир», «Җомга көн кич белән», «Яра», «Әтәч менгән читәнгә» кебек укыла торган әсәрләренең туу, язылу, басылу, бәя алу тарихыннан башлап, яшь чактагы егетлекләренә чаклы барып җитә. Сөйләүченең берәр чәркә капкач, арттырып, камырга чүпрәне өсти торып, күпертеп сөйләргә яратканын барыбыз да яхшы беләбез, шуна күрә аның бериш бәяннарын халык иҗаты үрнәге кебек, елмаеп-көлеп, «алай үк булмагандыр», «бераз арттырасыңдыр» кебек шик белдергәндәй башларны селкеп, нотыкчыны кыздырып, канына тоз сибеп утырабыз.

Арабызда барыбыздан да, миннән дә яшь, Иделне аркылыга йөзеп чыккан, шигыренә дә, яшәешенә дә узышчы холкы салынган Равилнең утырганын онытабыз. «Әйдәгез, теләгәнчә шыттырыгыз, абзыйлар, бу

өстәл янында демократия», ди иде кебек аның күз уйнатуы. Купертүләр гиперболага юл бирә башлагач, аның да тәкате корый.

— Аяз абый, бер ук вакытта өч гүзәл кыз артымнан бәйләнеп йөрде, дип, арттырасыңдыр инде.

Сөйләүче бүлмә хуҗасының сүзен бүлдерүенә исе китмичә, борын очына якынлашып килгән күзлеген күтәребрәк куя да:

— Соң, парин, без монда ни өчен җыелдык соң? Бераз өстәп күңелне күтәрмәгәч тә. Бу хәл минем белән булмаса, берәр каһарманым шундый бәхеткә тарган булырга мөмкин.

Шул рәвешле, елына бер яки ике була торган мондый очрашуларның «гаепле» кешесе талантларны таный, өлкәннәрне олылый белгән, күренекле шагыйрь, «Казан утлары»ның баш мөхәррире Равил Фәйзуллин дигән идек. Аяз әкәнең сөйләшүләргә юнәлеш бирүчән теле, Мәһдиевнең йомшакка утырткан булып катыга төшерүе, Ахуновның урыныннан сикереп торып, як-якка сибелгән чәчләрен тәртипкә чакырып чәчрәп чыгуы, бүгенгедәй күз алдында. Шул очрашулар барышында бер-беребезне аңлап, күктән эзләгәнне җирдән таптык. Тыштан караганда, безнең арада уртак нокталар да юк кебек. Равилнең бөтен барлыгын «шигырь җене» биләгән, мин шагыйрьләр иҗаты белән мәш киләм, публицистика белән шөгыльләнәм, алар исә татар прозасының умыртка баганасын тәшкил итәләр. Мәгәр тиздән барыбызны якынлаштырган уртак мәүзугъларның шактый булуы ачыклана.

Рус зыялыларының «литературные посиделки», «телешевские пятницы», XX йөз башында шәрык клубындагы очрашуларны (Тукай халык әдәбияты турындагы нәзари-гамәли чыгышын шунда ясаган) хәтерләтеп тора иде безнең күрешүләр рәсми статуска дәгъва итмәсә дә. Көнлектә, редколлегия утырышында алынган киеренкелектән котылгач, хәмер һәм ашау турында онытып, дивар буена тезелгән урындыкларга ук күчеп утырып, иҗади бәхәсләргә кереп китә торганыек.

Иҗат кешесенең кәеф сихәтләре каләм җимеше матбугатта басылып чыгып, җәмәгатьчелекнең бәясенә, ничек кабул ителүенә, дөрес аңлауларына бәйле. Мин аларның әсәрләрен тәнкыйть күтәреп алган чорда, күтәренке күңелле чакларында күрдем. Сирәк булса да, шатлыклары кителгән чаклары да булгалады. Үзләре арабызда яшәгән чорда прозабызның горурлыгы саналган язучыларыбызның әсәрләре дә гел «ура»га кабул ителмәде. Һәр чорда үзгәрә торган, татарча тәгаен тәрҗемәсе табылмаган «конъюнктура» аларны да читләтеп үтмәде.

Демократия җилләре исеп, фикер ирегә чоры килгәч, Г.Ахунов иҗаты тирәсендә бәхәсләр дә булып алды. Әдәбият дөньясында бу табигый хәл. Сүз сәнгате фикер төрлелегеннән башка яши дә, үсә дә алмый. Язучылар оешмасы коридорында, төрле редакцияләрдә, үзара аралашуларда мондыйрак сораулар ишетелгәләде. «Кара алтын табучылар турында, аларның хезмәтен романтик биеклеккә күтәреп, болай ук илһамланып «Хәзинә», «Хуҗалар» кебек романнарны язу кирәк булдымы икән? «Идел кызы» романы исемен аклыймы? Аның каһарманы мондый янгыравык атамага лаекмы?»

Төрле суларны айкаган, күфер фикерләрне чайкаган дулкыннар ярларына кайтып, аек акыл өстенлек ала башлагач, мондый сорауларны бирүчеләр азайды. Гариф Ахуновның тирән уйлар, җитлеккән тойгы-кичерешләр белән иҗат ителгән әсәрләренең алга карап, замана сулышын тоеп язылган икәнлеге вакыт чигенгән саен тулырак ачыла бара. Һәр әдәби әсәрнең үз вакыты, үз сәгате була. Әйтик, бүген Мирсәет Ардуанов турында да, нефть чыгаручылар хакында да Ахунов әсәрләрендәгечә язып булмый. Хәзергәчә яшәсә әлеге хәлләр, вакыйгалар, батырлыклар турында Гариф абый да башкачарак бәян итәр иде. Ләкин сәнгатьчә югарылыкта иҗат ителгән әсәр, үзәккә алынган

вакыйгаларга караш, мөнәсәбәт, кыйбла үзгәрү белән үзенең кыйммәтен югалтмый. Һәр чор әдәби әсәрне үз сәнгатьчә әзерлегеннән, иҗтимагый ихтыяҗыннан, сәяси тоемыннан чыгып бәяләргә тиеш. Әдәбиятның үзенчәлеге дә шуннан гыйбарәт. Татарстан нефте гөрләп аккан чорда олы каһарманнар, фидакарь шәхесләр туа; тетрәнүләр, шатлыклар, фаҗигалар, бәхетләр — һәммәсе аяк астында. Күпмедер вакыт узганнан соң, ул чорда яшәгән кешеләрнең батырлыгы урынсыз, үзләрен аямыйча эшкә бирелүләре елмаю уятыр, булсын дип үрсәләнүләре көлке тудырыр. Ләкин укучы үзен шул чорга куя белергә тиеш. Әйтик, Г.Ибраһимов белән Г.Исхакыйның гасыр башында язылган әсәрләрендә хәзерге яшәешебез белән чагыштырганда сәерлекләр азмыни? Зыя хәзрәтнең мунчада скрипка уйнаулары, ирнең өч хатын берлә интегүләре сәер, гаҗәеп түгелмени? Мәсьәләгә икенче яктан килик. Бер заман кара алтын катламнары суырылып бетәр, табигатьнең кояш җылысы, ай нуры, битум кебек байлыкларын эшкә җиккән адәм балалары Татарстан нефте, шул чорда яшәгән ихласлы һәм дуамал кешеләр турында мәгълүматны шул китаплардан гына алыр. Татарстан нефте, башка мөстәкыйль илләрдәге кебек, төп халыкка әллә ни бәхет алып килмәде, тирә-юньне пычратты, табигатьне начар якка үзгәртте дип әйтүчеләр табылыр. Бу сүзләрдә хаклык барын таныган хәлдә, шуны искәртәсе килә: юллар төзелде, яна калалар күтәрелде һәм кемнәрдер (шул эш белән шөгыльләнүчеләр) нефть акчаларының рәхәтен бик яхшы татыды, нишлисең, Ходай Тәгалә адәм балаларын тигез яратмаган шул. Ә «Хәзинә», «Хуҗалар» һәм «Идел кызы» романнары әдәбият тарихында калачак әсәрләр. Соңгы романның төп каһарманнарыннан берсе шактый үзенчәлекле, кабатланмас шәхес булып чыкты. Сүз Габбас мулла хакында бара.


*Г.Ахунов, Т. Галиуллин. 1990.*

Ясалма күннән эшләнгән кара кепкасын бастырып кигән Гариф абыйның җыйнак гәүдәсе офыкта күренүгә, Язучылар йорты тирәсендәге берсе, сүзне башкалар авызыннан тартып алып, хәбәр бирә:

— Җәмәгать, шауламагыз, Габбас мулла килә.

Шул кушамат Ахуновка чәер кебек ябышты. Чөнки Габбас мулла «Идел кызы»ның бер герое гына булмыйча, Гариф Ахунов прозасының ачышларыннан берсе иде. Язучы еш кына әдәбият тарихына бер әсәре, бер образы белән кереп кала. Гариф абый каләменнән төшкән башка характерларны да кимсетмәстән, Габбас мулла образының үзенчәлекле, кабатланмас кеше булуын искәртәсе килә. Ул үз сыйныфы кысаларына, кабул ителгән, күнегелгән күзаллауларга, кагыйдәләргә сыешып бетмәгән хәзрәт булып чыкты. Татар әдәбиятында бигрәк тә динсез совет чорында руханиларны артта калган, томана, үз мәнфәгатьләреннән башканы белмәгән, еш кына женси азгын комик затлар, шымчылар итеп сурәтләү модага кергән иде. Без шул гадәткә, дөресрәге гадәтсезлеккә, күнеккән идек инде. Дин әһеле милләтне артка сөйрәүче, мәдәниятне санга сукмаучы, ач күзле булырга тиеш. Аның бар кайгысы корсак тутыру. Гариф абый каләме тудырган Габбас мулла бөтенләй башка калыпта сугылган. Ул дин хезмәтчеләренә мөнәсәбәтне үзгәртеп, офыгыбызны киңәйтеп җибәрде.

Габбас хәзрәт дөньяга карашы, үзен тотуы, хакимият даирәләренә мөнәсәбәте белән әзер кысаларга сыймый, еш кына үз сыйныфында кабул ителгән кагыйдә-тәртипләрне боза, чыгымчы ат кебек, тәртәне ватып-җимереп чыга. Ана җәмгыятьнең катгый кануннары тар: яна хакимият шартларына җайлаша алмыйча бәргәләнә, өзгәләнә. Ул баш иеп, мескен кеше булып, һәрнәрсә белән килешеп яшәргә теләми, анын гыйсъян йөрәге, тынгысыз җаны ирек, мөстәкыйльлек таләп итә. Әлбәттә инде, кешене почмакка куып керткән, тулы буйсынуны таләп иткән совет җәмгыяте, шул исәптән якын кешеләре андый бунтарь, үзсүзле, үзфикерле кешене кабул итмиләр, аны рәнҗетәләр, җәберлиләр. Җәмгыять белән башимәс, гыйсъян шәхес арасындагы конфликтнын кем файдасына хәл ителәчәге мәгълүм иде. Шәхес ватыла, сытыла, имгәтелә, юкка чыгарыла. Башка мөхиттән булса да, совет җәмгыяте өчен җайсыз кешене Б.Пастернак доктор Живаго образында тудырды, шул әсәре өчен, акчасын алып, рәхәтен күрмәсә дә, әдәбият өлкәсендәге Нобель исемендәге халыкара бүләккә лаек булды.

Габбас мулла образына Г.Ахунов җир йөзендәге тәртип, шәхес иреге, уйлы кеше белән өстән көчләп тагылган кануннар, кыскасы, җәмгыять белән аның бер әгъзасы арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр турындагы фәлсәфәсен салган дигән тойгы-хис кала. Шигърияткә гашыйк, үзе дә иҗатка хирыс Живаго образында тәнкыйтьчеләр Борис Пастернакнын үзе белән уртак чалымнар тапсалар, ни өчен Габбас мулла образына Гариф абый күнеле тирәнлегендә йөрткән кайбер «көфер» фикерләрен салмаска тиеш әле. Бәлки, Гариф ага үзе дә Габбас мулла кыйбласында торып, аның белән килешеп, хәтта үзенең җәмгыятькә мөнәсәбәтен, сәясәтне бәяләвен каһарманына йөкләгәндер, үз уй-хисләрен анын авызына, язмышына салгандыр. Әдәбият дөньясы андый хәлләрне күпләп белә.

«Ерак сәфәр»ләрдән кайтып, гаилә корып, дөнья барышына үзгәрәк бәяләү сәләте ачылган А.Гыйләҗев социалистик реализм методы кысаларына сыймаган (икенче яктан яна методны «шыпырт» кына таркату эшенә Ә.Еники керешә — «Саз чәчәге», 1955; «Рәшә», 1962), дөресрәге, тәнкыйди реализмны яңа эчтәлек, мәгънә, сурәтләү алымнары белән баеткан «Өч аршын җир» (1962) повестен иҗат итә.

А.Гыйләҗевне колхозлашу елларын караңгы төсләрдә, димәк ки, совет чынбарлыгын бозып, берьяклы сурәтләүдә, адәм баласы фани дөньяда нинди генә байлыкка, дәрәҗәгә ия булмасын, аңа, ахыр чиктә, өч аршын җир җитә дигән фикердә үлем фәлсәфәсен, фатальлекне алга сөрүдә гаеплиләр (К.Фасеев).

Тәнкыйтьнең ачысын-төчесен шактый татып, үзен дөрес аңламаулары өчен гарьләнгән А.Гыйләҗев кабихларның күзенә чалынмау хәерлерәк булыр, дип, арткы рәтнең почмагында посыбрак утыруны мәгъкульрәк күрә, үз сәгате сукканны көтебрәк яши, яңа әсәрләр иҗат итә, балалар үстерә.

Борынгылар дөнья куласа, бер әйләнә бер баса, дип, юкка гына әйтмәгәннәрдер. Үткән гасырның соңгы чирегендә демократия җилләре исеп, мәңгелек саналган кыйммәтләр бәяләрен югалтып, дөньяга, шул исәптән әдәбият үсешенә үзгәрәк күзлектән карау вакыты суга. Совет чорын, җитәкчеләрен мактауга багышланган, йөзек кашы кебек кадерләп йөртелгән әсәрләр әйләнеп торган көпчәктән төшеп калган тиен хәлендә калалар. Каһәрләнгән, типкәләп йөртелгән иҗат җимешләре, киресенчә, яңа, күп очракта дөресрәк бәяләрен алалар. Аерым алганда, кеше мәңгелеккә кереп ятырга тиешле өч аршын җирне олылаган дип берьяклы бәяләнә килгән «Өч аршын җир» XX гасыр татар прозасының казанышы, әдәбиятның яңа үсеш юлларын барлаган энҗесе дип табылды. Үз хакыйкатенә инанган, дөреслекнең ахыр җиңәсенә ышанган А.Гыйләҗев соңарган ләббәйкәләргә,

мактауларга исе китмәгәндәй тотса да, алдагы рәткәрәк күчеп утырды, озак еллар дәвамында Язучылар берлегенә кабул итү комиссиясенең рәисе вазифасын башкарды.

«Өч баһадир» минем күнелемдә бер мизгелгә дә онытылмас затлар, иҗат олимпының түренә күтәрелгән каләм осталары, тормыш ияләре булып яшәүләрен дәвам итәләр. Дөнья барышының даими алышынып, үзгәреп торган матавыкларына, сөенечне куа килгән көенечләренә баш бирмичә, үз шәхси тормышларын, иҗатларын татар халкы язмышы белән үреп бирү сәләтенә ия шәхесләр, барына мәэмүн-канәгать булып, ясалма мөнәсәбәтне араларына кертмичә яшәү үрнәге калдырып киттеләр.

Өчесе дә бары бер тәнкыйтьчене генә танып, аны гадел һәм әдәби әсәрнең эчтәлеген сөйләүгә караганда, эчке янгырашын, теленең матурлыгын бәяли белә, дип санадылар. Ул шул чорның бердәнбер (ул заманда нигездә рус телендә язган Р.Мостафинны санамаганда) профессиональ тәнкыйтьчесе, югары зәвыклы, мәкаләләрен әдәби әсәр дәрәҗәсенә күтәрә алган Фарваз Миңнуллин иде.

Мактау сүзен азау тешен суырып, авызын кыйшайтып, дегетен тамызып кына чыгарса да, аны хөрмәт итәләр, фикеренә колак салалар, табигать баласы, ихласи җан Фарвазга ни әйтсә дә, ничек бәяләсә дә килешә, «бу әсәрең йомшак, каһарманыңның үзенә хас билгесе табылмаган», дип ычкындырганда да, аңа үпкә белдереп, табын яныннан торып китүче булмады. Фикерен үзләренә өздереп әйтсә дә, вак-төякне матбугатка чыгармады.

Мәһдиевнең колхоз тормышына багышланган «Мәңгелек яз» романының әле генә машинкадан чыккан вариантын Фарваз үзе дә җентекләп укыды, бәяләмә өчен (Татарстан китап нәшриятында эшли иде) мина да бирде. Якын дустыбыз булса да, Мөхәммәткә романның буш сурәтләүләр, диалоглар исәбенә озынгарак китүен, колхоз рәисен артык бизәп күрсәтүен, юк конфликтны бар итеп, аны ясалма тизлек белән чишүен искәрттек, башка сюжет чатаклыкларына игътибар иттек. Ният-максатыбыз изге иде: Мәһдиев кыска җөмләдә төгәлләнгән фикер әйтә алган, дөньяны ироник бәяли белгән югары кимәлле сүз остасы итеп танылган әсәрләре үрендә калырга тиеш. Фарвазның телдән әйткән фикерен тынлап, минем язмамны (ул чорда нәшрият бәяләмәләр өчен түли иде) карап чыккач, авторыбыз аркасын туры тотып, озынча тар бүлмәнең ишеге белән түре арасында йөреп алгач, горурлыгын җинеп (без кем дә ул кемсә), тәнкыйтьне өлешчә кабул итеп, чынында әсәрен шактый кыскартып, үзгәртеп бастырды. Колхоз рәисләренә мөкиббән китеп, аларны җирнең кендеге итеп сурәтләгән кайбер прозаикларыбыз әсәрләре белән чагыштырганда «шедевр» булса да, минемчә, «Мәңгелек яз» Мәһдиев мирасының иң йомшак әсәре.

Язучылык шөһрәтенең югары үренә күтәрелә килгән Мәһдиев безнең белән килешкәндәй булса да, матбугатта романын яклап, үзенең дөреслеген исбатлап чыгарга булды. «Актаныш районы, «Чишмә» колхозы рәисе Ясәви агай «сөйләгәннәрнең йөздән берен генә файдаланып» мин «Мәңгелек яз» дигән роман яздым. Нигәдер, әдәбиятчылар (ул Ф.Миңнуллин белән Т.Галиуллинны күздә тота дип уйлыйм. Ул тәрбияле кеше, ачыктан-ачык әйтми. — Т.Г.) минем бу әсәремне кабул итмәделәр. Кайберәүләр, «Мәһдиев колхоз тормышын белми, төп героеның гаилә, шәхси дөньясында гына казына» дип язып та чыктылар. (Г.Ахунов, мәсәлән, мәшһүр колхоз рәисе Фәйзи Галиев фикерен китереп, «Казан утлары»нда шулай язды)».

Язучының иҗат җимеше үзенә баласы кебек якын була. М.Мәһдиев тә әсәрен аклау юлын сайлый. «Болар хаклы, әйе, мин бүгенге агротехниканы, ветеринария, селекцияне, механизацияне белмим, комбайннарның маркасын аермыйм. Ләкин бит врачлар турында роман язучылар да

медицинаны белмиләр. *Әдәбият бит — кеше турындагы фән*» (курсив аныкы, — Т.Г.).

Автор бу очракта аңлы рәвештә укучыны читкә алып китә. Берәү дә анардан югарыда санаган фәннәрне белүне таләп итми. Сүз конфликтның ясалма булуы, социалистик реализм схемасы буенча бик тиз хәл ителүе, колхоз тормышын, бигрәк тә рәисен бизәп сурәтләү һәм акланмаган озынлыклар турында бара. Ниһаять, алдынгы кеше турында заказ белән язылган берәр әсәрнең уңышлы чыкканын хәтерләмим. Гомерләре прототип гомереннән озын булмый. «Мәңгелек яз» әсәре генә гомуми чыгармадан искәрмә була алмый.

Мәһдиевнең «классик сюжет» кора белмәвенә, дөресрәге, кирәк санамавына күпләр игътибар итә. Ф.Яруллин истәлекләренә болай дип теркәп куйган (1984, 7 июль): «Казан утлары»ның 6 санын укып чыктым. М.Мәһдиевнең «Мәңгелек яз» романы ике санда килде. Искитәрлек түгел. Теле шәп. Ләкин әсәрләрен бер сюжетка кора белми. Ахырыннан укысаң да барыбер. Сюжетсыз, конфликтсыз әсәр — әсәр түгел инде ул. Автор, әйтерсең, укучы алдында бер зур агачны тотып юна башлый. Ахырга таба ул агачтан йомычкадан башка берни дә калмый. Әсәр башындагы геройларны онытып, башка персонажларга күчә. Теленең җорлыгы, халыкчанлыгы укучыны тотып тора. Бәлки, сюжетсыз әсәрләр дә кирәктер. Халык укый бит... Бу жанрны төрләндерүнең бер ысулыдыр, бәлки. *(«Казан утлары». 2011. № 9. 169 б.)* Мәһдиевне «сюжетсызлыкта» гаепләп, тәҗрибәле язучы соңгы җөмләсе белән «Мәңгелек яз» авторын да, гомумән, соңгы елларда вакыйга җебенә ябышып ятудан бигрәк, кешенең психологик халәтен, рухи эзләнүләрен сурәтләүгә, мохит белән катлаулы бәйләнешләренә, аң төпкелендә яткан боргаләнү-сызлануларга өстенлек биргән прозада барган «төрләндерүгә» омтылышны аклый да куя. Фәнни яктан бәяләгәндә, «Торналар төшкән җирдә», «Бәхилләшү» кебек иҗат җимешләре белән чагыштырганда «Мәңгелек яз» Мәһдиевнең «сюжетлы», үзәк каһарманлы романы. Классик кануннарга җавап биргән әсәрләрне «таркаулыкта» гаепләү очраклары да бар бит әле. Мәктәп дәреслекләренә кергән язучыларны пәйгамбәр дәрәҗәсенә күтәреп йөри, әсәрләренә тел-теш тидерүне, тәнкыйтьне күз алдына да китерә алмый, булса аны изге кое суын пычраткандай кабул итә идек китап сүзенә ышанып яшәгән чорда. «Хождение по мукам», «Пётр I» кебек төгәл эпик вакыйгалы, анык сюжетлы романнар авторы Алексей Толстой бер мәкаләсендә «Анна Каренина» романының төзелешенә каты бәрелә. Янәсе, Л.Толстой әсәренең бүлекчәләрен, карта бутаган шикелле, урыннарын алыштырып укысаң да, берни югалтмыйсың, мәгънәсе дә, янгырашы да шул ук кала. Әдәби канунарга тәгаен җавап бирү яссылыгыннан гына килеп бәяләгәндә А.Толстой, әлбәттә, хаклы.

Шул ук вакытта Лев Толстойның бөеклеге әсәренен тормышның үзе шикелле каршылыклы катлаулылыгында, сикәлтәле итеп сурәтли, төп игътибарын җан диалектикасын ачу алымнарын төрләндерүгә юнәлтүендә түгелме соң? Мәһдиевнең, чәчәктән чәчәккә сикергән бал корты кебек, бер вакыйганы бәян итүне төгәлләмичә икенчесенә күчүе, бер каһарманының «эшен бетермичә» икенчесе белән мавыгып китүе аның ачышы, заман таләбе түгелме? Дөньяны бу рәвешле сурәтләүнең дә яшәргә тиешлеген, иҗат ирege дигән төшенчәгә җавап бирүен Мәһдиев иҗатына, өслүбенә мөкиббән китеп яшәгән шактый укымышлы укучылар фикере дә раслый. Байтак кешедән (мәсәлән, «Корстон» ял итү, күңел ачу үзәге генераль директоры Рәис Мөбарәкҗанов, элеккеге мәгариф министры урынбасары Гаднан Садреев һ.б.) мондыйрак сүзне ишеткәнем бар: эч пошканда, үзеңне кая куярга белмичә бәргәләнгәндә, Мәһдиев томын кулына алып, теләсә кайсы битен күз йомып ачып, берничә җөмләсен укуга, бик эссе көнне

салкын су белән коенгандай, иркенәеп, сихәтләнеп, «яңа дөньяда» яшәп алгандай уңайланып китәсең.

Димәк, бу мизгелдә адәм баласына сюжетың да, төгәлләнгән вакыйгаң да кирәк түгел. Аны Мәһдиевнең сүзе, җөмләсе, шулар аша күңелен әсир иткән моңы, сагышы, фәлсәфәсе, табигатькә мәҗүсиләрчә табынуы, тормышны бизәмичә, иннек-кершән якмыйча сурәтләве, нечкә күзәтүе — «йомычкасы», милләтнең бәхетле киләчәгенә ышануы әсир итә. Бу инде югары поэзия дигән сүз. Шигырьнең шул чордагы хиссе халәтенә туры килгәнен генә табып укыйсың ич. Кайсы вакыт сайлап, эзләнеп тормыйча...

Мәһдиев феноменын ачу, әдәбият һәм кешелек кануннары буенча шәрехләү киләчәк эше дип саныйм. Аның иҗатына иң гадел бәяне вакыт галиҗәнапләре бирер. Кеше — цивилизация тоткыны — табигатьтән, табигый яшәештән ераклашкан саен, күңел тыпырчынуын бастыру «даруын» Мәһдиев һәм башка элгәрләребезнең әсәрләреннән эзләр дип уйлыйм. Мондый фаразга нигез җитәрлек. Читкәрәк китүем өчен укучыдан гафу үтенеп, янәдән Ф.Миңнуллинга әйләнеп кайтыйк.

Якташы Ф.Миңнуллинны әсәрләренә тәнкыйть сүзе белән кагылса да, ни кыйланса да кыйлансын, тик еламасын гына дигәндәй, Мәһдиев гафу итә. Фарваз үзенә булган җылы мөнәсәбәттән, биләгән урыннарыннан кирәгеннән арттырыбрак та файдалана иде бугай вакыты белән.

Гадәттә тәнкыйтьче төрттереп, җанга тиярлек сүз әйтүгә әзерләнгәнен авыз, бит торышын үзгәртүдән, ягъни, хәрбиләрчә әйтсәк, «арт» әзерлектән башлый. Әүвәл салпы якка салам кыстырган була да, шунда ук ачысын тамызып куя.

— Мәһди, син бөек язучы, хәзерге татар прозасының мактанычы... Тик син кеше буларак «незрелый».

Мөхәммәт беренче җөмләне ишетүгә «кабынган» елмаюын сүндерә алмыйча, авызын ерып утыра бирә. Шулай да бу гаепләмәне җавапсыз калдырсаң, тәнкыйтьче аякларын салындырып муенына менеп атланырга мөмкин. Дус дигәч тә...

— Дәлилләрең кая. Бу бит теләсә кемгә әйтелерлек коры гаепләү.

Фарваз юан бармагын бөкләп, «дәлилен» китерә.

— Мәсәлән, син саранлык чүтеннән Әмирхан Еникидән генә калышасын. Хәтта Туфан Миңнуллин да синнән соң килә (әле генә Язучылар берлеге рәисе итеп сайланган драматургка үпкәләп йөргән вакыты иде).

Мөхәммәтнең теле усал, күзәтүчәнлеге хәтәр, бәясе куырып алырлык булса да, Фарвазга нисбәтән мәрхәмәтле, риясыз, гафу итүчән дидек.

Яшьлегендә, бигрәк тә аспирант елларында акчага кытлык кичергән Мәһдиев саранлык, юмартлык турында сөйләшүләрне авыр, үртәлеп кабул итә, ә бу мәүзугъ якташының яраткан «хоббие», форсат чыккан саен, язучыларны шул яссылыктан төркемнәргә бүлә башлый. Мөхәммәтнең кысмырлыкта гаепләгәнне өнәмәгәнен дә яхшы белә. Авырткан тешне кармалап торган тел кебек, Фарваз гел шул якка каера. Мөхәммәт бу шаяртуны чынга ала. Юморист үзенә кагылмаган көлкене генә аңлый шул.

— Фарваз ахири, син хаклы түгел. Янымда акчам булганда, мин дуслар өчен кызганып, саранланып тормыйм.

— Син бу сүзеңнең хаклыгын хәзер үк исбат итә аласың, — ди Фарваз, уенны дәвам итеп.

Сез инде Мәһдиев югалып, ыкы-мыкы килеп калгандыр дип уйласагыз, бик нык ялгышасыз. Юк шул, сез Мөхәммәтнең холкын «ничурта да» белмисез икән. Аркасын уклау йоткандай туры тотып, мәгърур атлап прозаигыбыз кибеткә чыгып та китте, ун-унбиш минуттан коньяк күтәреп, лимон тотып кайтып та керде. Фарваз шешәне кулына алып, селкетеп, тышындагы язуны укып, азау тешен суырып алды.

— Классик вә доцент башың белән өч йолдызлы коньяк күтәреп кайткансың. Биш, һич югында дүрт йолдызлыны аласы иден. Акчаң житмәгәндер, — дип мырлый-мырлый, миңа күз кысып, стаканга үрелде.

Мөхәммәт Мәһдиев прозасының яңачалыгын, илаһи матурлыгын, халкыбызның моң-зарын, хатын-кыз психологиясен иң белеп сурәтләгән, ямьле, тәмле, жиләкле, мамыклы тел иясе булуын ачып биргән тәнкыйтьчегалим нәкъ менә Фарваз Миннуллин булды.

«...Без Мөхәммәт Мәһдиев белән байтак еллар дуслар булып яшәдек. Танышлар уртак иде, серләр уртак иде. Миңа аның бөтен тормыш юлы, туганнары, нәсел-нәсәбе таныш», — дигән юллар («Яшьлекне сагыну» мәкаләсеннән) Фарвазның алдарак китерелгән шаяртуларын аклый да куя. Мөхәммәт тә «бурычны» өстендә калдыра торган шәхес түгел иде.

Саранлык-юмартлык «уеныннан» берничә ай үткәч, Фарваз грипп авыруы белән чирләп, хастаханәгә эләкте. Мөхәммәт белән каста янына киттек, бүлеген дә, бүлмәсен дә белмибез.

Кечкенә тәрәзәгә шакып, аннан ак халатлы, зур кара күзле кыз күренүгә Мөхәммәт телгә килде:

— Карале сеңлем, сезнең бульнистә тозлы кәбестә суы кебек аксыл чырайлы, рәсемдә ифрат матур чыга торган бер абзый ятарга тиеш. Палатасын белмибез.

— Фарваз Миннуллин абыйдыр. Ул 18 нче бүлмәдә, өченче катта. Тик анда кертмибез. Карантин.

Мәһдиев теге вакыттагы коньяк алдырып үртәүнең үчен, минем алда гына булса да, чыгарды тәки, дип уйлап куйдым.

Фарваз үзе безнең янга төште. Якташлар аркаларына суккалый-төрткәли күрештеләр, бер-берсенә теләкләрен әйтештеләр. Сүз күбрәк әдәбият, нәшриятта (ул чорда тәнкыйтьчебез аның баш редакторы иде) басыла алмыйча яткан кульязмалар турында барды. Икесе дә чын дуслыкның кадерен беләләр дип, мин читтәнрәк күзәтеп утырдым.

Фарвазның төртмәле теле Г.Ахунов белән А.Гыйләжев әсәрләрен дә чагып алгалады. Корт тешләгән шикелле, көтмәгәндә, уйламаганда. Беренчесен яшәешнең гел якты, матур якларын гына сурәтләүдә гаепләсә (бигрәк тә документаль нигезле әсәрләрен күздә тотып), А.Гыйләжевне иң мактаулы әсәрләренең берсе — «Жомга көн кич белән» повестеның каһарманы, яшьлегендә ут уйнаткан Бибинурны, карт көнендә, артык мескен, салынып төшкән, бөтен барлыгын, саулыгын биреп үстергән балалардан күктән ингәндәй мәрхәмәт көтеп ятуы, гафу итүе дөреслеккә туры килми, дип тәнкыйтьләде.

Аяз абый да үз ышанычыннан тиз генә кайта торган зат түгел иде.

— Бибинур образында мин татар хатыннарына хас олы жанлылыкны, динебез өйрәткәнчә, йомшаклыкларны, кичерә белүне, авырлыкларга тешен сындырып булса да түзә алуны, хәтта корбанчылыкны күрсәтергә теләдем. Син, парин, бу язмышка берьяклырак киләсең!

Фарвазында үжәтлек ун кешегә житәрлек. Урыныннан сикереп торып үз бәясен якларга керешә.

— Бу образың барыбер ясалма. Кешенең изгелеге жир суалчаны кебек тапталырга, сытылырга тиеш түгел. Үзебез белгән кешеләр арасыннан шундыйрак берәр мисал китерә аласыңмы?

— Бибинур жыелма образ. Гадәти бәяләрдән өстен торган, идеаллаштырылган шәхес. Грамоталы тәнкыйтьче буларак син әдәби әсәрнең тормышны нәкъ булганча сурәтләве мәжбүри түгел, язучының хыял жимеше турында да хәтерлисеңдер, дип уйлыйм.

Дөреслек өчен шуны да искәртергә кирәк: хәзерге тәнкыйтьтә әдәби әсәрләр

халкыбызны күрәшкә дәртләндереп, үз хокукларын яклый белүгә чакырып торырга тиеш, ә Бибинур язмышка буйсынып яшәүгә, мескенлеккә генә өйрәтә дигән фикерләр дә әйтелә (мәсәлән, Яр Чаллы тәнкыйтьчесе Гомәр Даутов).

Хәзер дә, сирәгрәк булса да, без Равил Фәйзуллин белән очрашып, аралашып, традицияләрне сакларга тырышып яшибез. Баш мөхәррирнең җәелеп аркасын кашырга да вакыты юк шул. Үз иҗатын, журналның тиражын кайгыртасы, пырдымсыз авторларны тынычландырасы, түрәләр белән мөнәсәбәтне билгеле бер дәрәҗәдә тотасы һәм башка бик күп хәсрәтләре бар. Шул ук реклама кәгазьләре җәелгән ялтыравык өстәл янына утырып, хәл-әхвәлләрне, гаилә тәртипләрен белешкәннән соң, «алтын чорыбызны» — Мәһдиевнең шук телен, урынлы кыстырган төрттерүен, Аяз абыйның ачы миләш кебек витаминлы сүзен, «паринын», Ахуновның «мин башкачарак уйлыйм» дип сикереп торуын искә төшерәбез. Күрәсең, үткәннәрне сагыну, элгәрләрне күтәрү — буыннарны бәйләп килүче, кешелекнең асылын билгеләүче җанлы җептер, хәтерне яңартып торучы иң камил, иң мөкатдәс хистер. С.Хәким Муса Җәлилләрне юксынып яшәве турында күп язган. Г.Бәширов та үзеннән иртәрәк киткән Х.Туфан, Ф.Хөсни, И.Гази, М.Әмир кебек аркадашларын сагынып картаюы турында истәлекләрендә бик үтемле әйтеп калдырган. Менә без дә, Габдрахман абый улы белән, бик «булдыклы» гына зарланып алабыз.

— Киңәшеп, туарылып, эчеңне бушатып утырырдай кешеләре дә азая бара. Әхлак нигезләре үзгәргән чорда йөрәк серең белән уртаклашу кебек «сантиментлар» яшәеш тәртәсенә сыймый торгандыр шул.

Ә инде саубуллашканда «сагыну хисен саклый алсак кына кешелек сыйфатларын югалтып бетермәс идек, кичерешләр сафлыгы җанның үлчәү берәмлеге булуын онытмасак иде», дип тә уфтанып куябыз, болары инде берәүгә дә кирәк булмаса да.

«Өч баһадир» һәм бер тәнкыйтьченең инде берсе дә арабызда юк. Бу олы шәхесләрнең гомер йомгакларында шунысы сөенечле: алар үзләреннән соң үлмәс, тутыкмас мирас калдырып, әдәбият күгебездә һәркайсы үз йолдызлыгын кабызып, сәламәт акыл, аек психологик халәт белән исәннәргә хәер-фатиха биреп, озын гомер теләп мәңгелек хозурына күчтеләр. Алдагы бүлекчәләрдә сүз ошбу шәхесләрнең минем күнелдә калган холык-фигыльләре, менәзләре, кешелек сыйфатлары турында барачак.

## Гариф абый

*Яшәсен!*
*егетләрнең бик түбәннән*
*күтәрелеп дан алганы.*
Р.Фәйзуллин.

Өч «баһадир»ыбызның берсе — Гариф Ахунов үткән гасырның икенче яртысында олимп тавының югары үренә күтәрелә, татар язучысы ирешә алган барлык регалийларны, депутатлыкның төрле дәрәҗәләрен ала, китаплары Казанда, Мәскәүдә, Уфада, башка телләрдә дә чыгып, уңай бәя ала торалар. Әлмәт Язучылар оешмасын дөрләтеп эшләтеп җибәргәннән соң, Татарстан Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибы (1968−1972), 1972 −1974 елларда «Казан утлары»ның баш мөхәррире, ун елдан артык (1974-1984) Язучылар идарәсенең рәисе вазифаларын башкару дисеңме, саный-атый китсәң, искитмәле... Ул обком, кабмин ишекләренең кайсы якка ачылганын тәгаен белеп яшәде, иң мәртәбәле мәҗлесләрнең тамадасы булды, Сергей Михалков, Юрий Бондарев, Федор Абрамов, Юрий Проскурин, Егор Исаев кебек «замана пәйгамбәрләре» белән аралашып, киңәшеп яшәде, кыскасы, XX гасыр ахыры,

яна йөз башы иркәсе Туфан Миннуллин кебек өф-өф итеп, уч төбендә генә йөртелде. Җинел аралашучан холкы, сүзгә җорлыгы, һәр очракка әзер мәзәге, җыры табылуы, нәкъ кирәк җирендә «мин сезнеке», дип елмая белүе, аның гомерен озайтты, яшәвен җиңеләйтте, дисәк тә зур хата булмастыр. Күренекле драматург Т.Миннуллин «Татарстан яшьләре»ндә (2001, 29 март) басылган мәкаләсенә «Ансыз күнелсез», дип ифрат төгәл исем биргән.

Олы шәхес дип һәр тарафтан җитлеккән, мәгънәле, милләтенә, нәселенә, гаиләсенә бирелгән, камил кешегә әйтәләр. Гариф Ахунов турында сүз чыкканда, аны искә алганда нәкъ менә шул билгеләмә телгә килә. Мәсәлән, мин аның кебек төрле буын, язмыш, холык кешеләре белән тиз мөгамәлә урнаштыра, уртак тел таба алган, тиз арада «үз кеше» булып китә белгән, башка язучыны хәтерләмим. Беренче шигырен, хикәясен күтәреп килгән каләм тибрәтүче, әле генә лаеклы ялга чыккан полковник, хәйләкәр авыл игенчесе, шахтадан туган ягына кайтып килүче күмер чабучы, ялганына үзе ышанган балыкчы дисеңме, Гариф абый һәммәсенең күнеленә ачкыч табар, хәлен сорашыр, шаяртып алыр, кирәк чакта юату җөмләсен кыстырып кую әмәлен табар. Җинел адымлы, терекөмеш кебек хәрәкәтчән, янгыравык тавышлы Ахуновның төрле очрак белән оешкан мәҗлесләрнең җаны булуы, сүзгә осталыгы, холкының комплекссызлыгы белән аңлатыла булса кирәк. Гариф абыйның һәр мәҗлестә кабатлый торган «көмеш билбауларын», «клише» җөмләләрен аның белән аралашып калу бәхетенә ирешкән кешеләр әле дә булса хәтерлиләр.

Мин белгән идарә рәисләре арасында иң гадие (примитив мәгънәсендә түгел), ачыклыгы, сафлыгы белән аерылып торды Гариф абый. Иң югары оешмаларда әгъза, депутат булып торганда да, кәпрәеп, һаваланып йөрмәде, «сез кем дә мин кем», дип, төрттерүне белмәде. Шул сыйфаты белән үзен хөрмәт иттерә алды.

Милли автоном республикалар арасында иң саллы, абруйлы язучылар оешмасының җитәкчесе булуы Г.Ахуновка башка төбәкләрнең күренекле сүз осталары белән якыннан аралашу мөмкинлеген бирде.

«СССР һәм РСФСР язучыларының пленумнарында, күчмә утырышларында, әдәбият көннәрендә, конференцияләрендә һәм симпозиумнарда ул үзбәк һәм якут, башкорт һәм Дагстан, Төньяк Кавказ һәм Урта Азия әдәбиятлары турында чыгышлар ясады. Монда бер нәрсәне онытырга ярамый: боларның барысы да Татарстан Язучылар союзы аппаратында зур эшләр алып барган (Г.Ахунов, — Т.Г.) кеше тарафыннан эшләнде бит», — дип яза Р.Фәйзуллин «Егет әдип» мәкаләсендә.

Җае чыккан саен, ә ул аны таба белде, Г.Ахунов үзенең Чыңгыз Айтматов, Кайсын Кулиев, Давыд Кугельтинов, Мостай Кәрим кебек СССР сәясәте тудырган бөекләр белән дуслыклары турында сөйләргә яратты. Өлкәннәрнең Мәскәү залларында берсен-берсе күкләргә чөеп, мактап, күтәреп яши белүләре турындагы бәяннары яшьләр өчен «белем күтәрү», сабак алу мәктәбе дә иде. Рәсүл Гамзатовка җылы мөнәсәбәте турында сөйләкне шул чорда ишетми калган язучы, әдип булмагандыр.

— Мин бер күрешүдә Гамзатовка «Рәсүл агай, сез ифрат халыкчан талантка ия шагыйрь, үзегезнең «Мой Дагестан» китабыгыз белән халкыгызны дөньяга таныттыгыз, сез бөек гуманист шәхес», дип, дәртләнеп мактарга керешкән идем, ул мине бүлдереп, «Гариф, дорогой, я и так знаю, что я великий, зачем ты это мне говоришь, ты об этом с трибуны скажи», дип әйтеп салмасынмы. Шып туктап калдым, малай. Бөекләр бездәй гидайларны шулай утырта беләләр.

Үзебезнең язучылар белән аралашканда килеп чыккан көлкеле, мәзәк хәлләр турында сөйләү мөмкинлеген дә ычкындырмый иде Гариф абый.

— Бер мәҗлестә өстәлгә урман чикләвеге куйдылар. Урыныбыз шагыйрь

Мәхмүт Хөсәен белән янәшә туры килде. Мин торып басып, сүземне әйткән арада теге, шайтан таягы, үзенең чикләвек кабыкларын минекеләр янына кушуы гына җитмәгән, шунда ук авызын ерып, «җәмәгать, игътибар итегез, өстәлдәге чикләвекнең яртысын Гариф ашап бетергән», дип, мине хур итмәсенме? Үзе көлә-көлә чүп өеменә төртеп күрсәтә.

Бу яланы җавапсыз калдырырга ярамаганны сиземләп, башны эшләтергә керештем. Җавап белән сузарга да ярамый.

— Җәмәгать, Мәхмүт Хөсәен чикләвекне кабыгы белән йота икән. Чирләп китеп, бәласе безгә булмасын, чикләвекне алдыннан алып куегыз!

Яшьрәк буынны шаккатырырга исәп тоткан бер «табышы» бар иде Гариф абыйның.

— Егетләр, абзагызны яшь кызлар бик ярата. Артымнан калмыйча, эзәрлекләп аптыраталар.

Сүзен чынга алыргамы, юкмы дип шикләнеп торучыларның берсе:

— Соң, алар төшемле рәислегенне, «Волга» машинанны хөрмәт итәләрдер.

Гариф абый бәйләнмәгән салам көлтәсе кебек як-якка асылынып төшкән чәчләрен «тәртипкә чакыра» да, башын арткарак чөеп, эре ак тешләрен ялтыратып көлеп туйганнан соң:

— Миннән ком коелып бара, кызлар бозда таеп егылмас өчен, миңа якынаебрак барырга тырышалар.

Күңелдә калган вакыйгаларның төрлесе була: бер ишесе авырткан теш кебек, туктаусыз борчып, бимазалап торса, кайберсе күңелне күтәреп, тыныч җәйге кичтәге ай нурыдай балкып бөтен барлыгыңа сөенеч индереп торалар. Гариф абыйга нисбәтән сөйләкләрнең күбесе көнчеләр, үзләре ярата белмәгән мескеннәр тарафыннан, аның Көнчыгыш романтик шигърияте дәрәҗәсендә хатынына, шулай ук язучы Шаһидә апага мәхәббәте, җылы мөнәсәбәте турында чыгарылганнары иде.

«Өч баһадир» да яратып өйләнгән хатыннары илә бәхетле тормыш кичерделәр. Кайгыны яшереп, «эчкә куып» булса да, бәхет күзгә, йөзгә, гәүдәгә чыга, диләр. Гомәр абый кызы Лилия мөстәкыйль холыклы булса да, Мөхәммәтенең һәр теләген алдан сизеп, үтәп яшәде, Нәкыя ханым Аяз абыйны өрмәгән җиргә дә утыртмады. Гариф абый белән Шаһидә апаларның яратышуы бөтенләй башка дәрәҗәдә, гаиләдә мин хуҗа дип борын күтәреп йөргән агай-эне башына сыймас кимәлдә иде. Гариф Ахуновның хатынына булган кешелекле, кечелекле, җырларда гына җырлана торган мәхәббәте турында легендалар йөрде, Фәрхад белән Ширин, Ләйлә белән Мәҗнүн, Джульетта белән Ромео кушыла алып, бергә картайсалар, барыбер Гариф белән Шаһидә кебек тату итеп яши алмаслар иде, дип җибәрүчеләре дә булды. Ярату хисе генә җиңә алмаганда, акылны ярдәмгә чакырып, берберсен шәхес буларак хөрмәт итеп, юл куеша белгәннәрдер, дип уйлыйм, студент елларында ук табышкан, сөешкән, аңлашкан ике яшь йөрәк.

Гомерләре буена бер түбә астында яшәсәләр дә, язучы Г.Ахунов басылып чыккан һәр китабының беренче нөсхәсен, багышлама белән хатынына бүләк итә торган булган. Матбугатта дөнья күргән китабын, гадәттә, үзенә кадерле була. Аны күтәреп кайтып, гаилә әгъзаларына күрсәтеп, бер-ике көн мендәр астына салып йоклаганнан соң, китап киштәсенә куясың. Кем тели, шуннан алып, мишәрең әйтмешли, теләгәнчә бага, укый ала. Китабыңны хатынына язып бирүне, әсәренне үзеңә бүләк итү кебегрәк бер фал, дип саный идек. Төптәнрәк уйлап карасаң, Гариф абыйның бу адымында, ул үзе дә эчтәлегенә бәя биреп житкермәгән, жете әхлакый мәгънә ята. Ул — гади ялагайлану гына түгел, якын кешеңә мөнәсәбәтенне «рәсми» белдерү, язма сүз аша аны кеше итеп тану. Уйлабрак карасаң, мондый юлламаларның

тирәндәрәк яткан икенче символик эчтәлеге дә шәйләнә. Бу очракта Гариф абый фани дөньяны иртәрәк ташлап киткәч, Шаһидә ханым (хәзер ул да вафат) кышкы озын кичләрдә, жил сызгыруын, бураннар улавын тынлап, өстәл лампасы яктысында юлламаларны кат-кат укып, кадерле кешесе белән уздырган тормышларын, ләззәтле мизгелләрен янартып, рухи таяныч, күнел тынычлыгы тапкандыр, итагатьле игътибарлы иренең сулышын тоеп, ялгызлык хисләрен жинүгә өстәмә көч алгандыр. Күпне күргән, күпне татыган Гариф абый автографларга мәгънә сала белә иде.

Бездә шулай бит: гаиләндә тәртип булмаса да телгә керәсен, артык дус, тату яшәсән, «хатын табаны астында көн күрә», дигән бәягә лаек буласың. Көнчеләр, бигрәк тә үзләре матур гаилә кора алмаганнары, Ахуновлар яшәешендә урнашкан мөнәсәбәтне ироник яссылыкка күчереп, тел чарладылар.

Язу өстәле артында аркасын катырып утырудан арып, «иреккә чыккан» каләм әһелләренең булмаган жирдә кызык табып, үзләрен юатып, тормышларын бизәп яшәргә тырышулары дәүләт сере түгел. Әлбәттә, күбесенең күнелендә усал ният, явызлык юк. Яратып шаярту... Ә шулай да... Юл бирешеп, күнел көрлегенә ирешеп яшәү начармы? Язучылар берлегенең коридорында туган мәзәкләр арасында кызыклары, ышандырырлыклары булган шикелле, чүптән чүмәлә ясаганнары да житәрлек иде. Сонгыларынын нигезендә Гариф-Шаһидә мөнәсәбәтенең югары эчтәлеген күрмичә, анларга көч куймыйча, олы мәхәббәтне көнитеш яссылыгына күчереп калдырырга тырышу ятты. Материал эзләп, ерак кыйтгаларга сәфәр чыгасы юк, төгәлләнгән сюжет кул астында, Г.Ахунов идарә рәисе, Шаһидә апа берлекнең китапханәсе мөдире, ягъни гашыйклар өйдә дә бергә, эштә дә янәшә. Көннәрдән бер көнне Гариф абый гадилеге белән, уйлабрак житкермичә, «бу мәсьәлә турында китапханәгә кереп, Шаһидә апагыз белән кинәшеп алыгыз әле», дип, ычкындырганын сизми дә кала. Ошбу җөмләсен ул кайчан, ни өчен әйткән, анысы беркемне борчымый. Юмористларнын хыял дәрьясына төшкән орлык шытып чыгып, мул «уныш» бирә.

Язучылар берлегенең коридорын «жылытып» торган төркемнән берсе зарланып ала:

— Егетләр, фатир ягым бик хөрти әле. Түбәсеннән су саркып торган почмак өчен 50 сум түләп торам. Гариф Ахуновка ярдәм сорап керергә жыенам.

Икенче акыллысы кинәше белән ашыга:

— Ә син, кортлы баш, әүвәл китапханәгә кереп, Шаһидә апа белән кинәш. Төкерегенне сөртеп булса да, күзләреннән яшь чыгар, яшәр хутыбыз калмады, балабыз чирдән чыкмый, дип тә өстә.

— Нишләп әле мин китапханәгә Шаһидә ханым янына керим, ди. Мина китап түгел, ә квартира кирәк, — дигән була тегесе берни анламыйча.

Тәмәке төпчеген сүндереп өлгергән өченчесе сүзгә кушыла.

— Юкка син мишәр дустынны тынламыйсың. Ахун (үзе юкта аны шулай гына «зурладылар») сине барыбер анын янына кертеп жибәрәчәк. «Акыллым, Шаһидә апаң янына кереп, барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бир. Ул нәрсә әйтер! Соңыннан, өйдә, минем искә төшерер», диячәге ике икен дүрт, Төркиядә төрекләр яши дигән кебек ачык.

— Минем дә Ахунга керәсе бар әле. Икенче малай туды. Ярдәм сорарга исәп. Күптәннән гонорар алган юк.

Иншалла, татар сүз сәнгате бер чорда да талантларга да, шаяннарга да кытлык кичермәде. Гариф-Шаһидә мәсьәләсе ачыкланып, ноктолы өтер куелгач, арадан берсе яна тәкъдим белән чыга. Бер үз кучәренә утырса, хыял дәрьясын туктатам димә... Арадан икенчесе рәсми сүз алмыйча гына, фикерен бушабрак калган башларга «төшерә».

— Җәмәгать, бездә «халык язучысы», «халык шагыйре» дигән исемнәр бар. Арада лаеклысы янында, титулны тәк кенә эләктергән әрсезләре дә җитәрлек. Барыбыз да яхшы белгән, йомышыбыз төшкәләп торган, берәүгә дә отказ бирмәгән рәисебезнең йөртүчесе Тәлгатне яхшы беләсез. Буе-сыны гренадерский, хатыны — шагыйрә, муенны катырып тота белә. Әгәренки, «татар халык шоферы» дигән югары исем кертелсә, ул аңа, һичшиксез, лаек булыр иде. Андый бүләк юк шул.

Тәлгатнең машинаны яхшы йөртүен, тәртиптә тотуын белгән шаяннарга бу фикер ошады. Совет чоры колхозы җыелышларындагы шикелле шаулаша ук башладылар.

— Андый исем булмаса ни? Нигә аны үзебезгә кертмәскә? Кем безне тыя ала?

Мәсьәләне чишүне озакка сузмыйча, Тәлгаткә «татар халык шоферы» дигән исем бирү турында бертавыштан карар чыгаралар һәм «әдәби киңәшчегә» бу хакта Тәлгаткә житкерүне йөклиләр. Тегe бу уенны житди кабул итә, «язучылар фикере минем өчен закун, рәхмәт сезгә», дип икенче көнне эшкә яңа статуста чыга. Дөрес, кайберәүләргә бу ашыгыч «юмартлыклары» өчен үкенергә туры килә. Шул көннән башлап, Язучылар берлеге рәисенең йөртүчесен алмаштырып куйдылар, диярсең. Ул житдиләнә, «тегендә барып кайтыйк, моннан әйләнеп килик», кебек үтенечләрне кабул итми, йә «ишетми», йә борылып ук китә.

«Татар халык шофёры» дигән «бөек» исемне Тәлгаткә кушуда Мәһдиевнең катнашы булганмы, юкмы, гөнаһысын өстемә ала алмыйм. Мәгәр бу уенның бер «нәтиҗәсе» турында «Без — кырык беренче ел балалары» авторының үз авызыннан ишеткәнне кәгазьгә төшерәм.

Язучылар берлегенең китапханәсендә Шаһидә апаның туган көнен билгеләп үтәләр. Хатынын ихластан яраткан, хөрмәт иткән Гарифҗан өстәлне әгъләдән әзерләтә. Мәскәү өстәлләрен күп күргән Гариф абый ризыкларның рәтен нәзберек М.Галиевтән  ким белми. Ф.Миңнуллин бәясендә «иң юмарт язучы» исемен алган Г.Ахунов затлы ризыкларга, эчемлекләргә акчаны кызганмый. Мәҗлестә кеше аз була, өстәлдә нигъмәтләр өелеп кала. Барчасын җыештырып, алып килгән чанталарына тутырып, таралышырга җыеналар, йортта «Волга» машинасының газ биреп, «татар халык шоферы»ның эчке утны кабызып, җыр тынлап утырганын белгән Мәһдиев тә өйләренә бергә, машинада кайтырга хыяллана. Ни күрсен: идарә хуҗасы ике кулына авыр сумкаларын тотып, машинасы ягына бармый, ә чыгу капкасына таба юнәлә.

— Гариф, кая китүең, машинаң теге якта, сине көтеп тора, — ди хыялый Мәһдиев.

— Ул бүген «машинаны карыйсы бар» дип ял алды. Шуңа ялынып йөрисем генә җитмәгән. Горький урамына чыгып, троллейбуска утырам да, рәхәтләнеп кайтам. Безнең йорт янында диярлек туктый. Җаным тыныч. Шаһидә соңрак кайтам, бүлмәне җыештырам, дип калды әле.

Аптыраган Мәһдиев машина ягына моңлы карашын ташлый да, «демократ» рәиснең сумкаларын күтәреп кайтасы килмәүдән дип уйлыйм, «онытып җибәрә язганмын, бүген университетта «Әллүки» берләшмәсе утырышы буласы, мин шунда йөгердем», дип башка якка юл ала.

Әлбәттә, Мәһдиев, кызык эзләп, сызгырттырмаган булса, Г.Ахунов шәхси шоферын гына тәртипкә чакыра алыр иде. Идарә хезмәткәрләреннән дә, тиешле сәгатьтә утыруларын таләп итеп интектерми. Иҗат кешесе андый ваклыклардан өстен торырга, һәркем үз вазифасын әйтмичә дә, җиренә җиткереп үтәргә тиеш, дип санады бугай совет чоры әхлагы баласы.

Гариф Ахуновның хәтере мәче тырнагы кебек үткен, кечкенә, әһәмиятсез

күренгән вакыйгаларны да күнелендә калдыра, теленә күчерә белә дигән идек. Мина мөнәсәбәтле бер хәлне ул еллар буена искә төшереп, көлдереп сөйләп йөрде. Тормышымда башка әһәмиятле вакыйгалар күп булу сәбәпле, шәхсән үзем анысын хәтер казаныннан күптәннән сызып ташлаган идем. Үткән гасырның җитмешенче еллары азагында,үзебездә докторлык диссертациясен яклау советы булмау сәбәпле, татар теле, әдәбияты галимнәре әзер эшләрен, күчтәнәчләр арасына кыстырып, әле кайчан гына Акмуллаларыбыз уку-язуга, әлпи-тисигә өйрәтеп йөргән Урта Азия, Кавказ халыкларына баш иеп, тез чүгеп барырга мәҗбүр идек. Шул шөгыль белән мина да кат-кат Алматыга очарга туры килде. Казакъ, үзбәк, әзербайҗан кардәшләр татар фәненең күп алга китүен сүздә таныган тәкъдирдә дә, хезмәтне яклауга чыгару вакыты якынлашкач, астыртын гына аяк чалу, сузу әмәлен таба белделәр. Шуңа күрә миңа Алматыга җәмгысе алты тапкыр сәфәр кылырга насыйп булды. Үз исәбемә дә, төрле оешмалардан (аерым алганда, үзем эшләгән Алабуга педагогия институтыннан) командировка алгалап та бардым. Шул чорда идарә әгъзасы булуымны да истә тотып, Язучылар берлеге рәисе Г.Ахуновка юлны түләүне сорап мөрәҗәгать иттем. Алга таба вакыйганың ни рәвешле үсүен ул үзе бәян итеп бирде.

— Язгы ямьле көннәрнең берсендә син Алматыга командировкага җибәрүне сорап кердең. Сәбәбен аңлатып бирдең. Бераз уйлап торгач, мин болай дидем: «Без ижтимагый оешма, юл ерак, шактый акча кирәк, мәсьәләне үзем генә хәл итә алмыйм, берсекөнгә идарә утырышы була, шунда карарбыз, иптәшләр каршы килмәсәләр, ышанам, синең үтенеч кире кагылмас, дидем». Син капылт кына урыныннан күтәрелеп, бүлмәдән чыгачыгышлый: «Гариф абый, борчуым өчен гафу ит, идарәгә чыгарырлык булгач, командировкагыз кирәкмәс», дип кырт кистең. Мин дә ялгыш җибәргәнемне аңлап, корт чаккандай сикереп торып, «шулай тынычрак булыр, дип кенә әйтүем иде, хәзер үк бухгалтериягә шалтыратам, командировочныеңны кереп ал, син дә Фарваздан күреп, усаллана башладың, дип өстәмәкче идем дә, тыелып калдым». Гариф абый очрашкан саен шул вакыйганы искә алып, үзенең кайтып төшә алуына сөенеп, детальләрне арттыра, тулыландыра барудан тәм, эчке ләззәт табып сөйләвен белде.

1999 елның сентябрь урталарында мине көтмәгәндә авыр чир аяктан екты. Сәламәтлекнең артык кадерен белмичә, көне-төне эшләп, дөнья куып йөрүнең очы күренде, бер елга якын әдәби хәрәкәттән, яраткан укыту эшемнән, дусларымнан аерылып тордым.

Инде аякка басып, язучылар йортында күптән күрешмәгән каләмдәшләрем белән беррәттән Гариф абыйны да очраттым.

— Тәлгат, нихәлләр, — дип кочаклап алды, авызын киң итеп җәеп. — Чирләп алдыңмы? Борчылма, чират җиткәндер, берәүне дә калдырмый, барыбызны да вакыт-вакыт тикшереп тора, Ходай Тәгаләбез.

— Булды шул, Гариф абый, — дим гаепле кеше сыман.

— Үз төсеңә кайтып барасың. Элеккеге бюрократ Галиуллинны хәтерләтәсең инде. Тик аякта калган бугай. Бетәр анысы.

— Анысын үзем сорап алдым. Алтмышны узгач, безнең нәсел кешесенә бераз аксамыйча килешми. Галиулла бабам беренче герман сугышыннан аягына төзәлмәс яра алып кайткан. Әтием Нәбиулла карт икенче герман сугышыннан чатанлап хатыны янына иңгән, берничә елдан соң аягын алдырган. Миңа да артык төз булып, арка катырып йөрү килешмәс, дип, герман ботинкасы — саламандер алып кидем дә, ул аякны кырды, — дип шомартам. Минем шаяртуның бәясен аңлаган Гариф абый, коридорны тутырып шаркылдап көлде дә, аркадан сөеп, «молодец, терел, син әле безгә кирәк», — дип, үзеннән бигрәк акча янчыгын зарыгып көтеп торган яшь шагыйрьләр янына титаклады.

Иҗат мәсьәләләренә, яшьләр белән эшләүгә Г.Ахунов вакытын кызганмады, һәр яңа әсәргә игътибарлы булырга тырышты. Шул чордан истә калган бер мисалны гына китерәм. Шагыйрь Г.Латыйпның илдәшләр сугышы чорына багышланган, шактый бәхәсле «Кызыл яр» исемле поэмасы басылып чыккач, ул мине Алабугадан махсус чакыртып, идарәдә (дөресрәге, ул секциянең киңәйтелгән утырышы булгандыр) әсәргә анализ ясатты. Автор үзе дә катнашкан бу сөйләшү бер әсәрне тикшерүгә генә кайтып калмыйча, поэманың барыр юллары турында җитди фикер алышуга әверелде.

Г.Ахунов кулына йомшак, зәгыйфь әсәр килеп керсә дә, каләм иясенең түшәмен, сәләт дәрәҗәсен чамалап, күтәрелеп бәрелмәс, авторның күңелен җәрәхәтләмәс. Җайлап, иплəп кенә дөньяда башка һөнәрләр барлыгын, кызыклыгын искә төшерер. Әдәби эзләнүдә киләчәкле фикри борылыш, гомумән үсеп китәрдәй оеткы тапса, ул киңәшләрен бирер, ярдәм кулын сузар. Әдәбият бусагасын атлаган сәләтлерәк кеше әйберен ашык-пошык әвәләп китерсә, ул Гариф абый кулына килеп керсә, яхшы сүз көтмә дә, үпкәләмә дә.

— Карале, дускаем, әсәрең әйбәт кенә буласы икән, ашыккансың! Вакыйгаларыңның очы-очка ятмый. Сүзләрне — карлыгачларны уйлап бетермичә очыргансың, — дип тезеп китә. — Ат дагалаганда бака ботын кыстыра димәсәң, менә мин «Тын Дон»ны тәрҗемә иткәндә Шолоховның бер җөмләсе белән ике көн утырдым. Мәгънәсен биреп кенә булмый бит. Эчтәлеге килеп чыкса, сәнгатьчә матурлыгы югала. Ә син кабалангансың, алай килешми. Салкында тунны төймәләгәндә генә ашыгу килешә.

Гариф абыйның тәнкыйте ничек кенә җайсыз, усал булып күренеп, автор эчтән генә сыкранса да, риза була, аек дәлилләре белән килешә. Чөнки ихластан, изге ният, булсын, татар әдәбиятының олы абруен төшермәслек әсәр өстәлсен, дип әйтелгән тәнкыйть ул, май чүлмәге кебек, тышыннан күренеп тора. Иҗат әһеле тәнкыйтьнең йөрәктән, әсәрне яхшырту өчен әйтелгәнен, кешенең рухын сындыру өчен, ачу белән чыгарылганыннан тиз аера.

Гариф абый, аңлавымча, гомере буенча табигатьнең иң югары казанышы — кеше дигән затны аңларга тырышып яшәде. Аның каләме тудырган әсәрләрне, аларның каһарманнарын гына күз алдына китерик. Күбесе үз көнен үз хәләл көче белән күрә торган хезмәт кешесе.

Гариф Ахунов тел бизәкләренә ифрат сизгер шәхес иде. Берәр матур сүз, янарак чагыштыру ишетсә, шуны көннәр буенча кабатлап йөрер. Иҗатында ул купшы, нәфис сүзләр эзләми. Халык телендәге иң гадәти сүзләрдән яна гыйбарә-сынландырулар үреп, аларны тәсбих төймәләрен тезгәндәй, матур, пөхтә җөмләләргә үстерер. Аларның нәфис бизәкләренә сокланып, читкәрәк китеп озын-озак итеп карап, тәэсирләнеп торыр. Шундый олы зат булып ул күңелдә мәңгегә урнашып калган.

Гариф абый урамнарга ташып чыгып, шигарьләр күтәреп кычкырып йөрмәсә дә, милләте өчен кайгыра, аның унай якларын күреп шатлана, үзен тиешле югарылыкка куя белмәве өчен борчыла, гарьләнә иде. Аның күңеле, сизгер сейсмограф кебек, тормыш җилләрен, замана кыйбласын сизеп, шатлану, тетрәнүләрен тоеп, үзе аша уздыра белде.

Гариф абыйны тормышында, иҗатында башка берәү белән бутау мөмкин түгел, ул күңелләрдә кабатланмас шәхес булып кала алды.

Күренекле шагыйрь Р.Фәйзуллин Г.Ахуновка багышланган бер уйлануын «Егет әдип» (1985) дип атаса, вафаты уңае белән язылганына «Зураеп калу» (2000) дигән символик мәгънәле исем бирә. «Ни нәрсәдән мәхрүм калганыңны югалткач кына аңлыйсың. Исән чакта, теге дә, ул да, мин дә дигәндәй, кайчандыр бер-беребездән мәңгегә аерылачакны белсәк тә, ул вакытта хис-тойгы әле шактый томанлы, абстракт, югалтуның ачы хәсрәте

сәгате суккач кына йөрәккә төшә икән. Гариф абый Ахунов үлемен ишеткәч тә шулай булды... Һәм әйтергә кирәк, Бөек Күчештән соң аның исеме, рухы фани дөньялыкта зураеп, үсеп калды» («Зураеп калу»).

## Аяз ага!

Кемгә ничектер, миңа «Аяз Мирсәет улы» дигән рәсми мөрәҗәгатькә караганда, «Аяз ага» дип эндәшү, күренекле сүз остасын олылау белән беррәттән, ниндидер рухи якынлыкны, хөрмәтне тулырак чагылдыра, җылырак яңгырый кебек. Холкының кырыслыгын бер мизгелгә дә онытмыйча, кәефе яхшы вакытта, үзенә дә шулай мөрәҗәгать итә, ә инде хатыны Нәкыя янында булганда, «җизни» дип тә ычкындыргалый идем. Соңгысына кечтеки генә хакым да бар иде шикелле. Чөнки мин аның гомерлек тугрылыклы юлдашы, шулай ук туган халкының язмышы, теле өчен җан атып яшәгән Нәкыя ханым белән Казан дәрелфөнүненең татар теле һәм әдәбияты бүлегендә биш ел бергә сабак алдым. Аяз ага, нахак яла аркасында, яшьлегенең иң матур чорын урлаган сөргендә булып кайтканнан соң, безнең төркемнең чибәр, акыллы, сабыр кызларыннан берсен — Нәкыяне оста мәргән кебек «чиертеп» алды. Группабызда аны иң матуры иде дип расларга алынмыйм, бердән, һәркемнең үз зәвыгы булса, икенчедән, бу «урынга», әтисе ишек төбен саклаучы гына булса да, «мин военком кызы», дип, төтен җибәрүдән ләззәт тапкан Галия белән чем-кара йөзле, кара күзле, «кыргый» матурлыкка ия Римма да дәгъва итеп йөрделәр. Чебешләрне көзен саныйлар дигәндәй, төркем кызларының берсе дә хатын-кыз вазифасын Нәкыя кебек, шундый күркәмлек белән үти алмады дисәм, зур ялгыш булмастыр.

Нәкыя белән дуслашып, безнең төркемгә кергәләп йөргәндә Аяз ага күңелгә җитез хәрәкәтле, фикерен берәүдән дә курыкмыйча өздереп әйтә белүче, тәҗрибәле вә хакыйкатькә турылыклы зат булып кереп калган. Ул чорда әле аның тормыш юлын, дөньяның ачысын-төчесен һәрьяклап татыган кеше икәнен бөтен тулылыгында белми идек.

Шәхес культы фаш ителгән булса да, аның коточкыч начар яклары турында тулы тавышка, ачыктан-ачык сөйләшү сәгате сукмаган иде әле.

Төркемебезнең тулы ай кебек түгәрәк битле, чем-кара озын чәчле, сабыр холыклы, укуга һәвәс кызы Нәкыя белән Аяз абый электән таныш булып, хат алышып торганнар икән. «Теgeннән» кайткач, группабызның булачак кияве, күпмедер вакыт көндезге бүлектә «бала-чага» белән буталып йөрде дә, читтән торып уку бүлегенә күчеп, «Чаян» журналында эшли башлады. Аның инде гаилә корып, балалар үстереп яшәү вакыты җиткән иде. Социологлар фикеренчә, утызның өске ягына чыккан ир-ат, буйдак тормышның «тәмен» татыгач, үзенә тиң ярын табу, гаилә мәшәкатьләрен җилкәсенә салу мәсьәләләрендә шикләнә, икеләнә, аны җаваплылык, шәхси ирекен югалту куркыта башлый. Аяз абый тимерне кызуында суга торган егет булып чыкты. Нәкыя дә өлешемә тигән көмешем дип, артык кыстатып тормыйча, кыз-кыркын тормышы белән хушлашырга булды. Көндезге бүлектә укуын ташламыйча, дипломын безнең белән бергә алып, Аяз абыйның текә холкына җайлашып, кирәк чакта салпы ягына салам кыстырып, шул ук вакытта тормыш-көнитеш дилбегәсен кулыннан ычкындырмыйча, минем белүемчә, үрнәк гаилә корып, төп көчен улларын тәрбияләүгә бирде.

Килен кешенең тәкъдиме беләндер дип уйлыйм, безнең төркемнән Аяз абый туйларына өч егетне чакырды: сонынннан радио дикторы, шунда ук әдәби-музыкаль тапшыруларның баш мөхәррире, Оренбург егете Рим Кәримов, группаның комсоргы, «Татарстан» журналының редактор урынбасары Шәүкәт Сәйфетдинов һәм ошбу юлларны язучы шундый бәхеткә тарган затлар булдык. Мәҗлес Островский урамында,

«Татарстан» кунакханәсе янында диярлек урнашкан йортта, кайсыныңдыр ерак туганнарының фатирында узды (ул йортларны инде күптәннән «җир йотты»). Ике якның да туганнары, Аяз абыйның үзе көндез укып алган төркем егетләре, кызлары чакырулы иде. Шул чор өчен өстәл шактый әгъләдән әзерләнгән булып чыкты, графиналарга, шешәләргә салып куелган «шайтан суы», жемелдәп «күз кысып», әллә нинди сөенечле вәгъдәләр биреп, ялт-йолт итеп үзенә чакырып тора. Без — томшыклары ныгып кына килә башлаган чебешләр — беренче курс талиблары мондый кичәләрдә үзеңне ничек тотарга икәнен белмибез, шуңа күрә, салганны эчеп, алда торганны ашап, кушканны үтәп, тәмам сәлперәеп төшкәнебезне сизми дә калганбыз. «Җемелдәп» утырган савытлардагы эчемлек, тәмле булып, җинел эчелсә дә, аякларны, билләрне мамык белән тутырылган хәлгә китерүгә «сәләтле» булып чыкты. Аяз жизнинең сыйныфташлары, күбесе соныннан күренекле язучылар, журналистлар, фирка хезмәткәрләре — Хәмзә Зарипов, Мөкатдәс Юсупов, Минвәгыйз Зәйнетдинов, Фаяз Хисмәтуллин (Дунай), Мидхәт Миншин, Фарваз Миннуллин, Кояш Тимбикова кебек, шул чорда ук үзләре турында югары фикердә торган гаярь егетләр-кызлар иде. Теге серле эчемлек аларның кулларын, телләрен «чишеп» җибәрде. Беришесе ата-анасының дәрәҗәсенә сылтама ясаса, икенчесе шагыйрьлеге, вакытлы матбугатта басылуы белән мактана, төрлечә туарыла, шаулаша башладылар, сөйләүчене бүлдерү ешайды. Туйның фәлән еллардагы, барысы бергә сөйләгән, колхоз җыелышына әверелү куркынычы туды. Мәҗлеснең ямен җибәрүчеләр күбәюгә, кияү дилбегәне кулына алып, үзенең холкын күрсәтә, тәртип бозучыларны, мактанчыкларны чоланга алып чыгып, әрдәнә итеп өеп куя, беришесенең «ипи шүрлегенә» дә менеп төшә башлады. Аның җитез гәүдәсе, елгыр йодрыгы әле бер почмактагы кабыргада, әле икенче яктагы арт санда ялтырап-ялтырап күренеп ала башлады. Берничә дәкыйка эчендә ул өйдә дә, чоланда да тәртип урнаштырды. Ярдәмчеләре дә бар иде бугай.

Үзе туктаусыз бер үк җөмләне кабатлый.

— Фукалар (соңыннан без аның «с» хәрефен безгә фарсыдан кергән «ф» белән алыштыруына төшендек), мин сезне якын итеп, җан дуслар күреп, шатлыгымны уртаклашырга чакырдым. Ә сез җәнҗал, тавыш чыгарып ятасыз. Бөек буласыгыз килсә, төрмә тоткасын имеп кайтыгыз, фукалар!

Баш хәрефе алышынган сүзне кат-кат әйтсә дә, Аяз жизнинең йөзендә җинүче кыяфәте юк. Чырай чытыклыгына караганда, аның бу «эшне» мәҗбүри башкаруы сизелә иде. Ул бары тик туйның тыныч, тәртипле узуын теләде кебек. Ә беренче сыйныф балаларының, ягъни безнең, тавыш чыгарырлык түгел, сөйләшерлек тә дәрманыбыз юк, почмактан тамаша шаһитлары булып утыру өчен генә ярарлык идек.

Аяз белән Нәкыянең туйларында булган хәлләр турында матбугатта да беркадәр фикер әйтелде, бигрәк тә мәҗлестә катнашучыларның үзара очрашуларында сүзләр, бәяләр шактый булды. Үзләренә җилдәй җитез йодрык эләккәннәре бу хакта сүз куертуны бер дә өнәмәделәр.

Аяз абыйның чүкеч йодрыгы эләкмәгәннәре, чүпрәне өсти торып, вакыйгалар агышын елдан-ел арттыра, куерта, детальләрне өсти тордылар. Күренекле публицист, шагыйрь Мидхәт Миншин А.Гыйләҗевнең үзен «дөмбәсләвен» искә төшерүне аеруча авыр кабул итә иде.

— Ничек инде без, шундый таза егетләр, кеп-кечкенә Аяздан кыйнатып торыйк, ди. Тузга язмаганны сөйләп йөрмәсәгез, — ди торган иде ул, ачулы күзләрен уйнатып.

Инде янәдән мәҗлескә әйләнеп кайтсак, без «чебешләр»нең үз хәле хәл. Аяклар зиһен шәрифләренә буйсынмый, буыннар боламык кебек изелеп төшкән. Ярый әле, шул тирәдә генә, Киров урамының (хәзерге Московская) башында

гына, ике катлы агач йортта фатирда тора идек. Шәүкәтнең дә Гадел Кутуй урамына, тулай торакка кайтырлык хуты калмаган иде, безгә иярде. Икенче көнне иң таләпчән укытучыбыз профессор Диләрә Тумашеваның лекциясенә дә бара алмадык. Ә туйда алган истәлекләр һаман да күңелдә, хәтердә. Мәҗлестә катнашкан, дәрт чүлмәкләре ташып торган егетләр һәркайсы кабатланмас чалымнары, сөйләшү манералары белән һаман күз алдында торалар. Күбесе инде гүр ияләре. Туйда катнашкан ике сабакташым, дусларым Шәүкәт белән Рим да җир астында. Татар мәдәнияте үсешендә һәркайсы үз үрен калдырган бу егетләрне тезеп бастырасы, янә бер кат Аяз абыйдан «тәртипкә» чакыртасы иде дә, үткәннәргә хәтер канатында гына кайтып була шул. Кичә булган хәлләр онытыла барса да, яшьлек хатирәләре күңелдән китми икән.

Шактый вакыт узгач, истәлекләргә бирелеп утырганда, мин тәнкыйтьче, туйның түрендә кияү егетенең дусты булып утырган Фарваз Миңнуллиннан «ни өчен Аяз абый шулай чыгырдан чыкты, сабакташларын тукмап ташлады икән», дип сорагач, уйланып торгандай булды да:

— Мин Аязны аңладым һәм гафу иттем. Мидхәт Миңшиннан башкалары аны-моны әйтмәде, үпкәләмәделәр кебек. «Каядыр бәрелгәнмен бугай. Кабыргалар кара янып чыккан», дип, зарланучылары булды анысы. Күбесе хәтерләми дә. Мин шешәләрдәге самогонның, чуаш кардәшләрнең аңкаласының көчен бәяләп, су гына эчеп утырдым.

— Аяз абыйның болай кыйланышын ничек аңларга инде?

Һәрнәрсәдә тәртип, тимер мантыйк тарафдары Фарваз, уң кулының бармакларын берәм-берәм учына яткыра-яткыра, иренмичә санап китте.

— Беренчедән, Нәкыяненң мәртәбәле туганнары алдында сабакташларының исерешеп тәртип бозуларын күрсәтәсе килмәде Аязның. Исеңә төшер (шуны аңларлык хәлдә булуына шикләнәм, дигән мәгънәдәрәк күзен уйнатып алды): табында утыручылар сизми калсын дип, ул әүвәл, чоланга чыгу ишеген ябып куйды. Икенчедән, үзе дә бераз салмыш иде. Аяз күңелен тырнаган хисләренә ирек бирде. Өченчедән, һәм иң мөһиме, димәк, сөргендә утырганда надзирательләр үзен дә шул ук сүзне әйтә-әйтә кыйнаганнар. Тирәндә, аң төпкелендә утырган ачу, үпкә хисе кайнаган май шикелле өскә чәчрәп чыккан. Билгесез көчләрдән үч алып, йөрәген тынычландырды. Гарьләнүе, рәнҗүе белән бүлеште.

— Соң бит алар аның дуслары, сабакташлары, — дип, үҗәтләнүемә дә Фарвазның исе китмәде. Чыраен сытып алды да:

— Ул мизгелдә Аяз өчен барыбер иде. Кызып киткән вакытта кеше үзен төрлечә тотарга мөмкин; тик кул астына гына эләкмә. Кыйнаганда надзиратель дә берсенең дә фамилиясен сорап тормагандыр дип уйлыйм. Сүгенү сүзләре дә шул чорныкы.

Соңгы җөмләнең мәгънәсен аңлап житкермәсәм дә, ачыклап торуга җөрьәт итмәдем. Адәм баласының психологик халәтендә ни ятканын, вулканның кайчан тышка бәреп чыгасын фаразлап булмый күрәсең, дип кенә нәтиҗә ясадым.

Соңыннан Аяз абыйның кемгәдер кул күтәргәнен (шул исәптән хатынына), якасыннан алганын күрмәдем, ишетмәдем, гөнаһысына керә алмыйм. Туры сүзнең тәэсире йодрыктан көчлерәк икәнлекне кем генә белми икән. Сәләте чикле, дәгъвасы хәттин ашкан каләм тибрәтүчеләр арасында Аяз Гыйләҗевнең ачы, нигездә гадел теленә эләккәнче, берне тондырсын гына иде дип уйлаучылары да аз булмагандыр. Ул абруйлы, мәртәбәле, исемле язучыларның әсәрләренә бәясендә дә дөресен, уйлаганын әйтүдән куркып тормый иде.

«Йәгез, бер дога» романын язганчы, А.Гыйләҗев лагерь тормышы турында сөйләргә, җанын җәрәхәтләп искә алырга яратмады.

Ибраһим Салахов, Гурий Тавлин, иң соңыннан Аяз Гыйләжевнның Сталин лагерьлары турындагы югары кимәлле әсәрләре белән танышканнан соң да, ул чор турында тагын ишетәсе, шул җәфа-михнәтләрне кичергән кешеләрнең башларыннан үткәннәр турында күбрәк беләсе килә иде. Аяз абый, бик теләмәсә дә, тоткынлык чоры турында бер тапкыр үз фикерләре белән бүлеште.

— Ни өчен Сталин һәм аның сатраплары күбрәк зыялыларны, аеруча язучыларны юкка чыгарырга омтылганнар? — дигән примитив соравыма, иренмичә аңлатмасын бирде.

— Һәр милләтнең рухын саклаучы, уйландыручы, яшәү мәгънәсен билгеләүче, көннәрдә өмет рухы кабызучы алдынгы, изге затлары була. Шуларның алгы рәтендә язучылар, кеше аңына сүз аша тәэсир итүчеләр тора. Өстә утыручылар каләм осталары юкка чыгарыла барган саен халык милли йөзен, телен югалта, зәгыйфьләнә, каршы тору рухы (оппозиция) сүнә, сүрелә килүне аңлыйлар. Татарның билгесез мәнфәгатьләрне яклап «батырлык» үрнәкләре күрсәтүе буйсынучанлыктан, хәтта куркаклыктан килә. (Искә төшерегез: безнең хәзерге милли халәтебезне Мәһдиев тә шулайрак бәяләгән иде).

Буйсынган милләтләрнең 1941-1945 еллар сугышына мөнәсәбәтен чагылдырган мәзәк тә бик урынлы китерелде.

— Командир окопта яткан солдатларына атакага күтәрелергә әмер биреп, «орлы, вперёд», дип кычкыра. Урыс, татар, чуаш, башка милләт вәкилләре алга ыргыла. Күбесе сугыш кырында ятып кала. Яһүдләр траншеяда качып калалар, «сез ник атакага бармадыгыз?» дип сорагач, «Мы ведь не орлы, а львы, а львам команды не было», дип аңлаталар.

Фикерен «нәзари» яктан раслаганнан соң, ул беркадәр тегендә күргәннәренә тукталып китте. Ниләр генә кичермәгән, нинди генә түбәнлекләргә дучар ителмәгән икән татар язучысы. Аяз ага ачылып китә дә, ашыгыч эше исенә төшкәндәй, туктап кала, «чыдадык, түздек, барысын җиңеп чыгарга мәҗбүр булдык», дип, сүзне җиңелрәк мәүзугъка күчерә. Гәпләшүебез барыбер күбрәк милләт, әдәбият, сәнгать елгасына килеп чыга.

— Башка милләткә буйсынып яшәгәндә, халыкның рухы зәгыйфьләнә, әдәбиятның биле сына, — диде ул минем «безнең әдәбиятка нинди тышкы сәбәпләр үсәргә ирек бирми?» дигән соравыма.

— Ни өчен шундый көчле, дөньяны дер селкетеп торган коммунистлар фиркасы юкка чыкты? Бу сөалемә ул шаяртып җавап бирде.

— Партияне мактауда яңа җөмләләр, чагыштырулар табуы кыенлашкан иде. Шуңар да ул мәтәлде.

— Нәрсә ул патриотизм?

— Ул үзеңне, рухыңны, аннан соң якыннарыңны ярату дигән сүз. Ләкин аның мәгънәсен, эчтәлеген боздылар.

— Туган илне ярату түгелме соң инде ул?

— Аны яратмаска өйрәттеләр. Ә туып-үскән, тәпи-тәпи йөргән җирне яратмый мөмкин түгел.

Туксанынчы еллар ахырында, яңа гасыр башында үзәктән иңгән сәясәтнең мәгънәсен, асылын ул тәгаен ачып бирде.

— Иманыбызга, динебезгә, телебезгә каршы бик астыртын, мәкерле, әйтергә кирәк, акыллы сәясәт алып барыла. Аны әүвәл тиле-миле булып кыланган, чынлыкта хәйләкәр Жириновский кебек рупорлар авызыннан әйттерәләр, аннан соң тормышка ашыра башлыйлар.

Аяз абыйның иҗади дуслары белән беррәттән, бакчачы, балыкчы, бергә ял иткән аркадашлары да житәрлек иде. Житмешенче еллар башында Идел буена гына урнашкан, Займище дип аталган төбәктән

зыялыларга бакча урыннары бүлеп бирделәр. Шундый бәхеткә тарган кешеләр арасында драматург Т.Миннуллин, Татарстан китап нәшрияты директоры Г.Шәрәфетдинов, «Чаян» журналының баш мөхәррире А.Яхин һәм А.Гыйләжевлар да була. Бу шәхесләрне уртак кайгылар, уртак шатлыклар һәм үзенең балыклары белән «Идел» елгасы якынлаштыра. Балык тотуларының мәзәкләре турында А.Гыйләжев та, Т.Миннуллин да язып чыктылар. Идел буенда йөргәндә, көймәдә йөзгәндә генә түгел, башка җәһәтләрдән дә Аяз абыйның «мин бирәүдән дә ким түгел, була да алмыйм», дигән үҗәт, көнче холкыннан юмористлар бик оста кызык хәлләр китереп чыгаргаладылар. Шуларның берсен А.Яхин уйлап таба. Әле бакчаларда кыяр өлгереп җитәргә иртәрәк бер вакытта, базардан сатып алып кайта да, иренмичә, һәр кыярын сабакларга бик нечкә җеп белән бәйләп куя һәм күршесенен, Аязның «хәлен белергә» юнәлә.

— Хәлләрең ничек, Аяз.

— Аллага шөкер, парин, озак еллар шулай булып торсын!

— Кичке ашыңны ашадыңмы әле? Өлгермәгән булсаң, миңа сугылыйк. Күрсәтәсе әйберем дә бар, — ди юморист, борынын ике тапкыр тартып, кул янтаулары белән чалбарын күтәреп алганнан соң. Сөйләшә-сөйләшә А.Яхинның бакчасына керәләр. Хуҗа кеше җәһәт кенә бөгелеп, «күршене яна өлгергән кыяр белән кунак итик» әле, дип, сөйләнә-сөйләнә, күрсәтә-күрсәтә бакча нигъмәтләрен «өзеп-өзеп» ала. Шуны карап торган кунак бер кызара, бер карала, Альберт кулыннан кыярларның берсен тартып алып, йөгерәатлый үз дачасына таба китә. Бакчасына керә-керешкә Аяз ага күтәрелеп бәрелеп, дулаган, хатыны белән әнисен «сез, әрәмтамаклар, икәүләп җәй буе бакчада ятасыз, кешенең әнә кыяры өлгергән, сезнең бер нәрсәгез дә үсми», дип кич буе, тамаша авторы кереп тынычландырганчы, ярсыган, ди.

Үләренә берничә ай калгач, А.Гыйләжев белән соңгы тапкыр, Татарстанның Дәүләт советы депутаты, Мәһдиев искә алып узган Фалис Вәлиевнең фатирында, тар мәҗлестә күрешеп калырга насыйп булды. Хәле бик авыр булып, Нәкыя ханымга таянып кына йөри алса да, дустының чакыруын кабул итеп, үзен җиңеп, очрашуга килгән иде. Минем анда булуымның сәбәбен әйтеп китү дә кирәктер. Без Фалис Әхәт улы белән якташлар, Норлат районының Кычытканлы дигән сәер исемле авылда туып-үстек, бергә мәктәптә укыдык, ул комбайнда эшләп, армия сафларын бизәп, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кергәндә, мин шул ук уку йортында ассистент вазифаларын башкарып йөри идем инде. Югары белем алганнан соң, аның карьера үсеше гаҗәеп тизлек белән барды: әүвәл Зәй районы Югары Пенәче авылында гади укытучы, шул ук мәктәпнең директоры, шунда урнашкан колхоз рәисе, районда партия контроле җитәкчесе, райсполком рәисе, берничә чакырылыш халык депутаты, атаклы «Зәй» совхозы директоры. Һәр эшендә үзеннән соң изге гамәлләр, ике катлы мәктәп бинасы, заманча фермалар, йортлар төзеп калдырды Фалис дус! Сайлаучыларының теләсә нинди катлаулы сорауларын канәгатьләндергән өчен рәхмәттән башканы таләп итми. «Фатих Әмирхан иреннәре» арасыннан «кешеләргә ярдәм итү депутатның, җитәкченең бурычы», дип кую һәм зәңгәрсу-соргылт күзләрендә хәйләкәр елмаю биетү белән чикләнә.

Эше һәрдаим муеннан булып, көне-төне кырда чабу, кешеләрнең гозерләрен үтәү белән шөгыльләнү сәбәпле, агымдагы татар әдәбиятын гел укып бара алмаса да, аның әйдәп баручы олы шәхесләренә Фалис һәрдаим игътибарлы булды. Җөмләдән, олуг язучыларыбыз Мөхәммәт Мәһдиев белән Аяз Гыйләҗевка ихтирамын яшермәде. Әлеге затлар Тукай премиясен алгач та, Татарстанның халык язучысы дигән исемгә лаек булгач та, аларны бүләге һәм тәмле сүзе белән, Зәйдә яшәсә дә, беренчеләрдән булып Ф.Вәлиев котлады.

Аяз аганың элегрәк сөйләгәне, кырмавык кебек, хәтердә ябышып калган.

— Яшәү өчен Зәйгә күченеп килгәч, күңелсез булыр дип уйлаган идем, парин. Фалис Әхәтович, моңланып, Казанымны сагынып утырырга бирмәде. Рухи бушлыкны, Туфанны, Мәһдине, Гарифны сагынуларымны игътибары, юморы, көлүе белән берүзе тутырды. Суыткычны буш тотмады. Иртән эшкә барганда, хәлне белеп сугылыр, кичен, шайтан сулы шешәсен кыстырып, иркенләп гәпләшеп утырырга килеп керер.

Аяз ага Казанга әйләнеп кайткач, Фалис та даими депутат эшенә Казанга күчте. Бередә дә, Аяз абыйның фани дөньядагы соңгы көннәренә чаклы, алар аралашып, дустанә яшәделәр. Сөйләшендә урам сүзләрен, тозлы-борычлы юморны кыстырып сөйләргә яраткан Фалис өлкән дусты янында тәртипле, итагатьле кешегә әйләнә дә куя, КДУның татар бүлеген «тәмамлаган» пишкадәм диярсен.

Мөхәммәт Мәһдиевкә мөнәсәбәте шулай ук игелекле һәм җылы булды.

Мөгаллиме белән якыннан аралашып яшәүне Фалис үзе өчен мәртәбә санады, ана төрлечә, бигрәк тә матди ярдәм итеп яшәргә тырышты.

Соңгы очрашу вакытында Аяз абый ашамады да, эчмәде дә, тирәнгә баткан моңсу күзләре белән карап, без шау-гөр килгәнне тыңлап кына утырды. Аяз Мирсәет улы турындагы истәлекләр зиһендә өзек-өзек кенә саклана шул. Аның төрле елларда, төрле дәрәҗәдә очрашуларда әйткән сүзләре, фикерләре заманында кәгазьгә теркәлеп барылмаган, онытылганнары әһәмиятсез, икенче, өченче дәрәҗәдәгеләре булгандыр дип кенә үзенне юатырга кала.

Аяз Гыйләҗев үзеннән соң төрле жанрларга караган гаҗәеп зур әдәби мирас калдырды. Бу байлык әле чын-чынлап өйрәнелмәгән. Бу очракта аның тормышының икенче бер күркәм сыйфатына игътибар юнәлтү мөһим. Ул бериш сәнгать әһелләре, шул исәптән язучылар кебек, «гаиләләребез тулы, балаларыбыз күп булса гына милләтне саклап була», дип, акыл сатып кына йөрмәде, шәхси яшәеше белән үрнәк күрсәтеп, милли җанлы, һәркайсы үз өлкәсен сөреп барырлык өч ир-егет, өч бөркет үстереп калдырды. Аларны да рәсемгә төшереп, өч әдибебез үрнәгендә, «өч баһадир», дип атап булыр иде. Нәкыя ханым КДУның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем эстәп йөргәндә туган олы улы Искәндәр хәзер тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан фәннәр академиясенең әгъза-мөхбире, икенче улы Мансур драматург, «Бичура», «Баскетболист», «Казан егетләре» һ.б. заманча фикерләүле, үзенчәлекле әсәрләр авторы. Аны тамашачы да, укучы да үз өслүбен, үз иҗат алымнарын тудырган язучы, дип бәяли. Өченче улы белән танышлыгыма мактана алмасам да, анысын шактый уңышлы эшмәкәр дип ишетеп беләм. Шактый гыйбрәтле туйдан башланган гаилә мул уңышы белән дә сөендерде. Балаларына хас талант, дәрт, куәт, иҗади эшкә сәләт Аяз абыйдан килсә, тәрбия, әхлак, халкына мәхәббәт, тормышны алып баруга,татар һәм башка телләргә өйрәтү Нәкыя ханым җилкәсенә төшә. Төп игътибарын балаларына һәм пырдымсыз иренә бирсә дә, бергә укырга кергән көндезге төркемнән аерылмыйча, хәтта «хәерче» студентларга матди ярдәм күрсәтеп, бурычка акча да биреп торып, өлгерештә дә калышмыйча, әйткәнемчә, безнең белән бергә дипломын да алды Нәкыя ханым. Ир белән хатын үзара туган лөгатьләрендә аралашса гына балалары шул ук телдә сөйләшә. Икенең берсе татарчаны ярым-йорты белеп, араларны «ачыкларга» туры килгәндә, русчага күчкән гаиләләрдән татар теленең нечкәлекләрен белгән, халкына турылыклы кеше сирәк чыга, милли әхлак, көнкүреш үзенчәлекләре, өлкәннәргә ихтирам, ата-ана алдындагы бурыч кебек сыйфатлар күңеленә сеңми. Аяз ага, карлыкканрак тавышы белән «милләткә өч егет үстереп бирәм», дип, Ахунов, Мәһдиев, Фәйзуллин кебек

дуслары янында күкрәккә кагып, мактанып утырганда, татар теле һәм әдәбияты укытучысы, тыйнак Нәкыя ханым балаларына Тукайның «Туган тел»ен җырларга өйрәтеп, «Су анасы» белән «Шүрәле»не укып, аталарының абруен күтәреп, улларын бакты, өй эшләрен башкарды. Нәкыя ханым теләсә кайсы редакциядә журналист, редактор, тагын әллә кем булып менә дигән итеп эшли алыр иде. Мәгәр ул мәктәпне ташламады, татар телен, әдәбиятын укыту методикасын камилләштерүгә багышланган үткен-үткен мәкаләләр дә бастырды. Моның төп сәбәпләреннән берсе — укытудан алган тәҗрибәсен үз гаиләсе әгъзаларына сеңдерү, балаларына рухи яктан да якынрак булуга омтылу, дип аңлатыр идем.

Татар милләте, төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә, сан ягыннан кими, телен югалта барган киеренке чорда үз халкының язмышы өчен җан атып йөргән өч бала тәрбияләп үстергән өчен генә дә Аяз абый белән Нәкыя ханым мактауга вә сокланугa лаеклы олы затлар.

Язучы үзе үлгәннән соң, мирасы турында кайгыртучылары булганда гына аның исеме, даны яши. Язучының исеме әйләнештән төшеп калмау талантына, варисларының игътибарына, җәмгыятьнең үсеш дәрәҗәсенә бәйле. Аяз ага бу яктан да бәхетле булып чыкты. Кадерле ирен югалтканнан соң, Нәкыя ханым чын-чынлап А.Гыйләҗевнең мирасын, бигрәк тә публицистикасын, әдәби тәнкыйтен барлау, өйрәнү, популярлаштыру шөгыленә керешә, туктаусыз мәкаләләрен бастыра, мәктәптә музей ача. Язучы үзе исән чакта басылмаган язмаларын, хатларын җәмәгатьчелеккә ирештерә. Фәнни әдәби аңлатмалары чын библиограф, тәнкыйтьче дәрәҗәсендә башкарылган булулары белән сокландыралар. Безгә, укучыларга, Аяз Гыйләҗев язмышыннан яхшы мәгънәсендәге көнләшүдән башка нәрсә калмый.

## Онытмадык сине, Фарваз дус!

Үткән гасырның 60-80 елларында әдәбият мәйданында ут уйнаткан гаярь тәнкыйтьче Фарваз Миннуллинга 2009 елның 5 августында җитмеш биш яшь тулган булыр иде. Мәңгелек хозурына күчкәненә дә байтак вакыт узса да, аның арабызда юклыгына күңел ышанмый, мондый хаксызлыкны җан кабул итми. Әдәбиятыбыз турында сүз барганда, ак йөзле, коңгырт чәчле, соры күзле, килешле гәүдәле Фарваз түзә алмыйча капылт урыныннан сикереп торыр да, учын учка сугып, «җәмәгать, мин сезне аңламыйм, ничек инде шундый урта кул әсәрне хәзерге сүз сәнгатебезнең казанышына кертә аласыз», дип ярып салыр, «әдәби тәҗрибәгә бәя биргәндә эчтәлекнең сәнгатьчә бирелешенә игътибар итмисез», кебегрәк фикерен дә өстәп куяр иде. Вакыт галиҗәнапләре ул яшәгән, иҗат иткән елларны ераккарак алып киткән саен аның юклыгы көчлерәк сизелә, юксыну хисе арта бара. Бу — шәхси кыбырсыну гына түгел.

Вакытлы матбугатта аның имзасы куелган җыйнак күләмле, әмма фәһемле эчтәлекле, нечкә зәвыклы тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр 60нчы еллар башында күренә башлый. Тиздән аның кыю, тәвәккәл, үзләрен тәнкыйди сүздән өстен санап йөргән абруйлар иҗатына да янача, вакыты-урыны белән кискен бәясен курыкмыйча, шул ук вакытта шәхесне рәнҗетмичә язылган мәкаләләре, әдәби портретлары, мирасыбызга багышланган чыгышлары даими басыла. Алдагы унъеллыкта Ф.Миннуллин сәнгатьчә фикерләү үзенчәлекләрен бәяләү сәләтенә ия, ачык, аналитик фикерле, тәэсирле телле профессионал тәнкыйтьче буларак үсеп җитә. Татар тәнкыйтенә Җ.Вәлиди, Г.Галиләр рухы кайткандай тоела.

Ф.Миңнуллин феноменын аңлау өчен шул чорның иҗтимагый-әдәби атмосферасына күз салу һәм әдәбиятның үсеш халәтенә бәйле хасиятен искә

төшерү лаземдер. Сүз сәнгате иҗтимагый тормышка бәйле, аның көзгесе булса да, әдәбиятның бирәү белән дә «санашмый», баш бирми торган эчке кануннары бар. Үсешенең яңа үренә менгән, сыйфат сикереше ясаган чорларда әдәбиятны аңлатучы, шәрехләүче, бәя бирүче, укучыга аның әхлакый-сәнгати көчен җиткерүче юлдашы — тәнкыйть тә күтәрелә. Мисал эзләп еракка барасы юк, XX йөз башы бөекләре Тукай, Исхакый, Ибраһимов һ.б. иҗатының яңачалыгын, татар әдәбияты үсешенең алтын чорына керүен аңлап, аңлатып бирердәй Җ.Вәлиди, Г.Рәхим, Г.Сәгъди, соңрак Г.Нигъмәти, Г.Галиләргә ихтыяҗ туа.

Үткән гасырның 60-нчы елларында әдәби барышта яңа тенденцияләр хасил була, беренче чиратта, үткәнебезгә һәм хәзерге рухи халәтебезгә бәя бирү омтылышы тудырган тәнкыйди рух көчәя. «Хрущев җепшеклеге» тәэсирендә СССР дип аталган ясалма империя төпкелендә яшәүче халыкларның зыялылары, уңай үзгәрешләрдән файдаланып, милли мәнфәгатьләрне кайгырту, мәдәниятләрен үстерү турында җитди уйлана башлыйлар. Тормышны аек бәяләү рухы, тәнкыйди караш яңа бер дулкын булып Ә.Еники, Р.Төхфәтуллин, Н.Фәттах, Х.Сарьян, А.Гыйләҗев, Г.Ахунов, М.Мәһдиев, Ф.Шәфигуллин, Ф.Баттал иҗатларына өстәмә көч бирә. Сугыштан соңгы чорда әдәбиятка үтеп кергән ясалма, идеал, хыялый каһарманнар, ялган мохит, барабаннар кагуны хәтерләткән гимннар кире кагылып, халыкта өмет, көрәш дәрте уятырдай әсәрләргә ихтыяҗ туа. Яңартылган тәнкыйди реализмның беренче карлыгачларыннан, совет режимының башбаштаклыкларына бәя бирү яссылыгыннан караганда, һичшиксез, А.Гыйләҗевнен «Өч аршын җир» (1962) повесте аталырга лаеклы. Язучы яшәеш вә табигать кануннарын ихтыяр белән генә үзгәртеп булмавын, кеше гомеренең фанилеген, күпме генә сикеренсәң дә, өч аршын җирнең һәммәбезне тигезләвен, бәлки, үзе дә аңлап җитмәстән, бөтен гаҗизлеге белән искә төшерде.

Алтмышынчы елларда барлыкка килгән әдәби «шартлау»ны (М.Кәрим сүзе) бәяләрлек тәнкыйтьчеләр кирәклеге сизелә. Шул ихтыяҗ Казан арты егете, Арча педагогия көллиятен (шул атаклы уку йортында Г.Ахунов, М.Мәһдиевләр белем ала), Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлаган Фарваз Миңнуллинны «эзләп таба». Дөрес, ул чорда татар әдәбияты тәнкыйтьчеләргә бай була. Бер үк чорда диярлек һәркайсы үз урынында Н.Юзиев, З.Мәҗитов, Р.Мостафин, Р.Сверигин, М.Вәлиев, Р.Мөхәммәдиев, бераз соңрак Р.Кукушкин (Рахмани), Мөдәррис Вәлиев, Ә.Мәхмүдов кебек әдәби сүзгә сизгер көчләр килә, «саф» әдәбият галимнәре Н.Хисамов, Ф.Галимуллин, А.Әхмәдуллин, Ш.Садретдинов, Р.Ганеева, Ф.Хатипов, М.Бакиров, Х.Миңнегуловлар да тәнкыйтьнең «кирәкле шәйдер» икәнен танып, агымдагы әдәби барышка катнашып китәргә «мәҗбүр» булалар.

Тәнкыйтьчеләрне үз артыннан ияртеп, әйдәп баручысы, әдәбиятның бу авыр төренә аяк баскан яшьләрне хуплап, хәлдән килгәнчә ярдәм итеп яшәүчесе Ф.Миңнуллин була. Хезмәт урыннары да жанр үсеше өчен җаваплылыкны тудыра кебек. Әүвәл ул «Казан утлары» журналының тәнкыйть бүлеген җитәкли, шактый еллар дәвамында Язучылар берлеге рәисенең иҗат эшләре буенча урынбасары, Татарстан китап нәшриятының әдәбият бүлеге мөдире, шул ук оешманың директоры урынбасары (баш мөхәррире)... язучылар, тәнкыйтьчеләр ничек кенә «уфтанмасыннар», аны сикереп үтә алмыйлар, һәммәсе күз уңында... Проза белән шигърият үсешен күзәтеп, җитәкләп барырдай затлар җитәрлек, тәнкыйть үзе дә кайгыртуга, игътибарга мохтаҗ дип саный гыйззәтле Фарваз әфәнде.

Тәнкыйтьчеләр арасыннан рус һәм татар телләрендә югары дәрәҗәдә

язу сәләтенә ия, бигрәк тә Җәлилне дөньяга танытуга зур өлеш керткән Р.Мостафинны күтәреп куюы Ф.Миңнуллинның акны карадан аера белүе турында сөйли. Әйтерсең лә, Р.Мостафин сонрак түгел, ә Фарваз яшәгән чорда ук Тукай бүләгенә лаек булган («Тәнкыйтьче бәхете»). Үз чорында иҗатка килгән һәр тәнкыйтьченең Ф.Миңнуллин кабатланмас, ана гына хас үзенчәлеген эзли («Әдәби тәнкыйтьнең яңа көчләре»). «Р.Кукушкин... мәкаләләрен фәнни, салмак стиль белән яза. Чәчелми, таралмый, бер генә өлкәдә басылып эшләргә ярата». «Мансур Вәлиев — эмоциональ тәнкыйть тарафдары. Дәлилләп бирүдән, анализдан бигрәк, ул еш кына хис белән, кайнарлык белән алдыра» (ул аның сонрак прозаик булып китүен аклаган сыман).

М.Вәлиевне үзе үстергән, тәнкыйть дилбегәсен кулына тапшырырга лаеклы алмаш санап, Фарваз горурланып, тышкы охшашлыкны да исәпкә алып, уенын-чынын бергә ялгап, «татарның Белинские» дип тә җибәргәли иде (дөрес, соңгы вакытта «пәйгамбәр» шагыйрьләр, «белинскийлар» күбәебрәк китте. Монда да Ф.Миңнуллинның тормадай ачы теле җитмәве сизелә). Шагыйрь, тәнкыйтьче, нәшир Мөд.Вәлиевкә бирган бәясе дә хәзергәчә иң төгәле булып кала. «Мөдәррис Вәлиевнең күпчелек мәкаләләре әдәби әсәр кебек укыла. Ул... чын мәгънәсендә сәнгатьчә тәнкыйть тарафдары».

Агымдагы тәнкыйтькә багышланган мәкаләсенең соңгы юллары хәзергәчә заманча яңгырый һәм уйландыра. «Язучы хезмәте — авыр хезмәт. Тәнкыйтьче хезмәте — тагын да авыррак. Әдәбиятны урта кул язучылар һәм урта кул әсәрләр басып китмәсен өчен, кыю һәм принципиаль тәнкыйтьчеләр кирәк». Бу таләп безнең көннәрдә чүп үләннәре кебек үскән үзешчән нәшриятләрдә, үзешчән такмакчылар чыгарган китаплар дөньяны басып киткәндә аеруча актуаль яңгырый. Хәзерге тәнкыйтьтә дә әле һаман Ф.Миңнуллинның чордашлары, аның фатихасын алып калган шәхесләр әйдәп баручы көч булып калалар. Дөрес, кайбер яшь әдәбият галимнәре, бигрәк тә хатын-кызлар, ул-бу булмасын дип, оялып, ярһенеп, як-якка каранып кына тәнкыйтькә кереп чыккалыйлар (Й.Нигъмәтуллина, Д.Заһидуллина, Н.Йосыпова, Г.Гайнуллина, һ.б.). Агымдагы тәнкыйтьтә хәзер комплиментарлык, чама белмичә мактау рухы өстенлек итә. Бу бигрәк тә «син миңа, мин сиңа» принцибыннан чыгып язылган, бер-берсен мактауга, тәкъдир итүгә корылган язучылар тәнкыйтендә өстенлек итә. Дөрес, мәрхүм Ф.Бәширов, Х.Бәдигый, Ә.Закиржанов, И.Вәлиулла кебек Ф.Миңнуллин юлын дәвам иттерүчеләр күренгәли. Кызганычка каршы, талантлы, фәлсәфи фикерле И.Вәлиулла иҗатында мажор төсләр, мәдхия өстенлек итә. Ул һәр шагыйрьдән «дәрья» ясап, тынычландырып, сугышчан рухны, эзләнүләр кинлеген тарайтуга гына этәрә. Иманым камил: Фарваз абыйсы аңа мондый киңәшен бирер иде: «энем, көмеш талантыңны әрәм-шәрәм итмә, мактау бер көнлек, туры сүз — мәңгелек».

Ф.Миңнуллинга С.Хәкимнең дә, шигърияттеннән бигрәк, тәнкыйть өлкәсендәге эзләнүләре якын («Чишмәләргә юл ачык...»). Тәнкыйтьче Сибгат аганың Тукай иҗатының, шәхесенең берәү дә игътибар итмәгән якларын ачуы; өлкән шагыйрьнең өметле яшьләрне вакытында күреп, танып алуы, ярдәм кулын сузуы, көч-куәтен дөрес бәяләп, юнәлеш бирүе, юл күрсәтүе сокландыра.

Моннан әле Ф.Миңнуллин тәнкыйть вә проза турында гына язып, шигъриятккә битараф булган дигән фикер калырга тиеш түгел. Ул ифрат самими, шигъри җанлы шәхес иде. Матур, ямьле табигате белән без ишетеп, укып белгән, Швейцарияне хәтерләткән Арча районына кергән Ишнарат авылында бары тик шагыйрьләр генә туарга тиеш кебек. Шагыйрьлек матурлыкны, табигыйлекне, ипле яктылыкны, миһербанлылыкны эченә алган төшенчә һәм ул шигырь язудан киңрәк мәгънәгә ия.

Кызы Йолдызның үзенчәлекле шагыйрә булып үсеп килүендә анасының (Асия Минһаҗева) яшьлегендә шигырьләр язуы гына түгел, ә әтисенең сизгер йөрәкле, югары интеллектлы, мәгърифәтле шәхес булуы да тәэсир иткәндер. Тик талантлы кызыбызга М.Цветаеваның артык элитар булып кыйланган шигърияте йогынтысыннан арынып, ясалма юлдаш хәлендә калмас өчен, милли нигезләргә якынлашу турында уйлыйсы бар кебек. Атасы өчен бердәнбер якты маяк та, шатлык вә кайгы чыганагы да халык язмышы иде бит.

Ф.Миннуллин сүз сәнгатенең бу төре турында язганда белеп, аңлап, олы шагыйрьләр алдында баш иеп, үрнәк алып фикер йөртте. «Җыр йөрәктә туа...» мәкаләсендә ул Х.Туфанны үзәккә ала һәм игътибарын шагыйрь иҗатының әхлакый сафлыгын, хисси тирәнлеген ачуга юнәлтә. Нәтиҗәсе катгый һәм ачык: «Тукай, Такташлардан соң, Туфан безнең поэзиянең байрагы булып барды. Җир шарын учына тотып сөйләшә алырлык бүтән шагыйрьне безнең поэзия хәзергә белми». Берничә битлек мәкаләнең язылу чоры итеп 1966 — 1983 еллар куелу да Фарвазның фикерен үзгәртмәве, әхлакый пафосыннан читкә чыкмавы турында сөйли.

Ф.Миннуллин мирасының иң зур өлеше прозага, аның шанлы тарихына һәм хәзерге торышына багышланган. «Якты юллар» исемле XX гасыр татар прозасының үсеш чорларын тәфсилләгән күләмле мәкаләсендә әдәбиятыбызның иң күркәм сыйфатлары итеп миллилекне, матурлыкка соклана белүне, миһербанлы, изге күнелле, әкиятләргә ышанучан, һәр вакыйга-хәлгә фәлсәфи бәя бирүгә сәләтле кешене алга чыгаруны, телебезнең матурлыгын, сыгылмалы көчен саклый, үстерә белүне саный. Әдипне татар әдәбиятында хатын-кызларыбызның тыйнаклык, эш сөю, бөтен барлыгын гаиләсенә, балаларын үстерүгә багышлаган образлар тудыра белүе әсир итә. «Безнең әдәбият үтә ягымлы, тулы канлы, һәркемгә үрнәк булырлык хатын-кыз образларына бай. Г.Кутуйның Галиясе, Г.Бәшировның Нәфисәсе, Р.Төхфәтуллинның Гөлзифасы... Күп алар... Минемчә, безнең әдәбияттагы бу мөлаем, тулы канлы образлар галереясын башлап җибәрүчеләр Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимовлар булды. «Акчарлаклар»дагы Газизәсе, «Матур туганда» романындагы Мәдинәсе белән Ш.Камал булды».

Ул аеруча яратып, белеп, тирәнгә төшеп, И.Гази, Г.Бәширов, Г.Әпсәләмов, К.Нәҗми кебек өлкән буын прозаиклары иҗатын тикшерә. Ә.Еникигә багышлаган мәкаләләренең исемнәре үк тәнкыйтьченең зәвыгы, язучы иҗатының төп үзенчәлекләрен сиземләп алуы турында сөйли: «Намус эше» (1964-1983), «Затлылык» (1989). Татар дәүләт гуманитар педагогия университеты уздырган фәнни-гамәли конференциядә дә, Милли китапханәдә узган искә алу кичәсендә дә (язучының тууына 100 ел тулу уңае белән) бик күп чыгыш ясаучылар Ә.Еники прозасына, публицистикасына хас төп сыйфат итеп «затлылык»ны атадылар.

Ф.Миннуллин Х.Камалов, Р.Төхфәтуллин, М.Мәһдиев, А.Гыйләҗев, Ә.Баянов кебек шул чор татар прозасын җигелеп тартучы чордашларының әдәби портретларын тудыра, яшьләргә дә төпле киңәшләрен биреп бара. Тәнкыйтьче бер мәкаләсендә дә тоташ мактау, мәдхия яудыру юлына басмый, уңышлы якларны күрү белән берррәттән, җитешсез, килешеп бетмәгән тарафларга игътибар иткәндә, автор киләчәктә тагын да камилрәк әсәрләр тудыра алсын дигән ният белән яза. Җөмләдән, Ә.Баяновның «Яшьлегемне эзлим», «Аязучан болытлы һава», «Дүрт монолог», «Тавыш — табигать бүләге» кебек повестьларына тулаем уңай бәя биреп, «Әхсән Баянов — тормыштагы, әдәбияттагы яңалыкларга аеруча сизгер язучыларның берсе... ул заманча уйларга, алай гына да түгел, заманча яшәргә... ярата» дип яза да, «Ә.Баянов әсәрләренең ышандыру көче йомшаграк булуын да әйтеп

узарга кирәк. Ул үз геройларының эш-хәрәкәтләрен, бер халәттән икенче халәткә күчүләрен мотивлаштыруга тиешле игътибар биреп житкерми», дип өсти дә, «Яшьлегемне эзлим» повестеның төп герое Әнис Бәдигинны кабул итмәгән каләмдәшләре белән бәхәскә керә, «повестьның төп герое, М.Маликова һәм А.Гыйләжевлар уйлаганча ук, беткән кеше түгел. Аның күнелгә ятышлы эшләре, унай сыйфатлары байтак».

Мәкалә 1983 елда язылган. Үткен пәкедәй кистереп ала торган теле һәм язучылык абруе белән шөһрәтенең үренә күтәрелә килгән чорында Аяз абыйга каршы сүз әйтергә жөрьәт иткән, аның белән килешмәгән башка затны хәтерләмим. Ә Фарваз өчен төп үлчәү берәмлеге үзенең сиземләве, үз аршины иде. Икенчедән, ул берәүгә дә ярарга тырышмады, лакей түбәнлегенә төшмәде. Икенче мисал да гыйбрәтле.

Х.Камаловның 1941-1945 еллар сугышын тасвирлауга багышланган әсәрләре шул чорда «ура»га кабул ителмәде, «бытовизм һәм натурализм» артык урын алган дип чыгучылары да табылды. Ф.Миңнуллин ике зур дәүләт арасында барган тартышу героикадан һәм романтик батырлыклардан гына тормады, бу сугышны белорус язучысы В.Быков, В.Некрасов, В.Гроссман кебек бөтен фажигале дөреслеге белән сурәтләү вакыты житте дип авторны полемик дәрт белән яклап, мактап чыкты. Кыскасы, тәнкыйтьче замана таләпләренә жавап биргән, үзенә ошаган әсәрләрне рәнжетүгә юл куймады. Күренекле тел галиме, әдәби процесста актив катнашкан профессор Латыйф Жәләй А.Расихның «Ике буйдак», Н.Фәттахның «Бала күнеле далада», Э.Касыймовның «Гомер ике килми» (1964 елда дөнья күргән) әсәрләрен «романның киртәсенә керү түгел, хәтта ул киртәнең янына да килмәслек» чәчмәләр дип бәяли *(«К.У.» 1969. № 11. 183 б.)*. Ф.Миңнуллин исә өчесен дә «прозабыз үсешендә күпмедер эз калдырган әсәрләр «Ике буйдак»ны әле хәзер дә әдәбиятыбызның бер казанышы дип йөртәбез», дип үз сүзен әйтеп, тәнкыйтьче «фикерләрен иплерәк итеп» тә яза ала иде дигән теләк белдерә.

Ә инде роман жанрының гомуми үсеш дәрәжәсе аны тәшвишкә сала. «60нчы елларда егерме бишләп роман язылган булса, 70-нче елларда чыккан романнарның саны да шул чаклы ук. Иң нык борчыган мәсьәлә — аларның сыйфаты... Татар романы акрын гына, сиздерми генә тарая, сыегая, вакланa бара», дип яза һәм сокланырлык әсәр итеп Н.Фәттахның «Сызгыра торган уклар» романын «халык әкиятләре кебек мавыгып укыла торган шәп роман булып чыккан. Калганнары турында жылы сүз әйтүе кыен», ди. Ә бит сүз А.Расихның «Ямашев» (1982), М.Хәсәновның «Шөгеревлар» (1980), Ш.Бикчуринның «Тирән катлам» (1981), М.Хәбибуллинның «Сулар үргә акса да» (1982), М.Маликованың «Ак давылда тал бөресе» (1983), Ә.Баяновның «Таш китап» (1983) кебек XXI гасыр башында да укыла, беришесе әдәбият дәреслекләрендә урын алган әсәрләр турында бара. Ф.Миңнуллин сыйфат бизмәнен бик югары күтәреп куя, татар әдәбиятының бөтен төрки, Идел-Урал буе халыклары өчен кайчандыр үрнәк-өлге булып торган чорыннан кайтышрак үсмәвен тели, шуны таләп итә. Ул әдәби әсәрләргә бәя биргәндә әшнәлек, мәжлестәшлек, мәсләктәшлек кебек хисләрне рухына үткәрми, ягъни аны «сатып алып» булмый иде. Гел бергә аралашып, дуслашып, соңгы тиеннәренә чаклы бүлешеп яшәгән Г.Ахунов, А.Гыйләжев, М.Мәһдиевләрнең яна әсәрләренә дөрес бәяне, матбугатка чыгармаган очракта да, күзләренә карап әйтүдән тартынып тормады. Иреннәрен бераз кыйшайтып, азау тешен суырдымы, «күк күкрәвен» көт тә тор. Шул ук вакытта Фарваз чын дуслыкның кадерен белә торган, таяныч, терәк булырдай шәхес иде.

Тәнкыйтьченең мирасы күләмле була алмый. Үзе исән чакта нибары дүрт

җыентыгын чыгарып кала алды. «Балта явызлар кулында» исемле соңгы китабына (исемне А.Гыйләҗевнең «Балта кем кулында?» исемле романына җавап рәвешендәрәк алган) миннән кереш сүз язуны сорады. Мин, әлбәттә, мондый тәкъдимне үземә мәртәбә, ышаныч санап, ризалаштым. «Озын итеп, артык фәнниләштереп язма, яме, мәҗлестә тост әйткән шикелле генә булсын» дисә дә, аның иҗатын берничә җөмләгә сыйдырып булмавы көн кебек ачык иде (мәҗлес яратучылар тостны да сәгатькә сузарга мөмкин). Мәкалә озынрак чыкса да, күңеленә хуш килде кебек. Китабын үзе күреп калды, әмма имзасын куеп бирә алмады. Башка җыентыкларын дустанә сүзләр белән бүләк итә килде.

1984 елда басылган «Талантлар юлы» китабын түбәндәге юллама белән тапшырган иде. «Тәлгат! Без начар яшәмәдек. Гомернең калган өлешен дә шулай яши алсак иде, дигән өмет һәм теләк белән Фарваз. 7.02.85».

Бу шәхси язмадан да тәнкыйтьченең тормышыннан канәгать булуын, байлыкка, сарайларга дәгъва итмәвен, рухи торгынлык кичермәвен сиземләп була. Фарваз матди кыенлыкларны аз күрмәде. Икенче гаилә коргач (үзәктәге фатирын, тыйнак кына бакчасын, булган җиһазларын беренче хатынына бәхәссез, дәгъвасыз калдырып чыкты. Чын егетлек үрнәге!), кеше өендә дә түләп яшәде, әмма беркайчан зарланмады, сорамады, ялынмады. Немецлар Фарвазны «характер нордический», дип бәяләрләр иде. Кырыс булырга тырышып караса да, эчке дөньясы, җаны аның гаять ихласи вә кешелекле иде. Туганнарына, энесе Маликка, балаларына җылы, кайгыртучан мөнәсәбәте күбебезгә үрнәк булырлык. Бу яктан ул чын татар баласы иде.

Шул ук вакытта ул курыкмыйча, түрәләр алдында тез чүкмичә, ышанычыннан чигенмичә яши белә торган үҗәт вә күпмедер дәрәҗәдә «бесшабашный» гайрәтле шәхес булып күнелдә калды. Иң кыен хәлләрдә, обкомга «келәмгә» чакырылганда (Язучылар берлеге рәисе Г.Ахунов обкомның бүлек мөдире яисә секретарь ми «юарга» дәшкәндә, юмалап Фарвазны җибәрә торган иде), хәтәр сөйләшүләр вакытында да минлегән югалтмыйча, мөстәкыйльлеген сатмыйча, үзе булып кала алды. Чөнки ул халкының, бигрәк тә язучыларның мәнфәгате, ихтыяҗы белән яшәде, иң югары мөнбәрләрдә дә үз сүзен бирмәде. Шул чорда мәдәният җитәкчеләренең котын алып торган, иң хәтәр цензор, обкомның культура бүлеге мөдире Мусинга «Мөдәррис Мусинович, сез бу әсәрнең юнәлешен, автор фикеренең тирәнлеген дөрес аңламагансыз», дип бары тик куш йөрәкле Фарваз гына әйтә ала иде. Аның өчен иң мөһиме милләт гаме, аерым кеше, каләм иясе кадере иде. Шул иманы ана көч, куәт, дәрт биреп торды.

Тәнкыйтьченең нигездә социалистик реализм кануннары өстенлек иткән чорда язылган мәкаләләре, бәяләре, фәлсәфи-эстетик карашлары искермәдеме, шул чор истәлеге булып калмадымы дигәнрәк сорауның тууы да ихтимал. Үзе дә «тәнкыйть — тиз искерүчән жанр» дип ычкындырды. Шуны онытмыйк: вакыт сынавын үткән талантлы хезмәт үз чорының догмаларыннан өстен тора, вакыт сынавына бирешми, карашлар үзгәрүгә карап искерми. Аристотельнең «Поэтика»сын, Буало, Гегельләрнең әдәби төрләр һәм жанрлар турындагы өйрәтмәләрен искә алып тормастан, В.Белинскийның, Җ.Вәлидинең, Х.Госманның, И.Нуруллинның, Н.Юзиевләрнең әдәби барышка, мирасыбыз тарихына ясаган сәяхәтләре, шигырь төзелешенә багышланган хезмәтләре искерде дип расларга кемнең теле әйләнер. Дөрес, Ф.Миннуллин мәкаләләрендә бинар оппозиция, экзистенциализм, интертекстуальлек, мегатекстуальлек, дискурс, нарратив, хәтта герменевтика кебек Көнбатыштан инеп, рус әдәбият белеме аша безгә кергән атамаларны тапмассың. Мәгәр игътибар белән укысаң, әлеге

терминнарның эчтәлеген, мәгънәсен кешечә, саф татар телендә аңлатып бирүен чамалау кыен түгел.

Аның реализм, романтизм, натурализм кебек төшенчәләргә, өслүбләр төрлелегенә, эчтәлек белән сәнгатьчә фикерләү алымнарының ярашуына биргән бәяләре XXI гасыр башында да заманча яңгырый. Купшы җөмләләрне, буш сүзләрне, томан җибәрүне яратмады Фарваз. Ул ачык фикер, төгәл сүз тарафдары иде.

Ф.Миңнуллин безнең көннәргәчә яшәсә, хәзерге прозага ниндирәк бәя бирер иде икән дип озак уйланып утырдым. Әлбәттә, ул М.Галәү, Н.Фәттахлар сызган ызанны дәвам итеп, халкыбызның фаҗигале тарихын дөрес яктыртуга алынган М.Хәбибуллин, Р.Батулла, Ф.Латыйфи, В.Имамов эзләнүләрен хуплар, өлкән буын прозаикларыннан М.Әмирханов, З.Зәйнуллиннарның кыюлыкларын бәяләр, урта һәм яшьрәк буыннан А.Хәлим, Г.Гыйльманов, М.Галиев, К.Кәримов, Ә.Гадел, З.Хөснияр, Р.Зәйдуллаларны аерып куяр, хатын-кызларыбызның ирләр кызыгырлык кыю эзләнүләрен хуплар иде кебек. Ә инде ике аяклы, җанлы, мөлаем кешеләребезне әдәби сәхнәдән кысып чыгара барган албастылар, убырлы карчыклар, канатсыз акчарлаклар, оча торган кешеләр, бичуралар, сары йортлар даирәсе азау тешне суыртмый калдырмас, «егетләр, безнең арабызда тере кешеләр калмадымы, дөньябызны хәшәрәтләр бастымы», дип өстәп куюдан да тартынып тормас иде. Чөнки ул иҗади гомере буенча татар прозасыннан халкыбызның гасырлар буена чарлана килгән милли үзенчәлекләрне, кояш нурларын үзенә сеңдергән чәчәкләр кебек җыеп алган, үрнәк-өлге булырдай тулы канлы геройлар эзләде, үз чорында ук уй-өметләре көнкүреш ыгы-зыгысын, гаилә низагларын сурәтләүдән өскә күтәрелә алмаган, зәвыксыз укучының кытыгында уйнаган әсәрләрне кабул итмәде, куркак, ялагай, басынкы, буйсынучан, кол халәтенә риза булып яшәгән язучыны да, әдәби персонажны да бусагадан кире какты.



*Уңнан сулга: Ә.Еники, И.Нуруллин, Т.Галиуллин. Алабуга, 1983.*

Фарваз табигать биргән сәләтен иҗтимагый тирә-җирлектән таптатмыйча, үз позициясен бирмәгән хәлдә дә (марксизм теориясенә артык мөкиббән китмәүдә гаепләгән профессор Х.Госман белән бәхәскә керүе, шуның аркасында ярым әзер диссертациясен тәмамламыйча аспирантурадан китүе дә мәгълүм. Үз иманында, сайлаган юлында камил шәхес булып кала алды.

Тукай «Мөхәрриргә» (1913) шигырендә Г.Исхакыйга мөрәҗәгать итеп, татар җәмгыяте «Алты ел торды чупансыз (житәкчесез, көтүчесез), аерылышты яшь көтү, Карт бүре күк, бары корган аерым-аерым бер оя», дип яза. Татар тәнкыйте инде 15 елдан артык «чупансыз», җитәкчесез яши. Берәү дә бу авыр йөкне иненә салырга җыенмый.

Фарваз тормышының соңгы елларында аеруча бер үҗәтлек белән эшләде. Үзе дә күп язды, татар теленә берничә роман да тәрҗемә итте, нәшриятта

эчтәлеге буенча унай бәя алмыйча тоткарланган бик күп әсәрләрне (Х.Сарьян, Н.Фәттах, С.Баттал, Ф.Шәфигуллин һ.б.) халыкка ирештерде. Ник шулай ашыгасың дигәч, «безнең нәселдә алтмыштан узып яшәгән ир-ат булмаган, эшләп калырга кирәк», кебек сүзләре шомлы кисәтү булып һаман колакта тора. Жанның иң тирән катламыннан сыгылып чыккан юксыну хисе якты монга уралып әйләнеп кайтып йөрәкне яралый. Без сине онытмадык, онытмабыз, Фарваз дус! Эшләгән эшләрең, изге гамәлләрең дога булып барсын!

## Татарда зыялылар бармы?

Туган халкының мәгърифәте, әдәбияты, үзаңы башка милләтләр дәрәҗәсеннән калышмаска тиеш дип янып-көеп яшәгән Мәһдиев кимчелекләребезне дә яшермичә, рухи халәтебезгә анык бәя бирергә омтылды; иҗтимагый фикерне уятып, болгатып, бер-беребезне «селкетеп» алу ихтыяҗын сизеп яшәде. Бу җәһәттән аның шул чорда күп чыш-пышлар уяткан, кемнеңдер авырткан сөяленә баскан, авторны берьяклылыкта, дөреслекне бозып күрсәтүдә, уңай үзгәрешләрне күрмәмешкә салышуда гаепләүләргә хәтле җиткергән «Татар зыялысы... Ул — кем?» мәкаләсе булды. *(Казан утлары. 1993. № 10. 142-146 б.).* Автор үзенә таяныч ноктасы итеп Тукайның «Бәгъзе зыялыларыбыз» исемле шигырен ала. «Татар халкы арасында» зыялыларыбыз «хисапсыз күп» булса да, вөҗданлы, кешелекле, намуслы затлар бик аз дигән фикер уздыра бөек шагыйребез.

Мәһдиев остазы белән тулысынча килешеп кенә калмый, хәвефле соравына җавап эзләп, арттырып та җибәрә: «бүген татар зыялысы юк». Үзләрен айдынга санап йөргән кемсәләрнедер рәнҗетүдән, җайсыз хәлгә куюдан курыкмыйча, кыю һәм кискен итеп ясаган нәтиҗәсенең эчтәлеген Мәһдиев үзе үк ачып бирә. Юк, сүз аерым шәхесләрне тырышмауда, ялкаулыкта, булганы белән канәгатьләнеп яшәүдә гаепләү турында бармый. Җавапны ул фаҗигале, алдынгы затларыбызны, морзаларыбызны юкка чыгаруга корылган тарихи үткәнебездән эзли. Русиягә көчләп кушылган милләтләрнең алдынгы, белемле, нәселле катламы системалы рәвештә юкка чыгарыла барган. Чөнки алар империянең яшәешенә зарарлы саналганнар. Бары тик XX гасыр башында, беренче рус революциясе нәтиҗәсендә генә, татар җәмгыятендә яңа зыялылар катламы күтәрелә. Күренекле дин әһелләре, аларның балалары, укымышлырак кешеләр яңа туган мөмкинлектән файдаланып калырга ашыкканнар.

Сәүдәчелекнең, эшмәкәрлекнең киң колач алуы мәгърифәтнең көчен, кадерен белүче байлар катламын күтәргән. Әмма 1917 ел октябрь инкыйлабы хакимияткә китергән коммунистлар патша самодержавиясеннән дә уздырып, хәлле, аңлы, зыялы кешеләрне, дин әһелләрен физик юк итү, рухи имгәтү шөгыленә керешәләр. Татарның шактый югарылыкка ирешкән, камил мәгърифәт системасы тар-мар ителә, сытыла, җимерелә. Мөмкинлекләре булган укымышлылар чит илләргә чыгып китү ягын караганнар. Мөһаҗирлек язмышын сайлаган Г.Исхакый, Й.Акчура, С.Максуди, Г.Баттал Таймаслар рус, төрек, француз, алман, инглиз, гарәп, фарсы телләрен белгәннәр. Аларны М.Мәһдиев чын зыялылар дип атый. Туган илләрендә калган Г.Гобәйдуллин, Г.Сәгъди, тарихи романнарын үзе тәрҗемә итеп, Мәскәүдә генә бастырып чыгара алган М.Галәү шикелле зыялыларыбызны совет хөкүмәте физик юк итә яисә кимсетә, изә, кешечә яшәргә бирми.

Мәһдиевнең кырыс җиз иләге аша күренекле татар прозаигы Г.Ибраһимов та үтми, ягъни зыялылыкка куелган таләпләргә җавап бирә алмый. Үзе табынган коммунистлар режимы тарафыннан юкка чыгарылган әдип татар халкының үзаңы уяна, үсә килгән чорда, милли янарыш байрагы Г.Тукайга

аяк чала, шигъриятенең әһәмиятен кимсетеп күрсәтә, Г.Гобәйдуллинга, бигрәк тә Г.Исхакыйга каршы ямьсез мәкаләләре белән чыга. Туган халкының алдынгы шәхесләренә күсәк күтәргән адәм интеллигент дигән югары исемгә лаек була алмый. Бу сынауны «үтү» хәтта Тукайга да җинел булмый. Яшьлегендә сатирик журналларда Фатих Кәрими, Габдрәшит Ибраһимов, Исмәгыйль Гаспринский кебек мәгърифәт йолдызларын, халкыбызның бөек улларын чеметкәләп алгалаган өчен ул Тукайны да тәнкыйтьли.

Дөрес, тормышны, җәмгыяви мөнәсәбәтләрне тирәнрәк аңлый барган саен Тукайга «прозрение» (күз ачылу) килә. Иҗатларын таныган тәкъдирдә дә, җибәргән хаталары өчен, К.Тинчурин, Г.Камалларга да зыялылар киштәсендә урын табылмый.

Интеллигентлыкны рус кешесе төшенчәсе белән тәңгәлләштерүне дә автор кабул итми һәм бу фикерен раслаучы дәлилләрен китерә. «Татарны канга батырып, чукындырып йөргән православие миссионерлары интеллигент булганмы? Юк, интеллигент ул — кешене, аның динен, телен, гореф-гадәтләрен ихтирам итүче кеше... интеллигент татарда гына түгел, русның үзендә дә юк», дигән катгый карарга килә әдип. Хәзергесе көндә зыялылыкка тулы җавап биргән затны эзли башлагач, ана ифрат югары таләпләр куйган авторның бөтенләй кәефе кырыла. Үз чорыбыздан ул айдын дип атарлык шәхесне тапмый. «Безнең буында булмады инде ул зыялылар». Кискен, кыю, утны үз өстенә алуга исәп тоткан бәянең күпләргә ошамасын, дошманнарын арттырасын белеп, үҗәтләнеп яза Мәһдиев. Үзләрен татарның алдынгы затлары дип санап йөргән бериш профессорлар, язучылар, журналистлар «яла ягучыга» фикерләрен җиткерүгә ышанып, «Мухаммат глубоко не прав», «булганны күрә белми, уңышларны күрергә теләми», дип, канәгатьсезлекләрен белдерергә ашыктылар. Мәкаләсен хуплау белән беррәттән, төрлечәрәк бәяләрнең булуын ишеткәч, Мәһдиевнең сөенеченнән кулларын чәбәкләп, авызын җыя алмыйча, шатланганын күрсәгез иде! Искәндәре флот хезмәтеннән исән-имин кайткач кына шулай түбәсе күккә тигәндер.

— Димәк, мәкалә вакытлы язылган, тәнкыйть урынлы. Һаваланып, борын чөереп, «мин кем» дип йөреп кенә интеллигент булып булмый. Черчилльнең бер сүзен онытмасыннар иде иптәш-әфәнделәр: зыялы дип аталыр өчен синең бабаң, атаң һәм үзең Сорбонна йә Кембридж университетын тәмамлаган булырга тиеш.

— Англиянең бөек шәхесе, бөтенләй үзгә мохиттә яшәгән, аның күзаллавы, таләпләре безгә килеп бетми торгандыр? Ә чит телләрне, дөнья мәдәнияте казанышларын үзләштерә алмаган, мөмкинлеге булмаган татар кешесенә ничек зыялы буласы? — дигән соравыма ул тиз генә җавап бирмәде. Моңсуланып калган күзләрен зәңгәр офыкның бер читенә төбәгән Мөхәммәт минем «янда» түгел иде. «Әллә инде күкләр белән киңәшә», дип, уйлау гөнаһысына керә яздым.

— Язмышыннан канәгать булып яши белгән, үз өстендә туктаусыз эшләгән кеше зыялы санала ала.

Бу сөалемнең артыклыгын аңлаган хәлемдә дә тыела алмадым.

— Син үзеңне зыялы кеше саныйсыңмы?

— Мин киттем. Ярты сәгатьтән дәресем башлана.

Соравыма вакыт тулы җавап бирде дип саныйм.

Мәкаләсенең ахырында интеллигентлык төшенчәсен Мәһдиев олы сәясәт, милләтнең язмышы белән бәйли. «...милләтебез киләчәктә бу катлауны эшләп чыгарырга тиеш. Зыялылары булмаган көе Татарстан дәүләте яши алмаячак».

Мәһдиев татар халкының киләчәгенә, дәүләтчелеген өлешчә булса да кайтара алуына ышанычын югалтмыйча арабыздан китте. Вакыт аның зыялылар катламын булдыру өчен чаң кагуының урынлы һәм кирәкле булуын раслады. Акыллы, белемле көрәшчеләр, зыялы җитәкчеләр җитешмәү нәтиҗәсендә (әлбәттә, сәбәпләре күп) без 90 нчы еллар башында ирешкән милли казанышларыбызны югалттык, мөстәкыйльлек учакларыбызны сүндердек.

«Татар зыялысы... Ул — кем?» мәкаләсе янә бер тапкыр Мәһдиевнең «коеп куйган прозаик» кына булмыйча, гражданин, ватандар, сәясәтче икәнлеген раслады.

Үләренә берничә ай калгач, ул күп кырлы иҗатына мәгълүм бер йомгак ясагандай, болай дип язган иде:

«Өендә гел язып кына утырган язучы минем хәтле язмый. Минем бигрәк тә соңгы елларда газета-журналларда 80-88-90 мәкаләм чыга барган. Ул кадәр күләмдә сирәк журналист яза. Шулай итеп, 65 елда бер журналист гомерен кичергәнмен. Без белгән күп кенә кешеләр бернинди фәнне эшләмичә, бернинди әсәр язмыйча бер доцент гомерен кичерделәр. Өчесен бергә кушсаң, 195 ел килеп чыга... Шулардан тора минем гомерем» («Миңа 195 яшь (М.Мәһдиев үзе турында»).

М.Мәһдиевнең ирониясенә, бериш коллегаларына нечкә итеп төрттерүенә «скидка» ясаган хәлдә дә, аның публицистик һәм фәнни эшчәнлегенең гаять тирән һәм күпкырлы булуына сокланмыйча калу мөмкин түгел. Аны М.Горькийның татар әдәбиятын бәяләве, йогынтысы борчый («Давыл хәбәрчесе — Иделдә» (М.Горькийның тууына 120 ел), чит илләрдә татар халкына, фольклорына мөнәсәбәт кызыксындыра («Европа — безнең хакта»).

Кем нәрсә турында гына язмасын, М.Мәһдиев кыйбласына тугрылыклы, халкыбызда ирекле яшәү рухын тергезү, коллык психологиясеннән арындыру, телен саклау өчен мәгърифәтле, олы җанлы зыялылар кирәклекне үзәктә тота. Аның «Ачы тәҗрибә» истәлекләр китабында, хатларында, әдәби әсәрләрендәге чигенешләрендә әледән-әле З.Камали, Һ.Атласи, Ш.Мәрҗани, Җ.Вәлиди, Г.Гобәйдуллин кебек бөекләребезне сагынып, юксынып язуыннан хәзерге галимнәребез, язучыларыбыз арасыннан милләтне үз артыннан ияртеп барырлык зыялылар катламын күтәрү турындагы хыялы калкып чыга.

## «Синнән башка хат язар кешем юк икән»

*Кадерең барда — кадерлән.*
*Кадерең беткәч, кабереңә әзерлән.*
М.Мәһдиев.

Бу гаять тирән мәгънәле, яшәеш фаҗигасен чагылдырган гыйбарәне Мәһдиев каядыр ишеткәнме, укыганмы, әллә үз күзәтүләренә нәтиҗә ясаганмы, анысы артык мөһим түгел. Халык мәкальләре фәлсәфәсен эченә алган бу җөмләне аерым бүлекчә итеп язып куюы бу сүзләргә җитди каравы, үз шәхси аңлавын салуы турында сөйли. Таркатып җыю (структур) методикасы белән тикшерсәң, тормыш тәҗрибәсен, гасырлар гакылын, әхлагын ике юлга сыйдырган ошбу афоризмнан бик күп юнәлешләр аерып чыгарып булыр иде. Гаиләннең, башкарган хезмәтеңнең, дуслыкның кадерен белеп, тормышына шатланып яшәүне, рухи көрлекне дә эченә ала ике халәтне капма-каршы куйган бу җанны тетрәткеч сөземтә. Кешенең фани дөньяда кунак кына булуын истә тотып, Мәһдиев һәр көненә шатланып, язучылык эшенә сөенеп, дуслыкның кадерен белеп яшәде. Танышлар, мәҗлестәшләр,

фикердәшләр табылып торса да, ышанычлы дуслар артык күп булмый, дип яшәде Мөхәммәт. Мин ана якташы, әдәби-нәфис әсәрләренә ин гадел, төпле бәя бирүче Фарваз Миңнуллин дәрәҗәсендә үк якын булмасам да, бер-беребезне хөрмәт итеп, дустанә гомер кичердек, дип әйтә алам. Шәхси архивымда кадерләп сакланган, мин Алабугада яшәгәндә (Казанга күчкәч, күбрәк телефон аша аралаштык) язган хатлары, җибәргән китапларындагы юлламалары күп нәрсә турында сөйлиләр. «Тәлгать! Сәламнәр һәм изге теләкләр. Сездән башка яшәү бик авыр... Сиңа гел мәшәкать тудырабыз, ләкин әлегә оялмыйбыз, чөнки әлегә син безнен өчен бик файдалы, игелекле егетләрнең беренчесе булып киләсең.

Повестем чыкты 11-санда, үземә бик ошады, сезгә дә ошасын иде дигән теләктә калам.

Толстой томнары бөтенләй килеп беткәч уптым гына акча бирермен дип торам.

Сәлам белән. Имза. 13.XI.78».

Тагын да мәгънәлерәк икенче сакланган хаты 1981 елның 28 февралендә язылган. «Тәлгать Нәбиевич! Сездән алып кайткан финский кәгазьгә хат язып карыйм әле. Минем синнән башка хат язар кешем юк икән дип уйлап та куйдым әле... Мин 15 февральдән повышениедә, филиалга беркетелдем дә, өч айга алган заданиене бер айда үтәп 18 марттан Дубултыга яки Переделкинога китәргә уйлап торам».

Кайсы килүендә (Сибгат Хәким Алабуга пединституты студентлары белән очрашуларга М.Мәһдиев, Ф.Миңнуллин, Г.Рәхимнәр «экипажы» илә килергә ярата дигән идек). Мөхәммәткә Суоми агачыннан ясалган кәгазьне биреп җибәргәнемне хәтерләмим, ә язучы өчен затлы кәгазь белән җайлы каләмнән дә кадерле нәрсәнең булмавын чамалап эш иткәнмен, күрәсең. Күрше Яр Чаллы каласында автогигант төзелә башлагач, институт ихтыяҗларына да файдасы күп тиде, шактый кирәкле, дефицит әйберләргә, шул исәптән фин кәгазьләренә дә мантып калдык.

Әлбәттә, инде хәл-әхвәл сорашу өчен генә хат язып тормыйлар, чикләвекнең төше булган шикелле, «Стамбул мәктүпләре»нең хикмәте, эчке бер мәгънәсе каядыр посып торырга тиеш. Чит ил һәм үзебездә эшләнгән кирәк-яраклар белән кибет киштәләре бүселеп торган безнең көннәрдә Мәһдиевнең гозерләре көлке булып тоелырга мөмкин. Совет хөкүмәте кешене рәнҗетә, түбәнсетә, сыта белде шул.

«Җиңгәңнең (ягъни хәләл җефете Лилия ханымның. — Т.Г.) һаман сиңа үтенече булып тора. Минем непрактичный икәнемне белә инде ул. Безгә шушы айларда ике әйбер кирәк буласы иде. Андагы югары агай-энеләргә шундый список бирә алмассыңмы?

1) Китап шкафы — 2 данә

2) Софа (бәясе 250-300)

---------------------------------------

менә шулар».

Берәр әйбергә ихтыяҗы туса да, Мөхәммәт аны болай гына сорамый, ә аның кирәклеген исбат итә, шуңардан башка яшәү мөмкин түгеллеген дәлилли. Аңа ни өчен ике китап шкафы кирәк булган икән дип уйлыйсың инде, кадерле укучым. Юк, ул аны һич кенә дә үз шәхси мәнфәгатьләре өчен сорамый икән. «Син миңа барлыгы дүрт китабыңны бүләк иткәнсең икән, шуларны кадерләп тотарлык шкафыбыз юк...

Перспективаны әйтеп бер чылтыратып алырсың әле, эшең күптер инде защита белән, мин изге теләктә. Сәлам белән. Имза. 28.II.81».

Ул чорда дуслардан, таныш-белешләрдән, туганнардан үтенечләр шактый килеп торса да, ректор кәнәфие биргән мөмкинлекләрдән файдаланып,

мин барысына да ярдәм итәргә тырыштым. Мөхәммәтнең гозерен үтәү белән шөгыльләнгән мәлдә, язгы матур көннәрнең берсендә, ул үзе килеп төшмәсенме! Кабул итүче итәкләрен җыештырып, чәйләрен кайната торсын дип, үзенең юлга чыгуы турында алдан хәбәр җибәреп йөрергә ярата иде Мәһдиев. Әле генә университетның татар әдәбияты кафедрасына мөдир итеп чакырылган, әдәбият галиме, драматургия белгече А.Әхмәдуллин «Волга» машинасы сатып алган икән дә, алар икәүләп кенә Чаллы, Алабуга якларын инләп кайтырга булганнар. Янында Мәһдиев утырганда йөртүчегә беркайчан да йокыга киту куркынычы янамый. Сөйләр әйбере бетсә (анысы да зур сорау астында), тәрәзә аша табигать күренешләренә бәя бирергә, аны кеше тормышы мизгелләре белән чагыштырырга керешер (барысы да бушлай).

Килешү буенча, Казан кунакларын институтның йортында каршы алдым. Кул бирешеп күрешеп, юл хәлләрен сорашып алганнан соң, алдан әзерләнеп куйгандай, Мәһдиев аралашуны булган хәлне, хәзер тарихи «статус алган» мәзәкне искә төшерүдән башлады.

— Күренекле шагыйрь Мостай Кәримне юбилее белән котларга Уфага Рәсүл Гамзатов килә. Дуслар туйганчы сөйләшеп, кунак булып алганнан соң, хуҗа Гамзатовка кичке Уфаны күрсәтеп кайтырга ниятли.

Теләк изге, кәеф яхшы, машина яңа, ажгырып тора. Мостай Кәримнең туган көненә Башкортстан хөкүмәте «Волга» бүләк иткән була. Ике классик сөйләшә-гәпләшә бара торгач, Мостай ага онытылып китеп, обком каршындагы чәчәк бакчасының уртасына килеп керә. Машина тып итеп сүнә. Сакта торучы сержант йөгереп килеп тә җитә, сыбызгысын ачы итеп сызгырта, сүгенә, документларын таләп итә башлый. Алгы рәттә утырган Гамзатов.

— Слушай, дорогой. Посмотри на грудь моего водителя. Раз у меня водитель депутат Верховного Совета Башкирии, ты должен догадаться, кто может быть его начальником?

Шул арада яннарына килеп бөялгән ГАИ майоры мосафирларны танып алып, үзе рульгә утырып, өйләренә озатып куйган.

Бер мәзәген дә юкка сөйләмәгән Мәһдиев, үзенә файдалы нәтиҗәсен дә ясап куя.

— Йөртүчем император университеты кафедрасы мөдире булгач, мин пүчтәк кеше була аламмы инде, иптәш ректор?

Ашханәдә чәйләп, машина янына чыккач, Мөхәммәт минем култыктан тотып, читкәрәк алып китте.

— Иптәш ректор, синең болонья плащың белән нейлон күлмәгең бармы?

— Юк, минем андый синтетик киемнәргә бик исем китми, — дим.

— Синең фәнни җитәкчең аларны күптәннән кия инде.

— Ул бит Хәмит Ярми, Казанның иң көяз кешеләреннән. Бик каты чирли дип ишеткән идем. Хәлен белеп килергә иде дип йөрим.

— Әйдә, без дә синең белән Әхсән Баяннарның күзен кыздырып, плащы ук булмаса да, ап-ак нейлон күлмәк, кара галстук тагып Бауман урамын бер әйләник әле.

Кунакларны озатканның икенче көнендә, Мөхәммәтнең «заданиесен» үтәү шөгыленә керештем. Тормышны тирәнрәк инләү өчен файдасы тиде, дип уйлыйм. Сирәк табыла, итәк астыннан гына сатыла торган тауарларны ул елларда гади кеше өчен җиде йозак элөнгән райпо (районное потребительское общество) складларында гына табып була иде.

Һәртөрле гозерләрне үтәү, шул исәптән плащ, нейлон күлмәк белән кара галстук эзләү барышында сәүдә хезмәткәрләрен сайлап алу, «тәрбияләү» эшенең гаҗәеп югары кимәлдә куелганлыгына хәзергәчә шакларкатып

яшим. Тирә-юнь вилаятьләренең (Алабуга, Менделеевск, Чаллы, Зәй, Мамадыш һ.б.) райпо рәисләренең барысы белән дә таныш идем. Күбесе урта яшьләрдәге татар кешеләре, һәммәсе диярлек гармунда уйный, күпме эчсә дә исерми, гәүдә тулы, чырай кызыл, гел уйнап торган күзләрнең төсен билгеләве кыен. Һәркайчан ачык йөз белән каршы алалар, склад мөдирен чакыртып китерәләр, яисә алдында яткан төрле төсле пасталы ручка белән имза куялар. Кызыл булса берни бирмәскә, яшелнең бер өлешен канәгатьләндерергә, карасы — үзең кара, бу эшкә мине бутама, дигәнне аңлата. Имза зәңгәр кара белән куелса, син алтын балык тоткандай, бәхетле. Алабуга райпосы рәисе Мирза Нурмөхәммәтовнын улы чит телләр факультетында укыганда, институт кешеләренә зәңгәр кара белән куелган рөхсәтләр шактый эләкте. Баллы-майлы айлар тиз үтеп китә шул.

Әлбәттә, ректорны Мирза абзый һәрвакытта «шатланып» каршы ала, хәл-әхвәлне белешкәннән соң, түче тавыш, пәрәвез мамыгы белән чорнагандай, сине изге ниятенә ышандыра. Бүлмәдә тиз арада склад мөдире пәйда була. Ул инде хуҗаның җиз иләге аша үткәрелгән ышанычлы кешесе. Ирләр күзе төшмәслек булса, нур өстенә нур.

— Фирая, матурым, безнең хөрмәтле ректорыбызга болоний плащ белән нейлон күлмәк кирәк икән. Синдә беткәндер инде алар.

Утызын биш-алты ел элек кенә тутырган, иңе-бие бер диярлек, кара халатлы ханым сөйләшүгә өйрәтелгән. Мохтар кебек сүзсез тыңлаучан, күзләрен түбәнгә төшереп, кара туфлиенең очлы башы белән идәндә түгәрәк ясый да, гаепле, әмма гөнаһсыз кешедәй:

— Кичә соңгысын биреп җибәрдем шул, Мирза Нурмөхәммәтович!

Тамаша дәвам итә. Рәис урыныннан күтәрелеп, мае эчтән саркып торган бармагын һавада уйнатып, кискен «әмерен» төшерә.

— Менә нәрсә. Иртәгә үк татпотребсоюзга машина җибәрегез. Алып кайтуга ректорга ничә кирәк шул чаклы бирегез.

Минем якка борылып, гафу үтенүләр, вәгъдәләр... Әлбәттә, ул плащ миңа эләкмәде. Мәһдиев белән Әхсән Баяннарның күзләрен кыздырып йөри алмадык тәки. Башка дефицит тауарлар белән дә гадәттә шулай була. Затлы әйберләр, алтын-көмеш кайткан көнне райпо йорты кара «Волга»лар белән тула. Райком секретарьларының, райсполком рәисенең, хокук саклау оешмалары җитәкчеләренең хатыннары, акчасын соңрак китерү шарты белән, төянеп китәләр. Ә төнлә ул складларда пожар чыга, гаепле табылмый. Мөхәммәтнең олы рухы мине бу фаразым өчен гафу итсен, язучылык, фән кебек төшемсез шөгыльгә кереп китмәгән булса, Мәһдиевтән менә дигән райпо рәисе чыгар, Санияләр, Фираяләр, «Мөхәммәт Сөнгатович, ни боерасыз, чәйләп алмыйсызмы?», дип янында орчыктай бөтерелеп йөрерләр иде. «Без — кырык беренче ел балалары» бәянында алыш-бирешкә, сату-алуга маһир егетләрне яратып сурәтләве шул гоманым тегерменәнә су коя түгелме? Гафу, гафу, шаяртып кына әйтәм, ул булса, миңа гел тамганы зәңгәр паста белән кул куяр иде, дип хыяллануым нәтиҗәсе генә.

Мин Казанга күчеп килгәнче, гел күрешеп, сөйләшеп яши алмасак та, бер-беребезгә җылы мөнәсәбәтебезне хатлар, телефон, яңа басылып чыккан китапларыбыз, шуларга язылган автографлар аша сиздереп яшәдек. Әсәрләребезнең язмышына да битараф була алмадык. «Фронтовиклар» романына Татарстан китап нәшрияты соравы буенча эчке рецензияне мин яздым. Әлбәттә, инде хуплап, соклануымны яшерә алмыйча... Әмма үзенә романның исемен ошатмавымны, эчтәлеккә туры килмәгәнлеге турында әйттем. Әсәрнең русчага тәрҗемәчесе, атаманың вакыйгалар агышын тулы чагылдырмавын сиземләп, аны Мәскәүдә «Большая земля под крылом» (1974) дигән исем белән бастырып чыгара (дөрес, монысын да колакка

ятышлы дип булмый). Романга исем биргәндә, күрәсең, автор сугыш михнәтләрен җилкәләрендә алып чыккан егетләр мәктәп кебек четерекле «фронтта»да сынатмыйлар дигән фикерен ассызыкларга теләгәндер. Үз иҗат җимешен автор теләсә ничек атарга хаклы. Җанрын да үзе билгели. Мәһдиев укытучылар тормышына багышланган романының исемен үзгәртүне кирәк тапмады. Аңа без дә күнектек, хәтта ошый ук башлады. Хәзер «Фронтовиклар» атамасы чор идеологиясе тегерменәнә су койган, үзен аклау (защитная реакция) алымы булгандыр, дип уйлыйм.

«Фронтовиклар» романы аерым китап булып басылып чыгуга аны миңа мондый юллама белән бүләк итеп җибәрде. «Бу китапның язмышына иң актив катнашкан мишәр дуска — асубынни зур ихтирам билгесе. Имза. 1.XI.73».

Табадан төшкән һәр яңа китабыбыз элемтәләрне ныгыта барып, Казан—Алабуга маршруты белән «йөреп торды».

1979 елда «Современник» нәшриятендә Юрий Галкин тәрҗемәсендә «Летят гуси» исемле мәҗмугасы басылып чыгуга М.Мәһдиев аны кызыл кара белән язылган, түбәндәге юллама белән җибәрде:

«Молодому цветущему ученому Талгату Галиуллину от старого писателя с чувством благодарности. Имза. (21.XI.79). Ул чорда әле иллесен дә тутырмаган Мәһдиев иркәләнеп, чытлыкланып, үзен «карт язучы» дип атый. Мөхәммәт гомере буена мөкиббән китеп, табынып яшәгән XX йөз башында, күрәсең, Тукайның яшьли үлемен бизмән итеп алып, М.Гафури, Г.Исхакый, Г.Камал h.б. үзләрен «карт язучы» (үзенә күрә мактану да булгандыр) дип йөртергә яратканнар. Ә инде илле еллык юбилее уңаеннан чыккан «Ут чәчәге» (1980) китабына якланмыйча, ифрат мәгънәле, фәлсәфи рухлы сүзләр язган иде. Миңа бик кадерле юллама белән укучыны да таныштырасы килә. «Тәлгат туган! Бер-беребезне сөендереп яшәсәк иде киләчәктә. Киләчәк — бик кызыклы да, гаҗәеп тә була гадәттә. Сине яратып. Исем, фамилия. 30.1.81. Казан».

Мин Казанга кайтып, аякка басканчы, Мәһдиев минем язмышка хәерхаһ булып, киләчәгемне кайгыртып, мине янәдән «ияргә утырту» хыялы белән яшәде. Бу очракта мин инде «Замана балалары» китабымда искә алып узган гыйбрәтле бер вакыйганы яңартып үтү Мөхәммәтнең холкын, менәзен тирәнрәк күзаллау өчен дә кыйммәтле дип уйлыйм. Вакыйга агышы аның янарак бер сыйфатын аңлауга ачкыч була ала.

1990 елның ямьле бер язгы иртәсендә өйдә телефон чылтырады. Мөхәммәт Мәһдиев икән. Хатыннар, балалар кайсы эшкә, кайсы укуга таралышкач, телефон аша булса да, сөйләшеп, хәл-әхвәлләрне сорашып, дәрелфөнүндә кемнең кайчан дәресе барлыгын ачыклап куя торган гадәтебез бар иде. Мәгәр бу юлы мин уйлаганча исәнлекне белешү, консультация сәгатьләрен ачыклау, язучыларның дивар гәзитендәге соңгы сандагы юмореска турында да сүз куермады. Хәтта Мәскәүдә һәм Казанда утыручы Татарстан депутатларын, шул чаклы уңайлыклар, умырып акча алып та, авызларына су капкандай залда тып-тын утырулары өчен «әрләргә» дә өлгерә алмый калдык.

— Тәлгат, сәлам, сәлам. Безгә тиз генә күрешеп алырга кирәк. Кызыклы гына хәбәр бар.

— Ни «хәбәр» тагын, — дидем мин сагаеп. — Туйган инде ул «дуслар» җибәргән сәламнәрдән.

— Сина мөнәсәбәтле.

— Нәрсә булды?

— Телефоннан сөйләшә торган сүз түгел. Эшкә барышлый миңа сугыл әле. Өйдә үзем генә.

Юк кына вакыйгага да зур әһәмият, янгыраш, уйламаган төсмер

бирергә, шуның өстенә серлелек томаны җибәрергә яратканын белә идем Мәһдиевнең.

Иҗатында да, яшәешендә дә ул бер үк. Бүген тавышында уен, кылану сизмәдем. Интонациясендә нindidер эчке борчылумы, дулкынланумы бар иде. Минем үҗәтләнеп:

— Телефоннан гына әйтмәссенме? — дигән сүземне санга сукмыйча, коры чыбык сындырган шикелле, кырт кисте.

— Ярамый. Минем телефон күптәннән тыңлана. Үзең чамаларга тиеш.

Әдәби персонажлары шикелле үк, табигать баласы Мәһдиев үпкәне дә, ачуны да, иң тирән серне дә эчендә озак саклый алмаганын тәгаен беләм. Яңалыкны вакытында әйтмичә, эчендә озак тотса, мишәрең әйтмешли, микъдары кәми, чирли башлый.

Бу юлы Мәһдиевнең яңалыгы җитди булмаса, тимер чыбык аша ул аның бер очын уйлана торырга миңа тоттырган булыр иде. Димәк, дөньялар тыныч түгел...

Ярты сәгатьтән Мәһдиевнең бер кеше генә сыярлык тар коридорлы, лилипутлар өчен дә кечкенә уенчык кухнялы, тыйнак җиһазлы, мәгәр һәрвакыт пөхтә җыештырылган фатирында идем. Ишек йозакларының биген кат-кат тикшереп, форточкалардан ераккарак утыргач (салкын бәрүдән курку хикмәте түгел, озын колаклар серне белеп алмасын), сүзен куллары белән дәлилли барып, сөйләп китте.

— Миңа бүген сине яхшы белгән, хөрмәт иткән бер районнан звонок булды. Үземдә укыган, хәзер җаваплы урында утыручы егет икән. «Галиуллин дигән кешене яхшы беләсезме? Сез бергә эшлисез бугай», ди. «Менә дигән, ышанычлы мишәр», дип җавапны кыска тоттым. Әле бит эшнең нәрсәдә икәнен белмим.

— Алабугадан Казанга ничегрәк кайтты? — ди теге.

— Минемчә, нормально кайтты. Анда инде озак эшләдең, житте, башкаларга да үзләрен күрсәтергә мөмкинлек бир, дип, Казанга күчердек. Педта бер ел рус әдәбияты укытты, хәзер университетта яңа факультет, докторлык яклау советы оештырып йөри, дим.

— Аны өстәмә урынга районнан депутатлыкка кандидат итеп тәкъдим итәргә уйлыйбыз. Галиуллинны белгән, аңарда укыган кешеләр район мәгарифендә күп икән. Иптәшләр белән тагын бер киңәшкәч, сезгә хәбәр бирермен, — дип бик җылы саубуллашты.

Язлар да узды, көзләр дә җитте, әлеге серле сөйләшүнең эзе комга сеңгән су шикелле югалды. Үз илендә һәркем пәйгамбәр дигән шикелле, нәкъ мин фараз кылганча булды нәтиҗәсе. Буш сүз, юк сүз.

Жиденче тоемым белән Мәһдиевнең мине, үземә караганда да, тырышыбрак депутат ясыйсы килүе, шуның өчен барысын да эшләгәнен сизеп торам. Соңга калып кайткан ир кебек урынында таптанып алды да:

— Күңеленә авыр алма инде, Тәлгат, теге егет «эшебез барып чыкмады, Казаннан башка кешене тәкъдим иттеләр, аннан соң Алабугадан да Галиуллинны бик мактамаган звонок булды, бигайбә», — дип күптәннән хәбәр салган иде, синең кәефеңне төшермәс өчен, әйтми йөрдем.

— Тынычлан, Мөхәммәт дус. Мин аның шулай буласын сразу сизенгән идем. Борчылып йөрүең өчен рәхмәт, — дип, сүзгә нокта куймакчы идем дә, җаваплы кешенең нәтиҗәсе калган икән.

— Да, малай. Депутат булу повесть язу гына түгел икән шул! Төшемле урын. Теләүчеләре табыла тора.

Мәһдиев белән аралашу турындагы истәлекләрне, иҗатына нисбәтән фикерләргә, нәзари тарафларга кереп китмәсәң дә, бер мәкалә, хәтта бер

китапка да сыйдыруы кыен. Хәзер бу язмаларга алынуымның төп сәбәбен ачу вакыты да җитте кебек.

Мөхәммәтнең вафатыннан соң берничә ел үткәч, мин төшемдә аны Горький урамындагы троллейбус тукталышында күрдем. Ап-ачык. Өстендә яраткан, буйга-аркылыга сызыклар төшерелгән аксыл пиджак, кара чалбар. Без, элеккеге политбюро әгъзалары шикелле, чапы-чопы үбешмәсәк тә кул бирешеп, ирләрчә кочаклашып, аркадан каккалап ала торган гадәтебез бар иде. Бу юлы да шулайрак күрешербез дип уйладым. Мин аның янына йөгереп килә башлауга, ул ике кулын боксерларча аркылы куеп, мине якын китермәде, кулын да бирмәде. Үз янына алмады, яшәргә рөхсәт итте.

Шул «очрашудан» соң минем күңелемдә истәлекләр язу теләге уянды. Аларның бер өлеше «Идел» журналында, «Мәдәни җомга»да басылып чыгып, уңай бәя алгач, шулар нигезендә М.Мәһдиев һәм аның дуслары турында китап язу ихтыяҗы сизелде. Сезгә тәкъдим ителә торган роман-эссе шул төнге «магик күрешү» җимеше.

## «Мине яратмаучылар белән көнләшүчеләр дә бар бит әле»

Теләчедәнме, Югары Осланнанмы очрашудан кайтып килгәндә Мәһдиевнең юл уңаенда гына әйткән бу сүзләренә әүвәл артык игътибар итмәдем, чытлыклана, мактау көтә дип кенә уйлап:

— Сине, Мөхәммәт, бу дөньяда яратмаган кеше юктыр. Менә дигән хатының бар, ике балаң аякка басып килә. Булмаган дошманны эзләү сиңа килешми, — дип, мәсьәләне ачылмас борын ябарга тырышкан идем дә, барып чыкмады. Сүзенең дәвамы бар икән.

— Менә син доктор.

— Ә син классик.

— Шаяртма әле, Тәлгат дус, үзеңнең белүеңчә, мин фәнни эзләнүләремә нигез итеп XX йөз башы эстетик фикеренең үсешен өйрәнүне алдым. Яңа роман язасы урынга күпме вакытымны архивларда чокчынуга, вакытлы матбугат битләрен актаруга, Дәрдемәнд белән Фатих Кәрими, Риза Фәхретдиннәрнең «Шура» журналын, «Вакыт»ны, Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камаллар язышкан гәҗитләрне өйрәнүгә бирдем; мәгърифәтебез күгендә ялтыраган, онытылган исемнәрне күтәрдем, тәхәллүсләрен ачтым, шуларга таянып, татар, рус телләрендә ике фәнни китап, әллә ничә мәкалә бастырдым.

Төптәнрәк уйлап караганда, ул хаклы иде. 20-30 еллар тәнкыйтен өйрәнү аша М.Мәһдиев үз күңел тартуы беләнме, кемнеңдер кинәшен тотыпмы, фәнни фикерен татар мәдәнияте үсешенең алтын чорын — XX гасыр башын өйрәнүгә юнәлтә. Анда да галим — проза үсеше яисә мәҗүсиләрчә табынган, һәр сүзен, җөмләсен, шигырен дога кебек изгеләштереп кабатлап йөргән Тукай иҗатын тикшерүгә алынмый. Игътибарын чорның әдәби-тәнкыйди мирасын, иҗтимагый-сәяси, педагогик фикер үсешен аерым шәхесләр язмышына бәйләп өйрәнүгә юнәлтә. Хезмәтләрендә XX гасыр башы әдәбият галимнәренең, тарихчыларының иҗатын милли гыйлемебез үсешенә керткән яңалыклары ноктасыннан чыгып бәяли. М.Гафури, Ф.Әмирхан иҗатлары белән рус телле укучыларны таныштыра. Гомеренең соңгы көннәренә чаклы әдип бу чорның фикер ияләрен, язучыларын олылап яшәде.

Бу юнәлештәге эшчәнлеген бәяләп җиткермиләр дип күңеле рәнҗүен аңлап, тынычландырырга тырыштым.

— Соң, шул хезмәтләре белән иптәш Мәһдиев татар әдәбият белеме фәненә ныклап кереп калды, ни кирәк тагы? — дим.

— Хатип Госман докторлык диссертациясен тәки яклатмады. «Марксистик методологиян аксый» дип, кат-кат тикшертте, тарихилык принцибы сакланганны бәяләү өчен тарих бүлегеннән дә кешеләр чакырды. Барысы да уңай бәя бирделәр, ә яклауга чыгарырга ярый дигән карар чыкмады.

Борчып, агач корты кебек үзен эчтән кимереп торган мәүзугътан читкәрәк алып китеп булмасмы, дип, янәдән шаярткан булам.

— Синең бит илдә чикләнгән булса да демократия урнашуга турыдан-туры катнашың бар. Оппозициягә үзең дә бәяләп бетермәгән олуг ярдәмең тиде, дустым.

Ул, сагаеп, минем якка борылды.

— Фикерне ачыграк әйтсәк?

— Докторский язам дип әдәби әсәрләр иҗат итеп, зур акчалар алып ятып, син совет хөкүмәтенең икътисадый хәленә ифрат зур зарар китергәнсең. Синең «корткычлык» нәтиҗәсендә СССР дип аталган империянең таркалудан башка чарасы калмады. Үзең язганча, профессор Х.Госман сине шуның өчен «фаш итте».

— Мин сиңа декан, яклау советы рәисе буларак үземнең моң-зарымны сөйләп барам. Син һаман уен-көлкегә борасың. Киләчәк буын минем күпме тырышып та фәннәр докторы була алмый калуымның серен, сәбәбен белергә тиештер дип уйлыйм. Х.Госман үрдәк кебек күлгә арты белән керсә керде, әмма хәйлә, мәкер илә эшемне яклауга чыгармады.

Чынлыкта, кафедраның күпчелек әгъзалары (И.Нуруллин, М.Бакиров, Х.Миңнегулов һ.б.), тарихчы галимнәр аның хезмәтен докторлык диссертациясе таләпләренә җавап бирә дип тапканнар икән.

Университетның тарих факультетының элеккеге деканы, профессор Рәмзи Вәлиев искә ала: «Бервакыт Мөхәммәтнең кафедра мөдире мине, яшь ассистентны үзенә чакырып алды. Ул чорда бер зур факультет идек. Олы абзый мине янына утыртты, эчтәге сулышын кысып чыгарып, борынын чистартып: «Мәһдиевнең менә шул эшен укып, тарихчы буларак, объектив бәя бир әле», — диде. Юнәлешне «күрсәтте»: «Мәһдиев марксистик методология мәсьәләләрендә ике аякка да аксый. Шул якка игътибарлырак булсагыз иде».

Мәһдиев белән якын дуслар булмасак та, аралашып яшәдек. Прозасына гашыйк идем. Фәнни хезмәте дә бик нык ошады, бернинди аксау, туксау, чатанлык галәмәтләре күрмәдем. Тарихны яхшы белүе, әдәби әсәрләргә бәя бирү маһирлыгы сокландырды. Кыскасы, кемгәдер ошарга тырышып, намусыма каршы бара алмадым, уңай рецензия язып, әдәбият кафедрасына кертеп бирдем. Мине утырышка чакырмадылар. Кирәкле «бәяләмә» яза алмагач, миңа ихтыяҗ бетте» (1910 ел, март).

Докторлык эшен уздырмагач, Мөхәммәт фән өлкәсеннән читләшә һәм ярсый-ярсый «Ут чәчәге» повестен яза башлый.

— Гали Халит «доктор — тик тор» сүзләрен кушып ясалган, ди бит. Доктор булсаң, шундый югары кимәлле әдәби әсәрләр яза алмас идең, ялкауланыр, халтура юлына басар идең, — дип карыйм.

Мондый арзанлы шомартуым да кабул ителми.

— Менә шул иҗади эшемнең уңышлы чыгуы кайберәүләрнең көнчелек кытыкларын уятты да бугай.

— Хатип абый зур галим, синнән көнләшеп маташмагандыр инде.

— Ул бит үзе генә бушлыкны тутырмый, аның танышлары, белешләре, факультет кешеләре барын онытма. Һәммәсе дә мине ярата дип уйламыйм! Соңыннан Хатип абый гомумән эшемне кафедрага чыгармады. Коридорда очратып сорасаң, кашларын җыерып, муенга нык утыртылган башын селкеп, үземне үк ачуланып ташлый башлады.

— Иптәш Мәһдиев, сез бит коммунист, Мозамбикта безнең хәлләр мөшкелләнеп бара. Провокацияләр ешая. Шундый вакытта диссертация белән чиләнеп ятып буламы соң? Шуңа Уганда, Әфганстандагы хәтәр хәлләр килеп өстәлә, Бабрак Кәрмалны, Нәҗибулланы үтерүләрне дә авыр кабул итәбез.

— Аннан соң үземә дә оят булып китә, — дип чыны белән ироник мөнәсәбәтен бергә кушып җибәрә.

Бу очракта дөрес күзаллау тусын өчен шуны искәртәсе килә. Фәнни хезмәтең җиренә җиткерелеп эшләнгән булса, басылган хезмәтләрең эчтәлеген чагылдырса, яклауга берәү дә комачау итә алмый. Казанда диссертация советы булмаганда элеккеге союздаш республикаларның күбесендә андый мөмкинлек бар иде. Алматыда, Ташкентта, Бакуда Казаннан килгән эшләрне теләп кабул иттеләр, авырлык белән булса да, югарыда әйтелгәнчә, яклаттылар. Хәзерге тел, әдәбият докторларыбызның күбесе, шул исәптән мин үзем дә, Алматыда яклап «кеше» булдылар. 1990 елдан Казан университетында төрки телләр һәм әдәбиятлар буенча докторлык яклау советы гөрләп эшләп килә. Шунда яклаган дистәләгән докторлар, йөзләгән кандидатлар илнең төрле почмакларында, уку йортларында халкыбызга хезмәт итәләр.

Мәһдиев исә фәнни җитәкчесеннән зарланудан тәм, шаяртуына ризык табып, һәркайсы буенча докторлык диссертациясе язарлык әдәби энҗеләрен иҗат итеп калдырды.

Күренекле галим Хатип Госманнан соң капылт кына әдәбият кафедрасы мөдире итеп, Мәһдиевнең үзе шикелле үк филология кандидаты, доцентлык таныклыгы да булмаган Альберт Яхинның билгеләнүе күпләр өчен аяз көнне боз яугандай була. Әмма Мөхәммәтнең А.Яхинга «ул мине беренче көннән үк кысрыклады», дигәнрәк үпкәсен дә мин иркә баланың (укы: танылып килгән язучының) үзен күбрәк яраттыруга дәгъвасы гына дип уйлыйм. Дөрес, яна мөдир кафедраның бер әгъзасы белән дә уртак тел таба алмады кебек. Күренекле әдәбият галиме, профессор И.Нуруллин башка кафедрага күчәргә мәҗбүр булды. Хикмәт шунда иде: «Чаян» журналының элеккеге мөхәррире университетның демократик яшәешен аңлый, кабул итә алмый, кафедраның барча әгъзалары да, сатирик басмадагы шикелле, хуҗаның авызына карап, аның кубызына гына биергә, барлык укытучы да уртак фәнни юнәлеш белән шөгыльләнергә тиеш дигән карарга килә. Күбесен профессор Йолдыз Нигъмәтуллина алга сөргән юнәлешкә тартып, әсәрләрне өлеш-кисәкләргә таркатып, икенче төрле — структур-системалы анализга өстенлек бирүгә мәҗбүр итә. Беренче мәлне иллә зур ачыш, яңалык булып күренгән, хәзер акрынлап онытыла барган альтернатив дәреслекләренең нигезендә дә шул ысул ята. А.Яхин кафедраның өйрәнү объекты итеп халык иҗатын ала. Бар галимнәр диярлек тиз арада «фольклорчы» булып китә. Мәһдиевкә «янача алым» белән халык җырларын өйрәнү бурычы йөкләнә. Урыслар әйтмешли, нет худа без добра, шул чорда А.Яхин мәкальләр, әйтемнәр, мәзәкләр, М.Мәһдиев җырлар, М.Бакиров дастаннар, бәетләр турында шактый үзенчәлекле хезмәтләрен язып, бастырып калдырдылар.

Мәһдиевнең фәнни тикшеренүе өчен җыр жанрын сайлавы бик табигый. Галимә Д.Ф.Заһидуллина бик хаклы язганча, «М.Мәһдиевнең әдәби әсәрләрендә халык җырлары аерым бер урын тота... Мәһдиев — язучы — психологизм остасы, җыр ярдәмендә кеше кичерешләрен бик үтемле аңлауга ирешә... җыр ярдәмендә укучыга тәэсир итә, аның җан дулкыннарына кагыла... Кайбер әсәрләрендә, мәсәлән, «Бәхилләшү»ендә язучы җырлар хакында, трактат язгандай, күңел биреп сөйли. Мөхәммәт абыйның җыр жанрына кагылышлы фәнни эзләнүләре дә бар *(Яхин А.Г., Мәһдиев М.С., табышмак, җырлар, 1982)*. Бу хезмәттә бик борынгы заманнарда

жырның ничек барлыкка килүе хакында сүз алып барыла, иҗат процессына табигатьнең тәэсире, ихтыяҗ булып туган-үскән йола фольклоры, ритм аның состав өлешләре кебек тәкъдим ителә» *(Мөхәммәт Сөнгат улы Мәһдиев, 2003, 15 б.).* Шул ук китапта Мәһдиев «халык җырларын өйрәнүдә К.Насыйри, Г.Тукайлар башлаган эшне дәвам иттерүчеләрнең берсе» буларак бәяләнә.

Нәтиҗәдә, татар фольклористика фәне алга бер җитди ыргылыш ясап алды. Иҗат кешесе Мөхәммәтнең «кара эш» белән шөгыльләнәсе килмәвен дә аңлыйм.

— Яхин минем очрашуларга чыгып йөрүемне яратмый. Дәресләрне уздырып, алыштырып бер-ике көнгә районга чыкканда да, гариза яздырып интектерә иде, — дип зарланганы әле дә хәтердә.

«Завкаф»ның Мәһдиевне өнәп бетермәгәнен башка гамәлләре буенча да сиземләп була иде. Җөмләдән, ул үзенең әдәбият буенча мәктәп дәреслекләренә дә, язучыларның тапкыр, хикмәтле сүзләреннән төзегән җыентыкларына да Мәһдиев иҗатын якын китермәде. Университетча фикер йөртү дәрәҗәсенә күтәрелә алмаган мөдирдән М.Бакиров, Х.Миннегулов һ.б. галимнәр дә иза чиктеләр, шунар да әдәбият кафедраларын бүлгәндә, А.Яхин заманында үзе җитәкчелек иткән коллективта кала алмады. Кызганычка каршы, кешенең үзенә мөнәсәбәт турыдан-туры (автомат рәвештә) аның иҗатына да күчерелә шул. *(Бу фикерләремне А.Яхин әле исән чакта матбугатта яңгыратып кала алдым).*

Ә бит язучы да, укытучы шикелле үк, җылы сүзгә, иң гади, гадәти игътибарга сусап яши. Аның пәрәвез җебедәй нечкә хисләрне, заманының иҗтимагый яшәешен, кешенең татлы хыялларын, өмет-ышанычларын сыйдырган йөрәге аңлауга мохтаҗ. Сүз остасы нинди генә биеклекләргә ирешмәсен, ул мәхәббәт һәм нәфрәт, ләззәт һәм кайгы кебек мең төрле кичерешләрне, гаилә бәхете, бала хәсрәте мисле бөек һәм гамәли хәлләрне башыннан уздыра.

Шуңа күрә инде танылган язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең «докторлык диссертациямне юри, көнләшеп яклатмадылар», дип үпкәсен түгүен дә аңлап була. Теләсә кайсы талантлы шәхескә ялан аяк вак ташлар өстеннән баргандай, үкчәләрен каната-каната үзен расларга туры килә. Кемгә кирәк инде Мәһдиевнең көтмәгәндә-уйламаганда әдәбият күгендә якты йолдыз булып кабынуы. Көнләшмичә соң!

«Мине яратмыйлар, көнләшәләр, аяк чалалар», дигән фикере сөйләшүләр дәрәҗәсендә генә калмыйча, аның публицистик язмаларына, уйлануларына да үтеп керә. Шигъри җанлы шәхес буларак, Мәһдиев һәр шәйне үтә нечкә итеп, иркәләнебрәк, арттырыбрак кабул итә. Кемгә зарлана соң ул? Остазы Тукай кебек, туган милләтеннән җәлләү, яклау көтә Мәһдиев. «1970 ел башыннан мине бик каты кыйный башладылар. Бер мәкаләм өчен. Шуннан мин неблагонадежный исемлегенә кердем (хәзер ул мәкаләне рәхәтләнеп цитировать итәләр). Шул елны әни бик каты авырый башлады... Саташа башлады... Шул чорда мин «Фронтовиклар» дигән роман яздым. Хәзер шуның икенче изданиесен әзерләп утырам. Шаккатырлык! Ничек яздым икән? Әгәр тормыш мине шулай кыйнамаган булса, мин аны яза алыр идемме икән?... *(«Язучының иҗат лабораториясеннән»)*.

Мәһдиев «Фронтовиклар» романының язылу-язылмавына шик белдереп, хәйләли, ыкыш-мыкыш китерә. Җәмгысе «биш авылда укытучы булып» эшләү тәҗрибәсеннән «качып котыла» алмас, яңгыр урынына боз түгел, таш яуса да ул әлеге романын барыбер иҗат итәр иде.

«Фронтовиклар» әсәренең язылу тарихына мөнәсәбәтен-шиген ул 1979 елның февралендә, аны «кыйный башлауга» шактый вакыт, тугыз ел узганнан соң

гына, истәлекләр дәфтәренә язып куя. Игътибар иткәнсездер: Мәһдиев үзе исән чакта матбугатка тәкъдим итү турында уйламаган-хыялланмаган язмасында да үтә сак эш итә, «кыйнаучыларнын» кем икәнен, мәкаләсенен исемен дә әйтми. Хыялын мөмкинлек биргән тәкъдирдә үзен чамала! 1967 елда Мәһдиев «Совет мәктәбе» (№3) журналында октябрь инкыйлабына чаклы Уфада эшләгән, бик күп татар-төрки зыялыларын, күренекле язучыларыбызны тәрбияләп чыгарган атаклы «Галия» мәдрәсәсенә («Галия» мәдрәсәсендә») багышланган мәкаләсен бастырып чыгара. Мәдрәсәләрне динне пропагандалау, халыкның анын агулау үзәге дип бәяләгән рәсми сәясәт Мәһдиевнең «Галия»не югары белем бирүче уку йорты дип бәяләвен дә хупламаска мөмкин иде, әмма җылы кәнәфиләрен югалтудан курыккан түрәләрне Бубый мәдрәсәсенә багышланган мәкаләсе ярсытты, ярларыннан чыгарды бугай. *(«Совет әдәбияты», 1969. 12 сан).* Беренче мәкаләдә сүз күбрәк мәдрәсәдә укыткан яисә шуннан күтәрелгән язучылар турында барса, икенчесендә Бубый уку йорты мисалында, инкыйлабка чаклы дөрләп эшләп килгән мәгърифәт учаклары, татар халкының үзаңын күтәрүгә хезмәт иткән үз укыту системасы булу, аны саклау ихтыяҗы, шул эшкә гомерләрен багышлаган фидаи затлар турында бара.

«Иж-Бубый мәдрәсәсенең тарихын өйрәнүгә мин бик очраклы килеп кердем. Бу минем өлкәм түгел иде. Гыйльми җитәкчем мәрхүм Хатип Госман миннән мондый буталчык тарихны түгел, марксизм-ленинизмның әдәбият-сәнгать теориясен таләп итә иде». Архив материаллары нигезендә язылган, тыелган мәүзугъны фәнни югарылыкта күтәргән «Бубый» мәдрәсәсе» мәкаләсенең басылып чыгуы өчен «Казан утлары»ның «яңалыкны яратучы» баш мөхәррире Р.Мостафин һәм тәнкыйть бүлеге мөдире Фарваз Миңнуллиннар күп көч куялар. Татар зыялылары, язучыларның күпчелеге галимнең бу адымын хупласалар да, рәсми оешмалар мәкаләне унай бәяләргә ашыкмыйлар. Бубыйларны күтәрүгә каршы чыккан К.Фәсеев, Х.Хәсәновләрне автор «карагруһчы»лар, концепциясен анламаган К.Гыйззәтов, М.Әмирләрне үзенә «суктырып» узучылар дип атый. Шул чорда гадәти хәл булган нәзари семинарларның берсендә иң олы түрәләрнең берсе С.Батыев та мәкаләгә «тибеп» уза. Мәһдиевне, җаваплы кешеләр бәясеннән бигрәк, татар зыялыларының анламавы, яклап күтәрелмәве рәнҗетә. Менә ул урамда «Совет мәктәбе» («Мәгариф») журналы хезмәткәре Вакыйф Зыятдиновны очрата. Ул «минем белән күрешкәндә бөтен мәһабәт буена, битенә елмаеп, «почти» шатланып болай диде:

— Ну, малай, Батыев кирәгенне бирде... Ну яндың да инде. — Вакыйф шул кадәр шат, бәхетле иде».

Холкы белән сак, аннан да бигрәк арттырып, күпертеп сөйләргә маһир Мәһдиев шул хәлләрнең уртасында кайнаган, бәхәсләрнең шаһиты, сонрак аралары кискен бозылган, — «Чаян» журналының баш мөхәррире А.Яхиннын бәясен болай сурәтли.

— Болай. Значит, болай, Батыев әйтте. Болай диде, Батыев әйтә: Мин ди, «Казан утлары»нда «Бубый мәдрәсәсе» дигән мәкаләне укыдым. Яшь галим язган. Шәп мәкалә. Кызыклы. Авторы да яшь, талантлы. Ләкин бер хата киткән. Мәһдиев анда Бубый мәдрәсәсен тәмамлаучылар арасында Юныс Вәлидов (жир эшләре наркомы. — М.М.) исемен телгә ала. Юныс Вәлидов бит — солтангалиевче.

Альберт шуннан башка берни дә әйтмәде. *(«Каһәрләнгән хәрәкәт, каһәрләнгән тема»).*

Хәттин борчылгандай күренергә тырышып, А.Яхиннын сүзләрен ифрат житди кабул иткән рәвешен китерсә дә Мәһдиев-сәясәтчене Мәһдиев-художник җинә. Бу очракта анын өчен иң мөһиме кыска, өтек җөмләләр белән, кискен итеп сөйләшүче әңгәмәдәше турында күзаллау, анын образын тудыру.

Әлбәттә, Мәһдиев архив материалларына, вакытлы матбугат биргән дәлилләргә таянып, халкыбызның 1917 ел инкыйлабына чаклы үз мәгариф системасы булуны, шул эш өчен җаннарын, малларын кызганмыйча хезмәт итүче мөрәүвәтле фидакарь шәхесләре күтәрелүне ачып салган мәкаләсенең башкачарак кабул ителүен, житди бәяләнүен көткәндер.

Минем шәхси күзәтүләрем шундый нәтиҗәгә алып киләләр: мәкаләсенең төрлечәрәк фикер уятуы, «кыйналуы» турында үзе үк куертып йөрмәсә, бәлки, татар мәктәп-мәдрәсәләре язмышына игътибар уянып, шул чаклы фәнни (А.Мәхмүтова, И.Таһиров, М.Госманов, Я.Ханбеков һ.б.) тикшеренүләр дә тумас иде. Күпертүгә маһир Мәһдиев, чебеннән фил ясап, үзен эзәрлекләнүче, өркетелгән зат итеп күрсәтергә тырышты, үзен «исәр», «шыксыз үрдәк» дип мыскыллаудан кызык табып яшәде. Бу яктан ул үзе XX гасырның икенче яртысы тудырган, тәгалләнгән, кабатланмас (әдәби) образ һәм реаль шәхес иде.

Мәһдиевнең мәдрәсәләр тарихын яңачарак яктыртырга омтылуын хәзерге чор галимәсе Д.Ф.Заһидуллина болай бәяли. «... татарларга революция генә мәгърифәт алып килде дип тукылдаган, иске мәдрәсәләр фәкать тискәре яктан, дини схоластика белән балаларның аңын томалаучы итеп кенә телгә алынган бер заманда яшь галимнең кирәсен исбатларлык дәлилләрне дөньяга чыгаруы зур батырлык була. Габдулла һәм Гобәйдулла Бубилар, Р.Фәхретдин, З.Камали, Г.Баруди, Ф.Кәрими кебек шәхесләр Мәһдиевне сокландыра, аларның хезмәтләре кызыксыну уята». Тыелган теманы күтәреп чыгуы өчен заманында күңелсезлекләргә юлыкса да, Мәһдиев мәдрәсәләребез тормышына, фидакарь мәгърифәтчеләрнең язмышына суынмый, 1992 елда «Мәдрәсәләрдә китап киштәсе» исемле җыентык бастырып чыгара.

Табигать яшәешендә, җәмгыять тормышында кабатланулар даими рәвештә булып торган шикелле, Мәһдиевне «рәнҗетүнең»дә соңгысы булмаган икән. Янәдән «Көндәлек битләреннән» язмасына күз салыйк. «1978 ел, 5 май көнне өлкә комитетына чакырып минем монографиягә суд ясадылар, шуның белән аның язмышы хәл ителде. Цензор бөтен галимнәрне сүгеп чыгыш ясады. Судта минем монография эчендә ни барын да белмәгән кешеләр утыра иде. Минем һәм И.Нуруллин (фәнни редактор) адресына күп гаеп ташладылар...

...Без матбугат көнен әнә шулай билгеләп үттек.

Фәннең, әдәбиятның әлеге цензор кебек наданнар кулына калуы бик кызганыч, әлбәттә» (5 т., 312 б).

Йөрәк әрнүе астан бәреп торган бу язмасында да Мәһдиев ифрат сак, үзен үткен, ике яклы пычак өстеннән баргандай хис итә, мәгәр монографиясенең исемен дә, катнашучыларның, аерым алганда, цензор иптәшнең фамилиясен дә атамый. Библиографик белешмәләрдән күренгәнчә, 1978 елга чаклы фәнни эзләнүләреннән «Татарская советская литературная критика» (1917-1932) исемле кандидатлык диссертациясенең автореферата (1964) гына басылып чыга. Лаисов Н.Х., Ганиева Ф.Ә. кебек галимнәр белән бергә язган «Әдәбият теориясе. Сәнгать төре һәм идеология формасы буларак матур әдәбият» кулланмасы 1979 елда дөнья күрә. Бу төр басмаларда «крамола» була алмый. Мәһдиевнең галимлеген раслаган, XX йөз башы әдәбиятын, эстетикасын, фәлсәфи фикер үсешен яктырткан «Әдәбият һәм чынбарлык: XX йөз башы татар әдәбиятына яңа материаллар» исемле китабы 1987 елда, «Реализмга таба: XX йөз башы татар әдәбиятында чынбарлыкның чагылышы мәсьәләләре» хезмәте, беренчесенең дәвамы буларак, 1989 елда басылып чыга. Татар әдәбиятының алтын чорын вакытлы матбугат, елъязма чыганаклар аша яңача бәяли галим бу хезмәтләрендә. Әдәби әсәрләр язмыйча, әлеге фәнни хезмәтләре белән генә дә Мәһдиев әдәбият тарихында калыр иде.

Тарихчы буларак, Мәһдиев фәнни эзләнүләренә таяныч, нигез өлге итеп документларны ала, расланган фактларга гына таяна. Вакытлы матбугат сәхифәләренә фәнни бәясен бирә. Киң карашлы кеше булуы милли яшәешне белем-мәгълүмат үсеше яссылыгыннан килеп аңлавында да ачык күренә.

Мөхәммәт докторлыгының очына чыга алмаса да, профессор дәрәҗәсендә йөргән әзерлекле доцент иде. Ул ифрат эрудицияле укытучы, чорга бәясендә төгәллеккә омтылучы, әдәби фактларны күнелендә тота һәм кирәк жирендә файдалана белүче галим, студентларның яраткан лекторы. Кыяфәт рәхим ит, йөрү горур, тавыш көр, төп таяныч — белем.

XX гасыр башы татар иҗтимагый фикере, әдәбияты үсешенә багышланган, заманасы өчен ифрат кыю, яңача карашлы хезмәтләрен нәшер итәргә, ноктасы куелган докторлык диссертациясен якларга чыгартмаган өчен гарьләнүле нөктәсен яшермәсә дә, кемгәдер (Х.Госманны еш телгә алса да) шәхсән үч тотмады. Кем белә: Мәскәү, Алматы, Ташкент, Баку кебек шәһәрләр юлын таптап, диссертация яклау мәшәкатьләренә кереп батса яисә үз кабырчыгына бикләнеп, эчке көчәнеш-каршылыклары, әхлакый кысалары тәэсирендә калса, хәзер татар кешесенең күңел түрендә урын алган берише әсәрләрен иҗат итүгә житешә алмаган булыр иде Мәһдиев.

*Ахыры киләсе санда*

---

## *«Казан утлары»на – 90*

### «Совет әдәбияты»




ЖУРНАЛЫБЫЗ «СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ» ИСЕМЕ БЕЛӘН 1933-1965 ЕЛЛАРДА ДӨНЬЯ КҮРӘ.

Җаваплы редакторлар:

Галимҗан Нигъмәти (1933, № 1).

Кави Нәҗми (1933, № 2-9; 1934, № 1-11, 1947, № 11 – 1949, № 4).

Гомәр Гали (1933 № 10; 1935, № 1-3; 1933, № 10-12 – вакытлы җаваплы редактор).

Г.Разин (Гомәр Бәширов) (1937, № 6-10, 1941, № 7-11, 1942, № 4-6, 9-10; 1937, № 3, 11, 1938, № 1-2, 1945, № 1-4 – вакытлы җаваплы редактор; 1942, № 3 – җаваплы редактор өчен).

Газиз Иделле (1937, № 4-5, 1945, № 5 – 1947, № 6).

Габдулла Ильяс (1937, № 12).

Төхвәт Имаметдинов (1938 № 3 – 1941, № 6).

И.Газый (Ибраһим Гази) (1942, № 7-8 – вакытлы җаваплы редактор).

Гази Кашшаф (1942, № 11-1944, № 4; 1944, № 10-12; 1950, № 5-1958, № 2 – вакытлы җаваплы редактор).

Афзал Шамов (1949, № 5-1950, № 4 – вакытлы җаваплы редактор).

Габдрахман Әпсәләмов (1952, № 4, 5)

Абдулла Гумеров (1958, № 3-1963, № 3).

Газиз Мөхәммәтшин (1963, № 4-1965, № 5) 1947, № 7 -10 – редколлегия.



Марис
Нәзиров

# КҮП СЫНАДЫ ЯЗМЫШ НЫКЛЫГЫМНЫ

## Гомер төсмерләре

**Әй, балачак:**
**Әткәй–әнкәеңнең**
**Тәмле сүзе, назлы куены...**
**Зәңгәр күлләвектә су чәчрәтеп,**
**Яңгырдан соң нурга коену...**
**Әй, балачак,**
**Күпер булып, төсле нур уены**
**Күккә әйдәп күздә калачак!**

**Әй, үсмер чак:**
**Учак ялкыннары,**
**Шук колыннар — җәйге кич яме.**
**Иртә яздан кара көзгә тикле**
**Болыннарда атлар кешнәве...**
**Әй, үсәр чак,**
**Агач аттан толпар канатына**
**Сынау кичәр өчен күчәр чак!**

**Әй, егет чак:**
**Беләктәге көчкә**
**Йөрәктәге дәрман тиңлеге...**
**Саф мәхәббәт ләззәт–газаплары,**
**Хыял дәрьясының киңлеге...**
**Әй, күбек чак,**
**Диңгез тубыктан дип исәрләнү,**
**Тиле яшьлек үтмәс кебек чак!**

---

Марис НӘЗИРОВ (1949) — *шагыйрь; «Йолдызлар табын кора», «Янә утларга керәм», «Еллар кары» һ.б. китаплар авторы. Башкортстандагы татар язучылары берләшмәсе рәисе. Уфада яши.*

**Әй, ир-атлык:**
**Ирмен дигән ирнең**
**Җилкәсенә тормыш атлану...**
**Шатланулар — эзсез югалмыйча**
**Таш атканга ашлар атканың...**
**Әй, рух ныклык,**
**Кыенлыкта акыл сабырлыгы,**
**Изге гамәлләрдә олпатлык!**

**Ай-һай, картлык:**
**Оныкларны багу –**
**Кулдан килгән тыйнак эш тәме.**
**Ә күңелдә учак ялкыннары,**
**Болындагы атлар кешнәве...**
**Әй, беркатлык,**
**Алтмышта да сабый ихласлыгы,**
**Туган һәр көн яшәп туймаслык!**

## Яман күздән сакла, Ходай!

**Яман сүздән сакла мине,**
**Сакла, Ходай, яман күздән!**
**Сулар кичеп, бозлар кистем,**
**Салкыннарга түздем, түзәм...**

**Үзем салган сукмак йөзен**
**Аер, Ходай, башка эздән!**
**Кырыс җәй дә кысыр түгел,**
**Татлы җимеш өздем, өзәм...**

**Якты күздә юлым өзмә,**
**Нур сүндермә, Ходай, күздән!**
**Бураннарга каршы барып,**
**Көртләр ердым, ерам тездән...**

**Гомер көзем — кузлы күмер,**
**Яңа учак дөрләр тиздән.**
**Очкын учлап, ялкын чөйдем,**
**Шигырь итеп тездем, тезәм.**

**Язлар кат-кат килсен назлап,**
**Имин кергәч кышка көздән.**
**Яман күздән сакла берүк,**
**Сакла, Ходай, яман сүздән!**

***

**Кар аклыгы капылт күзгә керде,**
**Кыш икән бит, инде кыш җиткән.**
**Башы түгел, хәтта уртасы да...**
**Язга карый кояш төшлектән.**

**Сафлык тулды кардан йөрәгемә**
**Койма яңгырларда күшеккән.**
**Күз башында сине югалтуны**
**Күтәрергә ничек көч җиткән?**

**Кайтмас җиргә киткәнеңнән бирле**
**Яфракларны коеп җил искән,**
**Миңа гүя вакыт туктап торган,**
**Күзләремә монсу көз күчкән.**

**Мине вакыт, хәрәкәтсез калып,**
**Газапларны ялгыз кичерткән,**
**Сиздермичә фасыл алышынган,**
**Гөл таҗларын кырау өшеткән.**

**Миңа гына гүя бу дөньяның**
**Буш тоелган чиксез киңлеге,**

Җаным гүя тәнне ташлап киткән,
Таш түмәргә башым тиң иде.

Син барында гел яз булгандыр ул,
Үткән гомер татлы төш икән.
Күзгә керде капылт кар аклыгы,
Кыш икән бит, күптән кыш икән...

***

Синсез кичләр —
Көчсез хисләр,
Төн караңгы,
Ә таңнары —
Бар да бер инде.
Син булмагач,
Тән тоймагач —
Кем килсә дә,
Ни кылса да,
Барыбер инде...

Синсез язлар —
Хиссез назлар,
Җәй кояшсыз,
Көз–кышлары
Бар да бер инде.

Син булмагач,
Җан елагач —
Кем күрсә дә,
Ни дисә дә,
Барыбер инде...

Синсез гомер –
Назсыз көйдер,
Җыр йөрәксез,
Ә сүзләре
Бар да бер инде.
Син булмагач,
Моң тумагач —
Кем сөйсә дә,
Җил киссә дә,
Барыбер инде...

***

Күп сынады язмыш ныклыгымны,
Сындырырга теләп сынады.
Ятим балачакта калган бозны
Карт көнемдә биткә сылады.

Сер бирмәгән булып йөзне бордым,
Тәнем түгел, җаным елады.
Йөрәк кошым ярсып кансырады,
Күкрәк читлегемә сыймады.

Үксез балачакның шул бозлары
Ник эреми һаман икән лә,
Күзләремә бага ике сабый,
Алтмыш берне узып киткәндә.

Мин әнисез үстем. Алар да бит
Әнисезләр хәзер, ятимнәр.
Гомер бетеп, инде мин дә китсәм,
«Әтием!» — дип кемгә әйтерләр?

Елардаем юктыр кебек иде,
Керфек төртеп яшем ургылды.
Инде тагын ниләр җанны иләр,
Күп сынады язмыш рухымны.



Әхтәм
Зарипов

# ГАЛИЯБАНУ ТУЕ*

КЫЙССА

Туй узачак авыл белән таныштыра башлаганчы, мәгълүм булсын — мин үзем дә Тансыктан.

Авылдашларыма хас җитешсезлекләрдән дә, мактанырдай сыйфатлардан да мәхрүм түгелмендер дип уйлыйм.

Миңа калса, авылыбызның исеме җисеменә бик тә муафыйк. Аны һәркем үзенчә аңлата. Хатыннар, ирләренә күрсәтеп, «тансыкларыбыз әнә шулар», — дисәләр, ирләре, бердәм булырга тырышып: «тансык» — димәк, «Юньле!», — диләр.

Элек-электән бездә егетләрнең күрше авыл кызларына өйләнүе макталган. Ихтимал, хатыннарының үз ирләрен белеп бетермәүләре шуннан да киләдер...

Тансыклыга гына хас сыйфатларның күбесен үзенә җыйган күренеклесе, хикәябез каһарманнарыннан берсе, 90 яшен тутыручы Миңгали Шәрифҗан улы Сәфәровтыр дисәм, якташлар мине яклар. Очрашып сөйләшкәндә авылдашлар, аның күзенә карап, «Мингали абзый» дисәләр, артында «Әкән» дигән кушаматы гына озатып кала. «Әкәнчә булды», «әкәннәнмә» дигән кебек сүзләр ишеткәндә, Мингали абзый гына күздә тотылмый. Бу сүз авылда мөстәкыйль яшәп, кем тарафыннандыр кылынган гайре табигый гамәлне, яисә, тузга язмаган эшне, мәгънәсезлекне дә аңлата.

Мингали Сәфәров, ягъни Әкән, көндәмлеге өчен макталса, кирелеге өчен сүгелә. Анын янгын каланчасында эшләгән елларын хәтерлик...

Әйтик, ураза вакыты... Каланчага эленгән сабан төрәненә сугып, сәгать ничә икәнен белдертергә кирәк. Ураза тотучылар сәхәр яки авыз ачуны Әкән сәгатенчә башкара.

Шайтан котырта диярсең, сәхәргә уяту чаңы бер сәгатькә соңлап яңгыраса, авыз ачтыру чаңы бер сәгатькә алданрак сугыла.

---

*Журнал варианты.

Әхтәм ЗАРИПОВ (1935) — *сценарист, режиссер; күпсанлы телевизион фильмнар, очерклар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Тансык диндарлары сүгенә, ә инде Әкәннең үз мантыйгы: «уразага соң кереп, иртә чыкканнын гонаһы бар икән — яртысын мина күчерегез, ә минем җавап әзер: «Чиләбе сәгате тәүлеккә ике генә тапкыр дөрес күрсәтә», — ди ул.

...Тансыкта кушаматсыз кеше юк. Әмма ләкин «Әкән» белән чагыштырганда башкаларныкы «маймыч» кына. Кушаматы ана үзеннән олыга да, кечегә дә «әкә» дип дәшүеннән тагылгандыр, диләр.

Аларның гаиләсе колхозлашу елларында, сатылу афәтеннән качып, Ташкент якларында тегүчелек кәсебе белән көн күреп йөргән. Илгә кайткач та Мингали әкәнең әтисе Шәрифҗан бабай үзбәкләрдән эләктереп кайткан гадәтен — ягъни авызына тәмәке көле тутырып, урман каравылчысы атында төкеренеп утыруын үлгәнче ташлый алмаган. Алай гына да түгел, кәсебен дә, бу чирен дә берданбер улына йоктырып калдырган. Әкән әкәнең:

— «Тәмәке тарту — расхутлы, шырпы-кәгазь исраф ителә,» — дип, нәкъ Шәрифҗан бабайча, ат өстендә «черт итеп» төкереп куюларын авылдашлар әле дә хәтерли. «Очсызга төшә», дип тәмәкене авызына гына салса да, «тамчысын да әрәм итми — тәтенне үпкәдә тоту» серләренә безне Әкән әкә өйрәтте.

...Авыл белән «Кәҗүннәй» дип йөртелгән урман арасында иген кырлары, ягъни, басу җәйрәп ята. Борчак, киндер, арпадыр — барысы шушында игелә. Без үскән чакта мал кермәсен өчен бу басулар ур белән әйләндереп алына иде. («Ур» — тирән чокыр, канау).

Хәзер, авылда мал асраучы калмагач, урның да кирәге юк икән, басуында да кукуруз белән рапс кына игелә, ди. Кукурузы кыш буе аягында калып, киләсе ел унышы өчен дым сакласа, рапсын «майлы культура» дип, каядыр илтеп тапшыралар икән. Нинди май икәнен дә, анын белән нәрсә майлауларын да Әкән әкә белми. Ул да белмәгәч, анын белән кызыксынучы юклыкка гаҗәпләнәсе дә юк. Ә менә урны да, ур эчендәге басуны да сагынучылар бар.

«Ур белән басуның Тансыктагы Галиябану туена ни катнашы бар?» — диярсез... Катнашы бар! Басусыз ур, Галиябанусыз — «Галиябану» спектакле булмаган кебек, урсыз Әкән — Әкән түгел, Әкәнсез Тансык — Тансык түгел!

...Авыл ягы чокыр-канау булса, басу ягына шул чокырдан чыккан балчыгы өелә. Аның аша кәҗәдән башка йорт хайваны сикереп чыга алмый.

Авыл капкасының басу ягында Әкәннең атасыннан калган куышы. Эчендә ат сыярлык иркен, елның-елына төрле үлән, печән-салам өстәлеп торгач, түбәсе манара кебек биек.

Әкәнең ярты гомере шунда уза дисәк, киметеп әйтү булыр; «бөтен гомере шунда уза», дияргә ул әле исән-сау. Теге чактагы, без белгән чордагы гомере, ягъни, сугыш чоры турында сүз бара.

...Малай вакытында ишәк тибеп сынгач, бер аягы икенчесеннән кыскарак калып ялгану сәбәпле, Әкән солдат хезмәтенә яраксыз, әмма крестьян тормышында бөтен эшкә кулы яткан егет булып үсә. Мәктәпкә йөреп укымаса да, кайдандыр, кемнәндер догалар өйрәнгән, шунадыр аны «гыйлем иясе» диләр. Гарәп, латин хәрефләре белән язылган язуларны җинел укый. Кириллицага өйрәнә алмый интегүе дә хәтердә калган.

Без белгәндә Әкән «кәҗүннәй» каравылчысы буларак лесхоздан «Жалуынжа», басу каравыллаган өчен колхоздан «трутдин» ала иде. Бернәрсә алмаса да, Әкән әкәнең авылдагы иң хәлле һәм иң абруйлы кеше булуын без — малайлар бик яхшы аңлый идек. Чәч алдырырга дисәң — машинкасы, тәрәзә ватсак — пыяла кистерергә алмазы, бүредән сакланырга мылтыгы — һәммәсе анда гына. Авылдагы берданбер сепарат ватылса «шестырнасын» алыштыра белүче дә, сәгать төзәтүче дә ул. Ә инде ишетмәсә дә «детектор» дигән колак радиосын тыңлатып, үзенчә, дөнья хәлләре белән таныштыруын исәпкә

алганда, Тансыкның Әбүгалисинасы да, Кулибины да, Ливитаны да ул.

«Әкән куышы» дигән могҗизалар оясына без, малайлар, атка атланып басу тирәсеннән каз, бозау куарга, аларны ферма утарына бикләргә, яисә кәртле уйнарга килә идек. (Кайчак, үзебезнең бозауларны да шунда япкан чаклар була иде)...

Колхозда өч бригадага унҗиде эш аты калган, персидәтел булып персидәтел янгын каланчасына беркетелгән атны җигеп йөри. Әкән әкәдә исә солы ашаган лесхоз алашасы. Ул үтә дә тыныч холыклы, сабыр. Теләсә кемне, теләсә кайчан атландыра. Малайлардан кемдер беребез бозау куарга, яисә ур җимереклеген тикшерергә китсә, калганнарыбыз куышта чыбыркы үрергә, («алтыдан», «сигездән») кәрт сугарга, тәмәке төтенен борын аша чыгарырга өйрәнә. Бушлай түгел: өч төрерлек тәмәкегә бер күкәй бирәсең. Стаканлап сатмый Әкән, «аналарыгыз сизәр», ди, «бәладән баш-аяк» ди. Сизәләр иде, тотыла идек. Тәмәке иседер дисәк тә, соңыннан беленде: бигүк тәмәке булмаган икән без тарткан үлән. Алдаган безне Әкән.

Хәер, кем генә алдамады икән безне ул чакларда? Кем генә алданмады икән?! Хәтта, Әкән әкәнең үзен дә алдый торганнар иде...

...Язгы чәчүләр бетүгә арыш утау башлана, Әкән куышын сипли. Димәк, кара көзгә кадәр авылның төп вакыйгалары нәкъ менә шушы басу капкасы төбендә, Әкән куышында кайнаячак. Хатыннарның күбесе утауга балаларын ияртеп йөри, иярә алмаганнарын бишекле арбада тартып бара. Кайтышлый, бишектәге бала түшәге астында азмы-күпме печән-үлән кайта. «Кешегә ярамаса — мал ашар» дигән язылмаган закон буенча арбасызлар алъяпкычларына, яисә баш яулыкларына төйнәп — кукы, кәҗә сакалы, балтырган, эт эчәгесе күтәреп кайтырга тырыша.

Куыш янында ат торса — хатыннар төенчекләрен кычытканлыкка ташлыйлар — имеш яшерәләр. Ат күренмәсә — куышка кадәр күтәреп киләләр. Шунда аларны Әкән эләктерә, кычкырыш, елаш, сүгенү башлана. Еламагае ертылсаң да, Әкән сүзе сүз — үлән куыш өстенә ташлана, чөнки колхоз рәисе Гофранның әмере шулай: «Жирдәге соңгы башак амбарга кергәнче басудан бер сабак үлән дә чыгарга тиеш түгел. Барсы да җину өчен!»

Ә инде урак өстендә без — малайлар өчен иң кызыгы башлана. Хәер, бездән дә бигрәк, Әкәннен үзе өчен кадерле булгандыр ул «урак өсте» дигән вакытлар.

... Куышына алып кереп анадан тума чишендерә иде ул хатыннарны. Чишендермичә ярамаган күрәсең. Чөнки хатыннар башак уып җыйган арыш, бодай яки борчак кузакларын шундый оста итеп яшерәләр иде, хәзерге кинолардагы шпионнарның яшерү ысуллары пүчтәк кенә... Әйтик, Фәндилнең әнисе Суфия апайны уракка барганда күрсәң — арык кына бер апай, күкрәкләре куна тактасы кебек тип-тигез. Сигез яшькә кадәр имеп, син суырып бетерден, дип, Фәндилне сүгә иде, мәрхүмә. Ә уракта кайтканда юанайган, калынайган, хәрәкәтләре салмак, күз карашлары...

... Әнә шул күз карашлары сата иде аны... Әкән түгел, без дә сизә идек: ашап кына юанаймаган бу апаебыз.

— Куышка керәбез!.. — ди Әкән.

— Ник?

— Тышта чишендерергә закун кушмый. Сал күлмәгең! У-хо-ха! Бу нәрсә бу?

— Муенса ич! Төймә!

— Муенса гәрәбәдән ясала, ә монда синең 1000 данә борчак кузагы!

— Хәзинәдә булганыннан ясап тактык.

— Хәзинә дәүләтнеке! Давай, давай ычкындыр! Ә бусы ни?

— Күрмисеңмени — ими капчыгы.

— Имиең кая соң синең?

— Күкрәкчәне имие булганнар гына кими — муда ул, матурлык өчен киелә. Иптәш Сталин әйтә... матурлык...

— Давай монда матурлыгың! О-һо-һо: монысы бодай! Ике кило булыр.

...Тагы шундый бер «показательный тентү» оештырганда Әкәнебез үзе кыен хәлдә кала.

«Колхоз милкен саклаучы солдатлар» исемендә атнага бер чыгып килүче «Сугышчан листок»ка каһарман эзләп, район газетасыннан фотоаппаратлы корреспондент килә. Ул, Әкән әкәнең көрәш чаралары турында хәбәрдар булгач, «персонажны непосредственно, производственный процесса снимать хочу», — дигән.

Билгеле булганча, Әкәнең «производство»сы каравыл куышында. Аңа идарәдән тентүне иң камил сыйфатлы уздыру бурычы йөкләнгән. Кич житә. Төркем-төркем булып уракчылар кайта башлый. Беренче төркемнән куышка алып керерлек кандидат табылмый. Икенче төркемдәгеләр, юлдан ук чишенә-чишенә кайтып, куышка житкәндә барысы да шәрә кала. Корреспондент, оятыннан, куыш артында яшеренеп торырга мәжбүр була.

Шунда «амазонкаларның» берсе Әкәнгә әйтә куя:

— Син безне түгел, әнә Хәдичәне кара.

Хәдичә, яшьли дөм ятим калып, атасының сеңлесе гаиләсендә, аннары приютта эш белән үскән авыл кызы. Булдыклылыгы өчен аны 7 нче классны бетергәнче үк мәктәпкә пионервожатый итеп алалар. Хәзер инде ул, башкалар кебек үк, ялгыз солдатка. Сугышның беренче аенда ук ирен озатып, өченче аенда тол калган бала-чагасыз яшь хатын. Чибәрлеге аркасында авылдашларының гына түгел, якын-тирә авыл егетләренең дә тынычлыгын бозган. Чөнки чибәрлеге өстенә танылган жырчы да ул. Бәйрәм кичәләре генә түгел, кунаклы мәжлесләр дә ансыз узмый. Йомшак теле, шаянлыгы, шук холкы өчен аның катнашуы мәжлеснең дәрәжәсен күтәрә. Каз йолку мәжлесенәме, Коръән укыту ашынамы кемнедер бик тә китерәсең килсә, «Хәдичә дә булачак» дип өстәсәләр, бу инде — кунаклар килүгә 100 процентлы гарантия дигән сүз.

Олы бәйрәмнәр хөрмәтенә куелган спектакльләрдә ул гел Галиябану ролен башкара. Әсәр ул туганчы ук язылган булса да, Әкән әйтүенчә, «Галиябану»ны язарга Мирхәйдәр абзыйны Хәдичәбану рухландырган. Тансык егетләре шуңа ышана, Сабан туйларында ул биргән бүләк сөлге өчен көрәшә-көрәшә сугышып та китәләр.

«Аны Минзәләгә чакырганнар, Өметбаев үзе алырга килгән, вәгъдәләшкән егетем бар, дип кенә театрга китүдән котылып калган»... Бу сүзләр Хәдичә апайны бер баскычка күтәрсә дә, серлелекне дә арттыра иде:

— «Кем ул аның вәгъдәләшкән егете?»

Гаташ — авылның гомерлек Хәлиле. Оста гармунчы, жырлавы да — чын жырчыларча. Әмма ләкин ул өйләнгән, агрономлыкка укыган жиреннән ияртеп кайткан Нәфисәсе корсаклы, — диләр.

Аннары, имеш, алар загслы түгел икән, Хәлил — Галиябануны гына ярата, имеш. Ягъни, Гаташ абый Хәдичәне генә сөя, — дигән сүзләр дә йөри... Белмәссең... Инде менә яңа хәбәр...

...Фин сугышы белән Олы сугыш арасында, язгы чәчүгә чыгу алдыннан кибеткә ситса кайта һәм аның беренче нәүбәттә заготконторага йон, тире, ит тапшырганлыкка квитанцияләре булганнарга гына сатылачагы билгеле була. Игъланны укыган һәркем, «кәпитәнсә» сорап, Әкәнгә килә. Чөнки авылда штатный тире-яры жыючы булмагач, мал суйган кеше аның тиресен Әкәнгә генә илтеп тапшыра. Әкән исә, кешесенә карап, йә тире хакын шунда ук түләп жибәрә, йә «утын әзерләгәндә исәпләшербез», — дип, клиенка тышлы

дәфтәренә теркәп куя. Һәрхәлдә, Әкәндә «кәпитәнсә» барлыкны Тансык халкы тәгаен белә!

...Әмма Әкәннең җавабы өметкә урын калдырмый:

— «Сез бит миңа кәпитәнсәсен алып кайтып бирергә» димәдегез.

— Үз исемемә алганын булса да бир. Бик тә кирәк иде, Мингали, мендәр тышларыбыз тузган... чаршауыбыз юк.

— Үз исемемә язылганын мин үз гаиләмә алам.

— Хатының, балаң-чагаң юк; сиңа бизәкле ситса нигә кирәк?

— Миңа кирәкмәсә, Хәдичәбануга кирәк булыр. Килен булып килгәч, ситса эзләп йөрисе булмас.

«Тансык басуына метеорит төшкән» дигәннән көчлерәк хәбәр була инде бу.

— Хәдичәбану?

— Әкәнгәме?

— Нәрсәсе гаҗәп?

— Куегыз булмаганны!

— Әкәннәнү генә бу!

— Галиябануыбыз сиңа чыгамы?

— Минем кай ягым Хәлилдән кайтыш?..

— Җырың юк. Тәрәзәсенә килеп җырлаганың бармы соң? Хәдичәбану җыр ярата бит, җыр!

— Ата сыерчык кына ана сыерчык утырган ояның авызына карап сайрый. Без хатынга җырлап түгел, аны малга күмеп ярарбыз.

— Туебызга рәхим итегез! Галиябану туена!

...Беренче мәртәбә Тансыкта «Галиябану туе» дигән сүз әнә шулай Әкән авызыннан 1941 елның 22 апрелендә, ягъни кибеткә ситса кайткан «Лилин көнне» әйтелсә, без бәян итәргә алынган туй — бөтенләе белән башка туй. Аңа кадәр әле Тансыкта күп туйлар узасы бар. Иң әүвәл Хәдичә апаның туе.

...Театрга китүдән «вәгъдәләшкән егетем бар» дип котылып калса да, кияүгә чыгудан котыла алмый Хәдичәбану.

1941 елның 14 нче маенда, ягъни, бөтен авыл бәрәңге утырткан көнне, Тансык урамнарында «Галиябану» көе яңгырый. Көпә-көндез. Әллә каян танылып тора — тальянда Хәлил ролен башкаручы Гаташ уйный. Бераздан дугасына сөлгеләр урап җигелгән пар ат күренә. Тарантаста Хәдичә апа, янәшәсендә аны кочагына алган...

— Кем? Әкәнме?

...Мәсәй, ягъни, без белә-белгәннән бирле Исмәгыйльне уйнаган Мәсәбыйх абый! Кузлада кулына тальянын тотып Хәлил — Гаташ утыра.

— Булмастыр ла...

— Нәрсә соң бу?

— Туй дисәң... Ни өчен Галиябану... Хәдичәбану Исмәгыйль — Мәсәй кочагында?

— ? ? ?

— ... Бу бит... бу бит хыянәт!

— Хыянәт кенә түгел — җинаять бу!

...Тансык халкы, бәрәңге утыртуын ташлап, тарантасны күзәтә. Ягъни, кем капкасына борылып туктар?!

...Кыңгыраулы пар ат Мәсәйләр капкасына борылмый узып киткәч, Тансыкта бәрәңге утырту кабат башлана. Тик... озакка түгел. Түбән очны әйләнгәч, гармун тавышы тагы Мәсәйләр урамына күчә дә, аларның ачык капкасыннан узгач, тына. Гармун тына, әмма авыл тынмый. Киресенчә, кайда да сүз «хыянәтчеләр» турында бара. Аларга хөкем карары чыгаралар.

Хәдичә — Галиябануны мәхәббәткә хыянәттә, Гаташ — Хәлилне авылга хыянәттә гаеплиләр.

— «Без аларны кызганып елаган булабыз, ә алар әнә нинди икән!»

— Гаташ өйләнгән бит, җәмәгать аерсынмыни?

— Мәхәббәтләренә хыянәтсез, эчтән генә сөешеп яшәргә була иде бит аларга. Үрнәк булып...

— Значит, Галиябану алданган! Ягъни, Хәдичәне Мәсәй...

— Мөмкин түгел...

— Галиябануны алдасын да, ди. Әмма Хәлилнен, Исмәгыйльгә яраргa тырышып, гармун уйнавын гафу итеп булмый.

— Нишлибез?

— «Галиябану» алданмаган, ул үзе алдаган. Хәлилне дә, безне дә.

— Җәмәгать: давай театр белән чынбарлыкны бутамыйк. Пәри башка, җен башка.

...Юк, кичермиләр! Туйлардан соң күп тә узмый Мәсәбыйх абзыйларның мунчасы яна! Әкән эше диләр. Тик тикшерүче бу хәбәрне кире кага. Медальле урманчы андый эшкә бармас! Янгын чыккан төнне Әкән болында печән чабучылар янында үткәрә, имеш. Шаһитлары бер авыздан шуны раслый.

...Аннары... ил иңенә төшкән хәтәр сынаулар Мәсәй мунчасы януга кагылышлы гайбәтләргә урын калдырмый, аны бер шуклык кына итеп искә алалар, ачу тотулар, үч кайтарулар онытыла. Чөнки бөтен Дөньяга ут каба, Европа яна, аның ялкыны төннәрне көн итә, агулы төтене айны— кояшны каплый, сөреме һаваны тутыра, барлык тереклеккә үлем яный, исән калу өчен, яшәү өчен илдә Ватан сугышы башлана.

1941 елның 22нче июне...

...Кулына корал тотарлык, балигъ булган сәламәт ир-егетләр Ил сагына баса. Башта «армия хезмәтен үтеп кайткан, дары исен иснәгәннәр генә чакырыла» дисәләр дә, чынлыкта 18 яшьтән 45 яшькәчә ир затлары һәммәсе солдатка алына. Хәрәкәттәге армиягә ярамаса — хезмәт армиясенә. Аннары чират хатын-кызларга җитә. Сугыш башланып ике ел узуга Тансыктан 369 солдат озатылып, җиңеп кайтучыларның саны нибары 99га гына кала.

...Галиябану ролен уйнаган Хәдичәнең Исмәгыйль ролен башкарган Мәсәбыйхка кияүгә чыгуына каршы бунт күтәреп, аларга байкот игълан иткән Тансык халкы, 270 санын сүзсез генә күңелендә саклап, әрвахлар рухына Коръән укытып, сабыр итеп яшәргә күнегә. Ватан исеменнән ни сорасалар да, «ник» дип тормый, һаман сораган саен солдатын, икмәген, итен-сөтен бирә, налогын түли. Җирен алганга да түзә, дәшми. Әмма кинәт «Галиябану»ын тартып алсалар? Әлегә эш аңа ук килеп җитмәгән җитүен дә...

1944 ел. Урак өсте. Каравылчы куышы янында чишенгән уракчы хатыннар төркеменнән берсе (Хәбирә апа бугай) Әкәнгә әйтә:

— «Син безне түгел, әнә Хәдичәне кара.

— Аны бүлнистә дигәннәр иде. Терелеп чыкканмы?

— Тугыз ай тулмыйча котылып булмый андый чирдән.

— Йогышлы түгелме?

— Йоктырган шул, йоккан!

— Корчаңгы түгелдер бит?

— Үзеннән сорарсың.

— Син башладың, син үк әйтергә дә тиешсең. Әйтмәсәң, солдатка турында гайбәт таратуың өчен силсәүиткә явит итәм...

— Силсәүит белмәс эш юк Тансыкта.

Куыш янына килеп җитә Хәдичә апай.

— «Юлыңа гөлләр үссен, Хәдичәбану».

— «Рәхмәт!»

— Ашыкмыйк, тукталып алыйк, ял булыр җаннарыңа.

— «Кеше очраган саен туктый башласаң, көне буе йөрерсең» — диме Галиябану?

— «Минем янымда аз гына да торасың килмимени?»— ди аңа Исмәгыйле.

— «Ашыгам шул», ди Галиябану.

— «Кая ашыгасың?»

— Ялгыштың, Миңгали абый. Галиябану «ашыгам шул» дигәч, Исмәгыйль «биш кенә минутка» дияргә тиеш.

— Мин бит Исмәгыйль түгел.

— Әмма бик тә ул буласың килә. Сүзләрен дә ятлагансың. Ләкин зрә интеккәнсең.

— Алыштыра алмаммы?

— Аның сүзләре белән сөйләшеп кенә, ай-һай, булырмы икән?

— Исмәгыйльне сәхнәдә уйнарга җыенмыйм. Мин тормыш кешесе. Минем үз сүзем бар. Мин — мин!

— Анысын да чамалыйм, Миңгали абый. Мунчага юкка гына ут төртмәгәненне беләбез. Күпләп ситса алуларың сәбәбен дә ишеттерделәр.

— Синең тирәдә козгыннар йөри диләр. Расмы шул сүз?

— Рас иде дә, котылдым инде.

— Кемнән?

— Кеше сүзеннән, гайбәттән.

— Аннан котылу ялгызыңа җиңел булмас, Хәдичә.

— Мин ялгыз түгел.

— Кемең бар тагын?

— Булмаса булыр.

— Кая ашыгасың? Тукта, сүз бетмәгән.

— Көтү каршылар вакыт житте. Сыер кайтканчы бозауны ябарга кирәк. Кичә дә сөтсез калдым.

— Бозавың ябулы.

— Ничек ябулы? Яланда бәйле калды ич ул.

— Урны җимереп басуга кергән. Тотып ферма утарына бикләдек.

— Арканын өзгәнмени?

— Нәрсәсен өзгәнен белмим. Белгәнем шул: кәнсәләргә барып штрафыңны түлисең дә, шул кәпитәнсәне күрсәтеп, иртәгә иртән бозавыңны аласың. Ә хәзер... Әйдә, куышка керәбез.

— Ник?

— Шигем бар.

— Нәрсәдән шикләнәсең?

— Юанлыгыңнан. Персидәтел әмере буенча — тентү.

— Шигеңне куышка кермичә дә бетереп була. Күрсәтимме?

— Куышта күрсәтерсең. Әйдә — кер.

— Башкаларны монда чишендерден бит, ни өчен мине генә куышка өстерисең?

— Аларны мин чишендермәдем. Үзләре... чишенде, су керергә төшешләре.

— Мин дә үзем чишенәм. Яшерер нәрсәм юк...

— Тукта, юләр, нишлисең син?

— Мә, кара, күр: биш айлык!

— Көмәнең?!

— Көткәнем!

— Мәсәбыйх китеп үлгәнгә ике ел тула. Кемнән?

— Менә анысы сер.

— Барыбер әйтәчәксен бит.
— Кемгә?
— Таныклык алганда, силсәуиткә.
— Анда син дип әйтермен: «Мингали Сәфәров» диярмен.
— Нужәли әйтерсең?
— Синең мине яратып йөрүеңне бөтен авыл белә...
— Синең мине яратмаганыңны да беләләр шул, Хәдичә.
— Алайса, син риза түгел?
— Көлмәгеңне киеп сөйләш!
— «Риза» дисәң киям.
— Димәсәм?
— Димәсәң дә киям.
— Риза!..
— Шуннан? Инде рәхмәт сүзе көтәсеңме?
— Синең дә «риза» дигәнеңне көтәм. Мина чыгарга.
— Мингали абый, ул сүзне әйтер өчен ярату кирәк. Яратуның ни икәнен беләсеңме соң син? Яратканың булдымы?
— Шуның газабын кичерәм.
— Ярату газабы мәхәббәт дип атала, Мингали абзый, ә мәхәббәт ике якның бер-беренә сүзсез тартылуы ул. Магнит тарткан кебек... Нинди көч аларны бер-берсенә тарта? Күзгә күренми... Кулга тотып булмый. Мәңгелек сер. Үпкәләмә, зинһар..
— Баланың атасы Мингали калырмы?
— Мингали абзый, син мине Галиябануга тиңләдеңме?
— Бөтен авыл сүзе.
— Ярый, шулай да булсын.
— «Булсын» түгел — шулай «булган!»
— Шулай булгач, күз алдына китер: әгәр Галиябану Хәлилгә Исмәгыйльдән авырым бар дисә — Хәлил нишләр иде?
— Галиябану андый түгел.
— Ә мин «андыймы»? Ягъни, бер кәнтәйме?
— Мин, бары тик синең «җилдән туачак» баланның атасы исемен күтәрергә рөхсәт сорыйм. Яманатың чыкмасынга, мәхәббәтем хакына.
— Үз атасы күтәрер.
— Күтәрер егет булса, син аның кемлеген яшермәс идең. Ул бәндә корсаклы булуыңны белми, яисә, беләсе килми...
— Башкача булу ихтималы юкмы?
— Анысы минем тәкъдимгә ризалашу.
— Үз тиңеңне тап, ялынып түбәнсенмә.
— Табылган: ул син.
— Әкән хатыны булып яшисем килми шул.
— Ялгышасың.
— Ялгышсам — сиңа үпкәләмәм.
— Мин үз дигәнемә ирешәчәкмен.
— Мин ирештем инде.
— Күрербез.

Әкән әкәнең, үчләшеп, нидер кылуыннан куркыпмы — икенче көнне Хәдичә апа һәм 3-4 хатын урактан... кайтмады.

Кичә күргәннәрне матурлап сөйләгәч, куыш янына бездән олырак малайлар да «спиктәкел» күрергә менгәннәр иде. Уракчыларның соңгылары капкадан узуга, малайларның күбесе, нәүмизләнеп, кайтырга кузгалды. Әкән аларга: «театр иртәгә булыр», — диде дә, Фәндил белән мине, үз янында калдырып, «шпиун»лык бурычы йөкләде. Мин «тегенең» өендә уты янамы,

юкмы — шуны карап килергә тиеш булсам, Фәндил, үз әнисеннән, кемнәрнең уракта булу-булмавын белергә тиеш иде. «Тегенең» өендә ут булмагач, мин шунда ук Фәндил артыннан чаптым. Күпме көтсәм дә ул чыкмады. Дөресе — аны әнисе чыгармады, өстеннән бикләп, үзе Әкәнгә китте.

Кача-поса куышка килеп җиткәндә, Суфия апай Әкәнне кыздыра иде:

— Адәм хурлыгы... Имеш, аның кеше баласына ата буласы килгән... Ата булыр өчен иң әүвәл аталыгың булырга тиеш. Бармы соң ул синең?

— Күрсәтимме?

— Күренергә яратмый ул, тизрәк качарга тырыша... Җылыга!

— Качырабыз, давай, ят!..

— Менә хәзер хатыннар җыйналып менәчәк, шунда качырганыңны карарбыз, син генә безне тентергә димәгән...

— Мин идарә карарын үтим. 1932 елгы «өч башак» законын хәтерлисеңме? Идарә шуңа таяна.

— Ә без ил карарын үтибез! Әнә, бүген синең хурлавыңа нәфрәттән 5 хатын уракка чыкмады. Иртәгә беребез дә чыкмаячак. ...«Өч башак» законы, имеш, (т...шак) законы ул.

— Ут белән уйныйсыз...

— Ә син кеше язмышлары белән.

— Сугышны мин башламаган...

— Синдәйләр аркасында сузыла ул.

— Ә сез приказга буйсынмыйсыз.

— Кая куйдың Хәдичәне? Югалтырга куштылармыни? Аның бала табуы кемгә комачаулый? Нурмысын кем ура? Синме? Безгә бүлеп бирәләрме?

Сорауларга җавап булмаса да, алар һаман ява торды. Чөнки төнге Тансыкта яңгыраган җан ачулы Суфия апай тавышына башка хатыннар да менде. Алар арасында үз әниемне дә күргәч, мин тизрәк өйгә тайдым. Әкән тарафыннан әйтелгән бер генә сүзне ачык ишетеп калдым: «Самосуд бу», «самосуд»...

Мин кайтып киткәч ниләр булгандыр — әни сөйләмәде, сораштырырга базмадым, куышта булганнар — куыш сере булып калды. Шулай да, Фаткыр Фәниле күргәннәрдән кайбер нәрсәләр ачыкланды: таң алдыннан капка шакуга уянып, тәрәзәдән караса — атын житәкләгән Әкән басып тора ди. Яланаяк, штаннан гына. Тәне, корт чаккандай, бүртеп-бүртеп чыккан, күз кабаклары шешенгән. Ул, Фәнилнең әнисе Саимә апай сораганнарга җавап бирмичә — һаман үзенекен сөйли: «воинный время законнарын күрсәтәм әле мин аларга, кычытканда үзләре ятып аунасалар да гафу итү булмаячак... Кая тизрәк балавызлы маенны сөрт!..»

Саимәттәй, белгән догаларын укып, кое суы белән коендырып, балавызлы май урынына каен тузы кайнатып ясаган таза дегет сөртеп, «тизрәк кеше бул» дип озатып калса да, Әкән әкәбез авыруының икенче көнендә дә кеше була алмый.

Ул көннәрдә безне куыш кызыксындырмый, күпләребезнең мунча мичләрендә (өйдә ярамый) сөтле ботка пешә, ә куырган бодай кесәдә.

...Без күргән тентүдән соң дүрт көн узгач «Сталин байрагы» дигән район газетасында һәм аның кушымтасы «Сугышчан листок»та Әкәнне күккә чөеп мактаган фоторәсемле мәкалә басылып чыга. Анда Мингали Шәрифҗанович Сәфәровның дошманны җиңү өчен фидакарьләрчә хезмәтеннән үрнәк алырга чакырып, «Ил байлыгын саклауда», хәтта булачак кәләшен дә кызганмады», — дип язылган була. Мәкаләнең фоторәсемендә Әкән каршысына басканы бер апай. Арты белән торса да малайларга, ягъни безгә танылa ул. Ә менә өлкәннәр танымагач, газетаны кат-кат әйләндереп яктыга карыйлар-карыйлар да, теләкләренә ирешмәгәч, кабат мәкаләдән «кәләш»нең исемен эзлиләр. — Әкәнне күреп туйган, кәләшенең йөзен күрәсе иде, кем икән, — диләр.

Озын толымнарыннан ук кемлеге танылып торса да исемен атамыйлар.

Бездән сорасалар без әйткән булыр идек тә — сорамыйлар. Ә сорамыйча сүзгә катнашучы малай-шалайга кем ышана? Житмәсә, «Әкән шайкасына»...

Чынында һәр Тансыклы «кәләшнең» кем булуын да, бу шантажның кем тарафыннан һәм ни өчен оештырылуын да белә. Бер генә нәрсәне белми алар. Исәнме?

Хәдичә, тентүләрдән соң, штраф түләп бозавын алып кайта да, аны сыерына кушып, медпунктка керә. Кан басымын үлчәтә, баш даруы сорап ала.

— Аннары, — ди Мөгаллимә апай, — өй ачкычын кайда калдырганын, сыерны көтүгә бозавы белән бергә чыгару зарурлыгын аңлатты, әҗәткә 50 сум акча сорады, 35 сум гына биргәч, үзеңә калмый, дип алмады. Тиз генә, өенә кереп, паспортын алып чыкты да «больницага киттем, тикшереләсем бар, кайчан кайтасымны әйтә алмыйм», — диде. Соңгы сүзе шул булды...

— Мәсәбихының каберен күрергә китмәдеме икән, үз күзләрем белән күрми ышанмыйм, — дип сөйләнә иде.

— Сөйләшү бер, гамәле башка.

— Фронтка китү ихтималы юкмы?

— Больницада юк, воянкомда да булмаган.

— Гарьлегеннән суга ташланмаганмы?

Тансыклылар иртән очрашканда, исәнлек-саулыктан соң, сугышка кагылышлы хәбәр-хәтер белән уртаклашсалар, кичләрен «юк, кайтмаган, табылмаган» җавабы белән өйләренә таралышалар. Сүзнең кем турында баруын, исеме аталмаса да, һәркем белә, аңлый иде.

Әкән әкә яңа хәбәр тарата:

— Мондагы врачларга ышаныч юк, акча биреп Ташкент ягындагы туганнарга озаттым, минем белән торырга күнмәсә дә балабыз исән тусын... Бер кайтмаса бер кайтыр.

Кемнәрдер, бу хәбәргә ышанып, Әкәнне кызгана, кемнәрдер көлә генә, юләр, ди. Әкән исә, мескен дә, юләр дә түгел. Терелеп дөньяга чыккан сәгатендә үк участковыйга шалтырата. Самосуд ясаучыларны утыртуны таләп итә ул. Социалистик милекне күмәкләшеп талаучыларны яклауда гаепләнмәс өчен участковый Гомәров Тансыкка килә, тикшерү эшләрен башлый. Тик, кемне генә чакыртса да, хатыннарның сүзе бер: авылыбыздагы бердәнбер сәламәт иргә нәфсебез төшеп әз-мәз назланганбыз икән — без гаеплемени? Алайса, кайтарыгыз ирләребезне!..

— Сез бит аны чишендереп кычытканда аунаткансыз.

— Бергә аунадык.

— Сез шешенмәгәнсез бит!.. Ә ул...

— Үзе чишенде, нәкъ чын ирләрчә...

—«Чишенү» димим, «шешенү» дим. Кая шешегез?

— Күрсәтикмени?

— Юк, кирәкми — чишенмәгез! Врачка күренеп, белешмә китерерсез дә — вәссәлам.

— Анысы булыр.

— Бүре дә тук, сарык та исән! Шуның белән бетте. Барыгыз, эшегездә булыгыз. Ни көтәсез? Бетте, дим.

— Юк, иптәш, бетмәде... Башлана гына әле.

Хатыннар «самосуд» ясаучыларны «утыртырга» дип килгән участковыйдан Хәдичәне таптыралар.

Ә Хәдичә... бу чакларда Тансыктан 25 чакрымдагы пристаньда пароход көтә.

Аны монда колхозларда уполномоченный буларак житмәгәнне житкереп

йөрүче райком инструкторы Хәмит Ризванович китереп, Тансыкка илтергә милиция машинасы килмичә беркая чыкмаска кушып, шкипер булып эшләүче авылдашы карамагына калдырып китә.

Урак өсте. Туктаусыз яңгыр ява.

...Иртән киләсе милиция машинасы кичкә генә килә. Ләкин ул килгәндә Хәдичә апай пароходка утырып киткән була. Шкипер бабай аның авылдашлары Мөгаллимәгә һәм Суфиягә дип язган конвертсыз хатлары белән күчтәнәч балыгын, шоферга биреп, бүгеннән дә калмый ияләренә тапшыруны үтенә. Хатта дебаркадердагы сөйләшүләр турында берни дә булмый. Бәрәңгеләрен, алгач, күпмесен кайда куярга, мал-туарларын кайсын кемгә иканен күршеләрендә ике төрле уй тумаслык итеп яза да, Хәдичә апай, бәхилләшеп, шигырьләргә күчә. Аларны укып күршеләре аңа «гүр газаплары күрмәсен» дип дога кылалар. Әкән исә, «мәрхүмәнең» авылдан чыгып киткән көненнән санап, «кырыгын» укыта, мул итеп хәер тарата.

Хәдичә юк дип, Тансыкта тормыш, яшәү тукталмый. Алай гына да түгел — почта бүлегенә участковый Гомәров тарафыннан махсус «запрос» ясала. Анда «немедленно сообщите ее адрес в органы милиции» дигән сүз булуы качып йөрмиме дигән шик тудыра.

Әкән әкә «адрес сообщать не можем, потому что не знаем кладбище, где она похоронена» дигән телеграмма суккач, «милиция шутки не любит» дигән җавап килә дә тына.

...Сугыш бетәсе елның кышы иртәләде. Игеннәрнең күп өлеше, җыелмыйча, кар астында калды. Ятимнәрнең саны һаман арта бара. Икенче ел рәттән октябрь бәйрәменә дә, 31нче декабрьгә дә «Галиябану» спектакле куелмый. Хәдичә юклыктан гына түгел. Калган рольләрне уйнарга да Тансыкта кеше табылмый. Октябрь бәйрәме җитәрәк кенә Гаташ абыйның «батырларча һәлак булуы» турында хәбәр килә. Ә Яна ел алдыннан Фәндилнең әтисе Сафуан абзый да «батырларча һәлак була». Сафуан абый «штатный Бәдри булса, аның хатыны Суфия апа Галимәбану була.

Яучы Бәдига карчыкны уйнаучы фельшер Мөгаллимә апай 8 март бәйрәменә булса да «Галиябану»сыз калырга ярамый дип, мәктәп балаларын яучылый. Тик аның планнары тормышка ашмый кала...

...Ул елны Тансыкта яз да башка елларга караганда иртәрәк килде. Халык моңа шатланды гына. Чөнки җир өсте кардан иртә ачылып, күздән урылмый калган игеннәрнең башакларын җыю мөмкинлеге бар. Аягында басып тора алган һәркем басуга ыргыла, башак җыеп киптерә дә тегермәндә он итәргә әзерли. Ашыкканнары, ярма ташында ярып, ботка пешереп ашый. Шуннан соң китә инде мәхшәр...

...Башлап ишле гаиләләр авырый. Башак җыеп, аннан ризык пешереп ашарга ярамаганны белә торып... «Андреевка» дигән урыс авылындагы участок больницасы авырулар белән тула. Тик әҗәлне больница гына туктата алмый. Тансыкның һәр өенә диярлек үлем үз тамгасын салып чыга.

...Иң беренчеләрдән булып Суфия апа белән аның терәге булган Фәндилне озаттылар...

...Бер кабергә күмгәннәр, җир туны эреп бетмәгән булган дип сөйләделәр. (Яшьтәшемне җирләргә бара алмадым, үзем дә авырып егылган идем).

Суфия апаның тагы ике сабые калды. Әтисе Сафуан абзый сугышка алынгач туган игезәкләр: Фәһим белән Фәһимә.

Әлеге дә баягы Ленин көннәре алдыннан Хәлил — Гаташ абыйның әтисе Әхмәдулла бабай белән килене Нәфисәне дә җирлиләр. Ни хикмәттер, каты авырып та Кадриясе исән кала. Көн саен булмаса, атна саен бер җеназа укыла. Район җитәкчеләре бу афәттән котылу максатында төрле чаралар күрәләр: капкаларга кисәтү язулары беркетелә, больницаларга салу ирекледән

мәжбүригә әверелә. Болар өстенә басу капкасы төбендә каравыл тору янартыла. Бу эшкә сугыштан кулын өздереп кайткан коммунист Хәтимъян абзыйны куялар.

...Жыелмый калган иген өчен персидәтел Гофран абзыйны гаепләп төрмәгә утырталар. Анын урынына Әкән әкә персидәтельлеккә сайлана. Шул ук жыелыш ахырында аңа авыл Советы рәисе вазыйфаларын да өстиләр, «каты куллы хужа кирәк, булдырсаң син генә булдырасын», — диләр. Жиңү көнен Тансык халкы үлем-төшемсез каршылый. Колхоз рәисе Мингали Сәфәров турында район газетасында «Үлемне жиңгән житәкче» дигән тагын бер зур мәкалә басылып чыга. Барысы да уңайга таба бара шикелле. Тик менә, көтмәгәндә-уйламаганда дигәндәй, Мингали Шәрифжанович өчен яна мәшәкатьләр өстәлә: авылда ятим калган балалар белән нишләргә? Кая куярга? «Детдом» дигән йортлар ятим балалар белән шып тулы, алмыйлар. Ярый ла, Суфиянең ике баласына фельдшер Мөгаллимә һәркөн кереп күз-колак булып йөри, ә башкалар белән нишләргә? Кая барып, кемнән киңәш сорарга? Әкән өчен шундый мәшәкатьле көннәрнең берсендә анын кабинетына, ягъни мәсәлән, персидәтел Миңгали Шәрифжанович бүлмәсенә конверт тоткан Мөгаллимә чәчрәп килеп керә.

— Ни булды?

— Хәдичәдән хат бар. Суфия исеменә язган.

— Ачып укыдыңмы?

— Миңа атап язылмаган ич, силсәвит ачсын.

— Дөрес эшләгәнсен. Бир монда...

— Исән икән... Галиябануыбыз...

— Анын исәнлегеннән безгә ни файда? Налуглары түләнмәгән... Ите, сөте, йоны шул килеш...

— Монда яшәмәгәч... нинди налог ана?!

— Өе тора бит! Үзе дә әллә кая китә алмаган. Сверлау өлкәсендә генә качып яткан икән...

— Тагы ниләр дигән?

— Сәламнәрен укып тормыйм... Тәк, тәк... « — Суфия апай, сиңа дөресен әйтим — барып чыкмады минем тормыш. Уйладым-уйладым да өздем араны. (Ничек өзүне кайткач сөйләрмен). Күрше Нәдершат авылы хатынына хат килде. Имеш, безнең якта кан чире таралган, ди. Каннын нинди чире булсын, жан чиредер ул? Жаным тыныч түгел. Ичмасам, баламны саклап кала алмадым. Хәзер инде кияүгә чыгу турында да, бала табу турында да хыяллану өзелде. Синен, ичмасам, ирен исән, балаларын өчәү».

... Тәк-тәк... Давай син, Мөгаллимә, болай эшлә: тот та бүген үк хат язып сал. Кайт, диген. Үлем-төшемнәр турында дөресен яз. Кайгырма, кайтсаң көтеп торучылар бар, диген.

— Сыерын суеп ашаулары турында әйтимме?

— Үзе сорамаганга кермә.

— Синең турыда ни диярргә?

— Минем хакта сорамаган бит.

— Соң син хужа!

— Үзең жайлап яз шунда, син бит безнең атаклы язучыбыз Бәдига абыстай... иден...

— Әйе, «идем». Бар иде заманалар. Барысы да үткән заманга калып бетте.

— Заманга берни булмый, замандашлар үзгәрә.

...Председатель хаклы: үзебез үзгәрәбез! Менә ул да әле кайчан гына «Әкән» иде, хәзер «Мингали Шәрифжанович»! Анын үз алдында «иптәш Сәфәров» дисәләр, артында «Хужа, Хужа ни әйтер бит», — диләр.

— Хужа ни әйтсен? Белгәнен әйтә, — диләр.

— Ә хуҗа кешенең белмәгәне буламы? — ди куштаннар.

— Хуҗа түгел — Түрә дип төзәтә кемдер.

— Түрә — хуҗа дигән сүз бит инде, — ди тегеләре, һаман куштанланып.

«Һәр хуҗа түрә була алмаган кебек, һәр түрә хуҗа да була алмый!», — ди иптәш Сәфәров, бәхәсләргә нокта куеп.

...Үз гомеренә бер китап укымаган Миңгали бу сүзләрне каян алып әйткәндер, әмма дөрес әйткән.

...Түрә дә, хуҗа да була алмый ул.

...Тансыклыларны җиңү белән тәбрикләргә, шунда ук язгы чәчүдән котылуны да «әтмичәт итәргә» Сабан туе кебегрәк җыен ясап, сугыштан кайтканнарны һәм тылда фидакарьлек күрсәткәннәрне сыйларга идарә карары чыга. Бухгалтер Шәүкәт тәкъдиме белән, табында торарга ит өчен колхозның берләнбер нәсел үгезен суярга булалар.

— Колхоз фермасында исән калган тугыз сыерның алтысы буаз, өчесе бозаулаган. Ягъни, тиз генә үгез кирәкмәячәк.

Кирәге чыккан очракта «Буденный»га мөрәҗәгать итәргә була, чөнки аларда өч үгезгә дүрт сыер, дип, ниятләрен гамәлгә ашыруда берниндиі дә киртә юклыкны ревком персидәтеле Ниязхан үзе раслагач, участковый ветеринар Билаловны махсус китертеп, үгезне «булдыксызлыкта һәм картаюда гаепләп, акт төзиләр. Ана ике кеше өчен бер кешедән кул куйдыртып (берсе уң, икенчесе сул кул белән) персидәтел Сәфәровтан пичәт бастыргач, табында утырачак кунаклар исемлеген төзергә керешәләр.

Фидакарьләр санын барлап бәхәс төн буена диярлек сузыла. Бактың исә, фидакарьлек күрсәтмәгән кеше юк икән авылда. Аның нинди мөһимрәк? Бизмәнгә салып үлчәп булмый.

Аптырагач, мәсьәләне кире ягы белән куеп карыйлар: кем фидакарьлек күрсәтмәгән?

Һәркем, көченнән килгәнчә, үлмәскә, яшәргә тырышкан. Бары шул гына. Нәтиҗәдә фидакарьләрне түгел, газеталарда исемнәре мактап телгә алынганнарны гына бүләкләргә булалар. Ә андый кеше Тансыкта берәү генә икән: Миңгали Шәрифҗанович Сәфәров! Ул, рәис буларак, болай да табын башында утырырга тиеш. Ахыр килеп, идарә әгъзаларына, сельпо персидәтеленә, участок милиционерына, мәктәп директорына һәм район житәкчеләренә табында утырмый ярамас дип килешәләр. Үпкәләшү, көнләшү гаугасы күтәрелмәсен өчен табынны урман эчендә яшерен әзерләргә булалар.

Белгән-ишеткән килер, килмәсәләр — гаепле юк. Чама белән 70 кешелек савыт-саба һәм эчемлек юнәтү сельпога йөкләнә, калганын колхоз үз өстенә ала.

— Аракыга дигән акчаны кайчан һәм кем кучерә, — дип сорый сельпо председателе.

— Минем мондый эшләрдә тәҗрибәм юк, — ди Миңгали Шәрифҗанович, — әнә бухгалтер карасын.

— Укытучыларга дигән эш хакы фондыннан силсәүит түләр, уборкадан соң колхоз аңа кучерер, — ди бухгалтер. Монда да тапкырлык күрсәтеп.

Аны мактыйлар, рәхмәт әйтәләр. Ә мәктәп директоры үзенекен бөгә:

— Мондый җаваплы мероприятиедән коммунистлар читләшә алмый, — ди ул бухгалтер тапкырлыгын партия оешмасы адресына кучереп.

Шуннан соң доклад сөйләүне парторгка йөклиләр.

— Мин болай да сүз әйтергә мәҗбүр. Докладны хуҗалык житәкчесе үзе ясарга тиеш.

— Мин коммунист түгел, сүз сөйли белмим, — ди Сәфәров киреләнеп.

— Язып бирербез, укырсың! Кирәк икән партиенный ясарбыз.

— Гарәп хәрефләре белән язсагыз укыйм.

— Монда диннең катнашы юк, причем гарәпчә?..

— Партиягез дин түгелмени? — ди Мингали Шәрифҗанович бәхәскә кәрәчин сибеп...

Ярый ла дилбегәне бухгалтер Шәүкәт тагы үз кулына ала.

— Иптәш Сафәров «дин» дигәндә Аллаһы Тәгаләне күздә тотса да, сүз башка турыда бара.

— Нәрсә турында?

— Кемгә, нинди бүләк бирәбез?

— Һәм ни өчен?

— Чәчү тәмамлану уңае белән дип язарбыз.

— Тәмамлану түгел, тукталу уңае белән, — бусы ревком сүзе.

— Өч тракторчыбыз бар: Тәгъзимә, Шәмсия, Нәсимә. Кайсын бүләклибез?

— Кайсысының тракторы чәчүдә эшләде?

— Эшләмәсә — үзләре гел шулар янында булдылар.

— Ремонтта! — ди Шәүкәт, — ышандырырлык кызып.

— Әгәр бүләкләмәсәк, тракторлар урак өстенә дә өлгермәячәк, карагыз аны...

Ниһаять, өч хатынны «Ир-егетләрне алыштырган өчен!» дип, ука йөгертеп язылган махсус грамоталар белән бүләкләргә булалар. Бәйрәм көне дип, июньнең беренче шимбәсе билгеләнә, ягъни печәнгә төшкәнче котылу хәерле, дип табыла.

...Әзерлек эше «хутлы» бара. Басу капкасына якын яланда багана утыртыла, мөмбәр сыман нәрсә корыла, ферма абзарының түшәмен сүткән такталардан эскәмияләр ясала...

«Корт бакчасы» дип йөртелгән урында олы кунаклар өчен озын-озын өч өстәл эшләнә, йөзәр литр су сыешлы ике казан асыла, балалар йорты ашханәсеннән әҗәткә савыт-саба кайтартыла.

...Җомга көнне нәсел үгезе көтүгә чыкмый.

...Эш авылның атаклы мал чалу остасы Гыйният бабайга килеп төртелә. Ә ул, нинди үгез суелырга тиешлеген белүгә, телсез һәм ушсыз кала.

...Фельдшер Мөгаллимәне чакыртып, укол кадыйлар бабайга. Күзен ачса да, авызын ачып сүз әйтәлми, урынында яткан килеш кала.

...Мингали Шәрифҗановичка өстен алыштырырга һәм үз пычагын алып килергә туры килә. Аннары, ярдәмгә бухгалтер Шәүкәтне, ревком Ниязханны ияртеп, көндезге сәгать 11 тулганда алар ябулы үгез янына керәләр һәм ...абзардан көтү кайтыр алдыннан гына чыгалар.

Кеше әйтеп, кеше ышанмас: ул көнне, ни хикмәттер, авыл көтүе башка көннәргә караганда күпкә иртә кайтты. Анда да сыерлар көтү булып түгел — аерым-аерым. Кайталар да, капкаларыннан керми — каядыр кырга таба, ферма ягына чабалар. Кигәвеннән качкандагыдай, койрыклары күтәрүле, күзләре тонган. Тансык халкы аптырауга төшә: әллә бүре өркеткәнме үзләрен? Җавапны теле кайткан Гыйният бабай бирә: «Сыер малы кан исен сизеп ярсучан була, авылда кан исе...»

Шимбә.

Бәйрәм буласы көнне авылда капкалар ачык, мал-туар үз иркендә. Тик... Сабан туе булачак мәйданда өч-дүрт малайдан башка кеше юк.

Каланчада унны сугалар. Унберне...

...Шунда гына лесхоз атын җиккән тарантаста Мингали Шәрифҗанович, Шәүкәт һәм Ниязхан абыйлар күренә... Алар мөмбәр янында сөйләшеп торалар-торалар да «Дан-сугыш һәм хезмәт батырларына» дигән лозунгны куптарып төргәч, кабат арбаларына утыралар. Шулчак кинәт басу ягыннан дулаган ике сыер чыгып, ат каршына килеп туктый.

... Һич арттырып әйтү түгел — алар атның күзләренә карап нидер мөгрәнәләр, үзләре телендә аттан нидер сорыйлар.

Ә үгез... үгезнең бер өлеше корт бакчасындагы ике казанда кайнаса, калган өлешләренең кая китүен белүче юк.

... Ат белә. Барысын күреп, ишетеп торды. Теле булмагач, нишләсен, барсын, җыеп, йота да — оныта.

... Тарантас урманга таба элдертүгә, без өч малай, өйгә карый чаптык.

... Кайтып керсәм — каян белгән, кемнән ишеткән — Хәдичә апа! Бездә!

...Сүзгә катышырга оялып, тыңлап кына торам. Аның, Тансыктан чыгып киткәч, пристаньда үткәргән көннәре турында инде беләбез. Ә менә пароходка утыргач ниләр булуын сөйләгәндә ул бер-ике җөмлә сүз әйтә дә — елый, елап туктагач — күз яшьләрен сөртә башлый. Аңлаганым шул: ул пароходта Молотов дигән шәһәргә кадәр бара. Үзе кебек эш эзләүчеләргә ияреп вакытлыча эшкә яллана. Урман кисәргә җибәрәләр. Шунда, агач басып, җитлекмәгән ир бала таба.

...Үлемнән чак калып, егерме өч көн больницада ята... Аннары, җиңелрәк эш эзләп, торф чыгару предприятиесенә килеп урнаша.

...Мөгаллимә апа язган хат килгән көндә үк расчет алып, юлга чыккан. Өч тәүлек дигәндә Тансыкта.

— Бәхетем бар икән, станцадан МТСкача кәрәчин машинасы утыртты, аннары «тәпи-тәпи»...

— Өең ничек торган?

— Ачкычымны таба алмадым, Мөгаллимә апа урынын алыштырганмы, югалтканмы — үзе өендә дә, медпунктта да юк.

— Алар Сабан туендадыр.

— Сабан туе гөрлиме?

— Гөрләргә кешесе юк бит. Ялан тулы көтүгә чыкмаган мал йөри. Котырган сыерлар бер-беренә атланыша... Ни булгандыр... — дим мин сүзгә катнашып.

— Юкны күргәнче, барны карарга иде. Ник ашамый кайттың?

— Анда ашатучы юк.

— Корт бакчасына меңәрләр. Үгез ашы шунда әзерләнә, ди.

— Нинди үгез ашы ул?

— Нәсел үгезен суйганнар. Җиңүчеләр хөрмәтенә.

— Юктыр ла...

— Мин дә ышанмадым. Олы бөтен Тансыкка бер калган үгезне суярга кайсы җөрьәт итәр икән?

— Сыерлар да тол калган алайса...

— Бәлки юк сүздер? Ите эләкмәсә, шулпасы калгандыр. Бар улым, күр, ишет.

— Калган аш сорарга мы? Булмый миннән...

— Бәйрәм ашын сорап алу да гаеп түгел. Мөгаллимәгә әйт: Хәдичә апай кайтты, ачкычын сорый, диген. Тиз йөре.

...Корт бакчасына менсәк, анда бернинди бәйрәм юк.

Берничә малай, кортлары үлгәч, бушап калган умарталарга ышыкланып, кузгалак ашыйлар. Өлкәннәр ышкыланмаган такталардан ясалган өстәлләр тирәли, ни тапсалар шуңа, утырганнар да, бухгалтер Шәүкәтне кысалар:

— Дөресен әйт: кем пычагы белән, кем чалды үгезне?

...Райкомнан җибәрелгән тикшерүчеләр ахмак түгел. Хәмит Ризванович үтенече буенча эшне зурга җибәрмиләр. Мәктәп коридорына урындыклар тезеп, кинәйтелгән идарә утырышы җыялар да, Сәфәров Миңгали абзыйны үз теләге белән эштән азат итәләр. Аның өчен гаризаны Шәүкәт язып, кулны

парторг куя. Шул көннән башлап Мингали Шәрифжанович Сәфәров кабат Әкәнгә әверелә.

Авыл Советы рәисе вазыйфасын Хәдичә апайга әйтеп карасалар да, «балаларымны ташлый алмыйм» дип тәкъдимнәрен кире кага. Шуннан соң колхоз рәисен дә, авыл Советыныкын да читтән китереп куялар. Бу традиция Тансыкта бүгенгә кадәр саклана.

***

...Хәдичә апай өч ятимне үз тәрбиясенә алуны рәсмиләштерергә берничә тапкыр район үзәгенә бара.

Аннан фактны раслаган белешмәләр сорыйлар. Шул белешмәләргә таянып, ниһаять, аңа «балалар үсеп балигъ булганчы алар мәнфәгатен яклап эш йөртәчәк кеше» дигән белешмә бирәләр. «Теләсә ничек дип атасыннар, тик балаларга гына әйбәт булсын», — ди ул. Гаташ белән Нәфисәнең сабые Кадрия аны «әннә» дисә, Суфияныкылар «әнкәй» диләр. Яшәүләре Суфия өендә. Суга йөрергә чишмәсе дә якын, абзар-куралар да, мунчасы да төзегрәк. Миче дә утынны аз ашый...

...Мәрхүмә Суфия, гадел кеше буларак, чыгымнарын-керемнәрен язып барган. «Сыерын суеп ашады» дигән сүз йөрсә дә, ул дөрес хәбәр булмый.

...«25 кило итне үземә алдым, калган 179 килосын сельпога тапшырдым, квитанциясе заем облигацияләре арасында. Мал азыгы булмады. Акчасы һаман алынмаган...

...Кем укырын белмим. Һич үләсем килмәсә дә, бу язуны язарга булдым. Фәндилем ачулана, кеше авырмый тормый, тереләбез, ди. Ә терелмәсәк? Уф... Эшнең күплеге... Бурычларымның быелгылары гына түләнмәгән. Яңа бәрәңге өлгергәч күз күрер».

...Бу язулар мәрхүмәнең кайчандыр Галимәбану ролен кучергән дәфтәрендә табыла.

Акрынлап булса да, балалар Хәдичәгә, Хәдичә балаларга ияләшә. Тормыш үз ярларында ага башлый. Кәҗә мамыгыннан шәл бәйләп сату һөнәрен үзләштерәләр. Бу кәсеп аларны ач итми, кием-салым алырга да мөмкинлек бирә.

Андреевка авылы урысыннан Кадриягә әтисенең тальянын төзәттереп алалар, ул инде анда «нәкъ әтисенчә», уйнарга өйрәнеп килә. Фәһимәсе патефон алдыра, Фәһимгә исә, тотылган булса да, велосипед бүләк итәләр.

Шулай бер көнне патефон уйнатып, өчпочмаклы солдат хатларын инде ничәнче кат укып, аларга җавап рәвешендә балалар әти-әниләренең рәсемнәрен ясап утырганда, ишек шакымый-нитми генә өйгә Әкән килеп керә.

— Ни булды, Мингали абзый?

— Ни булырга тиеш булса — шул.

— Ни булырга тиеш иде?

— Үлем.

— Әйтмәсәнә шул сүзне.

— Аны мин әйтмим — язмыш әйтә.

— Кайчан күреп сөйләштең язмыш белән?

— Ар авылына күрәзәчегә барган идем. Гомерең авылыгызның иң чибәр хатыны кулында, ди. Иң чибәр авыл хатыны син.

— Мин авыл хатыны түгел.

— Кеме?

— Шушы балаларның анасы.

— Ә минем шул балаларга ата буласым килә. Юк икән — үлем.

— Әллә берәр акыллы тәкъдим белән йөриме дисәм, һаман шул «әкәннәнүен»:

— Нинди тәкъдим күтәсең, әйт!

— Утыным бетте, берәр йөк утын китерер идең. Акчам бар.

— Атымны алдылар, ни белән китерим?

— Ирме соң син?

— Сынап карыйк.

— Әгәр шундый тәкъдимнәр белән йөри торган булсаң участковыйга әйтеп яптырам.

— Мин болай да ябулы.

— Үз язмышың — үзеңә.

— Барыбер минеке булырга тиеш син. Хакыңны гына арттырасың.

— Кем соң син? ... Әкәләсез имән.

— Әкәләсез, имеш... Син аны каян беләсең? Әйе, мин сабыр, түзәрмен. Әмма бел: син дә бер кәнтәй бит. Мин ишеттем, белдем, түздем...

— Ә менә мин түзә алмыйм: бар, ычкын, эзең булмасын бу йортта!

...Бу сөйләшүдән соң күпме вакыт узгандыр, Хәдичә апайны авыл Советының яңа председателе чакыра, дип килеп әйтәләр. Анда яхшы хәбәр белән чакыртмауларын Хәдичә апай белә. Узган ел, өч бакча бәрәңге утыртасың, дип өч хуҗалык налогы түләтсәләр, быел ике бакчасы буш, тагы ни булыр? Ник буш калдырдың дип салым салырлармы? Әллә өстәмә заем килгәнме?

Ит, сөт, йон, күкәй нормаларын үтәгәнлеккә, налоглар, самообложение, страхованиеләрне түләгәнлеккә квитанцияләрне һәм булган барлык заим облигацияләрен үзе белән ала да китә ул.

Авыл Советы урнашкан йортның аскы катында почта белән медпункт, өске катның яртысын «председатель ягы» дип йөртәләр, алгы бүлмәсендә секретарь белән салым җыючы агентлар өчен өстәлләр куелган. Эчтән тавышлар ишетелә, бәхәсләшәләр. Хәдичә апай, тыңлап утыра дип уйламасыннар өчен, урындыгын бинага керү-чыгу ишеге төбенәрәк куеп көтә.

Кычкырыш озакка сузылырга охшый...

— Нишләргә?

Сыер саугач килермен дигән уй белән урыныннан торса, ишек ачылып, бәхәсләшүчеләр күренә. Мәктәп директоры Солтанов, чыгуга, телефонга ташлана. «Әллү-әлү» дип күпме кычкырса да, җавап булмагач, председатель янына кабат кермәкче була. Тик ишек янында утырган Хәдичә апайны күргәч, «аңлашылды» дип, ялт кына чыгып та китә. Аннары председатель бүлмәсеннән фельдшер Мөгаллимә апа белән почта бүлеге мөдире Хөллия Хаҗиевна чыга.

Мөгаллимә апа туп-туры Хәдичә апайга килә:

— Ишек сакларга дип чакырдыларммыни сине? Ник, килүгә кермәдең?

— Әйтүче булмады.

— Күренергә иде!

— Кемгә?

— Яңа председательгә!

— Тагы алыштырдыларммыни председателебезне?

— Синеке дә ул. Тик... Монысы да озак тормас ахры, нәрсәгә кагылса — шул җимерек.

— Мине җимерек төзәтергә дип чакырдыларммыни?

— Утынга язу кайткан. Укытучылар исемлегенә сине дә кертергә тиешләр дип тәкъдим ясадым, чигенмә, каты тор.

— Мин укытучы түгел бит.

— Ятимнәр карыйсың.

— Ятим караучылар бер мин генәме?

— Синекеләр өчесе дә чит кеше балалары.

— Чит түгел алар миңа!

— Чит булмагач, гариза яз, бирсеннәр! Тиешләр! Фронтовик балалары алар.

Шунда почта мөдире сүз кыстыра:

— Мөгаллимә Кәшфиевна, нигә кыстыйсыз, гариза язмаган — значит, мохтаж түгел. Ул бит пособие ала, өчесенә дә!

— Ә син мохтажмы? Ирең мәктәп директоры — өч норма булмаса, ике нурмы утын ала. Шуның өстенә әле син дә сорыйсын. Нишләтмәкче буласыздыр ул кадәр утынны, валлаһи..

— Положено по положению!

Шулай ди дә, почта мөдире, ишекне каты бәреп, чыгып та китә. Шакылдаган тавышка секретарь Гәүһәр Камаевна атылып чыга.

— Ни булды? Нәрсә ватылды?

— Менә, Хәдичә килгән, ватылып...

— Утырыш беткәчме?

— Утырырга аның вакыты юк. Гаризасын язып бирә дә — балалары янына.

— Тотасыз да шул балалар белән козырәйт итәсез. Әйтерсең лә бала — орден... Беребезгә дә җинел түгел. Однако без... түзәбез...

Күкрәгенә «Почет билгесе» ордены таккан Гәүһәрнең бу сүзе Мөгаллимәне тәмам чыгырыннан чыгара.

— Орденны күп балалы аналарга бирәләр иде, балаң юк, ирең юк, сугышта да булмагансың... Нигә тактылар икән моны сиңа?

— Калинин бабайдан сорагыз!

— Ул ерак шул, белми мондагы бардакны...

— Кирәк җирдә беләләр.

— Алар белер, белергә тиеш... Бар, Хәдичә, кер, нәтиҗәсен миңа әйтерсең.

Ишекне ачып, үзен председатель бүлмәсенә керткәч, Мөгаллимә апаның Гәүһәргә: «Безнең авыл хатыннары орденнарын тагып йөрмиләр, кеше көлдермә!» — дигәнен ишетеп кала Хәдичә апа, ә менә председательнең үзенә әйткән сүзен ишетми. Анын калай белән тышланган мич каршына чүгәләп, тәмәке тарткан чагы икән.

— Нигә дәшмисез, Хәдичәбану? Үпкә асрыйсызмыни?

— Хәмит абый, җаныем-бәгърем, синме бу? Кеше үзгәрсә дә үзгәрер икән... Кулың да төзәлгән дисәм... Председатель дигәннәре синме әллә?

— Ишетмәгән идеңмени? Бүген егерме беренче көнем монда.

— Атна саен алыштырып торгач, игътибарга алынмаган, күрәсең... И-и-и, чәчең агарган, мыегың килешми.

— Мине китертүне сорап язган гаризада синең дә фамилияң булгач, мин тагы... әллә нинди хыялларга бирелгән идем.

— Хыял белән генә яшибез, барыбызда да шул хәл. Ни кирәк дисәң — шул юк. Гариза? Әмма ул гаризага мин кул куймадым.

— Хәлләреңне беләм, сөйләделәр. Ә менә кул куймавыннның сәбәбен белмим. Ачуланасыңмы?

— Әйтүче булмады. Кеше белән аралашып, чыгып йөрү гадәтем юк.

— Әйткән булсалар, куяр идеңме?

— Авыл халкы синнән зыян күрмәде бугай, куяр идем.

— Син күрдең зыянны.

— Үзе егылган — еламас, — диләр, искә төшермик. Хәзер инде барысы да тәртиптә. Синең дә шулайдыр, шәт?

— Кайда өзек — шуны ялгарга җибәрәләр. Ялганып бетми— тагы кайдадыр өзелә... Тагы күчерәләр. Тагы ертыла... шулай уза гомер. Бөке булып.

— Гаиләң белән ничек? Өзмәгәнсеңдер бит? Тәүбә-тәүбә...
— Өзәр-өзмәс. Ул килми, мин чакырмыйм. Кайта-китә йөрим.
— Ник алып килмисең?
— Буш йортында яшәп торырга рөхсәт итәрсеңме соң?
— Буш түгел ул йорт. Анда минем мәрхүм иремнең рухы яши.
— Теге чакта аның рухы чыгып торган идеме?
— Ул чакта сынган күңелне ялгаучы мәхәббәт булган, күрәсең.
— Хәзер юкмы?
— Хәзер аңа балалар хуҗа. Әгәр кабат бу турыда сүз кузгатсаң, яңа гариза язылачак. Анда инде, әлбәттә, үз кулым куелган булыр, фамилияң дә аталыр.
— Нинди гариза?
— Утын сорап түгел, билгеле.
— Кирәкмимени утын?
— Аны сорап тормыйлар.
— Син һаман шундый: «Тырт-мырт».
— Минем хәзер максатым, ниятләрем бар. Элек булмаган.
— Димәк миңа тагы моннан кучу ягына каерырга?
— Син бит үзеңне өзек ялгаучы, ертык ямаучы, диден. Ягъни, бөке. Хәбәр көт.
— Көткәндә, ярдәм итәрсеңме? Әллә дошманыма әверелерсеңме?
— Хәмит абый! Син миңа дус та, дошман да түгел. Өзек ялгарга дип җибәргәннәр икән — ялга. Без — шушы авыл кешеләре, ярдәмчеләрең булырбыз. Әмма түләүле ярдәмчеләреңнән сак бул!
Шулай ди дә, Хәдичә апа, ишекне ача. Ә анда Гәүһәр Камаевна басып торган икән. Көтмәгәндә, ишек ачылудан ул председатель бүлмәсенә ава, кулындагы карандашы идәнгә тәгәри.
— Бу ни эшең, Гәүһәр ханым? Шымчылык итәсең түгелме?
— Приемга бывший председательләрдән медальле лесник Миңгали Шәрифҗанович килгән иде. Почтага төшеп китте. Хәзер менә.
— Ник кертмәдең?
— Интимный сүзләрегез бетүен көттем.
— Чакыр, керсен!
— Мин китим, Хәмит абый, балалар көтеп зарыккандыр.
— «Ярдәм» дигәннән, Хәдичәбану, халыкны уятып җибәрәсе иде бит. Октябрь бәйрәменә өлгермәсә, 21 декабрьгә бирәр пьеса куймассызмы? Иптәш Сталинның 70 еллыгына Тансыктан бүләк булыр иде. Бөтен ил, халык бу олы бәйрәмгә өлеш кертү теләге белән яши. Без дә изге эштән читтә калмабыздыр. Спектакль булмаса — концерт. Всетаки «Сталин» колхозы.
— Кем белән?
— Укытучыларга мөрәҗәгать итәрбез, укучылар катнашыр. Нәрсәдер эшләргә кирәк иде инде. Сугыш беткәнгә дүрт ел.
— Колхозның үгезен суеп сатыгыз да... һәйкәл эшләтегез! Андый тәҗрибәләр бар монда.
— Нәрсәдән һәйкәл коярга җитәр дисең бер үгез акчасы?
— Балчыктан да, агачтан да ярый... Аның әмере белән корбан булганнар исеменнән уклар атар өчен, соңге кадар өчен...
— Шаяртасыңмы, әллә тилердеңме? Кайда икәнеңне онытма! Совет власте йорты бу...
— ...Иң беренче үзем кадар идем. Мәрхүм әткәй белән әнкәй исеменнән.
— Син бу сүзләрне әйтмәдең, мин ишетмәдем.
— Ә мин «спектакль» дигән тәкъдимеңне ишетмәдем.

— Спектакльсез калсак, безне дөрес анламаслар, Хәдичә, киреләнмә.

— Алайса, шул ук «Галиябану»га тукталабыз. Анда яхшылык белән явызлык көрәше нәкъ әнә шул 21 декабрьгә атап язгандай.

— Онытылма, Хәдичә, минем сине яклап калырлык абруем юк бүген. Дошманнарыма азык бирмә. Андый бәйрәм кичәләре чакырылган кунакларсыз узмый, беләсең, килерләр, күрерләр...

— Синең дошманың — үзең, Хәмит абый. Иң элек үзенне җиң син. Килештекме?

— Алайса, куегыз үзегез теләгәнне! Ләкин минем исемне катнаштырмагыз. Инициатива сездән.

— Ирләр ролен кем башкарыр икән? Авылда ирләр юк.

Шушы сүзне генә көтеп торган диярсең — ишектә Әкән күренә.

— Ничек инде олы бер авылда ирләр булмасын? Әнә берсе! Кемнән ким? Сәфәров. Әйдә, уз!

— Рәхмәт, иптәш Хәмит Ризванович... Шуны гына әйтер өчен чакырдыгызмы?

— Мин сезне чакырмадым.

— Почтальон кереп әйтте, хәзер үк яңа персидәтел көтә, диде. Чакырмасаң да киләсем бар иде барын.

— Хәмит абый, мин китим.

— Китмә, Хәдичә. Үз алдыңда әйтәм. Әгәр сүзегез теге чактагы сурәтле гәзит турында барса, анда минем гаебем юк. Куштылар — тентедек. Гофран кушты. «Өч башак» законы... Заманы шул иде. Ләкин анда язганнар барысы да хак. Минем яратуым да...

— Карале, кем — Миңгали Шәрифҗанович, мин синең ни турында сөйләвеңне аңламыйм. Бернинди гәзит турында ишеткәнем юк. Ихтимал, мине башка районга күчергәч булгандыр. Әгәр мөмкин булса, синнән бүген бер генә нәрсә сорала: ирләр кирәккәндә ярдәм итсәң иде, клубка..

— Ул бит мине «әкәләсез имән» ди?

— Ә кем соң син?

— Сиңа ярдәм итәргә теләүче гашыйк ир!

— Әнә спектакль куячаклар. Ирлегенне шунда күрсәтерсең.

— «Галиябану»ны куйсалар, болай да минсез куя алмыйлар. Чөнки авылда мылтык миндә генә.

— Килештек: мылтык ату синең өстә.

— «Служу СССР!»

— Эт син!

— Менә шушы сүздән соң минем мылтык атарга тиеш.

— Тик зинһар өчен, талаш-ызгышсыз гына.

...Яңа председатель шулай дисә дә, талашсыз гына булмый. Боларына үзем шаһит. Бигрәк тә Хәлил белән Исмәгыйль рольләренә артист билгеләгәндә температура «критическая»ны уза. Ниһаять, ике рольне дә хатыннар — Мөнәвәрә апа белән Сөембикә апа уйнарга ризалашкач кына тынычландылар. Бу юлы мин дә зуррак роль сорап алдым. Без инде «Садри»лыктан чыккан, күптән «Хәмзә»леккә күчәрлек, — дигәч, ризалаштылар. Шуңа өстәп миңа мылтык шартлату бурычы өстәлде. Аңлавымча, Әкән әкәдән бәйсез булу өчен. Моңа кадәрле куелган спектакльләрдә бу вазифаны Әкән әкә башкарса, монысына аны катыштырмауны Хәдичә апа шарт итеп куйды.

Пьесаның эчтәлеген авылда һәркем яттан диярлек белә. Хатын-кызларның күбесе Хәлил белән Галиябану җырлаганда, кайсы куплетны кайда күчереп, ничә куплетны төшереп калдырырлар икән дип, сынап-санап утырса, малай-шалайлар исә шул мылтык ату «могҗизасын» гына көтә, дөресрәге, гел шуны күрергә генә дип киләләр.

***

...20 декабрь. Иртәгә бәйрәм. Спектакль әзер. Районнан килгән «пулнамучилар» кереп утырган. Теге фотограф — гәзитче дә килгән. Председательнең «башлагыз» дигән сигналы гына кирәк.

Кемдер: «Утларны балкытыгыз», — дип акыра. Кемдер сәхнәгә менеп, кешеләрдән алып торган лампаларны боргалап маташа, шунда берсенең куыгы шартлый; кемдер «харап иттеләр бердәнбер куыгымны дип сүгенә, шулчак «башлагыз» дигән тылсымлы сүз яңгырый.

Райком вәкиле, сәхнә алдына басып, Иосиф Виссарионовичның биографиясен сөйли, аның җитәкчелегендә ирешкән уңышларны «саный».

Кемдер: «кәрәчин бетә», сузмагыз дип кычкыра.

Вәкил: «Иптәш Сталин яшәгәндә бернәрсә дә бетмәячәк!» — ди.

Кемдер: «Ачлык тамы?», — ди, халык көлә, вәкил ишетми, «Яшәсен Сталин!» — дип сәхнәдән төшә. Халык кул чаба һәм башлана!.. Яңалык шунда: бу юлы «Галиябану» көен ике тальянда, парлап, сукыр Наил белән Гаташ кызы сигез яшьлек Кадрия уйныйлар. Элек Гаташ абый үзе генә уйный иде.

...Спектакль шома гына барган кебек. Сүзне онытсалар — залдан әйтеп җибәрәләр. Кайбер урыннарында кемдер: бар сүзен дә сөйләп тормагыз, ахырын гына әйтегез, дип кычкыра. Сәхнәдәгеләр, әллә каушап, әллә юри бер сөйләгәннәрен кабат сөйлиләр. Буталыш булып ала. Шулай да «спиктәкел» алга бара. Ниһаять, соңгы пәрдә, соңгы күренешләр. Лампалар шуны сизгән күрәсең — икесе «лып» сүнә. Бер генә лампа кала, сәхнә караңгылана. Соңгысының гына кәрәчине бетмәсә ярый... Юкса дөм караңгыда уйнарга туры киләчәк. Тансык театрында андый очраклар булгаласа да, бу спиктәкел үтә дә җаваплы, «ЧП»ларга урын юк. Әмма «ЧП» шуңа күрә дә «ЧП» — ул гел көтмәгәндә килә. Кинәт өченче лампа да куыгы ватылып, сукырая. Карангыга күз ияләшкәнче «артистлар» тукталып кала. Сөнгатьне уйнаучы малай молодец — әтәч булып кычкыра, әпә Рәшит эт булып өрә. Сәхнәне чын ай яктысы яктырта башлый. Нәкъ кирәгенчә!

Сугышка кадәр куелган «Галиябану»ларда тәрәзәдән сикерүче Хәдичә апайны Гаташ абый тотып ала иде дә сәхнәнең каршы ягындагы агач сурәте төшерелгән пәрдә артына качалар иде.

Шул рәвешчә, Хәдичә апайны колачына алмакчы булып, Мөнәвәрә апай да (Хәлил) «өй артына» килеп баса, авызына ике бармагын каба. Килешү буенча бу урында Әпә Рәшит сызгырырга тиеш: ә сызгыру юк! Рәшитне эзлиләр. Залда өч-дүрт урыннан сызгыру ишетелә, кемдер эт булып өрә. Ниһаять, Хәдичә апа чаршау артындагы өстәлгә куелган урындыктан сәхнәгә сикерә... Тик Мөнәвәрә апа аны тотып кала алмый, икесе дә егылалар. Уйнап түгел, чынлап егылалар. «Бирнә» төенчеге чишелә, муен төймәсе өзелеп, гәрәбәләре идәнгә тарала... Хәдичә апайның чәкән сеңере тартыла. Сәхнә артында качып торган Исмәгыйль (ягъни, Сөембикә апай) ярдәмгә ташлана, Хәдичә апайны аягына бастырмакчы була, Мөнәвәрә апай (Хәлил) аны этеп җибәрә, эткәләшә-төрткәләшә башлыйлар, шунда Исмәгыйльнең (Сөембикә апайның) тиредән кисеп ябыштырылган мыегы куба, халык шуны гына көткәндәй, көлә.

Сөембикә (Исмәгыйль): «Нишлисең син, дивана, мин бит... Хәдичәне...

Мөнәвәрә (Хәлил): «Хәдичә түгел — Галиябану!», — ди.

Залдан: «Бутамагыз!» — дип кычкыралар.

Мөнәвәрә апа югалып кала торганнардан түгел — залга карап бер адым ясый да: Без — үзебезчә! (Аннары ачу белән Сөембикәгә таба борыла) «Ни кирәк сиңа?» — ди.

Исмәгыйль (Сөембикә): «Җибәр Галиябануны!» — ди.

Залдагылар: «Төшереп калдырмагыз!» дип кычкырса да, сәхнә елгасы үз

ярларында ага. Шул арада Сөембикә апа, мыегын табып, иренена беркетеп өлгерә (пешек сагызы кипми). Бу юлы мыек очлары өскә таба тырпаеп калса да, залдагылар сызгырмый, «үзләренчә» булгач, шулай кирәктер дип, револьвер өчен көрәш һәм атышу күренешен көтә. Тансык тамашачысы өчен спектакльнең нәкъ шушы төше — иң кискен сынаулар урыны, ягъни үзенә бер төрле «вермут» өчпочмагы. Шушында житкәндә рольләрне башкаручылар да, тамашачы булып утыручылар да уенны чынга, чынны уенга саный башлаган була. Ягъни, сәхнә белән чынбарлык чикләре югалып, тамашачы сәхнәдәге «эшкә» турыдан-туры «тыкшына» башлый.

...Минем өчен тарихи бу тамашада Әкән мылтыгы түгел, ә бакыр көпшәдән кисеп, үзем ясаган күкерт «наганы» шартларга тиеш иде. Анын өчен мин әнинең яшереп куйган алты кап шырпысыннан тыш, малайлардан да унар-унар шырпы җыеп, күкертләрен кырдым. Бар да әзер. Хәлил, ягъни Мөнәвәрә апа Сөембикә апага, ягъни Исмәгыйльгә: «Эт син!», — дигәч, мин корылган пугачның нечкә тишегенә ут төртергә тиешмен.

Ә «наган», чыра утын тидерүгә, «чаж-чож» итеп күкерт тишегеннән очкыннар чәчә дә... тына. Шартлау юк. Төтене генә күп.

Залдагы халык һаман колагын тотып, башын иеп шартлау көтә. Сәхнәдәгеләрнең сүзләрен ишетмиләр, йөзләрен күрмиләр. Алар өчен хәзерге моментның иң мөһиме — шартлау. Ул юк. Сәхнәдә Мөнәвәрә апа Сөембикә апаны куып йөри. Хәдичә апай бер агарып, бер кызарып миңа карап тора, ә мин Рәшиткә күрсәтәм. Янәсе, ул бит шырпы сызмады.

Шул арада залдагы халык башын күтәреп сәхнәгә карый, анда һаман куышып йөриләр.

— Әкән кая соң? Нигә атмый һаман?

— Бүген килмәгән ул.

— Как килмәсен? Әнә тора ич, мич артында көтә.

Залда утырган һәркем Әкәнгә таба борылып:

— «Эт син!» — дип кычкыра.

Мич артында ут көпшәсе күренә: көчле шартлау яңгырый; уң як диварга эленгән рамлы портрет, кадагыннан ычкынып, идәнгә төшә, пыяласы челпәрәмә килә...

... Халык спектакльдән бик тә дулкынланып, бәхәсләшә-бәхәсләшә, кемдер Хәлилне, кемдер Галиябануны гаепләп, акрын гына өйләренә тарала:

«Мондый спиттәкел күргән юк иде әле»...

«Барсы да уйлап эшләнгән».

«Эшләнмәгән».

«Хәлил тагын ялгышты, вәт дурак»...

«Лампаларына кадәр төгәл сүнеп, мылтыгы да кирәгенчә көттереп шартлады.

«Сталинның нәкъ вакытында егылып төшүен күр син. Чын театрдагыча булды!»

«Егылып түгел, атып төшерделәр».

«Кычкырма тиле, күрмисеңмени тыңлап ята. Ватылса да ишетеп ята ул!»

Залда калганнар, дәшмәсәләр дә, барысын да ишетәләр. Тәрәзәләрдән төшкән ай яктысы белән генә яктыртылганлыктан, алар әкияттәге албастылар кебек күренәләр. Шомлы тынлыкны Хәмит Ризванович тавышы ярып уза:

— Авыл Советы депутатлары белән идарә әгъзалары бирегәрәк күчеп утырыгыз. Гәүһәр Камаевна, протокол язып барырга туры килер, избачтан лампа алып керсеннәр.

— Избач лампасы грим бүлмәсендә, идарә әгъзаларыннан берәү дә юк, депутатлардан мин генә.

— Ничек инде син генә? Мине санга санамыйсыңмыни?

— Син үзең безне санга санамыйсың, Миңгали Шәрифҗанович. Безне генә түгел, хәтта юлбашчыбызны...

— «Тсс! Ти-хо!»

— Нәрсә «хәтта»? Әйтеп бетер! Нәрсәсе « тсс»?

— Әйтелер. Утыр.

— Утырмасам?

— Утыртырлар!

... Бераз вакытка тынлык урнаша. Райком вәкиле янына гәзитче фотограф белән ана ияреп йөрүче корреспондент күчеп утыра. Гәүһәр Камаевна сәхнә артындагы почмактан сукыр лампа алып чыгып, аны эскәмиягә куя.

Бу инде утырыш башлануга әзер дигән сүз.

Кышкы тынлыкны ара-тирә йөткергән тавышлар гына боза. Ниһаять, медальләр колодкасы беркеткән погонсыз кителен каптыра-каптыра, райком вәкиле торып баса.

— Шушы булдымыни «Сталин» колхозының иптәш Сталинга бүләге?

— Хәзинәдә булганы шушы инде...

— Юк, Хәмит Ризванович, сез әле хәзинәгездә булганның барын да күрсәтмәдегез. Бүген сез юлбашчыбызның портретына аттыгыз, иртәгә Совет властенә каршы атмассыз дип кем гарантия бирә? Партоешма секретаре кая? Ну-ка его сюда...

— Корымнарын сөртә, ул староста булып уйнады.

— Партоешмага сөртелгән корымны алай гына жуя алмас! Чыксын!

— Мин пәрдә артында гына, ишетеп торам барысын да.

— Кем кушты сезгә антипартийный пьеса куярга? Житмәсә, ирләр урынында гел хатыннар? Бу нәрсәгә киная?

— Бәйрәм саен шуны уйныйбыз ич...

— Яңа буын ирләр өлгермәгәч, нишлик?

— Юлбашчыбызга моның ни катнашы бар, ягъни аның 70 еллыгына?

Пәрдәне ачып, залга Хәдичә апа чыга.

— Бер катнашы да юк! Пьесада сүз намус, вөждан, кешелеклелек турында бара. Юлбашчыга бер катнашы булмаган төшенчәләр алар.

— Кайда язылган бу сүзләр?

— Әле генә үзегез әйттегез: «Юлбашчыбызга ни катнашы бар моның?»— дидегез.

— Демагогия бу! Сталин безгә жиңү тәэмин итте, хәзер кызу темплар белән илне торгыза. Ә сез публично ана экзекуция — казнь оештырасыз...

— Мин партоешма житәкчесе буларак шуны белдерүне кирәк саныйм: иптәш Сталин портретына атуда артистларның бер катнашы да юк, иптәш вәкил... без сәхнә артында идек.

— Күкерт мылтыгыбыз шартламагач залдан аттылар аны. Миңгали Сәфәров, ягъни.

— Ә миңа бөтен тамаша залы «эт син» дип кычкырды! Бу — сигнал.

— «Эт син» — «ат син» дигән сүзмени? Бу сезнең парольме?

— Шуннан соң мин атарга тиеш сүз ул. Кая, китабыгызны чыгарыгыз, карагыз. Гомер-гомергә, элек-электән шулай килешенгән: «Эт син»нән сон ату!

— Ах, заговор? Фетнә? Алдан килешү буенча? Сөйләшеп?

— Килешү буенча! Мин гомер-гомергә түшәмгә аттым. Ә Сталин... бер башымны ашаган иде, каһәрең, әйтерсең шуны гына көтеп торган, тагын мине элэктерде, ләгънәт төшкере — «гөрест». Кадагы штукатуркага аз кергән аның. Житмәсә рамының ике ягына авыр саплы ике флаг кадаклаганнар. Карагыз, шушы кадәр йөкне кадак кына тотамы? Ике пот булыр, валлаһи.

— Миңгали Шәрифҗанович, давай акланмыйк, теге чакта да, ягъни сугыш

беткән елны да юлбашчыбызның портреты белән яндың син, лутчы, дөресен әйт: ялгыштым, диген, гафу үтен...

— Ялгышмадым! Миңа әйттеләр. Бөтен зал: «Эт син» диде.

— Ә кем сиңа мылтык алып килергә кушты?

— Анысын Хәмит Ризванович кушты, кәнсәләргә чакыртып әйтте.

— Мин сине чакыртмадым, үзең килдең...

— Килдем шул! Шунда син әйттең: «Ир бул, ярдәм ит!— дидең. Ярдәм йөзеннән аттым. Миннән булсын яхшылык, дип. Харап булган икән. — Егылып төшкән! Эленеп торуы шулай гына булган. Бүген төшмәсә иртәгә төшәр иде... Шкатуры шкатур булса икән, әрмәннәр алдап киткән ак балчык бит, карагыз.

— Иптәшләр! Монда кулагәне миңа бору омтылышы сизелә. Мәсьәлә бик житди. Бу эш алдан уйланып, берничә кешенең катнашында башкарылган. Дөресен әйтергә кирәк, бу эшләрнең башында Хәдичә торуында минем бүген шигем юк. Әйе, совет властенә үпкәсе бар, ачуы да бар. Ул гына да түгел, юлдашчыбыз Сталинга шәхси үче барлыгын ул миңа үзе әйтте. Әлбәттә, мин аңа ул чак ышанмадым, шаяртадыр дидем. Бусы минем сәяси сукырлыгым. Мәсьәлә үтә дә житди. Шуңа күрә бу эшне, детально язып, органнарга тапшыруны мин үземнең коммунист бурычым дип карыйм. Бүген үк. Хәзер үк.

— Менә хәзер әйтәм инде алайса, иптәш Хәмит Ризванович, әйтәм... Әйтми калу ярамый.

— Әйт, Миңгали Шәрифжанович, партия ишетә дә, хәлгә дә керә белә. Яз, кем Гәүһәр Камаевна, бер сүзен дә төшереп калдырма.

— Мылтыгымда патроным берәү генә иде, анысы да ядрәсез, дары белән генә корылган. Әгәр берсе ядрәле булса — анысын сиңа гөрселдәткән булыр идем. Эт икәнсең, ә юк, эт үз баласын тешләми. Син тешләү түгел, ашарга әзерсең — тфу! Хәсис.

— Сез минем балаларым түгел.

— Шунысына Аллага шөкер. Сиңа «әткәй» дияр кеше юк.

... 1949 нчы елның 20нче декабрендәге тамаша «Галиябану»ның Тансык сәхнәсендә соңгы куелышы булса, Хәдичә апайның да сәхнәдәге соңгы чыгышы була.

***

... Елның иң кыска көне, иң озын төне...

... Бу көн, бу төн минем өчен дә истәлекле. Шушы төндә мин балалыктан яшүсмерлеккә күчүемне жаным-тәнем белән тойдым. Юктан да кызык табып, тормыштан гел рәхәтлек кенә, мәзәк кенә эзләп йөргән өмет белән тулы хыялый чордан көтелмәгән сынаулар белән тулы кырыс чынбарлык чорына күчү көне иде ул.

21нче декабрь иртәсендә әткәй белән мине мәктәп директоры Солтанов абый бүлмәсенә чакырталар. Анда участковый милиционер Гомәров утыра. Шырпы мылтыгы ясарга бакыр көпшәне каян алганы турында сорыйлар. Аны, каян алуны, авылның кайсы малаеннан сорасаң да әйтерләр иде, ни өчендер миннән генә әйттерәләр.

— Ташландык алма бакчасы чокырында күптән батып калган трактор радиаторыннан, — дим моңа, ихластан.

— Аның радиаторы юк.

— Мин алганда бар иде.

— Ничек алдың?

— Игәү белән кисеп.

— Калган өлешен кайда ташладың?

— Калганы калды.

...Гомәровның хөкеме каты: ничә еллар буена сазлыкта тутыгып яткан тракторны ремонтлап аякка бастырырга, яисә мәҗбүри эш эшләп трактор хакын түләргә дигән акт төзеп, эткәйнең шуңа ризалык имзасын куйдыралар. Эткәй-мәрхүм, үлгәнче шуны түләде.

22нче декабрь... кичендә СССР халыклары «Иң кадерле кешеләреннән иң сөеклесенә» 70 яшь тулуны бәйрәм итәргә әзерләнгән «бәхетле» сәгатьләрдә Тансыкка ике ябык машина килеп, берсенә Хәдичә апайны, икенчесенә Әкән әкәне утырталар да, район үзәгенә таба юнәләләр. Шул китүдән 1954 елның җәенә кадәр аларны күрүче дә, ишетүче дә булмый. Хәдичә апа тәрбиясендәге өч ятим сабый балалар йортына озатыла, өйләре авыл Советы карамагына күчә. Аларның язмышы белән кызыксынучыга авыл Советы рәисе булып Хәмит Ризванович урынына менгән Гәүһәр Камаевнаның җавабы әзер: «НКВДдан сорагыз»

Бу хәлләрдән соң ярты гасырдан артык вакыт узгач, йөзен үзгәрткән НКВДдан түгел, ә вакыйга шаһитларыннан сорыйсы килә: шундый хәлләр кабат булмасынга саклану чаралары күреләме? Әллә инде, ул вакыттагы кебек гаделлек, игелек, шәфкать, ихласлык, татулык, тугърылык, бердәмлек дигән төшенчәләр һаман тоткынлыктамы? Инде бу төшенчәләргә амнистия игълан ителеп, күңелдәгене киная белән булса да әйтү мөмкинлегенә ирешкәч, күргән җәбер-золымнар өчен һаман шул бер манъякны гына гаеплибезме?

Көз житкәч җылы якларга очып китеп баручы кыр казлары тавышын ишеткән йорт казлары, аларга иярмәкче булып, талпыналар, ләкин җирдән аерыла алмыйлар. Канат каурыйлары да житлеккән. Нигә соң күтәрелеп китә алмыйлар? Чөнки очу сәләтен югалтканнар алар.

Тансыклылар нәселдән-нәселгә, атадан-балага күчеп килгән игелек, шәфкать, гаделлек сыйфатларының үзләрендә барлыгын белсәләр дә, инде менә ничә еллар буе аларны тормышта тулысынча куллану мөмкинлеген тапмыйлар. Кеше, кайчандыр, койрыклы булган. Кулланылмагач, ул беткән. Шул хәлнең кабатлануы түгелме бу?

Спектакль барышында Хәлил белән Галиябануга төрле киңәшләр биреп утырулары, алардагы гаделлек тә, шәфкатьлелек, игелек тә оча алмаган йорт казлары талпынуын хәтерләтә. Моның шулай икәне Хәдичә апайның төрмәдән кайткач күргәннәрендә дә чагыла.

Бер гөнаһсызга биш ел төрмәдә утырып кайтуына аның йорты, авыл Советы карары белән Гәүһәр Камаевнага бирелгән булып чыга. Бик табигый рәвештә Хәдичә апа үз йортына үзе хуҗа булыр өчен авыл Советына гариза язып бирә. Мәсәбих абый белән Хәдичә апай, яратышып өйләнешсәләр дә язылышу кәгазен алырга өлгермиләр. Шуны сәбәп итеп, ул үз йортында яшәүдән мәхрүм ителә. Нишләргә? Кемгә барырга? Хәмит Ризвановичны, Хәдичә белән Мингалигә ябык «суд» булганчы ук, партиядән чыгарып, эштән куалар. Хәзер аның кайдалыгын да белүче юк. Бердәнбер чара — авылдашлары исеменнән республика газеталарына хат язып, имза җыеп, ярдәм сорау. Шул максат белән ул иң авыр чакларында да ташламаган Мөгаллимә апасына бара. Медпунктта кеше юк чакны туры китереп керсә, — Мөгаллимәне алыштырып куйганнар диярсең. — Хәдичәне танымый ул.

— Ни булды, Мөгаллимә апа?

— Анысын син үзең белергә тиеш: ни булды соң?

— Менә кайттым.

— Каян?

— Мин бит сиңа яздым: зинданнан! Җавабың булмаса да, хатларымны алганыңны беләм.

— Синнән хат килгәч, мине кайларга чакыртуларын беләсеңме?

— Аңа мин гаепleme?
— Жилсез яфрак селкенми.
— Миңа нишләргә хәзер?
— Нишләсән дә эшлә, тик бүтән монда кереп йөрмә. Дару кирәксә, башка кеше аша сорат. Булса — бирермен.
— Өенә килсәм?
— Харап итәсең. Монда кергәнеңне дә Гәүһәр Камаевна белмәскә тиеш.

Мөгаллимәдән чыккач, Хәдичә апа Мөнәвәрә апага бара. «Хәлил»гә. Өйдә икәнен белеп, мал-туарлар абзарга ябылып, эшләр беткәч бара, капканы ачмыйлар.

Сөембикә апага туктала. Ул хәзер мәктәп директоры булган, төпле киңәшен бирер, ярдәм итәр дип өметләнә.

Без инде ятарга жыенабыз, гафу итегез, дип ишеген ачмый.

Беткән баш беткән дип, теге елларда тентелү турында мәкалә язган фотограф-корреспондентны эзләп, район үзәгенә китә Хәдичә апа. Һәм... уйламаганда-көтмәгәндә үзенә теләктәш-ярдәмче таба. Аңа аһ-зарын, ниятләрен, балалар йортыннан нарасыйларын алырга теләвен барсын-барсын сөйли. Нәтиҗәдә, республиканың иң абруйлы газетында «Галиябануны кем күпсенә» дигән мәкалә басылып чыга һәм, шуның белән бер үк вакытта диярлек, Тансыкка авыл Советы һәм аның карамагындагы учреждениеләрнең эшчәнлеген тикшерергә өч кешедән торган комиссия килеп төшә. Бу чакта, әткәй үлеп, без әнкәй белән икәү генә яши идек, өйләре иркен дип комиссия әгъзаларын безгә фатир керттеләр.

Ун класс бетереп аттестат күтәп йөргән чагым. Көн дә диярлек избач тирәсендә чуалам. Комиссия, күбрәк шунда утыра, почтаның, медпунктның, мәктәпнең кочак-кочак кәгазьләре избачка күчеп, шунда тикшерү уза.

Минем бөтен курыкканым — әткәй үлгәч тукталган трактор өчен түләүнең яңару ихтималы. Ничектер, жай чыгарып, Нәүфәл исемле комиссия әгъзасыннан: «Колхоз кәгазьләрен тикшермисезмени, дип сорарга жөрьәт иттем. Минем соравыма сорау белән генә жавап бирде ул:

— Берәр шигегез бармы?
— Бер генә түгел.
— Документларны соратып алсак, ярдәмчебез булырга ризамы?

Курыксам да ризалаштым.

Әллә кая сикермичә, бик тирәнгә чуммыйча минем дә ярдәмем тиеп, тикшерү комиссиясе ачкан ачышларның бәян ителүче вакыйгаларга бәйләнешләрен генә атаганда, алар өчәү:

1) Хәдичә апайны кулга алып, балаларын детдомга озаткач, тиешле пособие акчасы, Тансыкта юк кеше исеменнән үзләштерелеп яткан.

2) Кан чиреннән үлгән ике әбигә шушы көнгәчә пособие түләнгән.

3) «ЧТЗ» дип йөрткән списанный тракторны, күз көеге булып ятмасын дип, детдом 1939 елда ук колхозга биргән. Документсыз тракторны, кабызып карасалар да, эшләтә алмаганнар. Сугыш башланган язда утыртылган алма бакчасы да, аңа беркетелгән тимер ат та онытылган. Спектакльгә мылтык шартлау тавышы кирәк булмаса, аны мин дә хәтерләмәс идем.

Күрәчәк — күмер ашатыр, ди. Әткәй мәрхүм шул списанный трактор өчен күпме сүз ишеткән, күпме штраф түләгән!

Штрафның хезмәт көне исәбенә тотылуын документлардан белсәм дә, әткәйнең сигез ел буе сазлыкта тутыгып яткан тимер өеме өчен мәҗбүри эш эшләүдән кичергән рухи газапларын күз алдына китергәндә, өшеп-туңып киткәндәй булам.

Ә колхозның утта янмас, суда батмас баш бухгалтеры Шәүкәт ага

Фазылыч көлә: «Хезмәт көне исәбенә котылып калуына сөенергә кирәк. Хезмәт көне нәрсә ул? Фикция! Ноль! Юлбашчыбызга рәхмәт укый-укый һәммәбез дә бушка эшләдек».

...Һәммәбез дә булмаган икән шул. Эшләү бушка булса да, корсак бушлыкны яратмый. Ирексездән, кеше үзенекен үзе урларга мәҗбүр ителә. Шулай, ниятләр гамәлдән аерыла, үз ялганына үзең ышану — яшәү нормасына әверелә. Бу авыруның вируслары, иктисадый-сәяси мохиткә яраклаша-яраклаша, безнең хәзерге көннәргә кадәр килеп житә. Статуслары законлаштырылып, үрчер өчен шартлар тудырыла, кылган гамәлләре мактала. Эш шуңа килеп житә, талау, урлау, алдау — «бизнес, коммерция» дип; ә буш сүз, ялган вәгъдәләр — мәгълүмат дип атала.

Акны — кара, яманны — яхшы, юкны — бар дип сөйләү бүген беркемне дә гаҗәпләндерми.

Ә элек? Элек шулай булмаганмы? 20нче гасыр тулысынча бер төрле уйлап, икенче төрле эшләп, өченче төрле сөйләү заманы. Ә 21нче гасыр исә, 19нчы гасырның янача кабатланырга омтылуы кебек. Сәясәттә, икътисадта, жәмгыять үсешендә. Яшерен-батырын түгел, илдәге үрчетелгән Гапончылык замана «декабристларын» ана карынында чакта ук үтерүгә ирешә. Ихтимал, шул сәбәптән — яңа идеал, яңа иман юк.

Ишкәксез һәм җилкәнсез тишек корабльдә каюталар корырга маташу кебек чор.

Гаҗәеп кызганыч та, кызыклы да заманабыз турында, бер гаепсезгә төрмәгә утыртылган әдипләребез дә, әлегә утырмаганнары да, күргән, булганны язмауда гаепләрен танып яздылар, язалардыр һәм язырлар да. Ә безнең үзебезгә килгәндә, башлаганыбызны төгәлләргә кирәк. Башлаганнарны ахырына житкерә алмауда гаепләп, оныклар көлмәсенгә.

Район һәм республика газетасында басылып чыккан мәкаләләр дә, авыл Советына караган учреждениеләр эшчәнлеген тикшерү нәтиҗәләре дә Хәдичә апайга үз йортын кайтарып алырга документ була алмый.

Нишләргә? Ул, кулга алынгач, бернинди тикшеренүләрсез, судсыз 58-7, 58-11нче мәгълүм статьялар буенча 20 елга ирегеннән мәхрүм ителүенең хаксызга булуын таныган белешмәләр артыннан органнардан органнарга йөреп, өлешчә теләгенә ирешкәч, балаларын күрергә дип, детдомга килә.

Детдом Тансыктан сигез чакрымнар чамасы ераклыкта, патша генералы Селезняков утарыннан калган биналарда урнашкан. Революциядән соң бу имениедә «Комминтерн» дигән җиләк-җимеш үстерү артеле оештырып карасалар да, ныгып китә алмый. Байдан калган «Фудзон» тракторларын, ашлык сугу, генератор һәм тегермән ташларын әйләндерүче двигательләрне эшләтер белгечләр булмый. Ахырда хуҗалык тулысынча ятим балалар тәрбияләү учреждениесенә бирелә.

Тирә-як халкы үзен-үзе туйдырырлык мал асраган, иген иккән, тулы булмаган урта белем биргән бу учреждениене «Детдом» дип кенә йөртә. Детдомның күпчелек хезмәткәрләре дә якын-тирә авыллардан килеп эшләүчеләр. Без бәләкәй чакларда әрәмәгә шомырт, карлыганга барганда әнкәйләр: «ак-ком чокырында җыймагыз, анда детдом балалары йөри— таларлар, Кандыз күленнән ерак йөрегез — анда детдомнар су керә — батырырлар», дип кисәтерләр иде. Сугыш вакытында һәм сугыштан соңгы елларда Тансыкта хәер сорашып йөрүче сәләмә киемле балаларны әбиләр-әниләр: «Кием алыштырып хәер эстәп йөрүегезне Капагызга әйтәбез» — дип куркыталар иде. «Капа» дигәннәре Капиталина Семеновна — детдомның директоры, усаллыгы белән районда мәшһүр шәхес. Детдом балаларына мондый кисәтү тәэсир иткәндерме-юкмы, әмма безнең авыл халкы өчен «Капа» дигәне дә, «детдом баласы» дигәне дә очратырга-очрашырга ярамаган куркыныч символлары иде.

Детдом территориясенә керү өчен капка баганасына терәтеп диярлек салынган «вахтерка» аша узарга кирәк. Вахтердан тыш анда төрле группалардан кизүләр төркеме, күчтәнәч бәрабәренә күрешергә килүчеләрне озатырга көтеп утыра.

Хәдичә апайны да шул кизүләр өере чорнап ала:

— Кого пригласить?

— Татарча белмисезмени?

— Нам нельзя... татарча.

— Фәһим белән Фәһимәне беләсезме?

— У нас таких нет. Есть Федя, есть Фая.

— Ә Кадрия?

— Сколько ей лет?

— Унөч.

— Айдате, мы вам сперва покажем Федю, потом и Фаю. Они у нас в разных отрядах. Тетя Соня, пропустите пожалуйста нас.

— Туктагыз. Сез, сенлем, кемгә килдегез? Нигә дип килдегез? Хәл белергәме, күчтәнәч китердегезме?

— Мин Хәдичә Мансурова булам. Менә минем документларым. Килүем турында телефон аша әйткән идем. Монда минем өч балам тәрбияләнергә тиеш. Тансык авылыннан, ике кыз, бер малай.

— Аларны башка детдомга күчерделәр түгелме сон?

— Кайда күчерделәр икән?

— Кайда урын булса — шунда инде.

— Балаларымның кайда булуын мин кемнән белә алам?

— Капиталина Семеновнадан! Әйтсә, ул гына әйтә.

— Барыгыз, озатып куегыз.

Хәдичә апайны ташлы юлдан алып китәләр. Башта алар янгын сүндерү насослары, буш мичкәле арбалар янынннан узып, колынлы бияләр ябылган утарга килеп чыгалар. Бер колын башкаларыннан аерылып, киртәгә таба чабып килә дә, Хәдичә апайга карап, туктап кала.

— Сахар просит.

— Шикәрем юк шул. Карамель ашыймы?

— А кто им даст?

— Кая, сумканы бирегез әле...

— А если им нельзя?

— Әнә бит күзгә карап көтә.

— Мальчики им соль дают.

Атлар абзары янындагы арбада китап укып утырган абзый юлчыга таба карап:

— Котыртмагыз хайванны, — дип кычкыра. Хәдичә апайга бу тавыш таныш тоелса да тизрәк китү ягына каера.

— Кем исемле әнә ул, китап тоткан кеше?

— Он у нас недавно... Всегда угощает конфетами. Поэтому... «Дядя конфет» зовем.

— Привет, дядя конфет!

... Кайдадыр этләр өрә, көлгән тавышлар ишетелгән кебек була.

— Сез мине адаштырыр өчен шулай уратып йөретмисезме?

— По той дороге злые собаки... У них свадьба.

— Кайдадыр, нидер яна түгелме?

Әче итеп сызгыру урман һавасын ярып уза. Озатучылар, бердәм борылып, өскә караса, агач ботагы такта кисәкләре салып эшләнгән корылмада бер малай утыра, кулында рогатка.

— Филя, не стреляй, это мы...

— Тогда держитесь правее!

Сулга карасалар — анда учак яна. Ә учак тирәли утырган малайларның кулларында озын таяк, таяк очында... нидер көйри...

— Нишлиләр ул малайлар?

— Голубей жарят.

— Ник?

— Толин день рождения отмечают.

— Кыргыйларчамы?

— Я пробовала, вкусно.

— Күмерме?

— Их же глиной мажут...

Озата баручыларның берсе — сумка тотканы — башлаган сүзен әйтеп тә бетерми, эт өргән тавышка таба агачлар арасына кереп китә.

Хәдичә апайлар да шул якка юнәлә. Йөз метрлар чамасы ара узуга, юан нарат ботагында утырган юлбарыска карап өрүче этне күргәч, туктлалар.

— Чынлап та юлбарыс көчегеме ул?

— Белого кота покрасили.

— Коточкыч.

— А вот это и есть наша контора.

Балан кагы төсендәге күлмәк, кара алъяпкыч һәм чәчсез башларына беретка кигән ике бала Хәдичә апайны контора урнашкан алпавыт йортындагы директор бүлмәсенә кертеп куялар да, күз ачып йомган арада юкка да чыгалар. Соңгы сүзләре «Джульбарс» була. Хәдичә апа тәрәзәгә килә. Урамнар буш. Ниндидер шомлы тынлык.

— Зайти можно?

— Вы уже зашли. Говорите!

— Я не говорить пришла.

— Татарча гына сөйләгез. Капа апагыз булабыз.

— Исәнмесез... Тансык авылыннан Хәдичә Мансурова мин. Кичә секретарегызга телефон аша әйткән идем. 1949 елның 21 декабрендә кулга алынып, егерме елга хөкем ителгәч, өч баламны шушы детдомга биргәннәр...

— «Биргәннәр» түгел, «урнаштырганнар».

— Нәҗметдинов Фәһим, Нәҗметдинова Фәһимә, Әкрәмова Кадрия, өчесе дә 41 елгы.

— Сезне нинди статья белән утырттылар?

— «Кешесе булса, статьясы әзер», — дигәнне ишеткәнегез бардыр? 58.

— Нәрсә өчен?

— Юк өчен.

— Юк өчен 10 ел гына бирәләр. 20 ел өчен нидер кирәк.

— Сталинны артык яратуны сылтау иттеләр.

— Аны барыбыз да яратабыз.

— Хәзер миңа балаларым белән кушылырга кирәк.

— Балаларың сезнеке булуын раслаган документларыгыз бармы?

— Аларга тиешле пособие акчасын алу өчен бирелгән шушы белешмәдән башка бер документым да юк. Ул чакта документ артыннан йөрү уе башка да килмәгән, ятим калган балаларны бер канат астына җыю теләге барсын да «җингән»...

— Мин сезне аңлыйм. Бу хәлегездә сезгә ул балаларны бирмәячәкләр. Хәтта очраштырмаячаклар да. Чөнки сез рәсми яктан аларга чит кеше.

— Мине алардан законсыз аердылар. Кушылырга дигәндә закон кирәкмени?

— Законнарга кадәр сезнең аларны тәрбия итә алуыгызга ышандырырлык

белешмәләр кирәк. Йортыгыз, яшәр урыныгыз бармы? Кайда да булса эшлисезме?

— Әлегә юк.

— Алайса, иң элек районга барып, опекунлык яки усыновление дәгъвалаган документлар юнәтегез. Шулар булган очракта гына мин сезгә ул балаларның хәзер кайда тәрбияләнүләре турында рәсми белешмә бирә алам. Юк икән юк.

— Биш елга сузылган тоткынлыкта миңа 10 хат язып шуларга 10 җавап алу мөмкинлеге бирелде. 10 хатымны да балаларыма юлладым. Берсенә дә җавап ала алмадым. Сезнең администрациянең бу эшкә катнашы бармы?

— Хат язу, хат алу һәркемнең шәхси эше. Администрациянең бу эшләргә катнашы юк, була да алмый. Дөресен әйткәндә, кирәге дә юк.

— Ә акча яисә посылка салган очракта ничек? Кем ала?

— Тәрбиячеләр аша эшләнә. Алар аны аерым журналга теркәп баралар. Ул журнал дирекциядә саклана. Менә ул. Алабыз, ачабыз, Назмиев Фагим, Назмиева Фагима, Икрамова Кадрия...

51 елда 29 декабрь — посылка на троих, без объявленной ценности; 52 елда — 6 ноябрь, посылка без объявленной ценности, на троих, сургучсыз ябык коробкада; 53 ел, 25 декабрь, посылка на троих, ценность не указано. Дальше теркәлмәгән. Барысы да Тансыктан, Г.Камаевадан, дигән. Китерүчесе Мөгаллимә Мусина — медсестра.

— Мин салганнары юк...

— Эзләтегез, почта белергә тиеш.

— Бүген мин балаларымның кайда булуын белүдән дә мәхрүм.

— Барысы да балаларны рухи җәрәхәттән саклау максатында. Инструкцияне боза алмыйбыз.

— Аңлашылмый.

— Макаренко кушканча.

— Сез мине Гусманова Ләйлә, Максудова Нәзиләләр белән очраштыра алмассызмы?

— Кемнәр алар?

— Тәрбиячеләр. Һәр посылкадан соң, рәхмәт әйтеп, телеграмма сугып баручылар.

— Кемгә?

— Посылка салучыга, Гәүһәр Камаевнага, Мөгаллимә Мусинага.

— Кызганычка каршы бездә сез атаган ул кешеләр тәрбияче булып эшләмәде.

— Кем булып эшләделәр?

— Андыйлар бездә, гомумән, юк.

— Кызганыч.

— Нәрсәсе кызганыч?

— Бу килүемдә мин балаларга «борын» кычыткanлык кына күчтәнәч алып килгән идем. Аны кире алып китү... Матур фал түгел. Әгәр рөхсәт ителсә...

— Калдырыгыз!

— Кемгә?

— Кече яшьтәгеләр группасына.

— Рәхим итеп алыгыз... (сумкасыннан әйберен тапмый)

... Гафу итегез, шушы сумкада иде... (бераз вакыт тынлык)

— ... Сумкагызны кулыгыздан ычкындырмадыгызмы?

— Вахтадан бирегә ике бала озатты... Алар тотып килде...

— Малайлармы, кызлармы?

— ??

— Хәзер үк монда чакыртып, күз алдыгызда җәза бирикме?

— Җәза?!. Аллам сакласын!

— Күнелләрдә шик калмасын өчен без моны эшләргә тиеш.

Ул өстәлендәге кнопкага баса, кайдадыр звонок тавышлары яңгырый, ашыгып, кабаланып бер хатын-кыз белән бер ир кеше керә.

— Хәмит Ризванович!

Бик аз гына вакытка тынлык урнаша.

— Менә нәрсә, Хәмит Ризванович, Светлана Максимовна, бу гражданканың сумкасыннан ун кило конфетын, ун кило печеньесын урлаганнар...

— Ун кило түгел — бер кило!.. Бер!

— Эш кәнфит авырлыгында түгел — хурлыгында. Хәзер үк вахтадан белегез — кемнәр озатып куйган. И... бөтен коллектив алдында...

— Нишләтмәкче буласыз? Бер кило кәнфит өчен?..

— Бер кило кәнфит өчен детдом балалары карак дигән хурлыкны күтәрсеннәрме?! Юк инде, күп күтәрдек. Эшегездә булыгыз!

— Бәлки мин кибеттә онытып калдыргганмындыр?

— Бәлки, бәлки. Бәлки сезнең посылкаларыгыз да, язган хатларыгыз да лагерьдан китмәгән, шунда ук юкка чыккандыр? Ә күләгәсе детдомга төшә, тәрбияләнүчеләр, тәрбиячеләр өстенә.

— Яктыны капламыйча күләгә төшми. Димәк, каплаучыны табарга кирәк. Кайда ул? Кем ул?

— Без монда ятимнәр ачтан үлмәсенгә көрәк белән казып, кәбестә, бәрәңге үстергән чакларда басуларда куныпятсак, сез анда тел чарларга өйрәнеп яткансыз күренә. Детдом сүз көрәштерү урыны түгел, гражданка. Монда эмоцияләргә урын юк.

Ул тагын кнопкага баса. Хәмит Ризванович белән Светлана Максимовна, Хәдичәне озаткан ике баланы алып керәләр.

— Йә — кайсыгыз карак? Светлана Максимовна, аңлатыгыз?

— Обычно, свиданиега килүче посетитель дежур торучыларга күчтәнәч бирә. Гражданка бу обычайны оныткanмы, башка сәбәбе булганмы — күчтәнәче сумкасында кала...

— Мина әйтүче булмады.

— Гражданка, мондый эш әйтеп эшләнми. Ул ихластан эшләгәндә генә изге эш санала. Короче, конфетларын бетергәннәрме?

— Ике штугы расходланган. Фантиклары исән, менә алыгыз.

— Хуҗасына тапшырыгыз. Ике штугы өчен акча бирегез.

— Сез нишлисез, гражданнар?! Минем нинди гаебем бар?

— Алайса, ятим балалар гаепле?!

Балалар икәүләшеп елый башлый.

— Аларга тимәгез! Мине гаепләгез! Мине!

— Бездә гаепленен, үз гаебен танып, публично гафу үтенүе генә мактала.

— Гафу итегез, балалар, күчтәнәчләрне үзегезгә алыгыз! Зинһар!

— Юк инде, алмый торсыннар! Хәмит Ризванович, үлчәп, опреходовать итегез дә, лабораториягә анализга бирегез... Нормально булса, вожатыйлары кул куеп алыр. Хәзер боларны карантинный блокка ябыгыз. Тикшерсеннәр. Авыру йоктырмаганнармы. Марш. Шулай, иптәш гражданка, һәр монастырьның үз уставы, үз настоятеле.

— Монастырь, имеш... Төрмә бит бу, зиндан! Ә сез... сез надзирательләр!

— Күрәм, күрәм, әйе, биш елыгыз бушка узмаган. Настоятель сүзе түгел, надзиратель боерыгы гына аңлаешлы сезгә. Кешене күнеккән җиреннән тиз генә аерырга ярамый шул, ашыкканнар...

Шуннан соң ниләр булуын Хәдичә апай анык хәтерләми.

...Капиталина Семеновна, кинәт, Сталин портретына әверелгәндәй була,

кайдадыр мылтык аткан тавыш яңгырый, аңа пыяла ватылу тавышы кушыла. Тансыкта алар яшәгән йортнын капка төбендә ябык машина туктый, йоклап яткан балаларның өсләренә юрган ябучы Хәдичәне НКВД хезмәткәре өстерәп алып чыга. Тәрәзәдә бала Фәһим күренә, аны кар каплый. Төрмә күренешләре. Вышка-каланчада сакчылар. Урман кисү, оекбаш бәйләү... Хат язу... Кара кайма белән камалган Сталин фотосы; Поезд чаба; Җәй. Хәдичә ат арбасында ята. Дилбегә Әкән Миңгали кулында. Ат акрын гына бара.

— Миңгали абзый, атыңны туктатсанчы. Сүз бар иде.

— Аткамы сүзең, миңамы? — ди Әкән.

— Кайсыгыз хәлемә керсә — шуңа.

— Кеше хәлен кеше белмәс, ат кына аңламаса... Сөйләп кара, тыңлап багыйк.

— Мин инде сөйләрлеген сөйләдем... Хәзер син сөйлә: өнме бу, төшме? Син кем? Мин кем? Кай җир бу? Сөйлә!

— Сөйләмим. Күргәннәрем, белгәннәрем кеше ышанырлык түгел.

— Әйт: күптәнме син бу детдомда?

— Кайтуга! Колхоз миңа эш тапмады, авылдашлар күрешергә дә курыктылар. Шунда Хәмит очрады, чакырды.

— Минем балаларны күреп сөйләшкәнең булдымы?

— Аларны озату алдыннан медсестра Мөгаллимә белән Гәүһәр Камаевна берничә тапкыр килде. Сельсовет аты белән. Шунда балаларны да күреп калдым. Соңыннан, дәшеп карасам да, миннән качтылар. Каникулларында очратырмын дисәм, укулары бетүгә югалдылар. Гәүһәр Камаевна белән Мөгаллимә, балаларны җыеп, менә шушы арбага утырып сөйләште. Соңгы килүендә хәтсез генә прәннек алып килгән иде. Фәһим аны сарык йонынннан бәйләнгән түбәтәенә тутырып, миндә калдырып торды. Кирәк саен килеп алырмын дисә дә, башкача күрешмәдек. Кеше аркылы эзләтеп тә карадым, тапмадылар. Каникулда ат белән авылга алып кайтырмын, йорт-җирләрен, әниләренең каберен күрсәтермен дигән ниятем үтәлмәде, укулары бетүгә ашык-пошык каядыр озатканнар үзләрен. Фәһимнең түбәтәен гел кесәмдә йөртәм. Үзебезнең малай бит, менә ул ... түбәтәй.

— Мин бәйләгән башлык!.. Димәк, алар посылкаларымны алганнар!

— Прәннеген дә бик озак сакладым.

— Кая җибәрделәр икән?

— Фәһимен поезд белән Хәмит Ризванович илтте, кызларны Светлана озаткан. Пароход пристаненә йөк машинасында Шәмсетдин илткән. Төнлә. Еламадылар, ди.

— Ни өчен башкалардан аерым, ашыгып озату кирәк булгандыр дисең?

— Өйләрен сатуга бәйле түгелме, дигән шигем бар. Берчак шулай Хәмит Ризванович әйтә: «Ник йортыңны сатмыйсың, алпавыт управляющие яшәгән таш йортның яртысы җитмимени сиңа? — ди. Хәзер яшәгән бүлмәне күздә тотып. «Сатам», — дидем. «Күпмегә», — ди бу. Шуның шикелле үк йорт салырлык, ат алырлык хак бирүче булса — йорт аныкы дидем. Шуннан тыш сөйләшү булмады. Шиге калды.

— Язган хатларыңа җавап ала алдыңмы?

— Язмадым да, көтмәдем дә.

— Мин көттем, яздым. Бирмәгәннәр. Посылкаларым да югалган. Ә менә башлыгы... башлыгы исән...

— Ничек тә Фәһимнең үзен күреп ачыкларга кирәк сиңа.

— Шуңа кайттым.

— Ал минем запас ачкычны, яшә шунда, йөрмә судлашып Гәүһәр белән.

— Син мондый түгел идең, абзый. Бөтенләй үзгә син, үзгә...

— Бәлки теге чактагысы мин булмагандыр? Хәзерге мин — миндер?

— Урман кисүчеләр бригадасында эшләгән чак. Балта-пычкы кулда. Азыкны үзебезгә-үзебез юнәтәбез. Бер көн шулай, печән чапканда чалгым урман тавыгының канатын кискән... Ит тәмен оныткан авыз тавык шулпасына кинәнде ул көн. Минем бригадада Ленинградтан пианистка бар иде. Шул... көртлек сөякләрен чәенә салып эчәр өчен озак саклап йөртте.

— Җәйге челләдә көртлек-суерлар каурыен алыштыра, оча да алмыйлар, ишетмиләр дә.

— Шундыйга туры килгәнсең.

— Мин шул суер хәлендә түгелме хәзер?

— Икебез дә шул хәлдә.

— Сунарчы булуыңны оныттырганнар ахры?

— Мин киекнең очып барганда атып төшергәнен генә трофейга саныйм.

— Шулай дисең дә, Капиталинагыз кабинетында хуштан язып егылгач, мине медсанчастькә илтмичә, үзеңнең бүлмәңә алып кайткансың: ник?

— Укол кадагач, нигә сине анда — медсанчастькә илтергә? Җитмәсә, Хәмит Ризванович бөтен кеше алдында «Конюхның хатыны» дип сөйләнеп йөргәнен ишетеп торганда.

— Хурландыңмы шуңа?

— Сине кызгандым.

— Инде шуңа үкенәсеңме?

— Үкенмим — үтенәм.

— Нәрсә үтенәсең?

— Гафу үтенәм. Ике көн бикләп асравым өчен.

— Бөтенләй башкага әверелгәнсең син. Үзебезнең Әкән димәссең... Чынлап та: кайсысы синең чыны?

— Икесе дә чын. Әкән ике була алмый.

— Сөйләшүең, телең бөтенләй үзгә.

— Гаҗәп түгел. Тегендә мине язмыш бик тә укымышлы, галим кешеләр белән дуслаштырды. Алар миндә китапка... ихтыяҗ уяттылар.

— Әйтәм аны гел икенче телдә сөйләшәсең, Тансык телен оныткансың.

— Тел онытылмый, тел үзгәрә, шомара гына.

— Фраер, не трехай зря, лучше падай на юрцы, разин шнифты! Шулаймы?

— Төрмә уголовниклардан гына тормаганны үзең дә күргәнсендер...

— Кайткач күргәннәр белән чагыштырганда, анда ничек итсәң ни буласын... алдан чамалап була иде. Ә монда сүз гамәлдән аерыла.

Шулчак алар каршына, көтмәгәндә-уйламаганда, мотоциклга атланган Хәмит Ризванович килеп туктый.

— Миңгали Шәрифҗанович, бу ни эшең, нигә тукталдың?

— Менә — син дә тукталдың бит! Тәкъдир! Язмыш! Күрәчәк!

— Мин бит сине төш җиткәнче әйләнеп кайт дип җибәрдем. Пычаксыз суясың бит...

— Әкәнең гаебе юк! Атыңны атлатып кына бар дип мин сорадым. Чөнки хәлем юк.

— Сезнең сүз директор каршында акланырлык аргумент була алмый, ханым.

— Ни булды, Хәмит Ризванович, ни бар?

— Телефонограмма алдык. Чистай приютыннан биш бала китерергә тиешләр. Шуларны пристаньнан каршы алырга кирәк. Пароход кич тугызынчы яртыда буласы, ди.

— Өлгерәм ич.

— Өлгермисең. Мин сине кордоннан утын алып кайтырга җибәрдем, дидем. Әгәр утын төяп кайтмасаң, холкын беләсең.

— Хәдичәне ярты юлда ялгызын калдырып китә алмыйм бит инде мин.

— Аны үзем озатам. Миңа барыбер авыл Советына төшәсе. Һаман шул тикшерүчеләр тынгы бирми. Хәдичә, утыр бишеккә, үзем озатам...

— Кайда минем балалар? Адресларын кем бирә?

— Мин бирәм!

— Ышанма, Хәдичә, башта ул адреслар буенча телеграмма сугып, тикшерт!

— Вакыт әрәм итмәгез! Тансык почтасының ишекләре сургучлап бикләнгән, Хөллиясе сак астында.

— Районга барыр.

— Районга барып, телефон аша сөйләшүгә заказ көтеп вакыт сузганчы, юлга чыгуы отышлырак. Әйдә, утыр!

— Әгәр утырмасам?

— Башка чараң бармы?

— Көн әйбәт, аякларым атлый. Мин... җәяү генә китәм!

Хәмит Ризванович та, Миңгали Шәрифҗанович та мондый җавап көтмиләр, әлбәттә. Шунадыр Хәдичә апай күздән югалганчы, борылып килер дә кем арбасына булса да утырыр, дип көтәләр. Әмма ләкин кулында балаларының адресы булган ананы арба белән кызыктырып буламы?!

Ул, очып диярлек, Гәүһәр Камаевнага килә.

— Рәхим ит, үз өеңдәге кебек бул, уз утыр, — дип каршы алды ул Хәдичәне.

— Нигә кебек? Мин үз өемдә түгелмени?

— Әгәр тагын шул турыда сөйләшергә килгән булсаң — минем позициям үзгәрмәде, үзгәрмәс тә.

— Безнең паласлар, юрган-мендәрләр кая?

— Көя кисеп бетермәгән булса, барысы да чормада, төйнәп куйган.

— Табак-савытны көя кисми. Алары да чормадамы?

— Монда бернәрсәне дә опись белән кул куеп кабул итмәдем мин. Син миңа: алтын табак белән көмеш самоварым кая, дисәң дә иркеңдә. Мин дә знать-незнаю дияргә иреклe. Пластинкаңны алыштыр.

— Ярый, әлегә алтын-көмешне калдырып торыйк. Мин балаларымны эзлим.

— Аларны закон саклый.

— Анасыннанмы?

— Уголовниклардан...

— Ярый әле үзеннең балаң юк, әйтер идем... Шул хатлар, ялган телеграммалар коткарыр дисеңме?

— Мине хөкем куркытмый. Синнән ничек котылырга?

— Мин әйттем: белешмә кирәк. Дөресе язылган. Имзалы, мөһерле.

— Яхшы. Белешмә бирәм. Тик ике шартым бар. Беренчесе: өч кеше кул куйган акт кирәк. Ул өч кеше сигез ел буе ятим балаларны каравыңны расларга тиешләр. Икенче шартым: бу йортка дәгъва итеп йөрүеңне туктатасың. Мин аның түбәсен толь белән яптырып, мичен дә яңарттым... Мәсьәлә чыгымнарда түгел. Документта йорт минем исемдә.

Өч көн дигәндә ул, Фәһимне эзләп, Чаршады «детдом»ына барып житте. Тимер юлдан да, су юлыннан да кырык чакрымнар ераклыктагы бу учреждение дә патша генералыннан калган утарга урнашкан икән. Утарны Кырмас дигән елга урап ага. Ат дагасы белән чагыштырганда, утарның тимер койма-капкалары дагадан бөҗра ясап, ябык утрау хасил итә. Өстәвенә елга яры буйлап чәнечкеле тимерчыбык сузылган. Кереп-чыгып йөрү иреклe

түгел, сак аша. Лагерьдардан лагерьга күчеп, кансыз төрмә сакчыларының күңелләренә ачкыч таба алган Хәдичәгә детдомның төнге каравылчысын үз кеше итү читен булмый. Ун минут дигәндә директорның бүген өйдә юклыгын, кайткач кай яклап якынаерга мөмкинлекне белгәч, төп соравын бирә:

— Фәһимне беләсезме? Тансыктан.

— Карантинда яткан малайдыр ул.

— Авырыпмы?

— Яңа килгәннәрне башта шунда җәфалыйлар.

— Аннары?

— Аннары алар үзләренә үзләре «кум».

— Шуннан.

— «Ошмонят малолетних, ищут под своей шконкой коца».

— Житәкчеләр күрмиме?

— Аларга нәрсә? Үгез үлсә — ит, арба ватылса — утын.

— Шулай дип утырып булмый ич. ...Хәрәкәтләнергә, чара табарга кирәк!

— Алар яшендә без тырмага чыккан, сабанга тотынган идек. Ә болар? Җәй күбәләк куалар, кыш кандала симертәләр.

— Үз күзләрем белән күрмичә ышанмыйм.

— Бу бит режимлы учреждение. Иртәгә кадәр селкенә дә алмыйсыз...

— Мин ерак юлдан килгән кеше, арыдым...

— Җәйге төн озын түгел, сүз белән сизелмәс.

— Сизелә башласа, кыскарта торган даруым бар, телисезме?

— Чыгарма даруыңны! Язва. Икенчедән, әгәр мин бер яртыга сатыла торган булсам...

— Бөтен итәрбез. Миндә житәрлек алар.

— Сатыла торган булсам, монда утырмас идем.

— Тәкъдим итәр башка нәрсәм юк бит.

— Узган сменада, шулай ук төнлә, атка атланып бер егет килгән. Кызы монда икән...

— Егетләр белән йөрерлек кызлар да бармыни монда?

— Йөрмәгәннәре буламы аларның? Бала табалар, бала!

— Үзләре бала ич әле алар.

— ... Килгән бу. Шул баланы чакырып чыгаруны сорый. «Әгәр ризалашсаң берне үзең өчен ияртеп чыгам», — ди. «Риза» дидем дә, тәвәккәлләп, кертеп җибәрдем моны. Алып чыккан! Миңа дигәне иң тыйнак, иң әдәпле дип йөргән кызыбыз булып чыкты!

— Исеме?

— Әйтмим! Икесен дә директорга тапшырдым. Хәзер ул шуларны кая барса да үзеннән калдырмый, ияртеп йөри.

— Ник?

— Тагын бер хәлне сөйлим...

Хәдичә апаның уенда ныклы фикер өлгерә: ничек булса да баланы моннан алып китәргә!

***

...Агач йортның аскы каттагы бүлмәсендә алты караватның берсе буш, бишесендә биш малай йоклап ята. Кулына сөлге белән теш щеткасы тоткан малай кереп, ишеккә якын караватта ятканын уята.

— «Шестерка» безне алдаган.

— Ничек?

— Аның анасы бар икән бит!

— Анасыз кеше булмый. Ул бит «үлде» дигән иде.

— Шырпы! Газет! «Велосипед» ясыйбыз.

«Первач» кушаматлы 14-15 яшьләрдәге малай йоклап яткан Фәһимнен аяк бармаклары арасына газета кисәге кыстырып, аңа ут төртә. Бармаклары пешүне сизүгә, Фәһим аякларын, велосипед педален әйләндергәндәй селки башлый.

— Нишлисез сез?

— Арабызда ялганчы булганда безнең күзгә йокы кермәс.

— Кем ялганчы?

— Безнең арага кергәндә әткәм-әнкәм мәрхүмнәр дип ант иттеңме?

— Шулай кирәк дидегез.

— Анаң исән!

— Мин анын каберен күрдем.

— Безне алдап сиңа нәрсә бар?

— Әгәр ул исән булып, аны күрү мөмкин икән — мин үләргә дә риза.

— Үлемгә кадәр сынаулар узасынны онытма. Әйт: безне алдау сиңа ник кирәкте?

Шулчак бүлмәгә тәрбияче керә. Авыз-борыны канаган, куллары артка каерып бәйләнгән Фәһимне күреп, бернинди гаҗәпләнү, аптырау күрсәтмичә, аңа торып басарга ярдәм итә дә, алып кергән алмаш күлмәк белән чалбар бирә.

— Мә, тиз генә юынып, сөртен, алыштыр бу киемнәреңне.

— Ә ни өчен аңа гына яңа киемнәр?

— Шулай кирәк булганга.

— За предательство?

— За терпение, за ожидание!

— Без көтмибезме? Без түзмибезме?

— Сезнең дә әти-әниләрегез табылырга язсын!

— «Шестерка»ның әти-әнисе исәнме?

— Әнисе исән! Ул биредә. Көтә!

— Юк! Ул үлде. Нигә ялганлыйсыз? Мәгез, кирәкми миңа башкалардан аерым өлеш, алыгыз бу киемнәрегезне!

... Кинәт ишек ачыла, Хәдичә апай күренә. Тәрбияче белән тәрбияләнүчеләр сөйләшүен ул ишетеп торган, күрәсен:

— Улым, Фәһим. Бу киемнәрне сиңа мин алып килдем бит. Ошатмадынмыни?

— Син кем соң?

— Мин синең әниең — Хәдичә. Менә килдем, кайттым.

— Минем әнием үлде. Ул Саймә атлы иде.

— Ә мин ул үлгәч, өчегезне тәрбиягә алып, сигез ел буе караган.

— Сигез ел буе безнен пособиене алып яшәдең дә... инде монда килеп, сүз итәсеңме?

— Бергә яшәдек, матур яшәдек!

— ... Аннары ташлап киттең дә, оныттын.

— Оныттырырга тырышсалар күнелемдә гел сез булдыгыз. Хатлар яздым. Җавап алмадым. Посылкалар җибәрдем — башкалар алган.

— Безгә Мөгаллимә апа гына посылка китерде... Биш елга өч тапкыр, кыш бабайдан, дип.

— Менә бу башлыкны таныйсынмы?

— Әкән абыйда онытып калдырганмын... Минеке ул.

— Мин аны сиңа кофтамны сүткән җептән бәйләгән идем. Оекбашларыгызны да, перчаткаларыгызны да шул җептән.

— Хәзер шуларга хак сорап килденмени?

— Ничек шулай әйтергә телең әйләнә, улым?

— Искедән бәйләгән бияләйләрне сүз итәргә синеке ничек әйләнә икән?

— Сафуанов, житте сиңа! Без сезне олылар белән шулай тупас сөйләшергә өйрәтәбезмени? Шулай кырыс булырга өйрәтәбезме?

— Тупаслыкка да, кырыслыкка да өйрәтәсе юк.

— Сүз көрәштермә, улым, әйдә җыен, кайтабыз.

— Минем өем монда. Мин беркая да китмим.

— Ник?

— Тюремщица балалары дип мыскылламасыннар өчен!

— «Шестерка!» Дурак булма! Син безне алдамагансың. Без сине аңламаганбыз. Әгәр безне шундый әниләр алырга килсәме? Кайт авылыңа. Син барлык сынауларны да үттең. Сынатмадың. Син безгә үрнәк.

— Мин беркая да китмим.

— Сафуанов, бу синең актык сүзеңме? Уйлап әйтәсеңме?

— Гражданка... иптәш Мансурова! Сезгә бирелгән вакыт бетте. Күрешү тәмам. Иртәнге автобус килергә күп калмады.

— Автобус кирәк булмастыр, ахры. Фәһим кайтмагач, миңа анда ни калган?

Үз уенда нык тора Хәдичә апай. Директорга хәлне аңлатып, барысы турында да ачыктан-ачык сөйләгәч, аны тәрбияче ярдәмчесе оклады белән детдом клубына эшкә алалар. Ул, җиң сызганып, эшкә тотына. Хор түгәрәге оештырып, төрле милләт җырларыннан тупланган репертуар белән башта якын-тирә авыл клубларында, аннары район, шәһәр сәхнәләрендә концертлар куеп йөри. Аларны яраталар, мактыйлар, чакыралар. Бер ел дигәндә «детдом хоры» мәгариф һәм мәдәният министрлыгының мактау грамоталарына лаек була. Хәдичә апайны тәрбия эшләре буенча директорның ярдәмчесе вазифасына күтәрәләр. Детдом мәктәбенә өч музыка укытучысы штаты өстәлә: концертмейстер, вокалист һәм хормейстер. Партиянең XXнче съездын Хәдичә апайның үзешчән балалар театры яңа спектакль белән каршылый.

Республика конкурсында «лауреат» исеме алуга алар турында республика телевидениесе ярты сәгатьлек фильм күрсәтә. Хәдичә апайга «Атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә.

Тансыкны да онытмый ул. Дөресрәге — онытмыйлар. Гәүһәр — Хөллияләр эше буенча аны шаһит буларак чакырталар. Суд Хәдичә апайның йорты законсыз үзләштерелгән дип таба, элекке хуҗасына кайтарып бирү турында карар чыгара. Гәүһәр Камаевнаны да, Хөллияне дә ирекләреннән мәхрүм итәләр. Детдомда эшләвенең беренче елында ук өч баласын да үз янына алуга ирешә Хәдичә апай, өч баласы кушылган көнне ул иң бәхетле көне дип хәтерли. Дүртесе бергә тормасалар да һәр көн очрашалар, бер үк уй, бер үк теләкләр белән яшиләр.

... Шулай дип уйлый ул һәм кылган гамәлләрен шушы бөтенлекне, бердәмлекне саклауга багышлый.

Ләкин... лəкиннән беркая да качып котылып булмый. Еллар уза, балалар үсә, эшендә яраталар. Хәдичә апайның өч баласы да өлгергәнлек аттестатына имтихан тота. Фәһим белән Фәһимәсе көмеш, Кадриясе алтын медаль белән чыга. Бу вакыйга шатлык кына түгел, бәхетле гаиләгә борчулар да алып килә.

Күрше авыллардан детдом мәктәбенә йөреп укучыларның ата-аналары, медаль алучыларны «хәрәмләшүдә» гаепләп, шикаять язалар. Кабат сынау алу оештырыла.

Район мәктәбенә илтеп аларның өчесенә дә рус теле язмасыннан һәм математикадан контроль эш эшләтәләр. Эшләрне тикшерүне республика мәгариф министрлыгының методик кабинеты инспекторларына йөклиләр.

Нинди билге куярлар дип көткән ул көннәрнең озынлыгы...

Детдомда сочинениедән «4»ле алган Фәһимгә монда «5»ле куела, Фәһимәнең дә «4»лесе «5»кә төзәтелә. Ә Кадриянең сочинениесенә «5»ледән соң «Очень оригинальная» дип тә өстәлә. Нәтиҗәдә, өчесенә дә алтын медаль бирергә, дигән карар чыгарыла.

...Тик, ул медальләр сонлап кайту сәбәпле, балалар үзләре теләгән уку йортларына урнаша алмыйлар: Фәһим хәрби училищега; Фәһимә педагогия институтына керергә мәҗбүр була. Ә Кадрияне музыкаль белеме юк дип, консерваториягә алмыйча, башта музыкаль училище тәмамларга күндерәләр.

Хәдичә шат. Кайда гына укысылар да укысыннар гына! Балалары укып бетергәнче, ул аларга ярдәм итәчәк! Ләкин ... Тагын бер «ләкин». Ятим балалар кимү сәбәпле, республикадагы балалар йортларын берләштерү башлана. Шаршада детдомы гарип балаларны дәвалау диспансерына әверелә. Шул сәбәпле, персонал да алышына. Алты ай буена Хәдичә апайның язмышы кыл өстендә була. Калдыралармы? Калдырмасалар кая барыр?

Калдыралар! Мәдәни тәрбия бүлеге мөдире вазифасында. Шул эшендә ул пенсиягә чыкканчы эшли. Балалары, баштарак, кайтып йөри. Әниләре мал асрый, каз-үрдәк үрчетә. Барысы да алар өчен, алар кеше булсын өчен. Тик барыбер «ләкинсез» бармый тормыш.

...Фәһиме — диплом алуга, өйләнә дә, кайтып та тормый — «по назначению» җир читенә китә; Фәһимәсе диплом алганчы ук кияүгә чыкмый гына, малай таба. Имүен ташлатырга дип, гарип туган улын Хәдичә апайга кайтарып ташлый да үзе каядыр эш эзләп китә һәм ... югала. Кадриясе, консерваториянең өченче курсына күчкән булса да, укуын ташлап, Израильгә китә. Бөтенләйгәме, кияүгә чыгыпмы, концерт беләнме?

Беркем белми, әллә инде белеп тә әйтмиләр.

Хәдичә апа көтә, чыдый. Фәһимәнең малае Энгельгә өч яшь тулуга аны үзе эшләгән диспансерга урнаштыруга ирешә. Чөнки тәпи йөри алмаган баланы күрше әбигә калдырып эшкә йөрсә, ул бала гомергә терелә алмаячак. Ә диспансерда белгечләр дә, махсус җиһазлар да житәрлек. Күзәтергә, шөгыльләнергә генә кирәк.

Ниһаять, милициягә гариза язып, эзләтеп табалар: Фәһимә валюта сатуда тотылып, 88 нче статья белән ирегеннән мәхрүм ителгән, тагы дүрт ел утырасы калган икән.

Ә Кадриясенә... Израиль гражданлыгы бирелмәгән, кунакта дип исәпләнә икән; димәк, иртәме-соңмы кайтырга тиеш.

... Хәсрәтләре белән туенып, күз яшьләре белән юынып күпме йөргәндер, малаенын туган көне белән котлап, Фәһимәдән бер мәл хат килеп төшә Хәдичәгә. Сәламнәрдән соң озак дәшмәве өчен гафу үтенә дә, «бик тиз генә Тансыктагы йортны сатып, акчасын салсаң досрочно котылу мөмкинлеге бар», — дип куя ул. Нинди йортны? 50 нче елларда ук авыл Советы балансына күчкән йортны бүген кем сатып алыр икән? Шулай да ситуацияне аңлатып, Тансык авыл Советы адресына тәфсилләп хат яза Хәдичә, «Ятып калганчы — атып кал», дигәннән чыгып. Әгәр сату ихтималы булмаса, өй хакының яртысы күләмендә генә булса да, әҗәткә акча салуны үтенә. Инде юктыр, булмагандыр дигәндә, көткән суммада акча килеп төшә. Дөнья матур — дөнья киң! Авыл Советы исеме астындагы кешегә рәхмәтләр укый-укый «Өй акчасын» салып, кызын көтә башлый. Тик кызы «досрочно» түгел, срогы тулып бер ел узгач кына кайтып төшә.

Фәһимәсенең кайту хәбәрен ишеткәндә Хәдичә апайның оныгы Энгельгә баскычтан менеп-төшү күнегүләре эшләтеп яткан чагы була. Анасының кайтуы турында балага белдерергәме? Әллә әйтми торыргамы? Мед.няня

белән кинәшләшкәч, Хәдичә апай фатирына үзе генә кайтырга була. Кайтса — ишеге шыр ачык өйдә, Фәһимәсе тәмәке тартып утыра.

— Кызым! Ачкычны ничек таптың?

— Что ачкыч! Разве замок шулай була? Вона, валяется...

— Монда ишекне бикләмәсәң дә керүче юк. Йөз аклыгы өчен генә эленгән йозак.

— ... Кая минем Энгель?

— Энгельне болай гына йөртеп булмый. Әмма хәзер Аллага шөкер: үз йомышына үзе атлап йөри башлады, укуы әйбәт...

— ... Как тоесть «йөртеп булмый»? Неужели так сильно уродовали баланы?

— Кайтарган чагындагы белән чагыштырганда... чагыштыргысыз.

— Мин сиңа нормаль бала калдырдым. Помнишь: одеялны чишеп карагач, үзең үк: «дүрт саны төгәл, калганы үсә-үсә төзәлер», — дидең. Что-то случилось?

— Соң ул чакта ятып кына торган баланың гариплеген мин каян күрим?

— Не «гарип», а с деффектом! Давай баланы! Миңа бүген китәргә кирәк.

— Китәр өчен нигә сиңа бала?

— Мин аны алып китәм.

— Рөхсәт итәрләр дисеңме?

— Минем балам, куда хочу — туда устрою.

— Юк, кызым... Ул бала хәзер тулысынча хөкүмәт карамагында. Аны сиңа болай гына бирмәсләр... Аннары ул үзе дә сине... белмәс.

— Син миңа әниме?

— Ана итсәң — әни.

— Бала итәсең килсә — поможешь.

— Ничек?

— Ә ничек башкалар помогают? Машина алып бирәләр, квартира...

— Мин үзем дә «служебный»да гына яшим бит, күрәсең... Һаман житешә алмыйм. Бурычларым да бар.

— Башта миңа ярдәм ит, аннары бергә яшәрбез, бурычыңны да түләрбез.

— Өйрәт?! Ничек итеп?

— Миңа баланы алып китеп, эштә глаз мозолить итү кирәк. И квартирага чиратка басарга. А может удасться внеочередно! Как исключение...

— Син, кызым, безнең баш врач белән сөйләшеп кара, бик акыллы кеше ул, нинди киңәш бирер икән?

— Төкерәм мин врач киңәшенә! Начнут тикшерергә, анализлар... Короче, малайны давай сюда и срочно!

— Бу хәлендә мин сиңа бала биреп жибәрү ягында түгел.

— Потому что, я тебе чужая! Поэтому ярдәм итәсең килми. Все ясно. Давай миңа әнидән калган украшениеләрне!

— Миндә аның бернәрсәсе дә юк.

— Ә менә бу сережкалар?

— Боларны миңа бергә эшләгән иптәш кызлар бүләк итте...

— «Бүләк»! Кому син кирәк?

— Мин аны сиңа болай да бирәм, холыксызланма. Әниең үлгәндә мин торфта идем, хәтерлә.

— Не оправдывайся, пожалуйста. Если оправдываешься, значит, виновата.

— Анысын таныйм, виновата.

— Есть шанс и возможность исправить ошибок...

— Синамы?

— Я права во всем! И правда на моей стороне!

— Алайса бар, правдаларын, праволарың белән килгән юлыңда бул. Мә, алкаларымны, мә — беләзегемне!..

— Юк инде, миннән алай психланып кына котыла алмыйсың.

— Тагы ни кирәк?

— Если Энгельнең үзен бирмәсәң, документларын бир.

— Аның нинди документлары бар? Син бит аны мина роддом справкасы белән кайтарып ташладың да оныттың. Туу турында таныклыгын да үзем эшләттем! Өч яше тулганда!

— Ну и вот! Давай мина шул таныклыгын!

— Аның төп нөсхәсе диспансер сейфында, конторда саклана, миндә күчермәсе калган булса гына...

— Давай копиясен!

Хәдичә апай, артык дулкынланганлыктан таныклык күчермәсенең кайда саклануын хәтерли алмый, сүзсез утыра. Аннары, нидер исенә төшеп, чемоданын актара башлый. Шундагы төрле салым квитанцияләре һәм заем облигацияләре арасында түгелме? Ә заем облигацияләре юк. Юк, юк, юк. Бернәрсә дә юк. Фәһимәгә әйтергәме, юкмы?

Сөлгеләргә төргән альбом килеп чыга: фотолар, хатлар. Хәдичә апай тагы «Галиябану»ны исенә төшерә: Хәлил Исмәгыйль кулыннан револьверын бәреп төшергәч килеп туган ситуациягә охшаш очрак түгелме бу мизгелләр? Әгәр таныклык табылып, аны надзирательдәй һәр хәрәкәтен тикшереп карап торган Фәһимәгә бирсә, револьверны Исмәгыйльгә Галиябану үз кулы белән җирдән алып биргән кебек түгелме бу? Әгәр бирмәсә? Шул бер кәгазь кисәге булмаудан кызы гомере буе квартирасыз интексә? Бусы Галиябануның Хәлилгә шул револьвердан атуына бәрабәр булмасмы?

— Ну, че? Че задумалась?

— Облигацияләр юк.

— Аларын... мин алдым.

— Ник?

— Потому что, алар безнеке!

— Елларын тикшереп карар идең, юләр, син бит институт бетергән кеше.

— Хватит, нечего баш катырырга! Бар, оригиналын алып кайт. Бер сәгать вакыт сина.

Бер сәгатьтән түгел, бер атнадан да әйләнеп кайта алмый Хәдичә апай. Теге чактагы кебек, йөрәген тотып егыла ул. Әле ярый, бүлмәләрне җыештыручы дежур санитар күреп ала аны.

...Үзләренең амбулаториясендә дәваланып, аягына баскач та өенә кайтырга курка ул. Ана, остения диагнозы куеп, егерме дүрт көнгә санаторийга озаталар... Өенә кайтса, өстәлдә язу ята: «В другой приезд тебе симуляция не поможет. Не ищи, сама найду. Ф...

...Эзләмиме соң инде Хәдичә?! Казлар суйгач, өчесенә атап мендәрләр эшләтә дә, таныш-белешләре аша эзләтергә керешә. Кадриясенең, кайтып, Мәскәү консерваториясендә укуын дәвам итүе турында белә. Ә Фәһимәсе... Фәһимәсен тагын утырткannар. Өч елга... Шулай үтә көннәре, үтә еллары.

... Энгельне махсус юллама белән Свердловский шәһәрендәге юридик институтка озаталар.

Ул, Свердловск шәһәренә барып, оныгын тулай торакның беренче катындагы бүлмәгә урнаштыруда булыша. Коляскадан котылып, култык таяклары ярдәмендә йөрергә өйрәнгән егет өчен әбисенең бу миссиясе бик зур ярдәм әлбәттә.

Оныгын урнаштырып кайтышлый, шатлыгы белән уртаклашырга Хәдичә апай Тансыкта тукталырга була.

Автобустан төшеп калгач, җәяүлеләр сукмагыннан урман аша турыга гына чыгып, авылына караса, Хәдичә апай куркып кала: ул белгән Тансык юк. Урамнары шул ук кебек үзе, тик чокылган, тимер-томырлар пәрәвезе чорнаган. Өйләре элеккеге урында кебек, әмма аларда җан юк, тормыш әсәре юк. Җаны булмаса агачны утын, диләр, үләнне — печән, кешене — мәет. Ә менә җансыз авылны ничек атарга? Хәдичә апай җавап таба алмый.

Ул басу юлы буйлап, кайчандыр Әкән куышы торган урынга килә. Андагы ташландык комбайн өстенә менеп үзе килен булып төшкәнче Мәсәбихы салган йортны күрмәкче була — танымый. Урыны-урыны белән түбәсе купкан, тәрәзәләренә аркылы такта сугылган, бәрәңге бакчасында шайтан таягы белән тигәнәк үскән. Ничә яшендә соң әле бу йорт? Ачлыкка кадәр салынып, мин туган елны күчкәннәр, дигән иде Мәсәбихы. Димәк, бу йортка инде 60 яшь тулган. Утырырга тиеш әле ул, мәрхүмнәргә һәйкәл булып утырырга тиеш!

Белешмә алмакчы булып, мәктәпкә керим дисә — ул бикле. Хәдичә апай, авылдашлары белән күрешеп сөйләшергә дип, кибеткә керә, сәламен алучы юк. Һәркем үз эше белән мәшгуль. Кышын да ягылмый торган мич артында өч ир кеше ни турындадыр бәхәсләшә, алларында шәраб шешәсе, шпрот консервасы, стакан. Яшь кенә ике хатын май үлчәтә. Сүз башлар өчен Хәдичә апай май үлчәтүчеләргә эндәшә:

— Үзегез сыер асрамыйсызмыни?

— Аның сөте балаларга да җитми ич. Ә сөт нурмасын май белән түләү рөхсәт ителә. Менә — алабыз да — салабыз. Мәшәкате юк.

— Алай икән... Өй түбәгез калай икән.

— Ә сез, апай, тикшерүчемени? Түбәләргә үк менеп киттегез.

— Шушы авылдан киткән кеше мин. Хәдичә атлы. Ишеткәнегез бармы?

— Инде бөтенләйгә кайттыгызмы?

— Килдем... Күрергә... Карарга...

— Тапкансын карар нәрсә... Бер минут та тормыйча чыгып качардай авыл бит ул Тансык.

Хәдичә апайның йөрәген яралаганы — үзен яшьләрнең танымаулары түгел, ә бәлки, аларның туган авылларына шулай гамьсез, битараф мөгамәләсе булгандыр, мөгаен.

Кемгә дә булса кереп чәй эчү ниятеннән, кучтәнәчләр ала да, урамның югары очына таба юнәлә. Тик беркемне дә очратмый. Кирегә китә. Бераз баргач, кемнендер артыннан чабуын сизенеп караса — бер карт ана таба килә-килә нидер ымлый. Әпә Рәшит бит! Исән икән, җаный!

— Ы...ы...ы...

...Килеп җитә дә кул биреп күрешә ул. Аннары төтен чыккан бер моржага төртеп күрсәтә. Әкән Әкәнең өенә күрсәтә икән.

— Өйдәмени? Исәнмени?

— Ыы...

— Озатып куй мине шунда!

— Ыы...

— Мә, шуның өчен кучтәнәч алырга ун сум акча үзеңә.

— Ыы...

Әкән әкәнең өе турына җитүгә ишек алдында парлап ике эт өрә башлый. Әпә Рәшиткә нәрсә — ул ишетми, ишетмәгәч эт өрүе бармы — юкмы ана, дөнья бетереп капка кага.

Бераз көттереп, йорт хуҗасының тавышы ишетелә.

— Пожармы әллә?

— Ыыы...

— Фу! Житте, өрмәгез! Фу!

— Ыыы...

— Син йөрисең икән... Коры жирнең көймәсе... Миндә әндри казнасы юк... Ни кирәк тагы? Кичә бирдем ич...

— Ыыы...

— Ялынма! Синең кебек пенсия акчасына гына яшим мин дә...

— Ыыы...

— Газ кертүчеләргә түлисем бар, йөрмә!

— Ыыы...

— Мингали абзый, бу — мин идем — Хәдичә. Рәшит озатып китергән иде. Ач капканны, күрешик. Озак тотмам.

— Рәшит китермәгән сине, Аллаһы Тәгалә үзе китергән, Хәдичә бану! Исән икәнсең! Кер! Менә сиңа, Рәшит, сөенчесенә бер сум үзенә, ә юк — ике сум булсын. Бар — ычкын. Шатландыр авылдашларны!

— Ыыы... ы...

— Әйдә кер. Бу арада гел уң күз кабагым тартты, гел кемдер килер төсле, сөендерер төсле иде. Син икән.

— Сөенерсеңме, көенерсеңме — күрешеп китим, дидем.

— Шул гомер көттереп кайт та, «китим» имеш. Эшләмисеңдер бит, пенсиядәдерсең?

— Документлар җыеп йөрим. Пионер вожатые булып эшләгән еллар өчен мәктәптән белешмә кирәк. Ишегендә йозак.

— Мәктәп кучте. Ике авылныкын бер иттеләр. Бала-чага аз бит хәзер... Авыл Советы да шунда, почта да.

— РОНОга барырга туры килә инде, алайса.

— Үзем барырмын. Бер эшем дә юк. Алгач, хат итеп салырмын.

— Андый белешмәне чит кешегә бирмәсләр шул.

— Мин сиңа чит кешемени, Хәдичә бану?!!

— Син миңа авылдаш, Миңгали абзый. Дус булмасак та, дошман да түгел. Рәхмәт сиңа, исән-сау икәнсең: кабат очрашулар насыйп итсен Ходай! Сау бул, яме, хуш!

— Чәй-фәлән эчәргә дә кермисеңмени?

— Көн яктысында атлый торыйм, бәлки автобуска да өлгерермен.

— Чәй эчмәсәң — яна балдан авыз итәрсең. Матаем бар, аннары кая кирәксә — шунда озатып куярмын.

— Шулай дисәң генә инде... Бисмилла...

Кече капкадан кереп, келәсен салуга урамнан машина кычкырткан тавыш ишетелә. Әкән әкә капкасын кабат ачса, ишегенә «Райгаз» дип язылган «УАЗ» машинасы килеп туктый.

— Кичә көн буе көттем, килмәдегез, кунак бар чакта бимазалап йөрисез...

— Шул кунак барлыкны Рәшиттән белеп килдек. Сәлам һәм хөрмәт.

— Кирәк бит!? Заказ белән оештырылган очрашу диярсең. Сезме соң бу, әллә күземә генә күренәсезме?

— Хәзер инде үзем дә буталам: минме соң бу? Ә син үзгәрмәгәнсең. Ахры михнәт-хәсрәт күрмәгәнсеңдер.

— Хәсрәт мине күрмәде, хәлемә кермәде — изде генә. Ә син яшәреп киткәнсең, Хәмит абый...

— Кабат партиягә алдылар! Стажым белән! Мин дә репрессия корбаны исәпләнәм хәзер!.. Әйе... Авылларга газ кертү буенча чабабыз. Эш күп, шул яшәртә.

— Сузган торбаларын алыштырыр вакыт җитеп килә, зәңгәр ялкыны һаман юк. Ничә ел буе ялкынсыз яна йөрәк. Акчасын җыялар да — кәнис.

— Хәдичәләр гаепле, Миңгали Шәрифҗанович, алар бит кабынган утны сүндереп тә тынычланмыйлар, яңасын кабызырга да комачаулыйлар. Пряме, бәла!

— Аңлашылмаган киная булды бу: нинди утны?

— Киная түгел — факт. Авылда ташландык йортлар күп. Синекеләрне генә алыйк — өчәү. Формально авыл Советына карасалар да юридически аларның хуҗалары исән бит. Каяндыр кайталар да, кеше яшәмәгән җимерек йортларына газ кертүне сорыйлар. План үзгәрә, сроклар күчә. Проект эшләтү үзе генә дә ярты ел вакытны ала. Шул сәбәпле «ялкынсыз яна йөрәк».

— Мин сорасам, миңа да шулай «ялкынсыз янармы» йөрәк?

— Йөрәккә кадәр күз күрергә тиеш: гариза буенчамы? Чынмы, юриме?

— Капка төбендә чишелә торган мәсьәлә түгел, кереп сөйләшик.

— Күңләште картлач! Ну, малай, булырсың икән кигәвен...

— Гел көтмәгәндә килеп чыгасың да, бөтен эшне бозасың.

— Чәйгә төшкән шөпшә кебекме? Ха-ха!

— Минем кебек буладыр инде.

— Сине көттек без, Хәдичә, көттек. Күп көттек. Авырганыңны ишеткәч бик борчылдык. Ничек соң? Уздымы, кеше булдыңмы?

— Кем белгән инде аны... Уздымы, аздымы... әлегә яшибез.

— Томаулап кына яту түгел шул, «астения» диделәр. Өстән түгел — астан изә торган чир.

— Анысына кадәр белгәннәр.. Гаҗәп...

— А как же! Син бит безнең знаменитость! Бөтен Тансык халкы үзен сиңа бурычлы саный.

— Аның каравы, минем беркемгә дә бурычым юк!

— Ә теге чакта авыл Советыннан алган акча?

— Өйне сату исәбенә алдан түләү дип кабул иттем мин аны.

— Кемгә кирәк ул өй? Кем ала аны?

— Алайса нигә шулай дип җавап язмыйча акча салалар?

— Миңа туры килде синең хат, миңа! Салдым!

— Белгән булсам, әлбәттә, алмаган булыр идем. Алганда кешенеке, биргәндә үзеңнеке шул. Процентлары белән ничә сум тиеш инде мин сиңа?

— Икебезнең дә бурычларыбыз бетте. Аллаһы әкбәр.

— Безнең арада сүз утыз ел элек киселде.

— Алай димә, Хәдичә. Дөнья — түгәрәк шар кебек. Китәм дисәң дә элекке ызанга чыгасың әйләнеп.

— Сумманы әйт! Бу хурлыкны күтәрү миңа авыр.

— Ә безнең паспортлар чиста, шәхескә тап төшерерлек штамплар сугылмаган.

— Аларны суктыручы да, сугучы да син үзең бит, Хәмит Ризванович. Мин шаһит... — дип, тавышын тагын да көчәйтте Әкән әкә.

— Син мәсьәләгә теге чактагы каравыл куышыңнан карыйсың. Ул заманнар ерак калды, абзый.

— Сине мин әле хәзер генә күреп аңладым шикелле, Хәмит Ризванович... Ничә сум бурычлы сиңа Хәдичә? Бөтен өй хакымы? Ярты өйме?

— Әйттем ич: гөнаһлары кичерелде!

— Гөнаһларны кичерүче бер Алла! Мә сиңа: бүгенге өй хакы! Машина алырмын дигән идем — матай белән майтарырбыз.

Игътибар Миңгалигә юнәлә. Шаяртамы? Максаты ни? Ул, күлмәкләрен

салып, ялангач кала. Капрон бау белән муенына аскан янчыктан акча чыгарып саный да, аны УАЗ капотына шапылдатып сала. Жинүче кыяфәтендә Хәдичәгә карыйм дисә, анысы җирдә ята. Тагы приступмы? Кылануымы? Шуннан соң ни булганын күз алдына китерүе кыен түгел.

Әйе, Хәдичәне машинаның йомшак диванына салып, медпунктка алып китәләр. Алар бәхетенә Мөгаллимә апай әле эш урынында була. Пенсиягә чыккач санитарка штатында гына исәпләнсә дә төп эшләрне һаман ул башкара.

Ул авыруның кан басымын үлчәгәч, Хәмит Ризванович белән Мингали әкәне, куркытырлык сәбәпләр юклыкка ышандырып, озата да, дарулар барлый башлый, укол кадамакчы.

— Рәхмәт, Мөгаллимә апа, узды инде, эзләмә. Миңа әлегә бернинди дә укол кирәкми. Кирәк булса, даруларны үзем белән сумкамда йөртәм — миндә астения бит.

— Һәй, хәзер инде бу яшьтә һәммәбездә дә астения. Зыян итмәс, мә эчеп куй, тынычланырсың.

— Тынычланулар безгә килер микән, әллә күрми узар микән?

— Аны син әйтәсеңме, минме... Теге чакта, төрмәдән кайткач, кешечә каршы ала алмавым өчен үкенеп борчылуларымны бер Алла гына белә. Син уйлама, гаепне бер Гәүһәр Камаевнага гына аударырга җыенмыйм мин. Һәр кешенең үз башы, үз йөрәге бар. Ә йөрәккә каршы барып кылган гамәлләр өчен һәркем үзе җаваплы. Гаеплемен. Гел исемдә булдың, гел янына барып гафу үтенергә җыендым — булмады. Пенсиягә чыккач, эзләп барырмын да тезләнеп гафу үтенермен, әйтәселәремне әйтермен дә, әманәтләремне бирермен, дип планлаштырдым. Юк, чыгып китеп булмый. Эш. Алмашка килгән кызга ышаныч юк. Райздравка диган булып нефтьчеләр профилакториясенә китә дә атна буе юк. Бүген дә... Райздравтан эзләтәләр. Ни диярге дә белмим... Сезгә китте, дидем.

— Эзләтүгә калгач, өметле түгелдер шул. Үз башымнан кичте ул эзләтүләр.

— Тәүбә. Синекеләрне медаль алдылар, дип телевизордан да күрсәткәннәр иде. Улым караган, мин эштә калдым. Күптән инде.

— Олы укуга киткәнче, бары да шөкер иде. Аннары күз күрде, кояш алды.

— Фәһимәсен дәме? Үлмәгәндер бит?

— Тере дип тә әйтә алмыйм. Таба алмыйлар. Утырткан нар дип ишеткән идем. Элек утырганын гына әйткәннәр булып чыкты.

— Бала-чага кулына керсә, югалтуы ихтимал, синдә саклансын, үскәч Фәһимәгә бирерсең, дип Саймә апа алкаларын миңа калдырган иде. Хәзер инде андый алкаларның модасы да чыкты, хакы да әллә ни кыйммәттән түгелдер... Шулай да, мин аны иясенә тапшырырга тиешмен, Хәдичә, Фәһимә табылмаса, нишләргә?

— Аның бик акыллы студент улы бар. Юридическийга керде. Шуннан кайтып килешем. Җаның тынычлансын өчен, әбиең истәлеге дип, аңа салырсың. Бу хәлдә бүтән чараң юк. Адресын калдырам.

— Әгәр алкаларны сиңа биреп, син генә тапшырсаң?

— Юк, Мөгаллимә апа, ул бит — истәлек, васыятьле — ядкарь. Варисларына үз кулың белән биргәндә генә кыйммәтле.

— Төрмәдән котылып кайтачагың мәгълүм булгач, Гәүһәр белән яннарына барып, сиңа иярмәскә, күчеп китәргә күндердек сабыйларны. Пособиегез өчен генә асрый ул сезне, дип ышандырдык. Яшермим, ул чакта минем үземне дә шушыңа ышандырдылар. Аңлыйм: син минем шул хыянәтләремне гафу итә алмыйсың. Мин дә кичерә алмас идем. Нишләргә соң миңа? Үземә

нинди жәза бирергә? Әйт, гәзиткә язып чыгыйммы?

— Юләрләнмә, исәр! Үзең әйтмәсәң, бу эшләрең турында мин әле белми дә үләр идем.

— Әниеннең алкалары Хәдичә апаңда, дип тә ычкындырылды. Бер көн килеп аны таптырырлар. Ал, Хәдичә, киреләнмә, коткар мине хыянәт тозагыннан!

— Алар миннән нидер таптырганчы, үзләрен табарга кирәк. Пенсиягә чыккач, Фәһимне юлларга ниятлим. Үлгән булса каберенә... таш куйдырырмын.

— Үлде микәнни? Узган ел 8-март бәйрәме белән котлап открыткалары килгән иде.

— Сиңамы? Бәбекәемдерлә...

— Каян исенә төшергәндер, соңгы күрешүдән егерме дүрт ел гомер узган!.. Менә ул открытка, пыяла астында саклыйм.

— Ни язган?

— Әфган сугышында гарипләнеп, орден тагып, үлем көтүчеләр йортында подполковник пенсиясенә кеше җәфалап ятам. Хатын ташлады, балалар юк, туганнарны борчыйсы килми; сәламәт чакта аралашмагач, әнигә язарга оят. Безне хәтерләүчеләргә сәлам, мина үпкәләмәсеннәр, шулай килеп чыкты инде, төзәлергә соң, — дигән.

— Адресы?

— Саннар гына. Госпитальдер.

— Кая, бир әле, үз күзләрем белән күрим.

— Язуы бик матур икән.

— Мөгаллимә апа, бу аның кулы түгел... Түгел!

— Берәрсеннән яздырды микәнни?

— Теле дә аныкы түгел. Түгел!

— Кемнекедер дисең?

— Димәк, ул үзе каләм тотып язарлык хәлдә түгел. «Гарип» дигән бит. Бәлки күзләре дә күрмидер. Кемгәдер әйтеп торып яздырган булып чыга.

— Башы эшли. Хәтерли. Борчыла.

— Мина бу частьнең кайда булуын белергә кирәк.

— Исәнлеген, дисәнче. Чөнки минем рәхмәт әйтеп язган хатыма җавабы килмәде... Шуңа борчылам.

— Әгәр аңа кемдер безнеңчә хат язарга булышкан икән, димәк, анда татарлардан ул гына түгел. Эзләргә, табарга кирәк.

— Менә бит, ә... открытканы алуга синең белән элемтәгә керәсе калган.

— Араларны өзмәскә кирәк шул...

— Әйе, бәйләнешләрне өзәсе булмаган. Мин гаепле. Белә торып, сизә торып... Белә торып, Гәүһәр оеткысы...

— Ул оеткы Гәүһәрнеке генә түгел. Күрәсең, һәммәбездә дә бер яхшы ниятка каршы бер начарлык яши.

— Әйдә, кайтабыз, ачыккансыңдыр...

—Өемне барып күргәч.

— Үзең генә барма, әнә Рәшит озатыр...

...Хәдичә апай үзенең килен булып төшкән йортына, белгән догаларын укып, бик сак адымнар белән керде. Үзе генә килгән булса, чынлап та ишек-капкаларны ача алмас иде. Ачтылар, керделәр, күрделәр: Ходаем, ул чак сарай кебек күренгән өй эче кысык кына бер бүлмә икән ләбаса!

...Рәшит йозакларны тиз ача алуына мактау көтеп, түр сәкедә тын гына утыра, Хәдичә апай саклаган әйберләрен барлый.

Гәүһәр Камаевна бөтенләй үк начар кеше булмаган, котылып кайтып күрешү насыйп булса, бәхилләшү кирәктер.

***

...Сүз озайтмый гына, рәхмәтләр әйтешеп саубуллашалар да, «Молоковоз» Хәдичә апайны Тансыктан тагы биш елга аерып, олы юлга таба элдерә.

Әйе, Хәдичә апайның үзен Тансыктан биш елга аерса, вәгъдә ителгән туйны да биш елга кичектерә аның бу сәфәре.

Чаршадага кайтуга улы Фәһимгә һәм адреста күрсәтелгән хәрби часть командирына хат язып сала ул. Хатларына җавап көткән арада пенсиясе өчен кирәкле документларны юллап, тиешле урыннарына тапшыра; Кадриясе белән бәйләнешкә керә; ниһаять, Фәһимәсен дә таба: «... «домработница»лыкка ялланып эшләгәндә тол профессорга гашыйк булып, кияүгә чыккан. Хәзер шунын тәрбиясендә, ягъни шуны тәрбияләп яши икән; бала-чагасы булмаган профессорның үзенең дә хәле шәптән түгел икән — укол белән генә торганлыктан, аны ташлап беркая да чыга алмыйм, Энгельнең адресын салсаң, акча җибәрер идем, дигән. Чынмы? Ялганмы?

Хәдичә апай аптырый, икеләнә: ышаныргамы, ышанмаскамы?

Энгельнең адресын салса ни булыр да, салмаса ни булыр? Салса, нигә адресын күрсәтмәгән? «Довостребование»гә дигән. Димәк, аның даими торыр урыны юк, яисә, хатның башка кеше кулына эләгүеннән курка ул. Нигә курка?

Озак көттермичә Фәһимәдән тагын бер хат килә. Монысы инде бөтенләй башка көйдә: «Әни! Мин Энгельгә чит кешемени? Димәк, син аны мина чит итеп тәрбияләгәнсең? Хәзер минем бүтән бала табар мөмкинлегем юк. Ильям (профессорым) шешә белән генә йөри. Вакчыл булмаса да көнчел. Мин аңа Энгель турында әйтмәгән идем. Шуңа күрә хатны «довостребование»гә язуыгызны сорадым. Ә болай әйбәт кеше ул. Мин аның белән «Правда» газетасына яклау эзләп баргач таныштым. Ул Адоратскийның кул астында эшләп, ЦКга үрмәләгән кеше. Партия органнарында мәкаләләре күп басылган; зур чиннарга докладлар язган абруйлы белгеч... булган...

«Булган» дигәнем шуна — авыруы аркасында хәзер ул төп эшеннән китәргә мәҗбүр. Консультант буларак кына эшли. Квартирабыз зур, дүрт бүлмәле. Мине ул язылышканчы ук пропискага кертте. Аннары мин аңа, квартирасына кызыгудан бигрәк, үзен хөрмәт иткәнгә ризалаштым. Хәзер инде (синең хаттан соң) Энгель турында да дөресен әйтәм. Аңлавына һәм шатланачагына шикләнмим.

Кадрия белән Фәһимгә адресымны бирүенә рәхмәт. Кадриядән хәбәр булса да Фәһим әлегә дәшми.

Сагыну сәламе белән, кызын Фәһимә».

Менә шундый хат килә Хәдичә апайга. Ул тагы аптырап кала: соңгы очрашуында бөтенләй диярлек татарча сөйләшмәгән кеше саф татар телендә хат яза аламы? Ул әнисенең ике хатын да Энгельгә җибәрә. Үзе хәл итсен!

Шул арада Фәһим яткан госпитальдән дә җавап килә: моннан бер ел чамасы элек мәрхүм булган. Бу турыда документлар тол калган хатыны адресына җибәрелгән, каберенә таш куелган.

Шулай яши Хәдичә апай. Аның һәр көне, һәр сәгате тәрбияләнүче балалар белән, шуларга бәйле. Аның тәрбиясеннән чыккан балалар да онытмыйлар. Әледән-әле хат язып, күчтәнәчләр җибәреп торалар.

Иң зур шатлыгы, әлбәттә, Энгеле. Өченче курсны бетергәч, әнисе янына Мәскәүгә күчәргә мөмкинлек чыга аңа. Нәтиҗәдә Фәһимәнең ире — Илья Энгельне Мәскәү халыкара багланышлар институтына күчерүгә ирешә, улы итеп яздыра.

Хәдичә апайга отпуск алып, бу шатлыклы үзгәрешләрне үз күзләре белән күреп кайту чарасы гына кала.

...Мәскәү, Казан вокзалы.

— Әни!

— Әбау! Фәһимә, синме бу? Чәчеңне ник үзгәрттең?

— Парик ул, әни, парик! Калганы барсы да үземнеке. Син дә нәкъ авыл карчыгы булгансың. Килешеп тора үзеңә.

— Шәлемме?

— Әби булу.

— Әби булгач... Энгель кая соң? Хәер, култык таягы белән йөрү.

— Култык таякларын ташлады ул, ипләп кенә үзен-үзе йөртә... Килмәвенең сәбәбе бөтенләй башкада.

— Тагын ни булды, Ходаем?

— Әтисенең хәле авырайды, аны саклап утыра.

— Нинди чир белән авырый соң кияү кеше?

— Анда нефролитизм белән некротический каниллит.

— Безнеңчәсе ничек була?

— Безнеңчәсе муенга аскан бутылка, шланг. Ята... и все там же.

— Тәүбә!

— Өйдәге җитмәгән — монда сөйләтәсең. Бик беләсең килсә, кайткач, үзең җентекләп карарсың, бутылкасын түгеп, чиста бутылка асарсың. Чыдамлыгың ничә көнгә җитәр икән?!

— Син нәрсә, кызым, мин гаепле шикелле тузынасың?

— Ә минем гаебем нәрсәдә? Только ленивыең бармак төртеп күрсәтми уза. Имеш, мин аның квартирасы өчен генә килгәнмен, мин аны чирләткәнмен. Дөрес, мин аңа чыкканда бутылкалы түгел иде ул. Чирен яшермәде, бөерләргә ремонт кирәк, диде. Үземнең дә бөерләр авырткач, мин аның хәленә кердем, ул — минем хәлемә. Булганы шул.

— Ярар, кеше чирләми тормый, холыксызланма, түз.

— Мин аның каршында уйнарга җыенмыйм. Квартирасы да кирәкми, акчасы да. Туйдым.

— Үзенә дә сиздерденме инде?

— Сине шуңа көттем.

— Нәрсәгә «шуңа»?

— Аны сиңа калдырып, ялга китәргә, аннары... Аннары күз күрер...

— Мин эшлим ич әле, кызым, эшләмәгән чагым булса...

— Синең мине чит итүең шуннан да күренә. Әйдә, тормыйк монда менләгән кеше арасында, кайтыйк.

— Юк, мин анда бара алмыйм хәзер.

— Бармый ни чараң бар?

— Билет алам да кире кайтып китәм.

— Сине Энгель көтә ич.

— Әйтерсең — озатырга килер.

— Син аны барып күрергә дә куркасың. Ә мин шуның белән яшәргә тиешме?

— Курыкмыйм. Синең җинаятеңнең шаһите буласым килми.

— Белдең, димәк, шаһит дигән сүз. Туктат бу эшне, нигә туктатмыйсың? Мораль уку җиңел ул.

— Кадрияләр беләме бу хәлләрне?

— Алар Германиягә киткәндә болай ук түгел иде ул.

— Димәк, мин бүген Кадрияләрне күрә алмыйм.

— Бүген генә түгел — бик озак, аларга кино төшерү җене кагылган. Бүлмәләренең ачкычы бездә. Анда куна аласың... Китәм дисәң — Энгельгә дөресен әйтәчәкмен.

— Китәм. Әйдә мине кассага илт тә, Энгельне монда җибәр.

— Ул минем күңелдәге давылларны белми, кара аны...

— Миннән белер...

— Шулай инде, син бит гел дөресен сөйләүче «артистка»...

— Кешенең ышанычын аклар, гомерен саклар өчен мин теләсә нинди корбаннарга да әзер. Булганны — бетерү, житкәнне — җимерү жинел ул. Бар — Энгель килсен!

...Чаршадага кайткач, Хәдичә апай тормышының яңа этабы башлана.

Балаларының шундый булуларына, әйдә, ул гаепле булсын. Ә менә авылларның, Тансыкның шундый ташландык хәлдә калуына кем гаепле? Моңа да ул үзен гаепле саный. Үзен генә түгел — авылны ташлап киткән һәркемне гаепли ул.

Димәк, авылга кайтырга, шунда яшәргә, өйне яңартырга кирәк. Энгеле дә шулай диде. Бу фикерен ул баш врачка да белдерде.

***

Хәдичә апайга 60 яшь тулуны сәбәп итеп, аны хөрмәтләп озату кичәсе оештырыла. Кичәгә Чаршада «детдом»ында тәрбияләнеп, хәзерге көндә дәрәҗәле урыннарда утырган кешеләр дә чакырыла.

Кичә сабан туйлары чорына туры килә. Кунаклар исемлегендә атказанган мәдәният хезмәткәрләре дә, врачлар да, юристлар, финансистлар, трест хезмәткәрләре, министр ярдәмчеләре, төзелеш оешмалары начальниклары да була.

Вакыйганы республика күләмендә яктырту өчен газеталардан, радиотелевидениедән хәбәрчеләр килә.

Кыскасы, кичә көткәннән дә яхшырак узып, гомум бәйрәм төсендә ике көнгә сузылды. Хәдичә апай өчен иң көтелмәгәне шул иде, ике төзелеш начальнигы, берләшеп, Тансыктагы йортын өр-яңадан төзергә барлык кунаклар алдында сүз бирделәр. Башкалары да, алардан калышмады — Хәдичә апайны бүләкләр белән күмделәр.

Бәйрәм уза, кунаклар таралыша. Мин — Тансык кешесе буларак та, Хәдичә апай уйнаган соңгы спектакльнең шаһите буларак та, аның турында документаль фильм төшерергә алынган автор-режиссер Шаршадада тагын бер көнгә тоткарлануны кирәк табам.

— Хәдичә апай, без икебез дә Тансыктан бер чордарак чыгып киткән кешеләр. Мине анда бүген җәлеп иткән, чакырып, тартып торган бернәрсә дә юк. Ә синең туган авылың Тансык түгел, әти-әниләрең дә анда җирләнмәгән, биш яшеңнән ятим калып башта ерак туганың гаиләсендә, аннары приютта гына тәрбияләнеп, Тансыкка килеп сыенгансың. Мәсхәрәләүләр, газап-михнәтләрдән башка нәрсә бирде сиңа Тансык? Нигә һаман шунда омтыласың?

— Әгәр без кемне дә булса үлеп яратабыз икән, бу аның безгә күрсәткән яхшылыклары өчен түгел, ә үзебезнең аларга сарыф иткән яхшылыкларыбыз өчен. Әйе, Тансык миңа якын һәм тансык. Чөнки мин аңа яшьлегемне бирдем, мәхәббәтем шунда бөреләнеп чәчәк атты.

— Шунда ук хыянәтнең дә ни икәнен, хаксызга рәнҗетелүне дә татыдың.

— Мәхәббәт барсыннан да көчлерәк, ул барсын да җиңә.

— Хәдичә апай, фильм төшерер өчен синең теге еллардагы, «тегендә»ге кайбер эпизодларны беләсе иде...

— Варлам Шаламовны укы, Солженицынны. Алар гел минем турыда яза. Минем кебекләр турында.

— Миңа синең үз сүзләрең кирәк.

— Кеше турында гыйбрәтле кино-фильм төшерер өчен сүзләр түгел, аның язмышы кирәк. Син әле минем турыда кино эшләргә әзер түгел.

— Шуңа күрә ярдәм сорыйм.

— Әгәр син әзер түгел икән, мин дә ярдәмгә әзер түгел. Беренчедән, әле минем язмышым түгәрәкләнмәгән. Яна тормыш башланырга тора. Икенчедән, кемгә кирәк ул фильм? Нигә кирәк?

— Киләчәк буыннар өчен.

— Киләчәк буынnарга ни кирәген син каян беләсең?

... Сөйләшүебез шушында өзелде, өйгә хат таратучы кыз килеп керде. Ул бик күп хатлар һәм рәсемле открыткалар белән бергә ике телеграмма тапшырды.

— Менә, энем Садретдин, шундый-шундый эшләр, тора-бара нишләр... Ә син «фильм» дисең... Тормыш артыннан өлгерә аламы ул? Юк бит.

— Кызганыч, сүзебез бетмәстән өзелә.

— Сүзне дәвам итеп булыр, ә менә гомерләр өзелсә...

...Заманалар үзгәреп китте, биргән вәгъдәмне үти алмадым — Хәдичә апайга багышланган фильм сценарий килеш сүнде, онытылды. Озакламый үземне дә пенсиягә сөрделәр. Тәкъдимнәребез кабул ителми, сүзебез үтми башлады. Шулай, үлмәс өчен көрәшеп, күпме гомер узгандыр, бер көнне киностудиягә чакырдылар. Яңа нәфис фильм төшерә башлыйлар икән. Фильмның директоры Артур чакырта имеш. Бардым, таныштым, сөйләшәбез.

— Нинди фильм төшерү турында сүз бара?

— Сезгә бик яхшы таныш милли классик әсәр буенча.

— Аларның барысы да яхшы таныш инде.

— Сез шул әсәр буенча куелган спектакльдә уйнагансыз да, телевизион фильм да төшергәнсез, диләр.

— «Галиябану»мы?

— Мотивлары буенча.

— Анда бер генә мотив.

— Ә безнең продюсер-сценаристлар ике фильмлык мотив тапкан.

— Аларның исемнәре серме?

— Хәзер инде, хөкүмәт карары кабул ителеп, сметалар раслангач, сер түгел: ирле-хатынлы Эмиль һәм Кэдри Клауслар.

— Алманнармыни?

— Сезнең сораулар таможня хезмәткәрләренеке кебек. Алманмы, яһүдиме — какая разница?

— Бик зур аерма.

— Безгә сез тәҗрибәле милли режиссер буларак кирәк.

— Режиссер буларак? Минме?!

— Төп режиссер Эмиль Клаус үзе. Аңа тел буенча, киендерү, милли колорит, җирле йолалар, гореф-гадәтләр буенча консультант—режиссер кирәк. Шул эш сезгә тәкъдим ителә.

— Тәкъдимне кабул иткәнче миңа сценарий белән танышып чыгу мөмкинлеге бармы?

— Фильмның күп эпизодлары төшерелеп, республиканың проектка җаваплы җитәкчеләренә күрсәтелде инде. Хәтта, хупланды. Бәлки рецензиясен дә укыгансыздыр...

— Төшереп бетмәгән фильмга рецензия? Укымадым.

— Исмәгыйльгә суд ясап аның Галиябану белән туй уздыру күренешләрен генә төшерәсе калды. Ну и колоритлы кичке уеннар кирәк....

— Сез мине котыртасызмы шулай? Нинди туй?

— Тыныч кына уйлагыз да хәл итегез: бу хезмәтегез өчен 350 000 сум гонорар каралган, ашатып-эчертү расходларыннан тыш.

Бу кадәр сумманы гомер буе эшләп тә алганым юк, ризалашырга туры килер. Шулай да, сценарийны уку кирәк булыр. Аннары...

— Кайсы рольне кемнәр уйнаячагын беләсе иде...

— Галиябануны Молдавиядән — Гуцула — сопрана; Хәлилне Баку театрыннан Ага Киши — баритон; Исмәгыйль — Рига театрыннан Липанш Гандис, Бәдри — төрек артисты Шөкрәтле; Галимә — Алма-Атадан — Асылҗан; Бәдига абыстай — Хәмзә театрыннан.

— Юк, сез йә шаяртасыз, йә үртисез. Нинди Рига, нинди Молдаван, кайсы Хәмзә, кем ул Шөкрәтле?

— Мин фильмның республика җирлегендә төшереләчәк өлешләренең рәсми директоры. Шаярырга түгел, сөйләшергә дә вакытым чикле. Әле фильмның монда төшереләчәк эпизодларына декорация төзү эшләре дә бетмәгән. Ә график буенча «атыш та», «туй»да августның егермесенә төгәлләнергә тиеш. Массовкага ничә кеше табасы, атлар, сбруйларны әйткән дә юк. Бер дә юкка гына сезгә 350 000 сум гонорар куелмаган. Бу эшләрнең күбесе сезнең ярдәм белән, сезнең тәҗрибәгә, сезнең абруйга таянып эшләнәчәк. Исегездә тотыгыз: бу халыкара проект.

— Джульетта әйткәндәй: «Не я, моя нужда дает согласие».

— «Болгар» кунакханәсенең 235 бүлмәсендә кич белән аванс алырсыз да, иртәгә сәфәр. Ә хәзер шартнамәгә кулыгызны куярга безнең офиска китәбез. Аннары, баш рәссам, башкаручы архитектор һәм дизайнерлар катнашында төзеләчәк объектларның макетларын кабул итәбез. Анда сезнең кул кую кирәк. Макетларны Хорватиядә эшләттек. Милли колорит сакланганмы, белмим? Сездән башка группада аны әйтер белгеч юк: баш рәссам — поляк, архитектор — Италиядән, ә дизайнерлар Финляндиядән чакыртылды.

— Сез — татар егете — шушы афераның башында торасызмы?

— «Классика — бывшая афера»,— диләр. Ә инде минем татарлыкка килгәндә, вообще-то, мин яһүд.

— Татарча яхшы сөйләшәсез.

— Хәзер бөтендөнья татарчага өйрәнә. Шуңа күрә беренче татар фильмы иң югары сыйфатлы булып чыгарга тиеш. Бөтендөнья игътибарын яуларлык!

— Инде ничәнче фильмыбызның һаман «беренче» икәнен беләсезме?

— Һәр эшне беренчесе һәм соңгысы дип эшләгәндә генә ул оригиналь була.

Шартнамәгә кул куеп, командировочныйлар һәм арендага УАЗ машинасы алып, группадагы кайбер иптәшләр белән икенче көнне бергә юлга чыктык.

Сәеррәк тоелган бу эшкә җиңел ризалашуымның гонорарыннан тыш тагын бер сәбәбе — «съемкалар» үзебезнең Тансык авылында узачак. Бу хәбәр бер яктан шатландырса, икенче яктан уйга да салды: ни өчен Тансык? Чын татар авылының рухын һәм йөзен югалтмаган авыллар республикада күп ич?!

Юлда бара-бара, сөйләшә торгач, бу сорауга да җавап табылды. Продюсерларның һәм авторларның берсе Кэдри Клаус үзебезнең Кадриябез икән ләбаса! Кадрия!

Ике-өч кешелек эпизодлар Кипрда төшерелсә дә, яшьләрнең кичке уеннары, атышу, суд, туй күренешләрен Тансыкта төшерү зарурлыгына Кэдри режиссерны, ягъни ире Клаусны ышандырып, күндергән булып чыга.

Русчаны яхшы гына сукалаган поляк (баш рәссам) Юзеф Браун да, хатыны — (костюмнар буенча рәссам) Магдалина да моңа гаҗәпләнәләр:

— Удивительно, как супруга вмешивается и подчиняет себе режиссера?!

— Она не только супруга, но и автор сценария!

— Не автор, а соавтор! Это разные ценности.

— Ценно, что они друг-друга взаимодополняют. Потому переполнены друг другом. Мы им говорим, что татарские деревни есть и в Польше, и в Литве, и в Белоруссии. Но они не в какую. Мы давно работали бы у другого режиссера...

— А этот... для вас не авторитет?

— Это его первая самостоятельная работа. Он долго работал под руководством Вайды, ну и вот случай...

— А кто их нашел?

— Скорее всего они нашли здесь кого-то...

— Самое главное, чтобы зритель в их фильме нашлел бы то, что потерял. Не так-ли?

— Откуда они знают о потерянном?

— Зато они хорошо знают, что им самим надо.

Шундыйрак сөйләшү белән юлны кыскартып, биш сәгать барабыз дигәндә Тансык күренде. Тик, ни өчендер, авыл исеме калайда «Танцы» дип язылган. Хәер, бәлки бу авылда Тансыктан берни сакланмагандыр?!

Калкулыкта, авылдан читтә чиркәүгә тартым бер корылма күренә. Юзеф аны мәчет дип аңлатты. Пенопласттан гына төзелгән икән. «Ни өчен элекке урынында түгел?», — дигәч, — «неэффектно», — диде.

Реквизит, бутафория һәм костюмнарны саклар өчен клубны җайлаганнар. Шунда ук парикмахерлар, гримерлар өчен дә урын көйләгәннәр.

Без барып кергәндә «Мосфильм»нан прокатка алып торган белгечләрдән дүрт хатын белән өч ир кеше балык ашап утыра иде. Бераз салмышлар.

Юзеф Браун рәсми тонда, бернинди сорау бирергә урын калдырмыйча, мине аларга, аларны миңа таныштырды.

Төп эпизодларны Тансыкта һәм «детдом»да төшерү планлаштырылган. Күп объектлар әзер булса да, «детдом»дагылар кинога төшерүне тоткарлый, ә төп көчләр Мәскәүдә хәбәр көтеп ята икән инде.

«Детдом»дагы йортлар, патша генералыныкы булса да бер хуҗадан икенчесенә күчә-күчә, ташландык хәлгә калгач, фамилиясе серле инвесторга сатылып, яңа хуҗа аларны (утары белән тулысынча) «Галиябану» фильмын төшерү өчен генә махсус оештырылган «Бәйрәм» студиясенә арендага биргән. Мин шул ярым җимерек йортларның экстерьерларын, ягъни, тышкы якларын такта белән тышлатып, буятып, Исмәгыйль Морза утары кыяфәтенә кертү эшләрен оештырырга, атлар, фоэтоннар кайтартырга, массовкага «артистлар» табарга, аларны киендерү, ашату-эчертү, кундыру мәсьәләләрен чишәргә тиешмен.

Никадәр кызыклы һәм гыйбрәтле булса да мин бу эшләрне тасвирлауга тукталмыйм. Алар эшләнде, мин макталдым, телеграммалар сугылды, режиссерлар да, операторлар да килде, Тансык объектларындагы эпизодлар да, «детдом»дагыларның да күбесе төшерелде. Исмәгыйльнең Галиябануга өйләнү һәм туй күренешләре генә калып бара.

...Бу туй хикәянең исемендә вәгъдә иткән туй түгел әле. Аңа кадәр төшеп калган бер очрашуны бәян итеп узу кирәк.

Тансыкка килеп төшкән төнне макетлар һәм сызымнар белән танышып, исәп-хисап эшләреннән арынгач, йокы алдыннан йөреп керергә дип урамга чыктым.

Үзебезнең өй урынын, яна хуҗа сала башлаган йортның яртылаш өелгән диварларын карап узгач, күңел тулып, Хәдичә апай йортын эзләп киттем. Карап барам — урамда күбесе яңа йортлар, тимер капкалар.

Ә Хәдичә апайга вәгъдә ителгән сарай кайсы икән?

Сарай юк! Иске йорты үз урынында. Ул гына да түгел — тәрәзәсендә уты бар. Капканы ачып керәм дә ишек шакыйм.

— Ишек бикле түгел... керегез!

— Хәдичә апай, син авылдамыни? Мәскәүдә онытында тора дип ишеткән идем. Ни хәлләрдә яшисең?

— Кышын анда, җәен монда. Исәнме-саумы үзең, нишләп йөрисең?

— Кино төшерүчеләргә ярдәмгә ялландым.

— Аларга ярдәм иткәнче ярдан этсәң мактаган булыр идем, ә болай син минем дошманым булып чыгасың.

— Син нәрсә инде, Хәдичә апай, кызың Кадрия белән киявең эше бит бу.

— Булса ни?! Башыннан ук ялгыштан башладылар алар. Коръәннән хата тапкан мулла кебек, «Галиябану»дан гел хата гына эзлиләр. Өч ел йөргәннәр шул тапкан хаталарын табыш дип исбатлап, кино төшерергә рөхсәт артыннан. Имеш, дөньяны шаккатырырга планнар коралар. Баштарак шалтыраталар иде. Соңыннан үзем кистем: әгәр шулай эшләсәгез, сез минә динен алыштырган кяфер, дидем.

— Алай ук кирәкмәс иде, Хәдичә апай, бәлки кызыклы гына кинофильм туып, чынлап та татарлар бөтен дөньяга танылырлар.

— Инде синнән дә шундый сүз ишеткәч, минем таяныр кешем юк дигән сүз. Хуш, ни йомыш?

— Йортың белән ничек соң?

— Ике КамАЗ машинасы ак кирпеч китереп ташлыйлар да... Шуның белән туктала.

— Кая соң ул кирпечләр? Авылдан чыгып качмагандыр бит?

— Аңа кем тамга салган? Кайсы гараж булып утырадыр, йә кемнеңдер мунчасы...

— Урлаганнар?

— Исраф булып ятмасынга, сорамыйча гына алып, файдаланганнар. Үзе юкның — күзе юк..

— Ярый, Хәдичә апай, съемкалар башлангач, иркенләбрәк керермен дә бу турыда сөйләшербез әле, җайларбыз. Хәзергә иптәшләр янына кайтыйм.

— Клубкамы? Килешмәгәнне... Анда ятма, монда кил. Җенле бит ул клуб.

***

...Съемкалар, график буенча үз вакытында башланып, шома гына барды. Тик, Исмәгыйльгә суд эпизодын төшергәндә, Тансык авылының вәкаләтле илчесе сыйфатында килгән Әкән — Миңгали агай гына көйләнгән эшне боза язды:

— Керәм дип тә керми йөрүеннән сәбәбе менә нәрсәдә икән?..

— Ни булды, Миңгали әкә, ни таптың?

— Соң... кеше үтерүчене яклыйсың ич!

— Мин режиссер түгел.

— Үтерүченең акланууын күрәсеңдер бит?

— Мона кадәр «Галиябану»ны куйган режиссерлар Хәлил кулындагы пәкегә игътибарсыз булганнар. Ә немец режиссеры бөтен игътибарны шуңа юнәлтә... Һәм бу бөтен процесска башка юнәлеш бирә, башка төс.

— Үлемнең төсе бер генә.

— Самооборонаны кая куясың? Үлем янаганда кешенең күзе генә түгел, үе да томалануны исәпкә алсак ни килеп чыга? Батырлык!

— Ату! Үтереш!

— Дөрес, Миңгали әкә. Ә атудан соң хөкем. Хөкемдә Галиябану Хәлилнең пычак тотып Исмәгыйльгә һөҗүмен таный. Башка шаһитләр мылтыкның тавышын гына ишеткән. Бетте. Кыскасы, мәсьәләнең бу ягы безнең эш түгел, немец уйламый эшләмәс. Безнең өстә башка бурыч.

— Синең бурыч Галиябануны яклау булырга тиеш. Ул безнең милләтнең йөзек кашы!

— Галиябану сценарийның ахырында башка юл сайлый — Исмәгыйльгә кияүгә чыгып, гаилә кора. Аның моңа хокукы булган кебек, немецның да үзенчә үзгәртергә хокукы бар.

— Син авылның, милләтнең җанына кизәнүчеләрне яклыйсың, егет.

— Мин авылыбызның даны еракларга яңгырасын өчен йөрим, абзый.

— Авыл егетләрне үстерсә, шул егетләр авылның данын үстерә. Син милли хәзинәбезне үтерүчеләр шайкасында. Син безнеке түгел!

***

...«К съемкам» дигән сигнал янгырый, эш дәвам итә. Шул көнгә билгеләнгән соңгы эпизодны төшерү башлана.

Австриядән кайтартылган фоэтон һәм трантасларга прокатка алган атлар җигелеп, агач күләгәсендә солы ашыйлар; массовкага чакырылган җитмеш кеше, баштан-аяк киендерелеп, инде өченче көн ашханәдә көтеп утыра. Кемнәрнең кайчан, кайда, нәрсә дип кычкырырга тиешлекләре сөйләшенгән, килешенгән. Өр-яңа милли киемнәргә киенгән бала-чагалар кияү белән кәләш килеп туктаячак капканы сакларга бастырылган.

— «Йола буенча кыз капкасы сакланырга тиеш!» — диючеләр булса да, аны немескә тәрҗемә итмиләр. Чөнки яңгырга кадәр эпизодны төшереп, график буенча планны үтәргә кирәк. Күктә яңгыр болытлары оеша башлаган кебек.

Массовкада катнашучыларның уенда бер генә сорау: «чәчелергә тиешле акчалар чынмы, ялганмы?»

Кемдер: «бер ягы патша, икенче ягы сәмруг башлы чын көмеш акчалар икән», — дисә, икенче берсе бу ялкынны сүндерергә ашыга, «хәзер патша башлы көмеш акчалар сугылмый, сәмруглы алюмин акчалар гына», — ди.

Чиллә кояшы кызуында, бөркү һавада, кышкы салкыннарда да туңмаслык киендерелеп, калын-калын парикларга һәм сакал-мыекларга ябыштырылган контингент инде күптән «артистланырга» әзер булса да, Исмәгыйльнең Япониядә яшәүче тол җингәсе ролендә уйнарга тиеш мәшһүр француз актрисасы мадам Монпасье килеп җитмәү сәбәпле, «мотор» сүзе һаман янгырамый. Мәшһүр мадам, хакимият даирәләре тарафыннан кабул ителүдән соң, прессконференция уздыруы сәбәпле тоткарлана, имеш. (Монысын мадам белән янәшә фотога төшеп мәшһүрләнгән җирле абыстай телефоннан шалтыратып үзе әйткән.) Күпмегә тоткарлана? Мадамны алып килергә бирелгән МЧС самолеты, кайдадыр газ торбасы шартлап, көтелмәгән эш килеп чыккач китеп бара. Аны алыштырырга тиешле нефтяниклар вертолеты прессконференция барган бинаның түбәсендә көтеп утыра.

Кино төшерергә һәм кинода төшәргә әзер халык, күләгәле урын табып, черем итеп алу жаен карый.

Кинәт генерал утарындагы иң биек йорт түбәсенә урнаштырылган репродуктордан «Общий обед»ка чакыру ишетелә. Халык, дөньясын онытып, кигән чапан-чикмәннәрен, фәсләрен, чалма-бүрекләрен кая эләксә шунда ташлап, ашханәгә юнәлә. Кирәк бит, нәкъ шул чакны туры китереп, күктә вертолет күренә. Ул, төшәр өчен әзерләнгән урынны таба алмыйча, утар өстендә әйләнгәндә «Отставить, срочно к съемкам!» әмере өч тапкыр әйтелә.

...Вертолет төшеп утыруга, Мадам Монпасьены киендерү бүлмәсенә алып китәләр. Шунда ук, әсбапларын күтәреп, визажистлар да юнәлә. Мадам нидер сөйли, көйсезләнә. Ашавын бүлдереп, ашханәдән тиз генә тәрҗемәчене чакырталар.

— Ни сөйли ул?

— Вертолетта аның шәхси пешекчесе белән, шәхси парикмахеры калган. Аларны алып килмичә киенмәячәкмен, ди.

— Никадәр халык алдында, шулай ялангач утырмас бит инде...

— «Бу минем табигый халәтем», — ди Француз бичәсе.

Монпасье әбинең пешкечесе белән чәчтарашын алырга киләләр. Йомышлысы да, йомышы югы да, сәбәп тапкан булып, киенү бүлмәсенә керә дә, алдануларын аңлап, бик тиз генә борылып чыгып та китә. Мадамыбыз бертуктаусыз тәмәкесен тарта, нидер сөйләнә. Тәрҗемәче тәрҗемә итми, «сүгенә» дип кенә куя да, нидер «мыгырдый». Күрәсең, тәрҗемә респондентыннан күңеле кайтып, үзе дә сүгенә.

Мадам Монпасьеның шәхси осталарын күптән алып килсәләр дә, «съемка — «мотор» сүзләре һаман әле ишетелми. Халык борчыла, бимазалана, пешә, сүгенә. Кемнеңдер сакалы, кемнеңдер париги купкан. Тирләгән тәнгә җилем берекми. Җиләс урын табып, җилләнергә, «кибәргә» тырышалар.

Ниһаять, электростанция эшли башлый, кояшны уздырырга теләп прожекторлар кабына.

...Ниһаять «мотор»-«съемка» дигән тылсымлы сүзләр яңгырап, мәйдандагы барлык җан иясе хәрәкәткә киләчәк. Тик аның өчен Бохара әмире ролен башкаручы фин артисты янына трантаска мадам Монпасье чыгып утырырга тиеш. Ә ул һаман көттерә. Сәбәбе соныннан гына беленде: Япониядән кайтканлыгын күрсәтү өчен «җиңгәйне» хезмәтче кыз веер җилпеп—җилләтергә, ә үзе бик озын мөштекле папирос тартып утырырга тиеш икән.

Репродукторда «Мотор!» сүзе яңгырый.

Егерме секундлык бу күренешләрне төшергәндә фин артисты Нумманеннең чалмасы сүтелеп, тәгәрмәчкә уралуыннан башка кызыклар юк.

Ә менә килен каршылау эпизодын төшергәндә кызык арты мәзәк хәлләр чыгып кына тора.

Хәер, «тычканга үлем, мәчегә көлке» дигән кебек — кемгә кызык, кемгә кызганыч.

Шуларның берсен хәтерләп узмасак, туебыз китек булыр.

...Күз алдыгызга китерегез: Австриядән кайтартылган фоэтонда «Исмәгыйль» белән «Галиябану» утыра. Молдованка берөзлексез мобильнигында сөйләшә, эстон егете шешә арты сыра шешәсе бушата. Күренеп тора — икесе дә талчыкканнар. Алардан да бигрәк атлар арыган. Иртәдән бирле су эчкәннәре булмагач, солыга да игътибарсыз алар. Ике як мичәүгә ике бурлы алаша, төпкә — чем-кара айгыр, алгы постромкага ап-ак төстәге бия җигелгән. Ничә сәгать буе тыны да чыкмый тәртә арасында басып торган «Скромный» кушаматлы айгырны әллә «Мотор» дигән әмер, әллә кучерның дилбегә кагып куюы, әллә инде «Исмәгыйль» ыргыткан сыра шешәсе хисләндерә — ул, кинәт, ниятен бөтен җиһанга хәбәр итеп, үзенең табигый хәҗәтен үтәргә, дөресрәге — гыйшкый халәтен күрсәтергә тотына.

...Ялгышлык белән бу тыйнаксыз тамашага күз салган һәркем, күрмәгәнгә салышып, башын читкә борган була. Ә «Скромный», нескромный эше беткәнче, «на» дигәнне дә, «тыру» дигәнне дә ишетми — үз туен туй итә.

...Көтелмәгән бу фокусны күреп, бөтен массовка җанлана. Режиссер өчен дә табыш була бу: ул өч операторга өч ноктадан торып, шатланган, көләч-шаян йөзләрне төшерергә боера. Бу кадәр дә бәхетле кешеләрне иң зур гонорар бәрабәренә, иң талантлы профессиональ артистлар да уйный алмас иде!..

Шул кызу сүрелгәнче режиссер кәләшне мендәргә бастыру, аның авызына бал-май каптыру эпизодын төшерергә тели. Кияү белән кәләшнең туганнары ролендә уйнаучы артистларны эзли башлыйлар. Шунда гына мадам Монпасьеның юклыгы беленә.

— Кая ул?

— Мәшһүр актрисаның шәхси пешкечесе сүзләренә караганда, мадам «Скромный»ның уенын тулысынча карап бетерә дә, кинәт егыла. Шоковое состояние!

— Монда һич тә гажәпләнәсе һәм куркасы юк, чөнки мадамның мондый хәлдә калуы беренче генә түгел, — ди пешекче.

Врач чакыртырга, дарулар турында сөйләнгәндә пешекче җаваплылыкны үз өстенә ала, үзенең дә профессиональ врач булуын аңлата.

Аның сөйләгәннәрен тәрҗемә итеп бетерүгә, режиссер фоэтонның капкадан кереп, кияү болдырына килүен кабат төшерергә була.

Аллея буйлап халыкны тезәләр, кулларына чәчәк букетлары тоттыралар. Алар чәчәкләрне атлар якынаюга юлга сибәргә тиеш була. Тик режиссерның бу «задумкасы» каршылыкка очрый. Беренче төркем букетны сүтеп тормый, төргән килеш ыргыта. Ак бия өркеп, читкә каера, «Скромный» аны яклапмы, әллә көнләпме — кешнәп җибәрә. Шул тавышка мадам Монпасье кабат һушына килә. Тиз генә аның паригын рәтлиләр, пудра сөртәләр һәм болдырга алып киләләр. Ул, үзенчә, нидер сөйләнә-сөйләнә, папирос кабызуга кинәт... кинәт... юк-юк, гел «Скромный» булмас... кинәт мылтык аткан тавыш бөтен утарны яңгырата: «Пух!»

Бөтен кеше ни булганны, кем атканны белергә тырыша, режиссер ярдәмчеләре, монтировщиклар атучыны эзли. Ә мин эзләмим. Чөнки беләм. Бу — Әкән әкә. Әнә ул — кайчандыр үзе эшләгән ат абзарлары янында мотоциклын кабызып маташа.

Сакчыларга әйтергәме, юкмы? Аңларлармы аны?

Юк, аңламаячаклар. Бәлки тәрәккыят өчен шул аңламау кирәктер? Әйтмәдем, дәшмәдем, күрмәдем.

...Әлбәттә, фильм төшерелеп бетә. Зур экраннарга чыкканчы, белгечләргә күрсәтелеп, «әйбәт» дигән бәһа ала, рецензияләрдә «татар милләтен дөньяга танытуда зур адым» дип язалар. Сценарий авторына, режиссерга, операторларга мактаулы исемнәр бирелә. Фильмның милли традицияләрне саклауга багышлап уздырыла торган фестивальләрдә призлар алачагына ышаныч бар. Ә мин... мин соң шуңа ышанаммы? ...Ышанмаслык хәлләргә дә ышанырга кирәк заман килде. Үземне-үзем ышандырырга тырышам.

Фильм безнең авыл җирлегендә төшерелгәч һәм минем дә бу эшкә катнашым булгач, директор Артурны Тансыкка кайтырга күндердем.

Исәп массовкада катнашып һәм бу фильмны төшерүдә нииндидер хезмәт күрсәткән кешеләрне җыеп, чәйләп-мәйләп үзләренә күрсәтү, фикерләрен ишетү иде.

Килделәр, карадылар. Эчтеләр, ашадылар. Ә фикерләре?

— Карагыз әле, абый кеше, мин сезнең фильмгә төшәргә дип, үз машинам белән «детдом»га унсигез тапкыр бардым. Егерме дип кул куйдырып, ике көн өчен генә акча түләдегез. Бензин хакы да юк. Тагы булырмы? Кайчан?

— Ничә тапкыр барган өчен түгел, ничә көн төшкән өчен генә акча түләнә.

— Француз маржасына ни өчен түләдегез? Егылган өченме?

— Ха-ха-ха!

— Такта коймамны сүттереп, читән үрдердегез дә шул килеш калды, утыра. Кем түли? Кайчан? Күпме?

Шушының ише сораулар бирелеп, аларга шома гына җаваплар алынгач, кайтырга дип дәррәү кузгалган халыкны Хәдичә апай туктап калырга мәҗбүр итте:

— Ничек оялмыйсыз сез, оланнар! Сезнең өчен мин оялып утырдым. Фильмны төшерүчеләр сездән фильм турында фикер сорыйлар. Ә сез «читән өчен кем түли?» Үзең түлисең! Шундый булганың өчен!

— Нинди булганым өчен?

— Фикерсез! Уйсыз! Гамьсез! Мәнсез! Тансыклар түгел сез — мәнсезләр.

— Нәрсә икән соң ул шундый кыйммәтле... төшенчәләрне үзенә сыйдырган тылсымлы хәзинә?

— Улмы? Ул «Галиябану»!

— Шушымы? Без караганмы? Хи... Пүчтәк!

— Бу — «Галиябану»ны гына түгел, милләтне хурлау, халык табынганны мыскыллап көлү. Белегез. Мин бу фильмны төшерүдә җаваплы кешеләрне судка бирәм: милләттән гафу үтенсеннәр!

— Кызың белән киявеңне гаепләп...

— Аларны беренче чиратта.

— Шуннан?

— Кемгә милләтебезнең җәүһәрләре кадерле, кем балаларының, оныкларының ата-бабалары телендә сөйләшүен, алардан калган гореф-гадәтләребезнең, йолаларыбызның саклануын тели, менә шушы гаризага кул куярга тиешләр. Бүген, хәзер...

— Әби, мин синең турыда «утырган» дип ишеткән идем. Тагы утырасың килмидер бит?

— Үз дигәнемә ирешү өчен утырудан да, үтерүдән дә курыкмыйм мин.

— Ха-ха-ха!

— Йә, кем беренче булып кул куя?

— Ха-ха-ха!

— Куркасызмы? Ярый, монысыннан курыктыгыз, ди. Әгәр үзебезнең көч белән үзебезнең клубта, үзебезчә «Галиябану»ны куйсак, катнашырга теләүче табылырмы?

— Югалган кеше генә табыла... Ә без югалмаган, без — бар!

— Миңгали абзый, син «бар» дидеңме? Спектакльдә катнашыргамы исәп?

— Гаризага да кул куям!

— Ха-ха-ха!

— Сез көләсез, ә мин чынлап һәм... ышанып. Гомерем буена мин шушы хатынга гашыйк булып, гомерем буена аңа тугры калдым, аннан башкага тәкъдим ясамадым. Ул миңа ышанмады, көлде, кире какты. Ә мин аңа гел ышандым, көттем, һаман көтәм.

— Көтмә, Миңгали абзый, бу юлы тәкъдимне мин сиңа үзем ясыйм: без бергә булырга тиеш! Сиңа туксан, миңа сиксән биш икән — ниһаять, безгә берләшергә вакыттыр.

...Клубка җыелган Тансык халкы бу күренештән соң көләргә дә, еларга да кыймыйча, ышанырга да ышанмаска да базмыйча сүзсез генә таралышты. Мин дә бу ике оригиналь шәхес каршына килеп, аларның бу соңгы адымнары турында сүз кузгатуны кирәк тапмадым. Беләм, күңелем белән сизәм: сез дә ышанмыйсыздыр бу феноменга. Финал өчен уйлап чыгарылган эффектлы бер күренеш дип карыйсыздыр. Тик финалга ерак әле. Гашыйкларның яңа тормышы башлана гына бит...

...Кулымда «Хәдичә — Миңгали» имзасы куелган туйга чакыру билеты.

...Әгәр Хәдичә апай турында фильм төшергән булсам, шуның бер күчермәсен бүләк итәр идем. Ә болай миңа шушы язмаларны гына тапшырырга кала. Көмеш туйларына, бәлки, фильм да төшерелер һәм ул, һичшиксез «Галиябану туе» дип аталыр. Кемдер: «И на старуху бывает проруха», — дияр, ягъни, дүрт аяклы ат та абына. Миңа калса, бу абыну түгел, бу — табыну...

# *«Казан утлары» архивыннан*



*Германиядән килгән Салиха ханым белән «Казан утлары» редакциясендә очрашу. Сулдан уңга: Җәүдәт Миңнуллин, Тәүфикъ Әйди, Мансур Вәлиев, Рашат Низамиев, Флүс Латыйфи, Рәдиф Гаташ, Салиха ханым, Кояш Тимбикова, Нияз Акмал, Шамил Маннапов, Мәдинә Маликова. 1989 ел.*



*Бөек шагыйрь һәйкәле янында шигырь бәйрәмнәре еш уза иде.*



*Шагыйрь Хәсән Туфан (1900–1981) дулкыннар хозурында. 70нче еллар.*



*Күренекле язучы Миргазиян Юныс «Ватаным Татарстан» газетасы хезмәткәрләре белән. 2004 ел. Ул елны язучы редакция коллективы исеменнән Г.Тукай премиясенә тәкъдим ителгән иде.*



*Республикабызның күренекле җитәкчеләренең берсе Рәис Беляев. Ул мәдәниятне, әдәбиятны яхшы белгән шәхес. Өстәвенә оста гармунчы да иде. 1985 ел.*



*Халыкара очрашуда (сулдан уңга журналист Рәсим Хөснетдинов, профессор Свами Агнивин (Һиндстан), профессор Х.Миңнегулов. Киев. 2007 ел.*

Марсель
Сәлим

# ЫШАНДЫРИН

САТИРИК ХИКӘЯ

Кайчандыр химфакта бергә укыган Хикмәт дустымны очраттым. Ул һич тә үзгәрмәгән, әвәлгечә күңелчәк.

— Ниһаять, мине котлый аласың! — диде, авызын колагына җиткереп. — Шәп дару уйлап таптым. Ышандырин дигән.

Хикмәт дусның хикмәтләренә мин инде күнегеп беткәнмен. Яшь чагында дингез суыннан бензин куарга хыялланып йөргән иде. Барып чыкмады. Елгыр егетләр аның идеясен урлады — бензинга елга суы кушып сата башлады. Моны белгәч, Хикмәтнең кәефе кырылды, әлбәттә, әмма югалып калмады. Яңа идеяләр канатландырды дустымны. Шуңа аның әлеге хәбәренә әлләни исем китмәде.

— Булыр, булыр синнән, алхимик! — дип көлгән идем, Хикмәт житди төзәтмә кертте:

— Алхимик түгел, нанохимик! – Һәм, дәртләнеп китеп, үзенең гыйльми ачышы хакында сөйләде:

— Нанохимия казанышларын киң файдалану бүгенге җәмгыятебезнең тотрыклы үсешенә турыдан-туры уңай йогынты ясый. Соңгы ачышымның әһәмияте ифрат та зур. Ышандырин — Русия гражданнарының организмы өчен үтә файдалы дару. Олы яшьтәге кешеләр аны, аспирин кебек, даими эчеп торырга тиеш. Иманым камил, тиздән минем ышандырин аспиринны алмаштырачак.

— Ай-һай!..

— Нәрсә, ышанмыйсыңмы әллә?

— Кеше ышанырлыкмыни?!

— Менә-менә! Безнең халык нәкъ синең шикелле — ышана белми. Кем әйтмешли, бу безнең иҗтимагый-сәяси чиребез. Аны бары тик ышандырин белән генә дәвалап була.

— Булды ди!

Хикмәт миңа гаҗәпләнеп карады да:

— Әйдә, алайса, сыныйбыз... синдә! — диде.

Аның бу идеясе миңа кызык тоелды. Яңа ачышның дөреслеген үземдә тәҗрибә ясап тикшерүдән дә ышанычлысы юк.

— Ярый, подопытный кролик булырга мин риза, — дидем. — Алга, алхимик... нанохимик!

Без якындагы Мәдәният сараена юнәлдек. Анда депутатлыкка кандидатлар белән очрашу бара иде. Зур залга үтеп, арткы рәттәге буш урынга кунакладык.

Трибуна артында — Түрәгали Күпертәевич. Гадәтенчә борчак сибә:

— Мин халкым өчен янып яшим. Аның ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатында соңгы айларда аеруча зур эшләр башкардым. Минем җитәкчелегем белән тар урамнар киңәйтелеп, киң тротуарлар тарайтылды. Автомобиль хуҗалары рәхмәт укып бетә алмый...

Шулчак янәшәбездә утыручы ак мыеклы абый кычкырып сүз кыстырды:

— Өемдәге сөекле автомобиль хуҗаларына, дип әйт! Хатының белән балаларыңның һәрберсендә — өчәр машина.

Түрәгали Күпертәевич бер секундка тукталып торды да сүзен дәвам итте:

— Әйе, хәзер сөекле халкыбызның тормыш шартлары нык яхшырды. Чөнки хезмәт хаклары, пенсияләр бертуктаусыз арта да арта. Шуңа янаданяна кибетләр ачарга туры килә. Киләчәктә арзан фатирлар төзүне дә җайга салырга ниятлибез. Ләкин моның өчен мине депутат итеп сайлавыгыз мәслихәт...

Әһә, түрәлектән туйган бу, тынычрак урынга күчеп утырырга исәбе. Минем уйларымны укыгандай, янымдагы Ак мыек:

— Ришвәт алып, баеп беткәч, җиңел генә җаваплылыктан качып котылмакчы, — дип куйды.

Гомер буе түрә креслосын биләгән кешенең бармагы үз ягына кәкре икәнен яхшы белгәнгә мин аның депутат булып халыкка тугры хезмәт итәренә тамчы да ышанмадым. Өметсез карашымны Хикмәткә төбәдем. Ул шундук, эшнең нидәлеген аңлап, миңа таблетка сузды. Аспиринга охшаган тылсымлы даруны йотып җибәргән идем... Менә сиңа кирәк булса, акылга сыймаслык могҗиза – Түрәгали Күпертәевичның кандидатурасы депутат булырга лаеклы икәненә ышандым бит, әй! Ә ник ышанмаска? Чынлап та, лаеклы шул. Элекке хаталарын аңлап, иске гадәтләреннән арынып, яңача яши һәм эшли башлаячак ул. Депутат итеп кенә сайласыннар!

Хикмәт миңа күз кысты:

— Йә, ничек?

— Шәп кандидатура! — дидем, күз дә йоммыйча.

Трибуна артына чираттагы кандидат менеп басты. Шәһәребезнең иң бай кешесе Алтынбай Карамаев. Болганчык заманда «кара алтын» белән әвеш-тәвеш итеп, кесәсен калынайтып калды. Байлыгы башыннан ашса да, саранлыгы белән барсын да уздырган бу замана бае, ишетәсезме, ничек сайрый:

— Әгәр мин депутат булсам, — ди, — меценатлык эшчәнлеген киң җәелдереп җибәрер идем. Үз акчама балалар бакчасы, мәктәпләр төзер идем, яшьләргә фатирлар, картларга ял йортларына путевкалар сатып алып бирер идем.

Һай, афәрин! Аңлаган, ниһаять. Урлап җыйган малның барыбер игелеге тими диләр бит. Кешегә өләшеп бик дөрес эшли.

Әмма кинәт юмартланып киткән саран байның программасы Ак мыекка ошамады

— Таштан юкә суелды ди. Күтеп тор! — диде ул, тегенең ихлас ниятен шик астына алып.

Җенем кузгалды бу Ак мыекка.

— Ә син күтеп торма, — дидем каты гына, — ышан да сайла!

Ак мыек җавапсыз калмады:

— Бик ышансаң, үзең сайла. Ә мин ышанмыйм.

Без әйткәләшкән арада трибунада ораторлар алмашынды.

— Хәерле иртә, минем хөрмәтле укучыларым! — дип югары пафос белән сәламләде безне үзен «публицист» дигәнне үлеп яратучы шәһәр гәзите мөхәррире Төчекаләмов әфәнде. — Сез тагын бу публицист исерек баштан тәүлек мизгелен бутый дип уйламагыз. Әле кич булуга карамастан, ап-аек килеш әйтәм: «Хәерле иртә!» Чөнки сайлаудан соң безне якты көн көтә. Праймеризларда елдам катнашып, мин инновацион стратегиябезнең системалы модернизациягә әйләнүенә шаһит булдым. Тиздән шундый модернизацияләнгән инновацион тормышта яшәү бәхетенә ирешүегез белән котлыйм сезне, хөрмәтле укучы-сайлаучыларым!

Берничә кеше иренеп кенә кул чапты. Ак мыек үзалдына тиргәнеп куйды да, миңа борылып:

— Син шушы алдакчыга ышанасыңмы? — дип сорады һәм җавабымны да көтмичә тәтелдәргә тотынды: — Мин аны совет заманыннан ук беләм. Ул чакта якты коммунистик киләчәк турында яза иде. Ельцин вакытында демократларны мактап, коммунистларны хурлады. Хәзер инде Ельцинны гаепләп, бүгенгеләргә дан җырлый. Гел бер төрле төче сүзләрдән торган су буедай мәкаләләре белән гәзитен тутыра. Аларны үзеннән башка укучы калмады бугай инде, гәзитенең тиражы кимегәннән-кими. Минемчә, Төчекаләмов үзенең язганнарына үзе дә ышанмый хәзер.

— Аның каравы, мин ышанам!

Бу сүзләрем Ак мыекка бомба шартлагандай тәэсир итте.

— Ышанасың?! Чынлапмы? — дип кат-кат сорады ул. — Димәк, син аның чынбарлыкта кем икәнлеген белмисең. Ә мин беләм. Заманында безнең колхозга килеп, итен, маен, балын төяп китә дә рәисебезне мактап гәзитенә яза иде. Бушка беркемне дә данламый ул. Син менә шундый кешегә ышанасыңмы?

— Ә нигә ышанмаска?! Журналистның эше шул — кирәк кешене мактау, кирәкмәгәнен таплау.

— Димәк, син аларның «икенче борынгы һөнәр иясе» икәнен беләсең?

Тәмам тәкатьне корытты бит, бәйләнчек! Чыдарлыгым калмагач, чәпәдем авызына:

— Яхшы беләм һәм барыбер ышанам!

Ак мыек утырган урыныннан егылып төште. Әллә инфаркт булды инде, тәүбә... Мин Хикмәткә бактым:

— Бу авыруга мотлак ышандырин кирәк. Бир хикмәтле даруыңны! Ләкин дусым минем борчылуларымны бар дип тә белмәде:

— Ярамый! Мин синдә тәҗрибә үткәрәм. Ә аның нәтиҗәсен үзең күреп торасың.

— Әйе, — дип килештем аның белән. — Бик ышанычлы дару икән бу ышандырин дигәнең.

— Мин аны сайлауда катнашучы берәр фиркагә сатам әле.

Шулай диде дә Хикмәт, кандидатлар белән очрашуның беткәнен дә көтмичә, чыгып йөгерде...

Ә мин ышанычлы ышандырин йогынтысында сайлауда дөрес тавыш бирдем.

Нанохимик дустымны күптән күргән юк. Белмим, хикмәтле даруын берәрсенә төртә алды микән?

Сайлау нәтиҗәләрен көтик әле...

# Мөнир Вафин

* **

**Нитратлы азык күшим дә,**
**Феноллы сулар эчәм.**
**Чәе бигрәк туклыклы дип**
**Мактап эчерә бичәм.**

**Саф һаваларга чыгам дип**
**Углерод, күкерт йотам.**
**Бу кадәрле матдәләргә**
**Бай ил юктыр ла бүтән.**

**Шуңа сөенеп яшимен**
**(Патриот булмый җебек).**
**Мин үзем дә күптән инде**
**Химик элемент кебек.**

**Гаиләм тулы элемент,**
**Илем тулы элемент.**
**Рәхмәт сезгә болар өчен,**
**Парламент Президент һәм!**

## Ялгыш кына

*Ялгыш кына кара*
*күзләреңә*
*Тиеп китсен иде*
*күзләрем.*

Рифат Сәлахов

**Машиналар, әнә, рәхәтләнеп,**
**Бамперларга бампер ләпәшкән.**
**Ялгыш кына маңгаеңа маңгай,**
**Их, бер килеп икән чәкәшсәң.**

**Башкалардай түгел, әллә нинди,**
**Әллә нинди минем теләгем.**
**Ялгыш кына уймак колагыңа**
**Тиеп китсен иде колагым.**

**Очрашасы иде тар басмада,**
**Булсын иде басма тардан-тар.**
**Үткән чакта шуны ялгыш кына,**
**Тиеп китсен иде борыннар.**

**Чакматаштай ялгыш кагылышсак,**
**Безгә башка көннәр киләчәк.**
**Шуннан инде иреннәргә ирен,**
**Кендекләргә кендек тиячәк...**

## Уртаклык

*Айнур Маратович,*
*Син бермәлне*
*Ару гына егет булырсың.*
*Кун курткадан гына такси көтеп,*
*Уфа урамында торырсың.*

Марат Кәбиров

**Булат Мөнирович,**
**Син бервакыт**
**Пәһлевандай егет булырсың.**
**Мескенләнеп такси көтмәенчә,**
**Машинаңда гына узырсың.**

**Машинаң да синең**
**Гади булмас,**
**«Мерседес»мы шунда, «Джип»мы.**
**Кул күтәреп торса, утыртырсың**
**Айнур Кәбир атлы егетне.**

## Икмәктәй иркәм

*Юлга алган ап-ак икмәк*
*Нинди тәмле иде!*
*Иркәм, шушы икмәк төсле,*
*Ап-ак тәнле иде.*

Галимҗан Гыйльманов

**Заманында безгә икмәк**
**Шундый тәмле иде.**
**Иркәм дә нәкъ икмәк төсле**
**Ап-ак тәнле иде.**

**Бернәрсәне дә аямый**
**Вакыт атлы хикмәт.**
**Бер көн килеп катып бетә**
**Икмәк кадәр икмәк.**

**Иркәмнең дә буыннары**
**Сохаридай катты.**
**Катса катсын, минем өчен**
**Ул барыбер татлы.**

Зиннур Хөснияр

## Авыл малайлары...

1

И, авыл малайлары,
Шәһәргә килдегез дә
Тулай торак ишегенә
Йозаклар элдегез дә...

Дөнья куган буласыз,
Артыннан да чабасыз.
Сизмичә, узып китеп,
Алдына да чыгасыз.

Ә дөнья бер чарасыз,
Арыган ул куышып.
«Көзнең» җиткәнен көтә
Авыл башына чыгып...

2

И, шәһәр бабайлары —
Каладан кайтканнар да,
Иске йортның капкасын
Каерып ачканнар да...

Фатир калган тегендә,
Малайларга, киленгә...
Маллар да шунда инде,
Аларга хәзер нигә!...

Туган нигез, и, тыныч,
Ишелсә дә капкасы.
Болай да рәхәт әле
Чуртыма ди яңасы!

Шунда гына яшәгез,
И шәһәр бабайлары!
Шушы газиз авылның
Кичәге малайлары!...

## Татар баеса...

Берзаманны баеп киткәнмен дә,
Түрә иткән кемдер аннары.
Балачактан хыял иде ласа,
Язмышның бу миңа язганы —
Түрә булды татар малае!

Түрә булу бик җаваплы нәрсә,
Үзем киттем хәтта сискәнеп.
Милләт аксый диләр, аңа да
Рәхәтләнеп ярдәм итәрмен.

Әдәбият, мәдәният! Бу ни бу!??
Титаклыйсың, хәлең юкмы әллә?!
Кул сузмаса безнең ишеләр
Ерак китәлмассың бу хәлдә!

Музейларны рәткә китерермен
Поши тояклары муеннан!...
Чабаталар бабайлардан калган
Һәм комганнар җиздән коелган!..

Мин түрә бит хәзер, күрәсезме:
Байлык миңа күктән ишелә.
Мәктәп—мәдрәсәләр ни хәлдә соң
Ярдәм тияр алар өлешенә.

Татар баеса хатын аера диләр,
Кай җирем ким минем алардан?!!
Милли данга зыян салып булмас,
Бер мин генә түгел арадан...

...Яшь хатыным әйтә акылга кил,
Өләшәсең бушка син нигә?
Музейдагы чабатаңны алып
Ник элмисең инде иң түргә?

Хикәят тә шуның белән бетә:
Булганнан соң мин зур бер түрә,
Хатыннарым, җыйнаулашып барып,
Чабатаны
Тәки элгәннәр бит иң түргә!..

# Нурислам Айбулатов

## Комиссия

Чираттагы каралуда
Безнең Гариф —
Ун ел элек кулсыз калды,
Хәзер гарип.

Комиссия әгъзалары —
Биш хатын-кыз.
Чишендереп капшадылар —
Нигә кулсыз!?
Сораштылар: кайда үстең?
Кайда тудың?
Ә хатының кайда эшли?
Ничә улың?

Кызың нинди күлмәк киеп
Йөри эшкә?
Оныгыңның машинасы
Нинди төстә?

Киңәшәләр: ышаныч юк
Гарипләргә...
Йөрсен килеп ел да, диләр
Табибларга.

Биреп торыйк группаның
Өченчесен.
Кулын кисеп бирәр җиргә
Яшермәсен.
Бирәр елда, бәлки кулы
Үсәр тагын:
Үлчәделәр гарип кулның
Калган ягын.

Комиссия һәр ел шулай
Эш башкара...
Ышанмасаң, әнә, Гариф —
Сорап кара!

Илдус
Диндаров

## Кырый урамда

Күзәттем мин җомга көнне
(Татар өчен мунча көне)
Зур авылның бер читен:
Ак мунчалар түбәсендә
Һич күрмәдем бу-төтен.

Тавыклар да кытакламый,
Терлек юк аранында;
Агач та үсми авылның
Бу кырый урамында...

Кырый урам — кыргый урам...
Чарасызлык һәрьякта:
Кемдер буылып ютәлли,
Һәм дә искән җил үтәли
Махра исен тарата.

Сораштым шунда бер карттан,
Кемнәр соң тора монда?
Әйтте ул теләр-теләмәс:
«Үлсә дә мәңге өйләнмәс
Буйдаклар урамы ла...»

## Солтан Морат

### Такмаклар

***

**Безгә соң, япуннар кебек,**
**Туксанга җитү — кайда?!**
**...Эш тә, фатир да — юк:**
**Озак**
**Яшәүләрдән ни файда?!**

***

**Китап укучы аз булу**
**Һич түгел каза...**
**Каза — Китап укымаучылар**
**үзләре... китап яза!**

***

**Кибетләргә кереп йөрдем,**
**Урадым базарлардан:**
**«Буш ботлары» үзебезнең**
**Кош ботларыннан арзан.**

***

**«Русия» диеп язылган**
**Самолет канатына.**
**Аек кеше юк сайларга**
**Дәүләт аппаратына.**

***

**Мафия «мерседес»ларда**
**«Эшләре» уңган була.**
**Милиция «УАЗ»икта**
**Аларны куган була.**

***

**Сандугач баласын юа**
**Гөл тамчылары белән;**
**Юк иттек совет властен**
**Юлбашчылары белән.**

***

**Хакимият бинасында**
**Җилферди ике әләм.**
**Халык белән көрәшүче**
**Демократларга — сәлам!**

***

**Туган илне сайламыйлар,**
**Данлыйк туган илләрне.**
**Таш бәйлик тә — суга салыйк**
**Такмакчы шагыйрьләрне!**

Хәмис Гарипов

## И Казан...

**И Казан, нурлы Казан!..
Яңгырый моңлы азан,
Дипломлы кеше күбәйде,
Никтер күбесе — надан?
Казан эчләрендә Казан,
Йөрсәм адашмам микән?
Мулла нигә русча укый,
Әллә саташкан микән?
Тукай кебек күпләр килә
Өмет баглап Казанга,
Өметләре акланмагач,
Сату итә базарда.**

## БӘДИГЫЙЗМНАР

- *Карак ул – уңнан да, сулдан да карак дип укыла.*
- *Галстук тагып йөргәнгә, хәзерге ата каракларны тануы бик авыр.*
- *Әгәр урлашу спорт төренә керсә, безнекеләр гел Олимпия чемпионнары булыр иде.*
- *Энә урлап тотылмаган карак осталыгын дөя урлап тотылганга кадәр шомартып тора.*
- *Караклык җәмгыятьнең грим салынмаган чын йөзен чагылдыра.*
- *Ришвәткә артындагылар җәмгыятьнең үзен дә тимер ишекләр артына куып кертте.*
- *Карак читлектә дә урлар әйбер таба.*
- *Угрылар тәгәрмәч кебек: эресе - акрын, вагы тиз әйләнә.*
- *Урлашу Адәмнең рөхсәтсез алма ашавыннан ук башлана.*

**Хәнәфи БӘДИГЫЙ**

---

**«Печән базары» конкурсының нәтиҗәләре Татарстан язучыларының XVII съездында (18 майда үтә) игълан ителеп, журналның бичы санында басылачак.**

# ФЛЕРА ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНАНЫҢ ШИГЪРИ ДӨНЬЯСЫ

*Эшелоннар кәтәм... эшелоннар, —*
*Шигъри йөкләремне төяргә.*
Ф.Гыйззәтуллина

Һәр кеше нәрсә дә булса көтеп яши. Кемдер бер тамчы елмаю йә ярату, кемдер илтифат, кемдер исем-бүләк, кемдер танылу, кемдер илһам килүен көтә... Ә тугызынчы дистәне ваклаган татар шагыйрәсе нәрсәгә өметләнә?.. Гомумән, шагыйрь күнеле картая беләме икән? 80 яшьтә мәхәббәт шигырьләре ничек языла? Нинди мәхәббәт? Кемгә? Нидән Флера Гыйззәтуллина иҗатында Себер, вагон, эшелон, тайга, рельс, тау сүзләре күп очрый? Хатын-кыз янәшәсендә гаилә, бала, күлмәк, чәчәк булгач җитмимени?.. Шагыйрәнең «Ашыгыч ярдәм көтәм» шигыре әнә шундый уйларга этәрде... Әмма:

*Күрәсезме? Мин бүген дә язам!*
*Телләремне, билләремне язам...*
*«Күп яздың!» — дип битәрләмә, Казан!..*
*Язу — минем теләп алган җәзам, —*

дип язуы белән ул сискәндереп тә җибәрә. Шагыйрь язмышы бер халыкта да җиңелләрдән түгел. Татар шагыйре өлешенә туры килгәне бигрәк тә ачы булса кирәк: Кол Гали, Акмулла, Г.Тукай, Һ.Такташ, М.Җәлил, Ф.Кәрим, Х.Туфан... Тормышлары фаҗига белән тулы әдипләр исемлеген тагын дәвам итеп булыр иде. Берьяктан, бу шагыйрьләр бик бәхетле язмыш ияләре: алар һәрвакыт халык күнелендә, шигырьләре халык телендә; бер сүз белән әйткәндә — алар халыкның йөз аклыгы булып кала бирә. Икенче яктан, аларның кайсын ятимлек ачысы, кайсын сугыш афәте, кайсын сәясәт кайчысы кырган.

Татар шигъриятендә даими күзәтелеп килгән үксезлек, ятимлек мотивы XX йөз башында аеруча көчәеп китә. Ятимлек башта хәерчелеккә барып тоташа, аннан чарасызлык, җитмәүчәнлек, ялгызлык, гаделсезлек, бәхетсезлек өстәлә. Кулга каләм тота башлауга, ятимлек кәгазьгә дә күчә башлый. Ф.Гыйззәтуллина сүзләре белән әйткәндә, «Язмыш безне — тере ятимнәрне / Төпсез чабатага тиңләде», — рәвешен ала. Шагыйрә язмышындагы әлеге ятимлек бүгенгәчә дәвам итә. «Ком бураны» (2005) поэмасында автор, язмышын узып китеп, җиңүче булырга да омтылыш ясап карый, әмма ятим баланың өмете акланмый. Шулай да шагыйрә иҗатында өмет мотивы шактый тотрыклы төсмер ала. Сугыш вакытында ягар өчен кышын кырга чыгып әрем уру, тунгач шул әремне ягып җылыну, әрем төтене ачысын ятимлек җәзасы итеп кабул итү һәм шул вакытларда да өмет чаткыларын югалтмау — болар барысы да Ф.Гыйззәтуллина шигырьләре өчен гадәти күренеш.

Шагыйрәнең берничә поэмасы табигый талант белән иҗтимагый тәрбия арасында тыгыз бәйләнеш барлыгын күрсәтә. Шундый әсәрләрнең берсе — «Ком бураны». Поэма тугыз бүлектән гыйбарәт. Казан каласына 1000 ел тулу көннәрендә

шагыйрә, кулына Коръән тотып, уйларга бирелеп утыра. Уйлары татар тарихына барып тоташа. Автор чын милли тарихны кайтарырга тели, шуна да бер кулы Коръәндә ятса, икенчесе кәгазьдә шигырь юллары төшерә. Хезмәте җинелләрдән түгел, чөнки «җан каурыен чор канына манып яза». Мәшһүр Кол Гали, Сөембикәләр искә төшә. Автор, вакыйгалар аша узып, һәр заманга нәтиҗәләр ясап бара:

*Әлегә бит татар тарихында*
*Коръән — калын, ирек — кечкенә!*

Татар фаҗигасенең башы Казан ханлыгы җимерелү вакыйгасына барып тоташуы мәгълүм. Сөембикәнең Мәскәүгә озатылуына үз бәясе бар авторның: «Каш ясыйм дип күз чыгарган дәвер — ханбикәсен тотып ашаган!». Аннан уйлар өч ятимен үги ана кулына калдырып сугышка киткән үз атасына барып тоташа. Сынау һаман дәвам итә. Җину килгәч, эти-әнилеләр вузга китә, ә ятимнәр — тайгага урман кисәргә.

Ф.Гыйззәтуллина шигърияте детальләр муллыгы белән аерылып тора. Мондый алым-сурәтләрдә аның үзенә хас осталыгы чагыла. Бер караганда шагыйрәнең поэмаларында бөтенләй сюжет юк кебек тоела. Вакыйгалар агышын аңлату да, эчтәлеген сөйләп бирү дә җинел түгел. Әмма Ф.Гыйззәтуллина поэмаларында автор хисләренең үсеш-үзгәрешенә нигезләнгән эчке сюжет өстенлек итә. Бер караганда, аның поэмалары лирик башлангычлы поэма булырга тиеш кебек («Йөрәк тавышы»), шагыйрә исә, лиризм чикләреннән чыгып китеп, эпиклыкка омтыла, хәтта публицистиканы да кушып җибәрә. Шул сәбәпле, күпчелек поэмаларын «лирик-публицистик» дип исемләү дөрес булыр.

«Ком бураны» поэмасы белән шул исемдәге татар халык җыры арасында уртаклык булуы табигый. Поэмада бер эпизод күңелдә аеруча уелып кала. Шагыйрә авыр язмышны «җиз иләктән үз комыңны иләү»гә тинли. Нәкъ менә **«үз комы»**, ди, үз иләге булса, кешечә дә килеп чыгар иде. Дөрес, халыкта «язмыш җиз иләктән или» дип әйтү яшәп килә. Поэмада автор, пенсиягә чыккач, үзе илисе комны «саклап утыра», ә менә «иләге юк». Бу ком Казан урамнарына кышын сибәсе ком булып чыга. Ком күп кирәк, иләүчесе юк, иләге дә күренми. Ком образы шул рәвешле шигырьгә кереп китә һәм тора-бара «комсыз»га ук әйләнә дә куя. Әлеге «комлы комсыз» янына «комлы эшсезне» китереп куйгач, заманча базар сурәте барлыкка килә. Поэмада Р.Харисның «Чехов базары» поэмасы белән охшаш сурәтләр дә чагылып ала. Фән докторлары да үз комын или, шагыйрьләр дә. Күңелгә тигәне шул: комны иелеп илиләр. Ә башы иелгәнгә тимиләр. Бу «башны» тәвә кошы кебек комга тыгып куйсаң, бөтенләй бернәрсә күрмисең! Менә кая барып чыга Ф.Гыйззәтуллина!

*«Аһ»ын җаным белән түләсәм дә,*
*Коллык комын, юк, юк, иләмәм!*

— ди ул катгый итеп.

Тора-бара әсәргә «гасыр комы» метафорасы килеп керә: «Ә Ватаным, оятын җуймас өчен, / Башын тыккан гасыр комына». Шагыйрәнең уй-фикерләре әсәрдәге «күзлек мәсьәләсе»нә барып тоташа. Ком иләгән докторның калын күзлеге белән «ком иләми торган шарлатан»ның кара күзлеге кисешә. Шулар аша автор «кара битлек»кә килеп чыга. Шагыйрә соңгы ике бүлектә заман күренешләрен сурәтли. Менә 1990 елларда барган ирек өчен көрәш нәтиҗәсе:

*Байлары яңа — үз байлары!..*
*Майлары да чиста — сары май!*
*Шәһри Казан тоткан меңьеллыкның*
*Маңгаенда балкый ярым ай...*

«Сары май» белән «ярым ай»ны рифмалаштырганны очраткан юк иде. Әлеге янәшәлек яңгырашы буенча гына «Камаз-намаз» (С.Хәким) рифмасын хәтерләтә.

Татарның «сары мае» белән исламның «ярым ае» янәшәсендә тирән эчке мәгънә ята. Юкка гына шагыйрә тарихи борылышлар, сәясәт китереп чыгарган катаклизмнарны Коръән эчтәлегенә бәйләп сурәтләми торгандыр.

Поэмада тагын күзгә бәрелеп торган үзенчәлек бар, хәер, бу очракта иҗатны тулаем алып карау да дөрес булыр, бу — өр-яңа метафора табу мәсьәләсе. Шигырьләрдә яңа метафора күп вакыт «кычкырып тора», хәтта текстның калган эчтәлеген басып китә. Аерым авторларда мондый сәнгати детальләр иҗат үзенчәлеген билгели башлый. Беренче карашка Ф.Гыйззәтуллинада искитәрлек яңа троплар очрамый да. Гадәти сүзләр белән гади итеп язган кебек тоела. Әмма «Ком бураны»ндагы «коллык комы» һәм «комлы комсыз» метафора-оксюмороннарын танымыйча булмый. Поэмада кинәйтелгән сәяси метафоралар тагын да бар: «парламент шобагасы», «татар ирегенең дәверләрдән кучкән макеты», «Россия табасын ялау», «комбасарлар», «ком тулган төпсез чабата», «ил иләгән иләк җиле» һ.б.

Шагыйрәнең шигырьләрендә шәхес, чор, язмыш төшенчәләре һәрвакыт бергә атлый. Шәхес, билгеле, — көрәшче кеше, чор-заманына карап, ә язмышны кем ничек кабул итә инде!

*Еланга хас кара язмыш, әйе,*
*Михнәт арбасына безне җикте.*
*Язмышларга киләчәктән карап,*
*Карурманнар кичәр вакыт җитте.*

Тугызынчы дистәне ваклаганда «карурманга керергә» ачы язмыш арбасына утырып караган кеше генә җөрьәт итә алыр. Татар шигъриятендә арба символы авыр тормышны гәүдәләндерүче деталь буларак күптән билгеле. Бу «арба» XIX гасырда шагыйрь Акмулланың яшәү урыны булса, М.Әгъләмдә шул исемдәге поэмага әверелде; З.Мансуровта арбаның статусы үзгәреп, милли-сәяси эчтәлекле «Екатерина II каретасы» шигыре пәйда булды; Р.Низамида әлеге арба, «Тормыш трамвае»на әверелеп, «дөнья буйлап үземне дә тартып барам, гап-гади бер татар бурлагы» рәвешен алды; Р.Хариста «арбага йөк тә төялгәч», ул «әкәм-төкәм кебек шуышып барган олау»га әверелеп, сәяси-символик киная объектын гәүдәләндерүгә кадәр барып җитте; Р.Шәриповта әлеге ватык «арба»га тешсез авызлы, «әткә-әнкә тулы сүзле», шешеп күгәргән йөзле юлчылар утырды...

Шагыйрь, ничек кенә атамасын, барыбер Арба үзе генә бармый, тартырга Ат кирәк була. Ф.Гыйззәтуллинаның «Ил агасы Илдә ат чаптыра», «Җирән Кашка исән булсын!», «Тимеркүк» әсәрләрендә нәкъ менә шул авыр вазифаны үз өстенә алган олы җитәкче образы килеп керә. Шагыйрә үзе дә атлар яратуын, ат ялын сыйпап, язар өчен шигъри илһам алуын яшерми. Шул рәвешле шигырьләрдә Ат-Җитәкче образы, ана салынган халык ышанычын сурәтләү рәвеше мотив төсен ала. Шагыйрә Ат образы аша сәясәткә барып чыга: «Аяклары тышауланган килеш / Җиңү яулый Татарстан аты!». Тагын да эчкәрәк кергәндә, әлеге тышаулы Ат образының «шигъри сүздә тояк тупырдаткан» шагыйрьгә барып тоташуы күренә. «Чаптарыңның ялын чал сыйпагач, / ил агасы, син дә нечкәрерсең!» юлларын ил башлыкларының да шигырьгә битараф булмавы дип кабул итик.

*Сабан тургаена җыр юлларымын:*
*Сабанчы дип минем нәсел-затым.*
*Шигърияттә мәйдан тоткан атым*
*Акламыйча аумас канат хакын, —*

дип, шагыйрә үзенең ярсу көчен дә күрсәтеп ала. Ф.Гыйззәтуллинаның «Язмыш сынавы» поэмасына да милли-сәяси эчтәлек салынган. Шагыйрә биредә Ирек яулап көрәшкән елларга әйләнеп кайта, ул шаулы еллар вакыйгаларын бүгенге вәзгыять белән бәйли: «Җиде башлы елан гына түгел, / Ыслый хәтта куян, керпеләр дә...»

Шагыйрә иҗатында тагын бер мөһим мотив Тау образы белән бәйле булып, шагыйрә үзе үк «таулардан көч алам» дип белдерә. Шунадыр, Ф.Гыйззәтуллина

шигырьләрендә Таулар хәтта «жырлый да». Ул «Тәнрем мине ташламасын» шигырендә «тау кадәр хисләр йөртәм» дип белдерсә, икенчесендә «кыя буласы» килүен яшерми, өченчесендә «Таугa карап, айлар, еллар санап, / Тау булмады иллә беркем дә», дип төшенкелеккә бирелә. Әлеге мотивларнын барысы да ятимлек төшенчәсенә барып тоташканлыктан, алар Ф.Гыйззәтуллина шигырьләрендәге бер юнәлешнең тармаклары булып күзаллана. «Тау рухы» (1995) шигыреннән бер мисал китерик:

*Жырымда тау да тау!*
*Жыр белән бизәдем*
*Тауларның биеген, сөзәген...*
*Тау рухы — кешедә!*
*Таулар да күшегә*
*Жырлатмый өзсәләр үзәген.*

Әлеге сигез шигырьдән торган циклга милли эчтәлек салынган. Шагыйрә туган тел язмышын таулардай зур борчуга тинли. Шигырь диалог формасына корылган: лирик геройның Таудаш белән әңгәмәсе формасында бара. Таудаш төшенчәсендә ул өйдәшне, тиндәшне, иптәшне, якташны күз алдында тота.

Шагыйрә Азнакай районының Әсәй авылында туган. Шуна анын иҗатында Азнакай төбәге белән бәйле шигырьләр булуы гаҗәп түгел.

*Кырык кызга туй кулмәге тектем:*
*Күреп хәйран калды барча җан... —*
*Акчаларын алдым Азнакайдан,*
*Парчаларын алдым Арчадан, —*

дип яза шагыйрә. Шагыйрәне Арча белән дә күп нәрсә бәйли. Беренчедән, Арча — бөек Тукайны биргән як, икенчедән, Арча — Г.Бәширов, М.Мәһдиев, Г.Ахунов кебек кабатланмас әдипләрнең туган төбәге, өченчедән, моңлы Рабигалары, Гөлзадалары белән кадерле як.

Ф.Гыйззәтуллина хис-кичерешләре, уйланулары Арча төбәге аша Казандагы Себер тракты буйлап, сөргенлек темасына барып тоташа. Шагыйрә үзен, «Мин болай да сөрген шагыйре...» дип атап, биографиясендәге Себер чоры истәлекләрен янартып ала. Шуна да шигырендә «Себер сөрәм!» дип куркытуның нигезсез булуын белдерә. Шигырь язганда Себерләр кичкән шагыйрә бозлы шпалларга рельс сузу яки чуен юллар кочып, тайга гизү кебек хисләр кичерә.

Әйтергә кирәк, шигырь язуны ни белән генә чагыштырмадылар, әмма соңгы елларда кәгазьдә «тайгада бозлы шпалга рельс сузган» татар шагыйре булмады. Себернең кырыс климаты шагыйрәгә илһам гына өсти булса кирәк. Һәр кыш саен Себер салкыннарын искә төшерүен яшерми, башкача мондый шигырьләренен циклга үк әверелеп китүен ничек аңлатасын?

*Тайга гизеп анда урман кистем,*
*Шахтасына төштем күмернең.*
*Билдән су эченнән вагон этеп,*
*Язмышымнан алда йөгердем.*

Әлеге шигырьләрдә лирик герой — Ф.Гыйззәтуллина үзе. Ул шигырьдә рольгә керми, уйнамый, сүзләрнең күчерелмә мәгънәләрен эзләп азапланмый, эзоп телен кулланмый гына хакыйкатьне ачып бирергә омтыла. Шагыйрә үз хисләрен генә белдерми, кырыс чор кешеләренең үзе кебек кичергән хисләрен туплап күрсәтүгә ирешә.

Хәзерге заманда зарлану, өметсезлек, үкенү, ачу, көнләшү, өндәү, өйрәтеп тәрбияләү кебек хисләр тулы шигырь күбәя. Бигрәк тә хатын-кыз шагыйрьләребез, дингә бирелеп китеп, яшь буынны шул юнәлештә тәрбияләүгә игътибар итә

башладылар. Тәрбиянең икенче юнәлешен татарның күренекле затлары үрнәгеν идеал итеп кую хасил итә. Ә менә Ф.Гыйззәтуллинада боларның берсе дә үсеш алмый. Шулай да без аның «хезмәт шигыре» язуын танырга тиештер. Шуна да бу иҗатта тагын бер мотивны тоймый калу мөмкин түгел: ул да булса — тегүчелек мотивы, икенче төрле әйткәндә, «күлмәкле шигырьләр». Аларда шагыйрә үзенең күп еллар буе тегүче булып эшләве белән горурланып яши.

*...Мин үзем дә кара халыктан ич!..*
*«Сарык» сүзе шактый эләкте.*
*Тик мин җиде ятка ялынмадым,*
*Үзем җөйләп кидем күлмәкне.*

Хезмәт аша тәрбияләү татар халык педагогикасына ук барып тоташа. Югыйсә, соңгы ике дистәдән артык вакыт эчендә яшь кешенең шактый өлеше, вуз дипломына ия булып, кирәкмәгән, эшсез статуслы армияне тулыландыра бара.

Тагын бер гаҗәп күренеш бар бу шагыйрәдә: иҗатта пейзаж лирикасы сирәк очрый, нигездә соңгы җыентыгында гына яз фасылы, март кояшы, бөреләр уяну, ал чәчәкләр килеп керә. Һәр шагыйрь яңа чыккан яшел үләнгә, беренче язгы гөрләвеккә, ал чәчәккә сокланмый калмый. Ә шигырь йә соклanудан, йә сызланудан, йә үкенүдән, йә ачудан туарга тиештер. Безнең шагыйрә дә соклана белә, әмма ул кышкы буранга, шартлаган суыкка, ярсу җилгә, биек тауга соклана. Шуңа аның сагышы да «кышкы сагыш» булып чыга.

*Юлда буран купкан көннән башлап*
*Туктамыйча дөрләү, янудан,*
*Мин бит сине кышкы сагыш белән,*
*Ярсу язмыш белән сагынам, —*

дип яза ул «Йөз аклыгы кирәк» шигырендә. «Йөз аклыгы» детале аның күп шигырьләренә антитеза булып килеп керә. «Түшемдә камыштан бишек үрәм» дип раслаган шагыйрәдә сентиментальлекнең күп булмавын тану дөрес булыр. Бу шигърият хатын-кыз шагыйрьләр иҗатыннан шуның белән дә аерыла. Әмма «Башкаемда дөнья исәпләре» җыентыгындагы «Бөре фалы» шагыйрәнең күнеле нечкәргән мизгелләре дә очравы турында сөйли:

*Мин бит инде Җир кешесе түгел! —*
*«Яратам!!!» — дип артык өзелмәм.*
*Еллар узгач, бер багармын язга,*
*Тамчы булып шигырь күзеннән.*

Шулай итеп, Ф.Гыйззәтуллина иҗаты чорның иҗтимагый таләпләренә җавап рәвешендә дөнья күргән, тематик яктан милли-сәяси эчтәлекле, лирик-публицистик юнәлешле булып, көрәшчел характерларга бай шигърият рәвешендә яши бирә.

**Фәридә ХӘСӘНОВА,**
*КФУ доценты*

# КОМ СӘГАТЕ ДӨРЕС ЙӨРИ, САКАУ КҮКЕ ЯЛГЫШМЫЙ

Камил Кәримовның «Ком сәгате», «Сакау күке» романнарын кызыксынып, мавыгып укып чыктым. Сәбәбе: әсәрләрнең икесе дә тормышны дөрес һәм тәэсирле итеп чагылдырган. Мин аларны безнең — Татарстан халкының — Ватан сугышыннан соңгы чорының үзенә күрә бер энциклопедиясе, шушы дәвернең реалистик картинасы дияр идем.

Дилогиядә тасвирланган вакыйгалар белән танышканда, мин, үземнең тормышымны күңелемнән үткәреп, Казан артында узган бала һәм үсмер чагымны әсәр герое Фазылның башыннан кичкән хәлләр белән янәшә куеп искә төшереп бардым. Казан артында яшәүчеләрнең дә, Казан алдындагыларның да тормышы бертөрле үк нужалы булган. Романда Динәнең, йөкле килеш ураза тотып, яндырып торган кояш астында көне буена, авызына су да капмыйча, хәлсезләнеп егылганчыга кадәр, кырда эшләвен тыныч кына уку мөмкин түгел.

«Ураза хәлне ала. Урак өстенә туры килүен күр... Ашамыйча түзәсең түзүен, сусауга түзәр хәл юк! Кояшлы мич эчендә, иртәдән кичкә кадәр бер йотым су капмыйча урак урыр өчен, Ходай Тәгаләне ничек яратырга кирәк булгандыр?! Уразаңны бозсаң, Алладан бигрәк, Габдулла мулла җәберә...»

«Адәм бу дөньяга түзәр өчен туган... Динә дә түзәр иде, үзе түгел — бәгырендәге нарасые карынында тибенә-тибенә су сорый. Ул тибенә, тибенә дә туктый, бераз көтеп тора да тагын тибенә. Тамагы кипкәнгә елавы микән үзенчә?! Ә бермәл ул бөтенләй туктады, аның белән бергә Динәнең дә йөрәк тибеше тукталган кебек булды. Ураксыз кулы белән эчен сыйпап күпме генә өметләнсә дә, бала бүтән кыймшанмады. Нарасый җаны белән Динә гомере дә сүнә башлады..»

Бездә дә, Казан артында да, хәлләр шундый иде.

«Сакау күке»дә Фазылларның, кача-поса, басудан, тачка белән, аркаларына салып, чүп үләне ташулары күренешен укыганда, мин малай чакта әнем белән, басуларны йөреп, бөртекләп дигәндәй җыйган печәнне кул арбасына төяп, колхоз председателе күрмәсен дип (күрсә арбаны ватып, печәнне алып кала), авылыбызның урамнарына кермичә, тирән чокырлы елгалардан алып кайтканыбызны күз алдымнан үткәреп утырдым.

Сугыш елларында һәм сугыштан соң да ярым ач: черек бәрәңге күмәче, үләннәр ашап, иписез яшәүләребез — барысы да нәкъ Камил Кәримов китапларында язылганча: татарларның язмышы, алар кайда гына, кайчан гына яшәмәсен, уртак, аянычлы, күрәсең.

Камил татар халкының тормышын — авырлыкларын гына түгел, күңелле якларын да — чынбарлыктагыча, ышандырырлык итеп сурәтләгән.

Болай язу, әлбәттә, җиңел түгел. Бу язучыдан зур осталык, кыюлык һәм тормышны һәрьяклап, яхшы белүне таләп итә. Мондый сыйфатларны исә табигать Камилгә мул биргән.

Осталык сүзе киң мәгънәгә ия. Моңа язучының әсәрнең сюжетын җайлы, шома гына итеп төзи белүе дә, вакыйгаларны табигый итеп үреп алып баруы да, геройларның психологик кичерешләрен үз күңеленнән үткәреп тасвирлый, табигать күренешләренең һәркемнең дә күзенә ташланып тормаган үзенчәлекләрен күрә белүе дә керә. Язучының осталыгы ул — аның бай, нәфис, үткен теле дә. Болардан тыш, хәзерге заманны тулы, дөрес чагылдыру бурычы язучыдан социаль-иҗтимагый вакыйгаларга объектив бәя бирүне дә таләп итә.

Бүгенге көндә инде зур тормыш юлы үтеп, җитди әсәрләр язып, әдәбият дөньясында үзен күренекле әдип итеп таныткан Камил Кәримов әдәби осталыкның әле әйтелгән билгеләренең барысына да ия дисәк ялгышмабыздыр.

Камилнең исемнәре аталган романнарының да, башка әсәрләренең дә уңышлы

булып чыгуының нигезендә яткан хәлиткеч нәрсәләрнең берсе — язучының әсәрләрендәге йөзләрчә, меңнәрчә мажараларны аңлаешлы, табигый итеп күрсәтә белүе. Дилогиядә тормышның күп яклары тулы яктыртылу, төрле шәхесләрнең, социаль катлау әһелләренең гыйбрәтле гамәлләре кызыклы һәм мавыктыргыч итеп сурәтләнү барыннан да бигрәк сюжет җебенең оста үрелеп баруы белән аңлатыла.

Мең хуҗалыклы, биш мең кешеле данлыклы Шәле авылында зур авырлыклар белән туып-үсеп, Казан шәһәренең бер каһәрле бистәсендә торып, әллә ничә еллар бораулаучы булып эшләп, Татарстанның күп районнарын гизгән, төрле-төрле кешеләр белән очрашкан, кыскасы, дөньяның ачысын-төчесен җитәрлек татыган, күпне күргән Фазыл һәм аның иптәшләре, аралашкан кешеләре аша язучы республикабызда алтмышынчы еллардан алып бүгенге көнгә кадәр булган катлаулы тормышны, әһәмиятле үзгәрешләрне һәм ул үзгәрешләрнең эчендә кайнаган күп төрле шәхесләрнең портретларын ачык буяулар белән күрсәтүгә ирешкән.

Камил Кәримов, үзе кечкенәдән үк зур кыенлыклар күреп яшәгән кеше буларак, әсәрләрендә хезмәт ияләренең авыр тормышын геройлары аша калку итеп күрсәтә. Романның төп геройлары гади авыл халкыннан, эшчеләрдән. Язучы аларны якын итә, хәлләрен аңлый, ул аларга теләктәш. Алар «утыз дүрт яшеннән өч бала күтәреп, салам түбә астында сытылган черек өй ишегалдында көрәк-сәнәккә, балта-уракка таянып калган тынгысыз җанлы» Динә, алтмыш чакрымлы Казанга барып бәрәңге сатып көн күрүче Хәмдия кебекләр, яшьтән ирсез калган тагын әллә никадәр бәхетсез хатын-кызлар, ярты-бер кило ашлыклы хезмәт көненә яшәп, налог, заем түләп иза чиккән, очны-очка көч-хәл белән ялгап барган Шәле һәм башка авыл кешеләре.

Дилогиядә автор Татарстан колхозларының сиксәненче еллардагы авыр экономик хәлен: авыл хуҗалыгы продукциясенең дәүләт куйган бәясе түбән булуын, кергән табышларының ашлама, ягулык өчен алган кредитны түләүдән артмавын, авылларның көннән-көн бөлә баруын һәм башка шундый хәлләрне игътибарыннан читтә калдырмый.

Авылның тормышы начараюның сәбәпләре Камил Кәримов әсәрләрендә аермачык күрсәтелә. Шуларның берсе — республика, ил җитәкчеләренең, көтүлекләрне культуралаштыру идеясе белән мавыгып, мул печән бирә торган, чәчәк атып утырган болыннарны сөрдереп бетерүе һәм нәтиҗәдә терлек азыгының нык кимүе.

«Шәленең кыргый болынлыкларын кинәйтеп культуралы көтүлек итәбез дип, Мишә елгасы янындагы Питрәч сазлыгын чабата кигән тракторлар ергалады: әрәмәләрне, ваграк куакларны, эре-эре карама, зирек, сөяннәрне, тәртә юанлык шомыртларны, миләш бакчаларын коммунистлар партиясе күрсәткән урынга өеп ут төрттеләр. Сазлыкларны ерганаклар буйлап агызып киптереп бетерсәләр дә, Мишә буендагы мелиораторлар болынын үлән чәчәрлек итеп тигезли алмадылар. Төпләр-тамырлар актарылып, кәс кантарлары тау-тау өелеп, җиләк-җимешле әрәмәләр кеше аягы баса алмастай кыргый чытырманлыкка әверелде... Табигатьне үзгәртеп корып булмаган кебек, көтүлекләргә дә культура кермәде. Көтү бер-ике кат таптап киткәннән соң, артык су сибүдән гумус, сыер авырлыгына түзә алмыйча, боламыкланып, тамыразыкны юкка чыгарды. Суга кинәнгән кысыр болыннарны сыер ашамый торган каз тәпие үләннәре басып алды. Колхоз көтүләре янадан элеккеге такыр, ләкин туклыклы болыннарга таралды. Культуралы көтүлекләрнең чыбыкларын өзгәләп, баганаларын урлап бетерделәр».

Табигый ки, зур тарихи чорны, андагы җитди вакыйгаларны сурәтләүгә багышланган эпик әсәрдә илдә барган төрле социаль-иҗтимагый күренешләр унае белән фәлсәфи уйланулар, борчылу-шикләнүләр булмый кала алмый. Дилогия авторы — фәлсәфи фикерләүнең остасы.

«Сакау күке»нең «Элек һәм хәзер» дигән бүлеге бу яктан аеруча игътибарга лаек. Автор, совет системасын үтереп мактаучылардан булмаса да, сиксәненче еллардан

башланган кискен үзгәртеп коруларның гади халыкка файдалы булмавын сиздерә, элегрәк хәзергегә караганда тормыш тәртиплерәк, иплерәк иде дигән фикер белдерә. Һәм, ихтимал, аның бу фикере дөрестер дә.

Кечкенә Фазыл, үзе җыйган бер чиләк шомыртны колхоз базарында сатып, дүрт сум акча алып кайта. Әнисе Динә мона шатланып бетә алмый. Алтынчы сыйныф өчен яңа дәреслекләр сатып алырга да, яңа сумкага да җитә бу. Элек ул дүрт сумга дүрт йөз дәфтәр алып була иде.

«Элек һәм хәзер...

Гомумән алганда элеккеге бәяләр белән бүгенгесен чагыштыру, үткән заман белән хәзергесен чәкәләштерү кебек сәяси өянәк — күчеш чорының котылгысыз чире.

Кискен борылышлар ясарга ярата иде Рәсәй империясе... Аның тарихы да — реформалар тарихы. Туксанынчы еллар алып килгән үзгәрешләрдә монарчы булган бөтен реформалар бергә буталып бетте. XXI гасырга килеп кергәнче: инкыйлаб һәм гражданнар сугышы, НЭП һәм кризис, ачлык һәм хәерчелек, шәхес культы һәм азатлык өчен көрәш, акча алышыну һәм җинаятьчелек, кыскасы — сиксән ел буе гади халык җилкәсенә төшкән афәтләрнең барысын да «базар мөнәсәбәтләре» өр-яңадан кабатлап чыкты. Әйе, үзгәрешләр күз алдында. Җир буена сузылган чиратлардан котылдык, җәмгыять янадан байлар кулына күчте. Күтәрә алмаслык акча җыйган капиталистлар, яклау эзләп, чит илгә кача тора... Ә колхоз базары төбендә калган халыкны яулар өчен сатучылар арасында сыйнфый көрәш бара... Үткәнне сагынабыз, ләкин кире кайтырга теләмибез, киләчәктән куркабыз, ә үзебез алга омтылабыз».

Язучы җәмгыятебездә соңгы егерме-утыз елда барган зур үзгәрешләрне дөрес билгели, аларны җете буяулар белән ясалган картиналарда күрсәтә.

«Егерменче гасыр төгәлләнер алдыннан бик күпләргә Текә дигән кушамат тагылды. Гомер кыскартып, озын берлек артыннан куу, инглизчә аталган исерткечләргә мөкиббән китү, эксклюзив киемнәргә төренү, мактаныр өчен генә юкка-барга көрәкләп акча чәчү, тән сакчылары белән масаю — Текәләрнең яшәү рәвешенә әверелде.»

«Унсигез миллион коммунист сул яктан уңга борылып яткач, байракларның төсе алышынды, кешеләрнең холкы үзгәрде, дөньяның асты-өскә килде — явызлар өскә менде, мәрхәмәтлеләр аска төште. Әшсез, өйсез, мөлкәтсез калдыручылар уңга сөйрәде...»

Камил Кәримов үзенең әсәрләрендә тормыш мәсьәләләрен кыю яза, көн үзәгендә торган проблемаларны кискен куя. Ул республика, халык язмышын кайгырта, хәзерге вакытта хөкем сөргән житешсезлекләр өчен борчыла...

« — Фазыл, мин наданга аңлат әле син, Казан шәһәре ник Идел суы эчә? Җир асты саранмы?...

— Казан халкына Идел суы эчертү — бүгенге җитәкчелекнең иң зур җинаяте. Безгә килеп җиткәнче, Идел, 1200 чакрым үтеп, үз юлында зур пристаньле җиде шәһәрнең әшәкесен юып алып төшә. Шәһәрне юу дигәндә, аның канализациясен, завод-фабрика калдыкларын, кыш буе җыелган мазутлы, әшәке кар суларын уйларга кирәк. Шуның өстенә Иделнең әле Ока, Сура, Зөя кебек дистәләгән кушылдыгы бар, аларның нәҗесен дә кушып сана.

— Әйтәм җирле, өйдәге су юынганда күзне әчеттерә...

— Безнең редактор саннар белән мисал китергәнне ярата. Суның киләчәге хакында фикерегез ничек?

— Татарстанның җир астында ике миллиард кубометр төче су бар. Нефть беткәч, без әле валютага су сата башлаячакбыз. Кибетләргә керсәң, су бәясе сөтнекен узып китте инде... Җөмһүриятебез уникаль урынга урнашкан: биш йөз елгабыз, җиде мең күл, өч мең чишмәбез бар. Шуның өстенә бүгенгесе көнгә алты мең артезиан кое бораулаган.

— Рәхәтләнеп эч, әйеме?! Йөз елга житә!

— Дөрес, безнең илдә су белән сүзнең бетәсе юк.»

Җәмгыятьтә хөкем сөргән гаделсезлек, социаль тигезсезлек күренешләрен

йөрәккә үтеп керерлек итеп бәян итү дилогиянең буеннан-буена кызыл җеп булып сузылып бара.

«Икмәк белән пычак гел бер табында. Икесе дә үз урынында. Берәүләр җитештерә, икенчеләр бүлә. Җитештерүче бүлүчене сөймәс, бүлүче җитештерүченең мон-зарына колак салмас..

Кемнәрдер тир түгә, эзләнә, таба, югалта, ялгыша...

Кемнәрдер шул кешеләрне бәяли, хөкемгә тарттыра, акыл өйрәтә, мәхрүм итә.

Байлар һәм хәерчеләр, явызлар һәм мескеннәр, түрдәгеләр һәм ишек төбендәгеләр, комсызлар һәм гаделләр, кораллылар һәм буш куллылар, сайланганнар һәм сайлаучылар арасында барган мәңгелек көрәш — яшәү дип аталадыр...»

Камил Кәримовның язучы буларак зур уңышы барыннан да бигрәк табигать күренешләрен гаҗәеп оста итеп, бары аңа гына хас матур бизәкле бер тел белән тасвирлый белүендә. Аның чагыштыруларына, ул уйлап тапкан тапкыр образларга битараф булырга мөмкин түгел.

«Май аеның сайрап торган көннәре исәпсыз-хисапсыз озын кебек тоелса да, барыбер кич җитә. Агыйделнең аръягыннан кояш баеп кайтты — сырхаулабрак тора, ахрысы — кайтты да яшьнәп торган уҗым басуы читенә, алсу болытларга төренеп ятты. Дымлы кич яңа гаиләне Язилә учагына якынайтты. Табигать яшәрешендә сайрар кошлар бәйге тота. Тургайларның көндезге чыгышын инеш таллыгындагы былбылларның кичке концерты җиңде».

«Нинди озын көн иде — тотылып бетте...Офык көннең соңгы кисәген йотты. Иннеккә буялган шәфәкъ нурлары Кама дингезенә төшеп эрегән...»

Камил Кәримовта сурәтләү алымнары күп төрле. Ул кайбер урыннарда рифмалаштыру ысулларын да кулланып куя. Һәм бу әйбәт кенә килеп чыга.

«Зәй ашханәсендә җебегән кәтлит белән иске бәрәңге боламыгы сыпыртып, Актанышта машиналарга бензин-солярка өстәп, Бута авылының шарлавыклы чишмәсеннән сулар эчкәч, Әлмәт, Чистай, Алексеевск районнарының юл өстендә аунап яткан авылларын үтеп, тавыкларын өркетеп, сарыкларын куркытып, сыерларына кычкыртып, кызларын үртәп бара торгач, ниһаять, Чулман елгасының иң киң җиренә — Саескан тавы кичүенә килеп җителгән».

«Яратты Әмир үз эшен, һай, яратты! Бер күрүдә гашыйк булган үсмерләрчә, әти-әнисен сагынып яшәгән ятимнәрчә, туган илен югалткан зимагурларча, суга сусаган гөлләр сыман яратты».

Табигатьне сурәтләүдә генә түгел, Камил Кәримов гомумән тормыш-көнкүрешнең теләсә нинди күренешен, әсәр персонажларының теләсә кайсын тасвирлаганда да татар теленең бөтен байлыкларыннан, әллә кайда, әллә кайчаннан онытылып яткан хәзинәләреннән мул файдалана, халык сөйләменең иң матур җәүһәрләрен эшкә җигә. Әсәрләрнең теле бик бай, үткен һәи бизәкле. Камилнең язу стилен тел галимнәре һәм яшь язучылар игътибар белән анализлап өйрәнсәләр файдасы күп булыр иде.

Камил, кечкенә генә бер нәрсәне атаганда да, гадәти генә күренеш, гамәл һәм кеше турында хәбәр иткәндә дә, гади генә итеп әйтәсе урында тиешле сүзен, кирәкле фикерен укучыга бизәкләп, сурәт-образ кулланып белдерә. Аның һәр сүзе мәгънәле, һәр тәгъбире кинаяле.

Мәсәлән, «агачларда каргалар каргылдаша» дип әйтәсен ул: «Яна Бистәдә туып-үскән каргалар, кайтканнан бирле, ояларында саташып ыңгыраша», ди. Трамвайлар йөри башлау, аныңча, «трамвайлар рельсларны саный башлый»; «Эш урыны юк Әмирнең — Идел йоткан аны» (Әмир дежур тора торган баржа су астына киткән); «Сәгатенә 150 тонналап Иделне йотып... (150 тонна су тотып −судан файдаланып — Р.Ю.) тире эшкәртә торган җиде фабрика»; «Коммунистлар заманында җыйган акчам демократия җылысында эреп бетте»; «Сайрар кошлар туктагач, чикерткәләр хуҗа булып калган — чабылган болыннар сызгырып тора»; «1971 елның җәе дөрес килде, хуҗалык мәшәкатьләрен үз урынына куйды»; «Октябрьдә кар яумыйча торды — буранлы болытлар азык чөгендере беткәнне көтте...»

Көннәр кыскару Камил Кәримов телендә «кояш юлы кыскару»; тиз арада квартир

бирү — «Нурлыгаяннның тәмәкесе сүнгәнче фатирлы итү» (Нурлыгаяннның тәмәкесе бер сәгатьсез сүнми икән); көләч йөзле кеше — «килгән бер кешегә елмаерга тырышып, күз төпләренә җыерчык чыккан кеше»; бик нык карының ачса, «гәүдә җинел, эчәгеләр коелып калган кебек була»; җәйге кыска төн — «сандугач йокысы гына ул»; «...кояшның баешы белән чыгышы янәшә...»; пассажирларның автобустан чыгуы — «коелып бетү»; «түбәдән тамчы тама» гына түгел —«өе булганнарның түбәсеннән тамчы тама» (янәсе, өйләре булмаганнар да бар әле — укучы белеп торсын!).

Мин мисаллар китерү белән мавыгып киттем, ахрысы. Сәбәбе — мина бик ошадылар алар. Ялыктырган булсам, укучылар моның өчен мине гафу итсен.

Дилогия авторының авыл халкы сөйләменең гыйбрәтле үзенчәлекләрен, үткен, сурәтле тәгъбирләрен бик яхшы белүен һәм аларны үзенең әсәрләрендә, бигрәк тә диалогларда, оста файдалануы хакында тулырак әйтеп китү дә урынсыз булмастыр.

Сүземне тәмамларга вакыт.

Мәгълүм булганча, күренекле язучы Камил Кәримовның «Ком сәгате» һәм «Сакау күке» романнары (дилогиясе) Татарстанның язучылар союзы тарафыннан Габдулла Тукай премиясенә тәкъдим ителде. Республикабыз язучылары оешмасының бу гамәле бик тә дөрес.

Камил Кәримов «Ком сәгате», «Сакау күке» романнары белән дә, аннан соң иҗат ителгән әсәрләре, бигрәк тә «Игезәкләр йолдызлыгы» романы белән, бөек шагыйребез исемен йөртә торган республика дәүләт премиясенә һәрьяклап лаек. Мондый язучыларның урыны түрдә булсын!

**Рүзәл ЮСУПОВ,**
*профессор, Татарстан*
*фәннәр академиясе академигы*

---

## *«Казан утлары»на — 90*

### «Совет әдәбияты»

ЖУРНАЛЫБЫЗ «СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ» ИСЕМЕ БЕЛӘН
1933-1965 ЕЛЛАРДА ДӨНЬЯ КҮРӘ.



Бу чорда журнал чыгаруда катнашкан язучылар:

Абдулла Әхмәт, Абдулла Гомәр, Кәрим Тинчурин, Хәсән Туфан, Мирсәй Әмир, Ләбиб Гыйльми, Ф.Исхаков, Гаяз Ризван, Гомәр Толымбай, Таҗи Гыйззәт, Гази Кашшаф, Шәриф Камал, Галимҗан Мөхәмитшин, Хәсән Хәйри, Сибгат Хәким, Фатих Хөсни, Нил Юзиев, Габдрахман Әпсәләмов, Хәй Вахит, Габдрахман Минский, Әмирхан Еники, Шәйхи Маннур, Әнәс Камал, Хәйри Гыймади, Әхмәт Исхак, Сибгат Хәким, Нил Юзиев.

# РӘМЗИЯНЕҢ «КӨМЕШ ТУН»Ы

Рәмзия Габделхакова белән моннан 4-5 еллар элек Әлмәткә баргач танышкан идем. Тантаналы кичәнең тәнәфесендә серле, сөйкемле, ипле һәм акыллы татар хатыны икәнлеге йөзенә чыккан бер ханым яныма килеп күреште. Лениногорск шәһәрендә яшәгәнлеген әйтте, минем шигырьләрне, поэмаларны бик мактады. Барган җирендә үз укучыңны табу бәхетле мизгел. Тәүфыйклы бәндә бәйләнчек булмый, вакытында килә дә, вакытында китә дә белә. 1-2 минутка гына сузылган бу әңгәмә күңелдә теләктәшлек, фикердәшлек, хәтта ниндидер бер җылы туганлык хисе калдырды. Мин аның кем икәнлеген белми дә калдым. Соңрак, интернет аша сирәк-мирәк аралаша башлагач, кемлеге бераз ачылды. Татар җанлы, һәр ябылган татар мәктәбе яисә газета-журнал өчен йөрәге янып йөргән чын язучы-әдибә икән. Түрәләр күбесенчә «ә» дигәнгә «мә» дип йөргәннәрне генә күрәләр, яраталар бит. Шуна күрә, михнәтен дә аз күрмәгән. Башка милләт кешеләре булса бер хәл, күбрәк үз халкыныңң ансыз мокытлары үзәккә үтә бит!

Туры сүзле булуы белән танылу алган журналист Флюра Низамова бер очрашуда Р.Габделхакованың «Көмеш тун» китабын бүләк итте: «Укы, шәп яза, «безнең кеше» булырга тиеш...» Рәмзия иҗаты белән моңа кадәр аз таныш идем. Без бит бер-беребезнең әсәрләрен аз укыйбыз, хәзер инде бигрәк тә. Флюра юк-бар китап күтәреп йөрмәс, рәхмәт аңа. Очраклы микән бу хәл? Үзем монда закончалыклы эзлеклелек күрәм.

Китап Ф.Низамованың сүзен аклады, укыган саен укыйсы, укылган саен «Көмеш тун» турында язасы килә башлады. Шунысы рәхәт, әйбәт китап турында язу кыен түгел. Төпле фикер, сәнгати осталык, нәфис сүз, ихласлык һәм автор күңелендәге илһам, көч үзенә дә күчә, булыша, аңлата, өйрәтә... Ике мең тираж белән чыккан бу китап татар әдәбияты өчен бик тә кирәк. Аның үлчәп тә, бәяләп тә булмый торган әхлакый йөге тираж саннарына гына сыеп бетми.

Беренче хикәя әфган мәхшәренә эләккән татар малае турында. Бу мәгънәсез сугыш бөтен СССР буйлап күпме яшь егетнең гомерен алды, җаннарын, тәннәрен имгәтте. Рәмзия монда вакыйгаларның катлаулылыгыннан качмый, аларны аклы-каралы төсләр белән генә сурәтләми, сугыш турында түгел, кешелек, Алла, әхлак, үлем турында яза. Инде онытыла башлаган бик җитди вакыйгалар турындагы хикәянең китапны башлап җибәрүе дә аклана. Онытырга ярамаган серләр күп бу дөньяда, бик оныттырырга теләгән бәндәләр булса да. «Сират күпере» аша үтәргә тиеш Рамилнең күз алдында әбисенең пәйда булуы кеше ышанмаслык уйдырма түгел, андый хәлләрне ишеткәләп торабыз. Дөнья серләренең без әле бер процентын да белмибездер, коточкыч курку белән килгән үлем киеренкелегендә күз алдына ниләр генә килмәс, мин моны һич тә әкият итеп кабул итә алмыйм. Язучының осталыгы да шунда — барысы да эзлекле, мантыйк, табигый, ышандыра. Ул бу мизгелләрдә дә җинелрәк, әкияти юлдан бармый, безне җиргә төшерә, шуның белән ышандыра да. Сүз монда аерым хәл, әдәби әсәр турында, әфган сугышында андый «могҗиза» булу-булмау мөмкинлеге турында түгел. Киресенчә, бу дөньяда барысы да мөмкин. Денсез, имансыз булырга гына ярамый. Мин үзем күпне күргән, чыныккан, каешланган кеше, ләкин әлеге хикәянең соңгы юлларына җиткәч, күзләрем дымланды.

Армиягә озату күренешен дә автор тормышчан ачы хакыйкать белән сурәтли, нәрсәнедер оялып, читенсенеп яшерми яисә ясалма бизәкләр белән чуарламый. Әдәбият нәфис сүз өлкәсе булса да, чынбарлыкның аяусыз кырыслыгы әсәргә

тормышчанлык бирә, ышандыра. Кемнәрнендер тешенә тиярлек хакыйкать ачылыгы күңелләргә инеп, битараф җаннарны сискәндереп үтә. СССРда атеистик тәрбия алган Рамил әбисе биреп җибәргән дога кәгазе белән аң җитмәслек кабахәтлек кыла. Адәмнең холкы шундый инде, әҗәл каршына килеп баскач кына Аллаһы Тәгаләне исенә төшерә. Тормышы да шундый бит, көтелмәгән кискен борылышлар ясап, уенда да килмәгән аяусыз сынаулар каршына куя.

Рәмзия Габделхакова әдәбиятка авырлык белән юл ярып килә, сайлаган юлында гайрәте чигеп, кыен ашап, язмышын-тормышын чатнатып-ватып йөрүдән башка әле бернинди файда күргәне юк, булса шул иҗат ләззәте генә инде. Монысының нинди бәхет икәнен язучы халкы гына, иҗатчылар гына беләдер. Соңгы бер-ике дистә елда гомумән язучыларның дәрәҗәсен-абруен, китап укуның түмен, ямен, мөһимлеген, кирәклеген санга сукмый башладылар. Мондый мөнәсәбәтне акча, исәп-хисап, беркатлы прагматизм, ялган идеаллар заманы алып килде. Яңа заман элеккегеләре белән якын куеп та, чагыштырып та булмый торган яңа җитәкчеләр алып килде. Кулына китап тотмаган буын үсеп җитте. Бу әле беренче буын, аларны әле китап тоткан ата-аналар үстерде дип әйтергә була. Алга таба шундый китапсыз буыннар чылбыры җәмгыятьтән үз үчен алачак әле, бүгенге көннең күзгә бәрелеп торган кимчелекләре чүп кенә тоелыр. Иң мокыт җитәкчеләр генә үз язучыларын шулай кимсетә. Тарих каләм ияләре буенча өйрәнелә. Ахмак, денсез, «туган-тумача» түрәләрнең тилелекләрен алар гына сөйли бөтен дөньяга. Моны аңларлык акылы булмаган түрә, күпме генә көчәнсә дә, талантлы җитәкче, ОЛЫ ШӘХЕС була алмый, моны безгә Тарих адым саен исбатлап килә. Түрәләр тиз китә, язучылар кала, аларның каләмнәре сызган тарих эзләре кала. Тәхеттән тәгәрәү белән кодрәтен югалткан әлеге түрәләрнең балалары, оныклары, дус-туганнары кала. Аларга ияреп, шул ук түрәләрнең әдипләр тасвирлаган акылсыз гамәлләре кала. Ул гамәлләрнең кайберләрен, төзәтеп булырлыгын, бәлки яңадан тормышның мантыйк агышына кертеп булыр. Ләкин төзәтеп булмаганы һәм кәгазьдә калганы мәңгелек. Шул турыда «каләм язганны балта белән чабып булмый» дигән урыс мәкале дә бар.

Каләм ияләре дигәч тә, сүз монда, билгеле, шигърияткә, әдәбиятка, мәдәнияткә, сәнгатькә катнашы булмаган такмаклар язып, нинди юллар беләндер ел аралаш китап чыгарып килүче, сәхнәләрне шар кебек бер генә тапкыр шартлый торган җырлар белән тутырган заман кәсепчеләре турында түгел, ә Р. Габделхакова кебек инсафлы, әхлаклы, иң мөһиме, талантлы чын иҗат кешеләре турында. Андый язучыларыбыз күп түгел, ләкин бар. Алар күпкә тыйнаграк, «ярдәм» теләнеп кабинет бусагаларын таптамый. Гомумән, түрәләр белән дус була белмиләр, моның өчен ялагай да, сукыр да, чукрак та булырга кирәк.

Түрәлеккә эләккән адәм тиз үзгәрә, анда гамь, дин-иман югала. Жылы тәхет шәхесне (хәтта кайчандыр акыллы, денле булганны) танымаслык итеп үзгәртә. Туган-тумачалык, әшнәлек буенча күтәрелгәннәрен әйтеп тә торасы юк, андыйлар күп очракта алынган эшенә яраксыз, халыкны елатучы карак, адәм имгәге була. Кечкенә генә булса да шул жылы урынын югалту шомлыгы аларны ихтыярсыз итә, Мәскәүнең куркак бер колына әйләндерә. «Азатлык көне»н инде оялып кына, куркып кына «Шәһәр көне» дигән булабыз. Оят! Нык, таза, икешәр катлы бинадагы татар мәктәпләрен ябабыз, вагракларын әйткән дә юк инде. Бу бит ИЛне җимерү, халыкны бетерү! Моңа каршы чыгучыларны эреле-ваклы түрәләр «дәүләткә каршы эш» алып баруда гаеплиләр, яныйлар. Миндә шундый хатлар бар...

Өстәрәк телгә алынган такмакчыларның затлы заллардагы «презентация»ләренә олы түрәләр йөри, ди. Җәнҗаллар белән дан казанган Мәскәү «йолдызлары»ның, минемчә, мәдәнияткә әллә ни катнашы юк, тулы заллар моңа дәлил түгел. Чын мәдәният ул бераз күләгәдәрәк, тыйнаграк. Гомумән, чын зәвык, чын мәдәни тәрбия җәнҗалларга урын калдырмый. Аларның тамашачылары да югары зәвыклы була, көндәлек чүпне мәңгелек сәнгатьтән яхшы аера. Иманым камил, кәсепче такмакчыларны да, аларны тыңлап, «су сибеп» үстерүче түрәләрне дә таркалган мәктәпләр һәм авыллар борчымый.

Сүзем Р. Габделхакованың китабы турында иде бит. Бу тайпылыш та эзлекледер, чөнки чын сәнгать тирән, гомуми кичерешләрне уята, гамь иңдерә, күңел төбендә

чарасызлыктан йоклап яткан уйларны кузгата, өметсезлектән дәртен жуя башлаган каләмгә жан өрә.

«Киттеләр...» хикәясендә Рәмзия безнең көндәлек, кайвакыт ямьсез, акылсыз гамәлләребезнең, кичерешләребезнең аянычлы, зур фажигаләр каршында вак-төяк, чүп-чар икәнлеген күрсәтә. Полякларда шундый мәкаль бар, якынча тәржемәсе мондый: «Кичәге көннең фажигасе бүгенге көннең фажигасе каршында югалып кала...» Ә хикәядә сурәтләнгән Дәһшәтле каланың нинди кала икәнен аңлатып торасы юктыр. Күреп торасыз, автор көнкүрешне, чүп кенә жәнжалны тасвирлап, шуннан күтәрелеп, нинди аянычлы, зур фажигаләргә килеп бәрелә, нотык сөйләми, акылга өйрәтми, онытылмаслык итеп күрсәтә генә...

Китапка исем биргән «Көмеш түн» әсәрен бары тик хатын-кыз гына язып, аның әчтәлеген, аянычын бары тик хатын-кыз гына аңлар иде кебек беренче тәэсир. Тирән уйга батырырлык «түн». Автор максатына ирешкән. Уйлаган саен, тукта әле, дим, нигә хатын-кызлар гына? Андагы кырыс, ачы хакыйкатьнең женси бүленеше юк. Көмеш түнны башка әйбергә алыштырып, урынын һәм шәхесен үзгәртсәң дә, әсәрнең тирән мәгънәсе кимеми. Ләкин бу инде бүтән, башка хикәя булыр иде. Катламнарга бүленгән жәмгыятьтәге кыргый гаделсезлек күз алдында ята. Ил байлыгы кем өчендер янгыр булып коя, ә кемгәдер тамчылап кына эләгә. Бу бүленешнең чикләре ачык билгеләнгән. Әлеге чикне узарга теләгең, хыялың булса, йә үлгәнче яисә эштән чыкканчы тир түк, йә булмаса... Менә шул «йә булмаса...»ның фажигасен Рәмзия сурәтләп күрсәткән дә инде. Һәр күренешнең, һәр вакыйганың, ахыр чиктә, һәр бүленешнең үз законнары, үз хакыйкате бар. Көмеш түн киеп, исерек, шикле бәндәләр йөри торган караңгы, буш урамнарда ялгыз гына йөрмиләр. Затлы әйбернең бүтән, үз атрибутлары — машинасы, ышанычлы юлдашлары, матур йортлары, үз урамнары, кайвакыт тән сакчылары була... Ә боларын инде «жае чыккан уңайдан» чәлдереп булмый, мул тормышның аерым кисәкләрен ваклап үзләштерергә маташу — котылгысыз фажига белән тәмамлана. Ә хыял... Ә хыял ул кешелекнең мәңгелек юлдашы. Һәркем үз хыялын көн артыннан көн сыйпап-сыйпап карый, шуннан да ләззәт таба. Кайвакыт, бу хыял бәйләнчек идеягә әйләнеп, үз вакытын, үз жаен көтеп тора. Шундый жай көтмәгәндә килеп чыга да, тормышыңны икегә бүлә. Ике ягында да койма, бер койма артында зират, икенче койма артында төрмә, тоткыннар... Ә уртада тормыш, ничек кенә авыр булса да, хәтта көмеш түнсыз булса да... Ләкин бу — Тормыш!

Рәмзиянең кырыс прозасына шигърият чалымнары да чит түгел. Хикәяләрен тәмамлаганда әлеге шигъри авазлар күңелләргә нур, ышаныч өстәп, юатып, күңелләрне йомшартып кала. Беләм, Рәмзия шигъриятне бик ярата. Чын шагыйребез мәрхүм Нияз Акмал турында истәлекләрне аннан башка язучы булмады бугай әле. Менә шундый ихлас, чиста күңелле тынгысыз шәхес ул Рәмзия Габделхакова. 2011 елда аның «Тау артында кояш бар» дигән яна китабы дөнья күрде. Белеп торыгыз, татар әдәбиятына талантлы, гамьле, намуслы, тынгысыз каләм иясе, сокланырлык шәхес килә. Ничек кенә таптасалар да, кимсетсәләр дә, кәсепчеләр халык зәвыгын жимерсәләр дә, бай, борынгы тарихлы чын татар әдәбияты яши! Тапталган жирне дә, асфальтны да ярып чыга, тырмашып үсәргә тырыша! Кызганыч, көчләр тигез түгел...

**Рәниф ШӘРИПОВ**

# НУГАЙЛАР ТАРИХЫННАН СӘХИФӘЛӘР

## Нугай бәк

Сүзне үз исемен нугай этнонимында мәңгеләштереп калдырган Җучи хан оныгы Нугай бәктән башлап җибәрү мәслихәт булыр. Бу шөһрәтле шәхес әле Батый хан (1227-1256 елларда идарә итә) исән чакта ук үзенә биләмәгә бүлеп бирелгән Дон белән Донец елгалары арасындагы далаларда күченеп йөргән төрки ( каңлы, угыз-кыпчак, болгар һ.б.) вә төркиләшкән мангул ( мангыт, найман һ.б.) кабиләләрен берләштереп, шулар белән идарә иткән. Кабиләләр арасында иң зур күпчелекне мангытлар тәшкил иткәнлектән, алар биләгән җирне «Мангыт йорты» дип йөрткәннәр.

Бәркә хан (1258-1266 елларда идарә итә) заманында Нугай бәк ун меңлек атлы гаскәр (төмән) башында Алтын Урданың көнбатыш тарафларына юнәлә һәм атасы Мувалдан варислыкка күчкән Днепр белән Днестр елгалары арасындагы шактый киң вә бай биләмәләргә хуҗа була. Тора-бара ныгып алгач, ул Сарай хакимиятеннән бәйсез хәрби хәрәкәтләргә күчә. Византия биләмәләренә яу чаба, Константинопольне камап тора (1265), Балкан төбәген бөлгенлеккә төшерә (1270), Дунай буе болгар кенәзлекләрен (Видин,Тырново һ.б.), шулай ук Сербияне буйсындыра (1271-1278). Бер ук вакытта үзенең вассаллары булган рус кенәзләре белән Литвага (1274-1278), Польшага яулар оештыра.

Әлеге сугыш хәрәкәтләре Нугай бәккә зур танылу китерә, аның йогынтысы бермә-бер арта. Хәзер ул Сарай ханнарына баш бирмәү генә түгел, үзе теләгән ханзадәне тәхеткә утыртып, ярамый башласа, бәреп төшереп яисә үтертеп, янә үз кешесен хан итеп куярга хәленнән килгән көчле хөкемдарга әверелә. Мисал өчен, 1280 елда Мәнгу хан кинәттән үлеп киткәч, ул тәхеткә Тәдән Мәнгуны утырта. Ләкин хан йомшак вә ихтыярсыз булып чыга һәм Нугай бәк аны тәхеттән алып ташлый (1287), ә аның урынына утырткан Теләбуга ханны исә, аралары бозылгач, үтертә (1291). Нугай бәк Теләбуга урынына Тыктайны (Тәктагу) хан итеп билгели.

Бу вакытта Нугай бәк кул астына, үзе алып килгән кабиләләрдән тыш, Днестр белән Дунай елгаларының түбән агымындагы төбәкләрдә гомер итүче Молдавия волохлары, румыннар, болгарлар, шулай ук «бродниклар» дип аталган рус казаклары кергән. Ә инде үз биләмәләренә Кырымны да кушкач, аның карамагындагы җирләр вә кавемнәр тагын да ишәя. Кыскасы, Нугай бәк, 1290 елларда Алтын Урданың гаять йогынтылы хакименә әверелә. Аның күтәрелүе аксөякләрдә, шулай ук Тыктай ханда ризасызлык тудыра. Яшь хан баштарак химаячесенең киңәшләренә колак сала торган булса да, соңга таба идарәне үз кулына алу ниятенә килә. Бу инде ике арадагы мөнәсәбәтләрнең бозылуына сәбәп була. Нәтиҗәдә, Тыктай хан белән Нугай бәк гаскәрләре арасында берничә тапкыр каты сугыш була. Ниһаять, соңгы бәрелештә Нугай бәк чирүе тар-мар ителә, ә бәк үзе һәлак була (1300). Әлеге вакыйгадан соң Нугай бәкнең көнбатыштагы биләмәләре таркала, төп кабиләләре Идел — Җаек арасындагы далаларга кайтып урнаша.

Нугай бәкнең идарәсе шундый тирән эз калдыра ки, аның һәлакәтеннән соң Алтын Урда дәүләте үз эчендә күбрәк «Нугай йорты» дип йөртелә башлый.

## Идегәй мирза

Нугай кавеменең тарихы дастаннарда дан җырланган мәшһүр Идегәй мирза (1352-1419) белән тыгыз бәйләнгән. (Аның батырлыгы, зирәклеге һ. б. уңай сыйфатлары нугай, татар, башкорт, төрекмән һ.б. төрки халыклар авыз иҗатында киң чагылыш таба). Идегәй мирза елъязмаларга нугай дәүләтчелегенең чишмә башында торучы оста оештыручы булып кына түгел, куәтле Алтын Урда мәмләкәте белән ике дистә ел идарә иткән кодрәтле дәүләт җитәкчесе буларак та кереп калган. Аның нәсел башы атасы ягыннан — гарәпләргә, ә анасы буенча — төркиләргә барып тоташа. Идегәй мирзаның атасы ягыннан борынгы бабасы Мөхәммәтнең (с.г.в.) каен атасы Әбүбәкер Садыйк була. Әбүбәкернең кызы Гайшә — пәйгамбәребезнең хәләл җефете булганын беләбез. Мөхәммәт (с.г.в.) фани дөньядан бакыйлыкка күчкәч, Әбүбәкер пәйгамбәр урынына кала һәм гарәпләрдән беренче буларак хәлифә итеп сайлана. (Хәлифә — дөньяви вә дини хакимияткә ия булган иң югары дәрәҗәле дин әһеле).

Мәгълүм булганча, 1312 елда Алтын Урда тәхетенә Үзбәк хан утыра (1342 елда гүр иясе була). Ул, ислам динен таратыр өчен дин белгече сорап, Мәккәгә ышанычлы кешесен җибәрә. Күп тә үтми Үзбәк хан хозурына үзенең өч улын ияртеп Әбүбәкернең 14 нче буын нәселдәше булган Чәчле Азиз (татарлар аны Төксел Баба дип йөрткәннәр) килеп җитә. Төксел Баба бик күп төрки вә мангулларны ислам диненә күчерү бурычын үтәгәч, олы һәм уртанчы уллары белән кире Гарәбстанга кайтып китә.

Идегәй мирза тамырларында төрки каны агуы белән бик горурланган, чөнки анасының нәсел башы изге зат — Хуҗа Әхмәт Ясәвигә (мөселман дөньясында танылган суфый шагыйрь, төрки телдә иҗат иткән, 1166 елда фани дөньядан китә) барып тоташкан. Идегәй шәҗәрәсенең бу тармагы турында халык дастанында Идегәй улы Нуретдин сөйли.

Төксел Баба ике улы белән Мәккәгә кайтып киткәч, аның монда калган кече улы Тирмәк Үзбәк ханга хезмәткә күчә. Хан якты чырай күрсәтеп, аны «Мангыт йорты» кабиләләре башлыгы итеп куя. Үзбәк ханның ышанычын казанган гарәп мөһаҗире Идегәй атасы Котлыкыяның бабасы була инде. Котлыкыя дошманнары кулыннан корбан булгач (дастанда бу фаҗигадә Туктамыш хан кулы уйнавы турында хәбәр ителә), атасы урынына «Мангыт йорты» кабиләләре башында Идегәй кала.

Идегәй мирза 1383 елда Туктамыш хан кызына өйләнә, ханның гурһаны (кияве) буларак зур дәрәҗәләргә ирешә. Аның уңышлары ханны әйләндереп алган вәзирләрдә хөсетлек хисе уята һәм алар Туктамыш ханга Идегәй тарафыннан куркыныч янавы хакында әләк ишеттерәләр. Ханның үченнән шикләнеп, Идегәй Сәмәрканд әмире Аксак Тимер янына качып китә (1388). Киләчәктә Алтын Урда тәхетенә Чыңгыз хан нәселеннән булган Тимер Котлыкны утырту теләге белән, яшь ханзадәне мөмкин булган хәвеф-хәтәрдән саклап калу максатында, Идегәй аны Сәмәркандка элегрәк озатып җибәргән булган. Соңрак, 1391 елда Аксак Тимер тарафыннан Алтын Урдага каршы оештырылган яуда Идегәй мирза белән Тимер Котлык та катнаша. Кондырча суы буендагы хәлиткеч орышта Туктамыш хан чирүе тар-мар ителә.

Аксак Тимер әлеге орыштан соң, шактый сирәгәйгән гаскәрен тулыландырыр өчен, урдаларның төрле якка таралган яугирләрен җыеп, аларны Сәмәркандка озатырга боерык бирә. Идегәй белән Тимер Котлык, өстәмә көчләр алып килү сылтавы белән, үзләрен җибәрүне сорап Аксак Тимергә мөрәҗәгать итәләр. Боларга һәрвакыт ачык йөз күрсәтеп килгән бөек әмир риза була. Алар шушы китүдән әйләнеп кайтмыйлар инде.

Идегәй мирза үзе юк чакта шактый таркалган «Мангыт йорты» кабиләләренә яңа сулыш өрә. Аксак Тимер яуларыннан соң үзәк хакимиятнең зәгыйфьләнүеннән файдаланып, биләмәләрен киңәйтә һәм, иң мөһиме, Алтын Урдадан аерылып чыгып, мөстәкыйль Мангыт олысы төзи. Тора-бара әлеге башлангыч дәүләт берләшмәсеннән Идегәй балалары тарафыннан идарә ителеп килгән мәшһүр Нугай Урдасы үсеп чыга.

* * *

Аксак Тимернең җимергеч яуларыннан соң, Алтын Урда җирләрендә берберсе белән һәрдаим низаглашып торган дүрт бәйсез дәүләт барлыкка килә. Сарай җимерекләрендә һәм аның әйләнә-тирәсендә хан тәхетенә Аксак Тимер утырткан Коерчык, Әстерханда һәм аның тирәләрендә тәхеткә Идегәй мирза ярдәме белән утырган Тимер Котлык, Кырымда шул тарафка китәргә мәҗбүр булган Тuктамыш хан хакимлек итәләр. Ә Идел — Җаек — Эмба елгалары арасындагы Мангыт олысы биләмәләрендә, әйткәнебезчә, Идегәй мирза ныгып урнаша. Әмма мондый хәл озакка сузылмый. Идегәй белән Тимер Котлык югары хакимиятне кулга төшерү хәстәрлеген күреп килүләр. Тиздән алар максатларын гамәлгә ашырырдай хәрби көчкә дә ия булалар. Башта Тимер Котлык Коерчыкка каршы чыга һәм аны Сарай тәхетеннән куып җибәрә. Ә аның биләмәләре яшь хан белән Идегәй кул астына күчә. Аннары алар бергәләп Туктамыш ханга каршы чыгалар (1396-1397) һәм аны да Литва короле Витаутас янына качып китәргә мәҗбүр итәләр. Әлеге вакыйгалардан соң Алтын Урда тәхетенә Идегәй ярдәмендә Тимер Котлык утыра (1397).

1399 елның җәендә Тимер Котлык белән Идегәй мирза Туктамыш хан чирүе белән көчәйтелгән Витаутас гаскәрен тар-мар итәләр. Әлеге җиңүдән соң Тимер Котлыкның абруе бик нык үсә. Әмма шул ук 1399 елда билгесез сәбәпләр аркасында яшь хан кинәттән үлеп китә. Тимер Котлык исән чакта ук иң югары хәрби дәрәҗәгә (әмирләр башлыгы) ия булган Идегәй мирза хан вафатыннан соң бинибая зур дәүләт белән идарә итүне тулысынча үз кулына ала. Белгәнебезчә, Чыңгыз хан нәселеннән булмаганга күрә, Идегәй мирза үзенә хан титулын ала алмый. Шунлыктан ул тәхеткә хан нәселеннән чыккан ханзадәләрне утыртып, шулар исеменнән хакимлек итә башлый һәм алга таба 20 ел буена (1399-1419) дәүләт белән идарә итү дилбегәсен үз кулыннан ычкындырмый.

1411 елда Идегәй мирза тәхеткә Тимер Котлык улы Тимерне (1411-1412) утырта. Тик яшь хан бик тә үзсүзле һәм нык холыклы булып чыга. Остазының күрсәтмәкиңәшләренә колак салу түгел, киресенчә, ул мирзага түзә алмаслык шартлар тудыра. Идегәй Сарайны ташлап китәргә мәҗбүр була. Ул сыену урыны итеп Хәрәземне (Үргәнеч) сайлый. Әмма анда да озак тора алмый. 1414 елда Үргәнеч диварлары янында чирүе белән Сәмәрканд әмире Аксак Тимер улы Шаһрәх пәйда булгач, Идегәйгә бу ныгытманы калдырып китүдән башка чара калмый. Бу юлы ул Сарайга түгел, ә Сарайчыкка кайтып китә.

1419 елда Идел һәм Җаек арасына, ягъни Идегәйнең төп биләмәләренә Туктамыш ханның төпчек улы Кадыйр Бирде үтеп керә. Инде олыгайган мирза (аңа бу чакта 67 яшь була) Сарай тәхетен дәгъвалаучы ханзадәгә каршы чыга. Бик каты орыш була. Канлы бәрелештә дошманнарның икесе дә һәлак була, ә гаскәрләре төрлесетөрле якка качып китә.

## Нугай дәүләтчелеге

Идегәй белән олы улы Нуретдин арасында сәбәбе ачык күренеп тормаган, әмма озак елларга сузылган киеренкелек хөкем сөргән. Шуның тәэсирендә булса кирәк, Идегәй мирза һәлак булганнан соң, аның васыяте буенча Мангыт олысы башында олы улы түгел, ә күп ир балаларыннан берсе — Газый исемлесе кала. Урта куллы Газыйны сәләтле Нуретдин алмаштыра. Нуретдин дастанда оста сәргаскәр буларак тасвирлана. Аның гомере канлы үч алу теләге белән янып йөргән Туктамыш ханның бер оныгы тарафыннан киселә (1422). Чынлап та, 1406 елның кышында Көнбатыш Себер урманнарында яшеренеп яткан Туктамыш ханны үтерүдә Нуретдиннең катнашканлыгы да билгеле. Нуретдиннән соң аның урынын улы Оказ (Аказ) били. (Бу кабиләнең тамгасы ак каз булган. Шуңа күрә Оказның исемен Акказ дисәк дөресрәк булыр, мөгаен). Акказ үзен бик булдыклы башлык итеп күрсәтә. Ул атасыннан соң кабиләләр арасында йомшара башлаган элемтәләрне яңадан торгыза, биләмәләрне киңәйтә һәм бу башлангыч дәүләт берләшмәсен чын мәгънәдә бәйсез дәүләт дәрәҗәсенә күтәрә. Акказ заманыннан алып Мангыт олысын «Нугай Урдасы» («Нугайлы») дип йөртә башлыйлар (1430).

Акказ шулай ук канлы үч алу корбаны була (1447 еллар тирәсе). 1440 елларда, ягъни Акказ идарәсе вакытында, Нугай Урдасы Көнчыгышта Иртеш елгасыннан алып, көнбатышта Иделгә кадәр һәм төньякта Чулман (Кама) буйларыннан башлап, көньякта Сыр-Дәрьяга кадәр җәелгән биләмәләрне үз эченә алган гаять зур дәүләт була. Пайтәхете — Җаек елгасының түбән агымында урнашкан Сарайчык каласы. Нугай урдасы «Олыс» дип аталган берәмлекләргә бүленгән. Һәр олыс белән мирза идарә иткән. Нугайлы дәүләтенең иң зур һәм бердәнбер хөкемдары бәк (бәй, би) исемен йөрткән. Нугай Урдасында дәрәҗәсе ягыннан икенче кеше «Нурадин» («Нуретдин») исеме белән аталган. Ул Идел буенда көченеп йөргән кабиләләр белән идарә иткән. Нурадин бер үк вакытта бәкнең кече идарәдәше һәм тәхет варисы булган. Өченче дәрәҗәдәге түрә «Кәйкуват» исемен йөрткән. Аның карамагына Җаек — Эмба елгалары арасында көченеп йөргән кабиләләр кергән. Ниһаять, дәрәҗә баскычында дүртенче урын тоткан түрә «Тайбуга» дип аталган. Ул даими рәвештә бәк хозурында торган.

Нугай бәге киңәшләшү өчен «Карадуван« дип йөртелгән диван (киңәш мәҗлесе) җыйган. Бу диван, гадәттә, Сарайчык каласында үткәрелгән. Мәҗлеснең рәисе «Карадуван Турган» исемен йөрткән. Карадуван утырышларында дәүләт эшлеклеләре, гаскәр башлыклары, дин әһелләре, казыйлар катнашкан. Алар дәүләт тормышын тикшергән, сугыш һәм солых мәсьәләләрен караган, кануннар чыгарган һәм аларны гамәлгә ашыруга күзәтчелек иткән. Карадуванда шулай ук Нугай дәүләтенең тышкы сәясәте билгеләнгән, чит җирләрдән илчеләр кабул ителгән. Диванда кабул ителгән карарлар бәк тарафыннан расланган.

Моннан башка нугайларда Зур мәҗлес — «Корныш» уздырылган. Корнышта рәислекне бәк үзе башкарган. Бу Зур мәҗлескә морзалар, карачылар кебек дәүләтнең олы дәрәҗәле түрәләре җыйнала торган булган. Җирле идарәне морзалар (мирза белән буталмасын) алып барган.

Нугай Урдасы башка илләр белән сәяси һәм дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыра. Мәскәү дәүләте, Төркия, Литва һ.б. дәүләтләр белән төзелгән бу элемтәләр нугай сәүдәгәрләре өчен бик файдалы була.

Нугайлар күчмә көтүлекле терлекчелек — сарык, кәҗә, мөгезле эре терлек, ат, дөя үрчетү белән шөгыльләнгән. Бу хайваннар күчмә нугайларнын төп байлыгы булып саналган. Шулай ук кош-корт (тавык, каз, үрдәк) асрау, балык тоту, ауга йөрү кебек кәсепләрне дә атарга кирәк. Болардан тыш йорт тирәләрендәге җирләрдә күпмедер тары, бодай, солы ише бөртекле культуралар чәчкәннәр, җиләк-җимеш, кавын-карбыз үстергәннәр. Нугайларның төп табышы атлар белән сәүдә итүдә булган. Әлеге үтә чыдамлы һәм талымсыз дала атлары карап торырга шактый күренексез булсалар да, хәрби походлар һәм бәрелешләр өчен махсус булдырылган токым икәнен белгәнгә күрә, алар русларда зур ихтыяҗ тудырган. Морзалар Мәскәү ярминкәсендә генә һәр елны 40-50 шәр мең баш ат сатып, баеп кайта торган булган.

Шундый ук зур ярминкәләр башка урыннарда да оештырылган. Әйтик, Пензадан ерак түгел Сура елгасының уңъяк ярындагы болыннарда һәр елны зур-зур ярминкәләр үткәрелгән. Нугайлар монда күп мең санлы елкы көтүләре куып китереп, җәй буе сату иткәннәр.

* * *

Акказдан соң Нугай Урдасы белән бер-бер артлы аның уллары Муса (1502), Ямгурчы, Арыслан (1509) идарә итә. Арыслан үлгәч, Мусаның күпсанлы балалары арасында хакимият өчен көрәш башлана. (Белешмә сыйфатында: Муса бәкнең 5 бичәсеннән 40 баласы булган). Нәтиҗәдә хакимлекне араларыннан берсе — Сәед Әхмәт дигәне (1521-1548) кулга төшерә, ә аңардан соң тәхеткә бертуганнар — Шәех Мамай (1548 — 1549), аннары Йосыф мирза (1549-1554) ия була.

1554 елда Мәскәүгә каршы сәясәт алып барган Йосыф бәкне Явыз Иван котыртуы буенча энесе Исмәгыйль үтерә һәм шул рәвешчә тәхетне кулга төшерә. Тик ул озак хакимлек итә алмый. Әстерхан ханы Дәрвиш ярдәме белән Йосыф бәк балалары тәхетне кире кайтара. Исмәгыйль исә гаиләсе белән Сарайчыкны ташлап, Мәскәүгә химаячесе янына качып китәргә мәҗбүр була. Бөек кенәз Исмәгыйльгә

хәрби ярдәм күрсәтә: рус гаскәре килеп Йосыф бәк улы Юнысны тәхеттән төшерә, янадан Исмәгыйльне утырта (1555). Юныс, нуретдин (тәхет варисы) титулын кабул итеп, Иделнең түбән агымындагы үз биләмәләренә кайтып китә.

Исмәгыйльнең кылган гамәлләре татар-нугай дөньясына бик кыйммәткә төшә. Менә кайбер мисаллар. 1552 елның август-сентябрь айларында, Казан рус гаскәрләре тарафыннан камалышта торганда, Ядегәр хан Сөембикәнең атасы Йосыф бәк белән Төркия солтаны Сөләйман I Канунигә ярдәм сорап мөрәҗәгать итә. Йосыф бәкнең кул астында ат һәм дөяләрдә хәрәкәт итәрлек 120 мең сыбайлы булуына һәм ярдәмгә барырга әзер торуларына карамастан, Исмәгыйльнең каршылыгы аркасында бу гаскәр Казанга булышлык күрсәтергә җибәрелмичә кала. Хәтта солтанның Исмәгыйльне Мәскәүгә каршы яу белән барырга күндерергә тырышуы да (камауны туктату максатында) бушка була, гәрчә Сөләйман I аңа бүләк итеп биләмәгә Азак (Азов) каласын һәм аның әйләнә-тирәсендәге җирләрне бүлеп бирергә вәгъдә итсә дә. Солтанның үзенә килгәндә исә, Европаның көньяк-көнчыгышында яулап алу сугышлары алып барганга, аннары Кырым ханлыгында тәртипсезлекләр башлану сәбәпле, аның Мәскәү өстенә барырга тәвәккәллеге җитмәгән, күрәсең.

1553 елда Исмәгыйль мирза Әстерхан тәхетеннән Йосыф бәкнең аркадашы Ямгурчы ханны бәреп төшереп, аның урынына туганы Дәрвишне утыртырга тели. Тик моның өчен аның коралы җитми. Казанны алганда русларга теләктәшлек белдереп, аларга комачаулык итмәвен искә төшереп, ул Иван IV дән суднолар һәм туплар белән ярдәм итүне сорый. Тегесе Исмәгыйльнең үтенечен канәгатьләндерергә ризалык бирә, тик бер шарт белән: әгәр дә ул абыйсы Йосыф бәккә каршы сугыш ачса. Исмәгыйль бу таләп белән килешә. 1554 елда Явыз Иван утлы корал (мушкетлар) белән коралланган 39 меңлек рус гаскәрен, туплар белән тәэмин ителгән корабларга утыртып, Дәрвиш житәкчелендә Әстерханга каршы җибәрә. Үзара үтереш сугышы (Ямгурчы белән Дәрвиш — туганнар — Олы Урда ханы Әхмәтнең оныгы балалары) Ямгурчының җиңелүе белән тәмамлана.

Аның бәхетсезлеккә очравында фәкать Исмәгыйль гаепле: ул үзенең атлы гаскәре белән өч атна буена Йосыф бәкнең хәрәкәтен тоткарлап, Ямгурчы ханга ярдәмгә килергә ирек бирми. Алдагы вакыйгалар күрсәткәнчә, моның белән генә эш бетмәгән. 1556 елның кышында Исмәгыйль бәк янә Явыз Иванга мөрәҗәгать итә. Бу юлы ул әле күптән түгел генә тәхеткә утырырга үзе булышлык күрсәткән Дәрвиш ханны, Йосыф бәк балалары белән дустанә мөнәсәбәтләрне саклап калуда гаепләп, тәхеттән төшерүне сорый.

Күп тә үтми Явыз Иван гаскәре килеп җитә. Руслар Дәрвиш ханның Идел тамагындагы судноларын яндырып, әллә ни зур булмаган чиркүен туздыра һәм Әстерханны яулап ала (1556). Әле моннан соң да Дәрвиш хан берникадәр вакыт азатлык көрәше алып бара, әмма уңышка ирешә алмый. Соңыннан төрекләр кул астындагы Азак каласына кереп бикләнә. Ханлыкның тулысынча яулап алынуына шик калмагач, Мәккәгә китеп бара (1558). Күренә ки, Казан вә Әстерхан ханлыкларының һәлакәтендә Исмәгыйль бәкнең роле гаять зур. Шуңа күрә татар тарихында ул юкка гына Шаһгали белән бер дәрәҗәдәге сатлык җан булып кереп калмагандыр.

## Нугай Урдасының таркалуы

Исмәгыйль бәкнең Мәскәүгә сатылуы, Казан вә Әстерхан ханлыкларын бәладә калдыруы, бертуган агасын үтереп тәхеткә утыруы, аның балаларын эзәрлекләве h.б. ачык яисә яшерен эш-гамәлләре дәүләттәге гомуми тотрыксызлыкка китергән сәбәпләрдән булып, эчке таркалу процесслары башлануга китерә. Дәүләтнең таркалуы Шәех Мамай (Исмәгыйльнең абыйсы) балаларыннан башланып китә. Аның алты улы төп Урдадан аерылып чыгып, үз кешеләре белән Жаек һәм Эмба елгалары арасындагы далаларга күчеп китә һәм шул җирләрдә мөстәкыйль «Алты ул» дигән урдага нигез сала. Аннары Сәед Әхмәтнең оныгы Казый мирза (? — 1577) Азак (Азов) дингезе белән Төньяк Кавказдагы Кабарда төбәге арасында күченеп йөрүче Кече Нугай Урдасын (Казый олысы) оештыра. Бүленүдән калган өлеш Зур

Нугай Урдасы дип йөртелә башлый. Анын биләмәләре көнбатыштан — Иделнең сул яры инкүлеге (әлеге җирләр Нугай ягы яки Нугай чиге дип аталган); төньяк-көнчыгыштан — Иртеш елгасы кушылдыклары (Тубыл, Ишим), шулай ук Иртешнең югары агымы төбәге (монда ул Себер ханлыгына терәлеп торган); көнчыгыштан — Эмба елгасыннан алып Арал дингезенә, Сыр-Дәрьяның түбән агымына; ә көньяктан — Хәзәр (Каспий) дингезенең төньягына, шулай ук Сулак һәм Терек елгаларының түбән агымындагы җирләргә хәтле сузылган.

Әстерхан ханлыгына каршы алып барылган хәрби кампания вакытында Иван IV басымына бәйле, Исмәгыйль бәк ике арадагы «дуслык һәм хезмәттәшлек» килешүенә кул куя (1557). Тулысынча буйсынуга нигезләнгән әлеге килешү Зур Нугай Урдасын Мәскәүдән бәйле (вассал) дәүләт дәрәҗәсенә төшерә. Тәхеткә хыянәт юлы белән утырган Исмәгыйль бәк, үч алудан, тәхетне кулдан ычкындырудан куркып, шикле дип уйлаган туганнарын берәр уйдырма йомыш белән Мәскәүгә (алдан сөйләшеп, кире кайтармауларын сорап) җибәрә торган булган. 1561 елда Мәскәүдә нәкъ шул юл белән озатылган бертуганнары һәм 70 яраны белән Туктар Кутумов дигән мирза пәйда була. Ахырда ул кайтып китә алмыйча, рус җирләрендә төпләнеп кала. Көндәшләреннән котылуның тагын бер юлы, ул да булса, рус патшасына хәрби ярдәм сыйфатында Ливония сугышына олактыру. (Бу сугыш 1558-1583 елларда Балтыйк дингезенә чыгар өчен Иван IV тарафыннан Ливон ордены, Польша һәм Швеция белән алып барылып, Мәскәүнең җиңелүе белән тәмамлана). Исмәгыйль бәк тарафыннан әлеге сугышка озатылган «ышанычсыз» дип саналган Ибак, Бикбулат вә башка морзаларның 1559-1564 елларда Смоленск һәм Полоцк походларында рус гаскәрләре белән җитәкчелек итүе билгеле.

1558 елда нугай далаларында бик каты корылык була. Ачлыктан, үләт зәхмәтеннән биниһая күп кеше һәм хайван кырыла. Күчмәннәр яшәгән урыннарын ташлап китә башлый. Зур-зур кәрваннар ерак юлга кузгала. Аларның бер өлеше Төньяк Кавказ, Кубан якларына (Казый олысы биләмәләренә), Урта Азиягә (Хәрәзем вә Бохарага) юл тотса, калганнары Сыр-Дәрья тирәләрендә кыргызлар, Чулман (Кама) буйларында, Казан артында гомер сөргән төрки-татарлар җирләренә килеп чыга... Күчеп килүчеләр тора-бара җирле халык белән аралашып, туганлашып, алар арасында эреп-югалып, әлеге кавемнәрнең этнос буларак оешуында катнашалар. Мисал өчен, күчеп килгән нугайларның төрки-татарлар белән бәйләнешенә күз салыйк. Чыганаклар Казан артына килеп урнашкан нугайларның инде XVI гасырның икенче яртысында ук бу төбәктәге төрки-татарлар белән кушылып бетүе хакында бәян итә. Бу чорга караган рус чыганаклары нугайларны, кавем буларак, төп төрки-татар массасыннан аермый диярлек. Әлеге факт, үз чиратында, бу заманда татарларның этнос буларак оешып житүен раслый. Нугайларның төрки-татарлар белән шактый тиз арада кушылып бетүе, дөресрәге , эреп югалуы, бердән, үзара тел, матди һәм рухи тормыш, мәдәният якынлыгы аша билгеләнсә, икенчедән, аларның бу чорда аерым этнос булып оешып житмәүләренә дә бәйле. Әлеге мисал нугайлар күчеп утырган башка төбәкләргә дә хас гомуми күренеш булган.

Күченү процесслары алдагы елларда да дәвам итә. Бу юлы күчмәннәр башлыча Кырымга, ә беркадәре рус җирләренә юнәлә. Куллары канга буялган Исмәгыйль бәккә буйсынырга яисә аның белән Йосыф бәк балалары арасындагы бәрелешләрдә катнашырга теләмәгәннәр авыр һәм ерак юлга кузгала.

Идел кичүләрендә унъяк ярга (ягъни Кырым тарафына) чыгар өчен торган саен күбрәк кәрван, тирмә, терлек көтүләре килеп туплана. Көймәләр, паромнар бу ташкынны елга аркылы чыгарып өлгерә алмый. Исмәгыйль бәк ничек тырышса да, дәүләтне зәгыйфьләндерүче күченү шаукымын туктата алмый гаҗиз була. Ә инде Кырымга үз балалары Тинбай белән Котлыбай да китеп баргач, хафага төшкән Исмәгыйль бәк ашыгыч рәвештә ярдәм сорап янә рус патшасына мөрәҗәгать итә. Ул анардан халыкны Идел аша чыгармас өчен өч төп кичү урыннарында, аерым алганда, Иделнең Донга ин якын төшендә, Самара елгасы тамагында һәм, ниһаять, Иделнең сул кушылдыгы Зур Иргиз елгасы тамагында йә кораллы сак куюны яисә ныгытмалар салуны сорый. Хәлбуки, Сарайчыктагы хакимлек өчен барган тартыштан хәбәрдар булган Иван IV «дусты»ның гозерен үтәргә бик ашыкмый. Ә

шул арада чирек гасырга сузылган, болай да хәерче рус җирләрен тәмам бөлгенлеккә төшергән Ливония сугышы башланып китә. Шунлыктан патшада ныгытмалар төзү кайгысы булмый һәм нугайларның таралуы дәвам итә. Иделдәге кечү урыннары белән берләттән, Чулманның түбән агымында, хәзерге Мурзиха белән Саескан тавы арасында тагын бер кечү эшләп килгән. Мәскәү хөкүмәте яна яулап алынган Казан ханлыгы җирләрен, бер үк вакытта кечүдән нибары 70 чакрым ераклыкта гына урнашкан Казанны әледән-әле кабатланып торган татар-нугай һөҗүмнәреннән саклар өчен Лаеш ныгытмасына нигез сала (1557).

Мәҗбүриләп җибәрүдән тыш, Мәскәүгә үз ирегe белән китүчеләр дә, аеруча югары катлау арасында (әйтик, олыс, кабилә башлыклары, башка аксөякләр) байтак була. Алар үзләренең кораллы атлы төркемнәре белән Иван IV хозурына хәрби хезмәткә ялланырга дип киләләр. Әлбәттә инде, Ливония сугышы барганда хәрби ярдәм буларак, патша аларны колач җәеп каршы ала. Иван IV Зур Нугай Урдасыннан күчеп килүчеләргә Идел буендагы Романов шәһәрчегендә ( хәзер Ярославль өлкәсендә Тутаев шәһәре) урнашырга рөхсәт бирә. XVII гасыр урталарында патша аларны Чистай тирәсенә (хәзерге Иске Ромашкино авылы) күчереп утырта. Әлеге нугайлар заманында нәзек йонлы роман токымы сарыкларын үрчетү белән дан казанган. (Күпләр әле хәзер дә «романов кыска туннары»н («романовские полушубки») хәтерлидер).

* * *

Исмәгыйль бәк 1563 елда дөнья куя. Үлем түшәгендә ятканда ул Иван IVтән балаларын үз яклавына алуны, җир биләмәләре бүлеп бирүне сорый. Исмәгыйльдән соң тәхеткә аның икенче улы йомшак холыклы Динәхмәт утыра. Динәхмәтнең күтәрелүендә Мәскәү кулы уйнавы ихтимал. Ни өчен дигәндә, нуретдин (тәхет варисы) буларак хакимлек Йосыф бәкнең олы улы Юныска күчәргә тиеш була. Динәхмәт атасы сәясәтен дәвам итә. Шуның бер мисалы: Иван IVнең үтенечен канәгатьләндерү йөзеннән, Швециягә каршы бик шәп коралланган 1500 нугай җайдагын җибәрә.

Хакимияттән читләштерелгән Юныс бәк энеләре Ибраһим һәм Әл белән 1564 елда Мәскәүгә рус патшасына хезмәткә күчеп килә. Иван IV аларга зур суммада акча түли башлый. Менә шушы бертуган морзаларның иң кечесеннән, ягъни Әл морзадан (? — 1611) Россиядә данлыклы кенәз Йосыповлар нәселе башланып китә. 1670 елда алар христиан динен кабул итәләр. Әлеге нәселнең соңгы вәкиле патша Николай IIнең туганы кызына өйләнгән Феликс Йосыпов (1887 — 1967) патша сараенда үз кешесе булган атаклы авантюрист Григорий Распутинны үтерүдә катнаша (1916).

Динәхмәт үлгәч (1578), тәхеткә Исмәгыйльнең өченче улы гайрәтле Ырыс утыра. Атасыннан һәм агасыннан аермалы буларак, ул Мәскәүгә дошман мөнәсәбәттә була. Нугай аксөякләренең байтагы русларга каршы сугышырга теләмәсә дә, Ырыс бәк Кырым ханлыгы һәм Казый олысы гаскәрләре белән берлектә 1581 елда руслар өстенә яу чаба. Бик күп хуҗалыкларны бөлгенлеккә төшереп, меңләгән тоткын алып, чирү кире борыла. Моңа җавап итеп Иван IV нугайларга каршы баштанаяк коралланган казак гаскәре җибәрә. Казаклар Сарайчыкны яндырып, мөселман зиратларында кабер ташларын мыскыллап, башка вәхшилекләр кылып «үч ала» (1586).

Гәрчә Ырыс бәк көчле хөкемдар булып саналса да (мәсәлән, ул идарә иткәндә Бохара әмире Сарайчыкка ясак түләп торган), руслар 1586 елда нугай җирләрендә — Идел буенда Самара, Агыйделдә Уфа кебек үтә мөһим ныгытмаларны төзегәндә аларга каршы чыга алмый. Ырыс бәк 1590 елда кинәт үлеп китә. Аннардан соң хакимиятне мирас итеп Динәхмәтнең Урмәмәт белән Тиңмәмәт исемле олы уллары ала. Тыныч холыклы булганга, алар идарәсенә караган вакытка берниндн гадәттән тыш хәлләр теркәлеп калмаган.

Хәлбуки, 1600 елда тәхеткә боларның энесе, Динәхмәтнең дүртенче улы Иштирәк морза утыргач, хәлләр кискен үзгәрә. Югары катлау арасында хакимият өчен янәдән тартыш башлана. Бу юлы кораллы бәрелеш Исмәгыйльнең кече улы Тиңбай һәм

Ырыс бәк балалары белән Динәхмәт нәселе арасында килеп чыга. Үзара үтерешүне игътибар белән күзәтеп торган Әстерхан губернаторы низагны тирәнәйтү һәм киңәйтү максатында йә бер якка, йә икенчесенә хәрби ярдәм күрсәтеп, дөрләп янган учакка утынны өстәп тора...

1604 елның 13 октябрендә Ялган Дмитрий I Россия чикләренә үтеп керә. Татардан чыккан патша Борис Годунов, Польшага каршы сугышта нугайларны да җәлеп итү максатында, үзенең туганы окольничий (югары дәрәҗәле бояр) Симеон Годуновны шул хакта сөйләшүләр алып барыр өчен Иштирәк бәк янына җибәрә. Менә шушы бояр Әстерханда Борис Годунов исеменнән Иштирәк бәк белән Ырыс бәк балаларын үзенә сыендырган Яңарасланны килештерә. Годуновлар Иштирәкне Польшаның «бихисап байлыкларын» алу өчен 60 меңлек атлы гаскәр куярга күндерергә тырыша. Әмма 1605 елда Ялган Дмитрий Iнең рус тәхетенә утыруы алдыннан хәзер инде татулашкан Иштирәк, Яңараслан һәм Тинбай улы Канай морзаларның «яңа рус патшасын» танулары, хәтта аңа хәрби ярдәм күрсәтергә теләүләре нугай житәкчеләренең Мәскәүгә ышанмавын белдерә. Тик Дмитрий I тәкъдим ителгән ярдәмнән баш тарта, ул мөселман гаскәрен христианнарга каршы кулланудан курка.

Ни генә булмасын, шулай да 1608 еллар тирәсендә Иштирәк бәк низаг вакытында бүлгәләнеп беткән Зур Нугай Урдасын янадан бәйсез дәүләт сыйфатында торгызуга ирешә. Үзенең мәркәзе Сарайчыкта ачыктан-ачык төрек солтанын, Кырым ханын, Бохара әмирен һ.б. дәүләт башлыкларын кабул итә. Әмма бу бәйсезлек озакка бармый. 1617 елда Иштирәк бәк күпчелек атлы гаскәрне үз йогынтысында тоткан Урмәмәт улы Килмәмәт морза ризалыгы белән (әйткәнебезчә, 1552 елда атлы гаскәр Исмәгыйль кул астында булып, аның ризалыгыннан башка Казанга ярдәм җибәреп булмаган) Михаил Романовка мөрәҗәгать итеп, билгеле бер күләмдә «хезмәт хакы» бәрабәренә янадан аның вассалы булырга теләк белдерә. Ул бу акчаны Әстерхан губернаторы аша түгел, ә турыдан-туры үзенә тапшыруны шарт итеп куя. Бер үк вакытта ул патшадан бичәләренә, кызларына кара мехтан тегелгән кыйммәтле туннар, үзе һәм яраннары өчен мех бүрекләр, тирмәләрне жылытырга ташкүмер, үзенең тән сакчыларына 300 калкан, шулай ук 300 табак кәгазь җибәрүне сорый. Гомумән, Иштирәк бәк Россиядән ел саен патшаның Кырым ханына җибәрә торган «күчтәнәчләреннән» дә ким булмаган «бүләкләргә» өмет баглый.

1619 елда Иштирәк бәк һәм тәхет варисы Шайтирәк морза берьюлы диярлек серле рәвештә үлеп китәләр. Мондый очракларда һәрвакыт диярлек кабатлана торган көрәш — хакимият өчен тартыш кабынып китә. Низаг Урмәмәт нәселе белән Иштирәк балалары арасында куба. Ә инде ике арага руслар да килеп кысылгач, әлеге эчке чуалыш аеруча кискен төс ала. Руслар Урмәмәт нәселенә хәрби ярдәм күрсәтеп, Иштирәкнең тәхет варисына хакимияткә килергә ирек бирмиләр. Ахырда Иштирәк балалары руслар белән урмәмәтләләр басымы астында кабиләләре белән Эмба елгасы тарафларына күчеп китәргә мәжбүр була.

1623 елда патша Михаил Романов Польшага каршы сугышта ярдәм күрсәтү шарты куеп, Тинбай улы Канай морзаны (Исмәгыйль оныгы) нугайларның бәге, ә Кара Килмәмәт морзаны тәхет варисы (нуретдин) итеп билгели. (Канай бәк патша таләбен үти — Польшага каршы көчле атлы гаскәр җибәрә).

Гамәлдә исә нугайлар арасында ныклы тынычлык барыбер булмый. Мисал өчен, Мәскәү тәкъдиме буенча Канай бәк калмыклар белән дуслык мөнәсәбәтләре урнаштырырга тели. Тик бу омтылыш шундый зур каршылыкка очрый ки, хәлләр кораллы бәрелешкә кадәр барып житә. Канай бәк белән аның сәясәтен хупламаган Кара Килмәмәт арасындагы сугышны Әстерхан губернаторы гына булдырмыйча кала.

1630 елда көнчыгыштан калмыкларның пәйда булуы Эмба елгасы буенда көн күрүче кабиләләрне (шул исәптән бу тарафларга күптән түгел килеп урнашкан Тинмәмәт белән Иштирәк бәк балаларын да кертеп) кыен хәлгә куеп, аларны Иделгә якынрак күченергә мәжбүр итә. Ә кайбер кабиләләр тагын да ераграк, Кубан елгасы буйларына — Кырым ханлыгы биләмәләренә хәтле барып житә. Калмыкларның 1634 елдагы хәрәкәте тагын да күңелсезрәк нәтиҗәләргә китерә. Алар бу юлы

төп биләмәләрне тәшкил иткән Түбән Идел — Җаек арасына үтеп керә. Көченеп китүләрдән, үзара низаглардан халкы сирәгәйгән Зур Нугай Урдасы калмыкларның һөҗүменә каршы тора алмый һәм Иделнең уңъяк ярына чигенә. Монда аларның бер өлеше, юлларына аркылы төшкән Дон казакларының каршылыгын сындырып, көнбатышка хәрәкәт итә һәм Донны кичеп, Кырым ханлыгы белән берләшә. Ә икенче төркем, Иделне аркылы чыккач, көньяккарак юнәлә һәм Кече Нугай Урдасына (Казый олысы) килеп кушыла.

Көнчыгыштан күчеп килүче кабиләләр исәбенә Кече Нугай Урдасының көчәюен булдырмас өчен Мәскәү Казый олысы өстенә кенәз П.И.Волконский җитәкчелегендә шактый зур гаскәр җибәрә. Боларга ярдәмгә Дон казаклары, аннары патша әмерен үтәп, үз теләге белән булмаса да, Канай бәк бүлеп биргән 8250 нугай җайдагы да килеп кушыла. Берләшкән гаскәрләр дүрт көн буена Казый олысын талый, яндыра. Казаклар кулына 2000ләп әсир, бик күп сугыш атлары эләгә.

1639 елда Канай бәк үлгәч, яңа башлык билгеләнми. 1640 елларда Идел буенда чикләнгән мәйданда көченеп йөргән яисә Төньяк Кавказда Кабарда төбәгендә ыстаннарда торган кабиләләрне җитәкләгән Җанмәмәт морза Канай бәк урынын дәгъвалап карый. Тик Мәскәү белән тыгыз мөнәсәбәтләрдә булуын белгән нугай морзалары каршы чыга, әлбәттә инде, берсе дә үз ирege белән аның кул астына керергә теләми. Ахыр чиктә, Идегәй мирза кебек барлык кабиләләрне, олысларны бер канат астына берләштерерлек көчле шәхес булмагач, әле кайчан гына гаять киң мәйданнарны биләгән, күршеләренә көчле йогынты ясап торган, «исәпсез-сансыз» ( рус елъязмаларында: «многочисленны, как песок морской») халкы булган Зур Нугай Урдасы дәүләт буларак яшәүдән туктый (1650 еллар тирәсе).

* * *

Нугайларның хәзер үз административ-территориаль бүленешләре юк, алар төрле төбәкләрдә — Ставрополь краенда, Дагыстан, Чечен, Ингуш республикаларында, Карачай-Чиркәс автономияле өлкәсендә сибелеп яшиләр. Диннәре — ислам диненең сөнниләр юнәлеше.

Нугай теле төрки телләрнең кыпчак төркеменә керә, ләкин лексик-фонетик яктан үзләре яшәгән урыннардагы халыклар телләренә бәйле. Әйтик, Әстерхан нугайларының әдәби теле — безнең татар теле. Дагыстанның Хәсәү-Йорт, Баба-Йорт районнарында яшәүчеләрнең әдәби теле — кумык теле. Нугай сөйләш теле өч диалектка бүленә: үзнугай (Ставрополь нугайлары), каранугай (Дагыстан нугайлары), акнугай ( Карачай нугайлары). Алар бер-берсенә бик охшаган, бары кайбер фонетик үзенчәлекләр белән генә аерыла. Бүгенге көндә нугайларның гомуми саны нибары 75,2 мең кеше (1989). Моны тугандаш халыкның ачы язмышын, дәүләтен югалткан кавемнең тарих мәйданыннан төшеп югалуын дәлилләүче бер мисал буларак кабул итәргә кирәктер.

**Гамир ГАРИФУЛЛИН**

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Акъегет

Акъегет авылы Зеленодол районында, район үзәге Зеленодол шәһәреннән 48 чакрымда, Урмар тимер юл станциясеннән — 10, Козловка пристаненнән 31 чакрым ераклыкта урнашкан. Акъегет — җирле үзидарә Советы үзәге. Аңа Бакырчы һәм Юынчы авыллары карый.

Акъегет авылы янында археологлар борынгы Болгар чорына нисбәтле табылдык әйберләр билгеләгән.

Д.А.Корсаков (XVIII гасыр) тарафыннан чыгарылган тарихи җыентыкта авыл Ишмәмәт (Эшметово), шулай ук Акъегет — «деревня Эшметова, Акзегитово тожь, при речке Мусерма» дип искә алына. Анда 157 йомышлы һәм 66 керәшен татары яшәгәнлеге күрсәтелә. 1859 елда авыл Акъегет (Ишмәт) дип йөртелгән һәм андагы 224 хуҗалыкта 647 ир-ат һәм 674 хатын-кыз көн иткән, мәчет булган.

Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, Акъегет, Юынчы, Эрә Бакырчысы авыллары халкы июнь ае башында Симек-чимек җыены бәйрәм иткән.

Аксакаллар сөйләвенә караганда, авылны Казан артындагы Мәңгәр якларыннан килгән Акъегет һәм Ишмәмәт дигән ике кеше нигезләгән дип әйтәләр. Икенче берәүләр исә Акъегет монда, ягъни авылда беренче туган бала дип тә сөйли.

Бакырчы белән Акъегет арасында иске зират булган. Элек җиде авыл халкы мәетләрен шунда китереп җирләгән. Ул зират хәзер сукаланган инде. Иске зиратка элек Акъегет, Бакырчы һәм Өрәңгәр авылы кешеләре барып йөргән. Элек алар чуашлар кебек симек-чимек үткәрергә, ягъни туганнарының каберләренә, ашагыз-эчегез дип, пешкән әйберләр салырга, сыра түгәргә барганнар. Башта авылда мәчет булмаган. Халык мәчеткә Эрә авылына йөргән.

Авыл, сөйләүләргә караганда, 7 нәселдән торган, һәр нәселнең үз тамгасы булган. Тамгаларның түбәндәге төрләрен искә алалар: чүкеч, казаяк, дүрт сука, бәти, өчборма, чана, муен, тустаган.

Акъегет авылында Заһидулла Шәфигуллинның кызлары өчен салдырган ике катлы агач йорты бар. Акъегет авылында 1840 елның декабрендә туган, Иркутск шәһәренең икенче гильдия сәүдәгәре З.Ш.Шәфигуллин үзенең туганы Шәйхулла белән Россия империясенең Красноярск, Иркутск, Чита кебек зур шәһәрләрендә мех, әзер күлмәкләр белән сату иткән. 1889 елның октябрендә ул Казанның икенче гильдия сәүдәгәре Мөхәммәтсадыйк Борнаев белән «Борнаев һәм Шәфигуллинның сату йорты» дип йөртелгән уртак оешма төзи.

Заһидулла Шәфигуллин сату-алудан тапкан шактый зур капиталын яңа, алдынгы ысуллар белән укыта торган татар мәктәпләре челтәре төзүгә тота. Ул үз исәбеннән Зөя, Чуел (Цивиль), Тәтеш өязләрендә унлаган мәчет һәм мәдрәсәләр төзетә. 1891 елда агалы-энеле Шәфигуллиннар Иркутск шәһәренең мөселман җәмгыятенә йорт янындагы җире белән мәчет төзү өчен бер йорт бүләк итәләр.

Элек Акъегет авылында барлыгы 3 мәхәллә булган дип сөйлиләр. Мәдрәсәдә исә 300ләп ир бала укый. Алар арасында тирә-юнь авыллары балалары гына түгел, бәлки Зөя, Тәтеш, Чистай өязләреннән килүчеләр дә була. 1898 елдан З.Шәфигуллин мәдрәсәдә укытуга алдынгы яңа ысуллар кертә. Анда арифметика,

*Дәвамы. Башы 2006 елның бнчы санында.*

география, Көнчыгыш тарихы, ә 1909 елдан рус теле укытыла башлый. Яна ысулны популярлаштыру өчен мәдрәсәдә һәр елны ачык имтиханнар үткәрелә һәм аларга күрше өязләрдән дин әһелләре һ.б. кешеләр чакырыла. З.Шәфигуллинның бу өлкәдәге эше бик уңышлы бара. 1911 елда Чуел өязендә яңача укытыла торган 12 мәктәп, шул исәптән Акъегет авылында кызлар мәктәбе дә була.

Ләкин З.Шәфигуллинның бу өлкәдәге эшчәнлеге губерна хакимияте тарафыннан яклау тапмый. Хәтта аның белән бергәләшеп, кулга-кул тотынышып эшләүчеләр дә губерна идарәсендә утыручылар тарафыннан эзәрлекләнә. 1911 елның октябрендә Акъегет мулласы Әхмәтша Мөхәммәтфатыйхов, Бакырчыныкы Әхмәтша Мөхәммәтҗанов, Чугенеке Шәрәфетдин һәм Габдрахман Бәшировлар эшләреннән алына.

Авыл зиратында авыл һәм тирә-юнь авыллар халкы өчен күп игелек эшләгән икенче гильдия сәүдәгәре Заһидулла Шәфигуллинның (1840–1919) кабере бар.

## Алгай

Алгай авылы Мамадыш районында, район үзәге Мамадыш шәһәреннән 42 чакрым ераклыкта, җирле үзидарә Советы үзәге Көмеш Күл авылыннан — 2, тимер юл станциясе Кукмарадан — 46, Гурьевка пристаненнән 20 чакрым ераклыкта урнашкан.

Алгай авылын И.А.Износков искә ала. Өскебаш суы ярына утырган авылда 169 ир-ат һәм 195 хатын-кыз көн иткән.

Өлкәннәр сөйләвенә караганда, элек бу урыннар калын кара урман белән капланып алынган булган. Борынгы чорларда (кайчан икәне бик билгеле түгел, кайбер кешеләр 880 ел элек дип тә әйтә) монда килеп урнашкан кешеләр агачларны кисәләр һәм шушында өйләр салып яшәп калалар. Авылга Алгай дип исем кушалар. Ләкин зур корылык булган елны авыл халкы хәзерге Оренбург якларына китеп урнаша. Анда барып төшкәч тә бер болынлыкта күк тәкә суялар һәм шуның хөрмәтенә үзләре урнашкан авылны Күк Тәкә дип атыйлар. Шунда нигез корып яшәп тә калалар. Болар хәзерге Алгай авылы халкының бабалары була.

Шулай итеп, 1110 еллардан соң Алгайда яшәүче калмый. 1115 елларда авыл урынына чирмешләр килеп утыра. Алар йортлар салып, җирне эшкәртеп авыл корып яши башлыйлар. 1415 елларда татарлар бирегә янадан килеп урнаша һәм чирмешләрне урман эче буйлап куалар. Авылда «Чирмешләр качкан сукмак» дип йөртелә торган сукмак та бар. Килгән татарлар монда игенчелек белән шөгыльләнә башлый. Авылны бу вакытта халык Урта Өске дип йөртә.

XV гасырлар тирәсендә Урта Өске авылыннан ике кеше ат белән хәзерге Оренбург шәһәре тирәләренә бара. Шунда алар Күк Тәкә исемле теге авылга кереп куналар. Алар кунган йортның хуҗасы ап-ак сакаллы бер карт була. Бу ачык йөзле матур карт алар белән бик яхшы итеп сөйләшә, кайсы яклардан килүләрен сораштыра. Юлчылар үзләренең Казан губернасы, Мамадыш өязе, Урта Өске авылыннан булуларын әйтәләр. Бу сүзләрне ишеткән йорт хуҗасы түбәндәгеләрне сөйли: «Сез әйткән авыл миңа бабай сөйләвеннән таныш. Минем бабалар хәзер сез яши торган Урта Өске авылында гомер иткәннәр. Ул авыл янында Өске елгасы ага торган булган. Ләкин алар бу авылда озак яши алмаганнар. Бик нык корылык булу сәбәпле, ачлыктан котылу өчен шушында күчеп китәргә мәҗбүр булганнар. Алар күчеп киткән авыл Алгай исемендә булган...»

Урта Өске кешеләре кире әйләнеп кайткач, халык белән киңәшәләр дә авыл исемен Алгай дип үзгәртәләр. Шул вакыттан бирле авыл Алгай исемен йөртә.

Авыл матур җирдә, ямьле тау итәгенә утырган. Тирә-ягында нарат, каен урманнары, кырлар, болыннар. Якында гына Каранглы Тау дип аталган урман бар. Авыл янәшәсеннән Өске суы ага. Өске суы Түбәнбай үзәнендәге чишмәдән башлана. Түбәнбай үзәне күршедәге Югары Өскебаш урманы уртасында.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# М

**МОСТАФИН Мөсагыйть** (25.9.1909, Самара губернасы Бөгелмә өязе Бәйрәкә а. – 6.12.1941), язучы. Балалар өчен язылган «Очрашу» (1931), «Үсү» (1931) хикәяләр җыентыклары авторы. 1941 августта үзе теләп фронтка китә, сугышта һәлак була.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**МОСТАФИН Рафаэль Әхмәт улы** (14.5.1931, Баулы р-ны Баулы пос. – 14.4.2011, Казан), әдәбият белгече, әдәби тәнкыйтьче, филол. фән. канд-ты (1971), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1985). Казан ун-тын тәмамлый (1954). 1961-63 елларда Казан телевидение студиясенең әдәбият-сәнгать тапшырулары бүлегенең баш мөхәррире, 1959 елдан башлап Казан ун-тында укыта, 1965-69 елларда «Казан утлары» ж-лы баш мөхәррире, 1991-97 дә «Татарстан» ж-лы баш мөхәррире, 1997-2001 дә «Казанские ведомости» г-тасынын әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире, 2001-2011 кабат «Татарстан» ж-налында. М.Җәлилнең гомере һәм иҗатына багышланган «Эзләнү дәвам итә» («Поиск продолжается», 1965, автордаш), «Геройшагыйрь эзләреннән» («По следам поэта-героя», М., 1971), «Өзелгән җыр эзеннән» (1974), «Муса Джалиль» («Муса Җәлил», 1986) дигән китаплар авторы. Хәзерге татар әдәбиятына, милли әдәбиятларның бер-берсе хисабына баетылу мәсьәләләре, әдәби тәрҗемәгә багышланган мәкалә һәм рецензияләр авторы. М.Җәлил исемендәге ТАССР комсомолы премиясе (1976), Г.Тукай исемендәге ТР Дәүләт премиясе (2006) лауреаты. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әс.: Кабан күле серләре. К., 1990; Казань и её слободы. К., 2001 (автордаш); О времени, о жизни, о себе. К., 2002; Силуэты: Литературные портреты писателей Татарстана. К., 2006; Репрессияләнгән татар әдипләре. К., 2009.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

**МОСТАФИН Шаһинур Сафа** (Әхмәтсафа) улы (12.2.1948, Мамадыш р-ны Арташ а. туа), язучы, ТРнын атказ. мәдәният хезмәткәре (1999). Казан ун-тын тәмамлый (1972). 1968 елдан «Коммунистик хезмәт өчен» исемле Мамадыш район газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли. 1970-82 дә (бүленеп) Кукмара районының «Хезмәт даны» газетасы редакциясендә башта әдәби хезмәткәр, соңрак бүлек мөдире вазифаларын үти. 1983-88 дә ТАССР Мәдәният министрлыгының фәнни-методик үзәгендә халык иҗаты һәм мәдәни-агарту эшләре буенча баш мөхәррир. 1988-92 дә СССР, соңрак РСФСР Язучылар берлеге Әдәбият фондының Татарстан бүлеге директоры. 1992-99да «Казан утлары» ж-лы редакциясенең хатлар һәм пропаганда бүлеге мөдире. 1999-2005 тә ТР Язучылар берлеге рәисе урынбасары. 2006 дан «Сүз» нәшриятының баш мөхәррире. Публицист һәм документаль проза остасы буларак таныла. Бөек Ватан сугышында һәлак булган геройларны эзләп табу, исемнәрен халыкка кайтару буенча зур эш алып бара: «Хәтер яктысы» экспедициясен җитәкли, «Батырлар китабы – Книга героев» (2000) белешмә басманың мәкалә авторларының һәм мөхәррирләренең берсе. Док.-публицистик характердагы «Васыять» (1995) һәм «Хәтер яктысы» (2004), «Яшәү яме» (2006) шигъри повесте, балаларга атап язылган шигырьләре тупланган «Бака кашыгы» (2003), «Яна меңьеллыкка очыш» исемле док. очерклар һәм пов. җыентыклары авторы. ТР журналистларының Х.Ямашев исем. (1982), РФнең М.Ломоносов исем. (2007) премияләр лауреаты.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

*Г.М.Габделхакова.*

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

**МОСТАФИН Эдуард (Идик) Госман улы** (31.1.1945, Башкортстан АССРның Калтас р-ны Кәс а. – 1997, кабере билгеле түгел), шагыйрь. 1963 елдан Башкортстан һәм Татарстан район газеталары редакцияләрендә эшли. 1968-73 тә М.Горький исем. Әдәбият ин-тында (Мәскәү) укый. Төзүче булып Уралда, Чирчик (Үзбәкстан), Нефтекамск, Казан шәһ.дә рәссам булып эшли. Тәүге шигырьләре «Беренче карлыгачлар» (1970) күмәк җыентыгында дөнья күрә. «Бишенче фасыл» (1979), «Туасы көн» (1986), «Ут. Кәгазь. Каләм» (1992) җыентыклары авторы. М. иҗатында драматизм көчле, поэтик теле ассоциацияләргә, метафораларга бай.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

**МӨГАММӘ** (муамма) (гарәпчә: шигъри табышмак, шарада, ребус), 1-2 юлдан торган катлаулы шигъри шарада, табышмак. Шәрекъ әдәбиятында кин таралган, татар әдәбиятында сирәк очрый. Ул мөстәкыйль дә, аерым әсәрнең бер өлеше дә булырга мөмкин. М.дә кинаяле рәвештә шигырьдә кайбер гарәп хәрефләре б-н хәрәкәт итәргә күрсәтмәләр бирелә: мәс., ноктаны хәрефнең өстеннән астына күчерергә (нәтиҗәдә бүтән хәреф барлыкка килә); хәрефне бер сүздән икенчегә күчерергә һ.б. Үзгәртелгән хәреф һәм иҗекләрдән җавап (чишелеш) барлыкка килә, мәс., ялгызлык исеме. Еш кына М. формасындагы әсәр ахырында кайбер мәгълүматлар (автор турында, язылу урыны һәм вакыты хакында) китерелә. Мәс., Һ.Салиховның «Төхвәтел әүлад» («Балаларга бүләк») китабында авторның һәм әсәрнең атамасы М.не чишү аша билгеле була.

Әд.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*Х.Й.Миннегулов.*

**МӨДӘРРИС (Мөдәррисов) Шәрәф Хасиятулла улы** (1.11.1919, хәзерге Чүпрәле р-ны Түбән Каракитә а. – 28.4.1963, Казан), шагыйрь. М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1956). Бөек Ватан сугышында катнаша. Төньяк-Көнбатыш фронтының минометчылар ротасында хезмәт итә, «За Родину», «Фронтовая правда», «Знамя победы» фронт г-таларында хәрби корреспондент сыйфатында сугыш юлын уза. 1946 дан «Кызыл Татарстан», «Яшь сталинчы» г-таларында әдәби хезмәткәр. «Үскәндә» исемле беренче шигырьләр җыентыгы 1937 елда басыла. Бөек Ватан сугышы темасы «Тупчы Вахап» (1944) поэмасында, «Фронтовик татарлар» (1944) очерклар һәм «Җыр үткән юл» (1947) шигырьләр җыентыкларында чагылыш таба. «Биш минут» (1949), «Яшел тасма» (1952), «Үлемсезлек» (1959) поэмаларында сугыш фаҗигасе сурәтләнә, кичәге көрәшчеләрнең хезмәт батырлыкларына дан җырлана. Сугыштан соңгы елларда М. сатирик шигырьләр, памфлет һәм фельетоннар («Көлке түгел», 1954), сугыш һәм тыныч хезмәт геройлары, әдәбият һәм сәнгать әһелләре турында очерклар, әдәби-публицистик мәкаләләр («Йолдыз атыла», 1963; «Ильич нурлары», 1969) җыентыклары иҗат итә. У.Шекспир, Дж.Байрон, М.Шелли, Һ.Һейне, А.С.Пушкин, Н.А.Некрасов, Т.Г.Шевченко әсәрләрен, К.Ивановның «Нарспи»ен татар теленә тәрҗемә итә. Шекспир сонетларын тәрҗемә итү белән шөгыльләнү М.нең үзенә дә бу катлаулы шигырь формасында иҗат итәргә этәргеч бирә. Ул татар поэзиясендә беренчеләрдән булып сонет жанрына юл ача, аның матур үрнәкләрен язып күрсәтә. Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән.

Әс.: Минем яшьтәш: Сайланма әсәрләр. К., 1956; Дуслар күңеле. К., 1980; Сквозь пепел дней. М., 1974.

Әд.: Хисамов Н. Үлемсезлек җырчысы // Казан утлары. 1969. №11; Әхмәдулла Ш. Нурлы сыны хәтер түрендә // Мирас. 2002. №7.

**МӨЛӘММӘГЬ** (гарәпчә: чуар, ялтыравык) Шәрекъ мөселман халыкларында шигъри юллар яки аерым очракларда мисраглар төрле телләр катнашында (гарәп, фарсы, татар һ.б.) иҗат ителгән шигырь. Гадәттә робагый яки фәрд язганда файдаланыла. Татар поэзиясендә М. киң таралган; аның татар, гарәп, фарсы һәм рус сүзләреннән торган үрнәкләре Харәзми, Сәйф Сараи, Өмми Камал, Г.Утыз Имәни, Ш.Зәки, Г.Тукай, Г.Кандалый әсәрләрендә очрый.

Әд.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*Х.Й.Миннегулов.*

**МӨЛЕКЕВ Сөләйман Мифтах улы** (5.1.1920, Балтач р-ны Пыжмара а. – сентябрь 1941), шагыйрь. Туган як табигате, мәхәббәткә багышланган беренче лирик шигырьләре вакытлы матбугат битләрендә 1930 еллар ахырында күренә башлый. 1940 та Кызыл Армия сафларына алына, сугышның беренче айларында Киев тирәсендә барган сугышларда һәлак була. Соңыннан шигырьләре «Алар сафта» (1961) исемле күмәк җыентыкка керә.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986.

**«МӘЛХӘМӘ»** (гарәпчә – поэма, эпопея), шигъри формада юрау китабы. «М»нең эчтәлегеннән чыгып караганда аның авторы Искәндәр-патша исемле кеше булырга тиеш. Китапта һәр айга карата 14-25 юрау, төрле табигать күренешләрен, аларның җәмгыять тормышына (ачлык, сугыш һ.б.) ясаган тәэсирләрен тасвирлау урын алган. Татарлар арасында 16 гасырның 1нче яртысыннан кульязма рәвешендә тарала башлый. Казанда беренче тапкыр 1891 дә басыла.

Әд.: Әхмәтҗанов М. Татар кульязма китабы. К., 2000.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**МӨРӘББӘГЪ** (гарәпчә квадрат, дүрткырлы мәгънәсендә), Шәрекъ классик поэзиясендәге лирик шигырьнең строфик формасы. Төзелеше б-н 7-9 юллык строфалардан тора, аааб вввб схемасы буенча рифмалаша. Гадәттә, һәр строфаның соңгы икеюллыгы бөтен М. өчен бер. Автор текстына бүтән автор юллары да кертелергә мөмкин. Татар поэзиясендә М. кин тарала таба; аның үрнәкләре Габдессәлам, Д.Юлтый, Г.Камал әсәрләрендә очрый.

Әд.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**МӨСӘГЫЙТЬ (Мөсәгыйтов) Фатих Шәриф улы** (14.9.1904, Оренбург ш. – 1990, Казан), әдәби тәнкыйтьче. «Хөсәения» мәдрәсәсендә (1916) укый, Халык белеме татар ин-тын (Оренбург, 1923), Татар коммунистик ун-тын (Казан, 1928) тәмамлый. «Кызыл яшьләр», «Кызыл Татарстан» г-та редакцияләрендә эшли. 1920-30 еллардагы әдәби процесска багышланган, вульгар социологизм һәм сыйнфый көрәш б-н сугарылган мәкаләләр авторы.

**МӨСӘДДӘС** (гарәпчә: алтыюллык, алты кырлы, алты мәртәбә кабатлана торган), Шәрекъ классик поэзиясендәге фәлсәфә мәсьәләләрен, мәхәббәт темасын үстерүче лирик шигырьнең строфик формасы. Төзелеше б-н аааааа бббббa вввввa схемасы б-н рифмалашкан 4-10 алтыюллык строфадан тора. Строфаның ахыргы юлы бөтен шигырь өчен уртак. Соңгы строфада, гадәттә, псевдоним (тәхәллүс) кулланыла. Кайвакыт М. контаминация, нәзыйрә ысулы б-н языла. Бу очракта автор бүтән шагыйрь шигыренең (гадәттә, газәл) һәр бәйте алдыннан, аның үлчәмен, ритмын, төзелешен, идеясен саклап калып, үзенең 4 юлын өсти. Татар поэзиясендә М. фәкать строфик форма буларак кына очрый (Габдессәлам бине Ураи, Ш.Маннур һ.б. иҗатында).

Әд.: Краткая литературная энциклопедия. М., 1968. Т.5; Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**МӨХӘММӘДӘМИН Гомәр угылы** (18 йөзнең 2 нче яртысы), язучы, Казан губернасы Иске Кишет а. мәчете имам-хатибы. 1783 тә Гарәп иленең изге урыннарына сәяхәт кыла. Бу турыда шартлы исем астында чыккан танылган «Мөхәммәдәмин сәяхәтнамәсе» китабын язып калдыра. Алар «Ике хаҗиның рихләтнамәләре...» (1862) исемле җыентыкка кергән. М.нең әсәрләре исемнәре теркәлгән 4 кульязмасы сакланган (Казан һәм С.-Петербург архивлары һәм китапханәләрендә саклана).

Әд.: Алеева А.Х. Списки «Мөхәммәд-Әмин сәяхәтнамәсе» и живая народная речь в её языковой структуре // Истоки татарского литературного языка. К., 1988.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

Фәнис
Яруллин

# ХӘТЕР ТӨПЛӘРЕНДӘ УТЛЫ КҮМЕР

КӨНДӘЛЕКЛӘР

**1991**

**12 май.** Телефон эшләми һаман. Ай була инде, төзәтмиләр. Бөтен микрорайон телефонсыз утыра. Төнлә чирләп китсәң, «Скорый» чакыртырга да мөмкинлек юк. Кайдадыр кабель өзелгән ди. Өзек кабельне без эшләгәндә икенче көнне үк ялгый торган идек. Әгәр 2-3 көн төзәтелмәсә, ул зур ЧП булып санала иде. Хәзер гомумән җаваплылык бетте. Узган җәйне җылылык үткәрүче трубаларны ялгар өчен асфальтны 2-3 җирдән казып атканнар иде, шуларны һаман күммиләр. Машина белән кереп тә булмый өй янына. Юл булмагач, утырткан агачлар өстеннән йөри машиналар. Гөрләп үсеп килүче агачларны таптап бетерделәр инде. Бер начарлык икенчесен тудыра.

**10 июль.** Бу көн безнең өчен зур күңелсезлек алып килде. Бакчадан кайтып килгәндә машинабызны бер «КамАЗ» машинасы бәрдереп китте. Без кюветка очтык, кызулык белән каеннар арасына килеп бәрелеп туктадык. Ничектер Ходай саклады: үзебез исән калдык, машина көлчә булды. Безне бәргән «КамАЗ» туктап тормады, качты. Бу — кичке алтынчы яртылар иде. «КамАЗ» машинасы прицеплы, кызыл кирпеч төягән иде, номерын карарга өлгермәдек. Безнең тәгәрәгәнне күреп бер «Жигули» машинасы килеп туктады. Алар безне каеннар арасыннан этеп чыгарырга маташканнар иде, көчләре җитмәде, чөнки машинаның алгы подвескалары сынган, тәгәрмәчләре тәгәрәми. Руль борылмый, ишекләр ачылмый. Алар тагын бер машинаны туктатып, көч-хәл белән безнең машинаны агачлар арасыннан чыгардылар. Ишекләрне ачтык. Ул машиналар Зеленодолга баралар иде, алар ГАИга һәм «Ашыгыч ярдәм»гә хәбәр иткәннәр. Берәр сәгать чамасы үткәч, ГАИ һәм «Скорый» килеп җитте.

«Скорый»дан пеләш башлы бер врач безнең янга килеп карады да: «Сынган, яраланган җирләрегез юкмы?» — дип сорады. «Юк бугай», — дигәч, китә дә башладылар. Шунда мин аларга: «Мин йөри алмый торган инвалид, мине өйгә кайтарып куегыз, монда агачлар арасында ята алмыйм бит инде мин», — дидем. «Безнең машина инвалидлар ташыр өчен түгел, берәр попутный машина тотыгыз да кайтыгыз», — дип китеп бардылар. Хәтта пульсны да тотып карамадылар. Ә безнең хәлләр бик шәптән түгел иде анда. Мин ике тапкыр аңны югалта язып алдым. Йөрәк әллә нишләде. Нурсөянең дә хәле начар иде. Просто кызулык белән генә йөрде ул да. Ярый ГАИдан килгән сержант ярыйсы кеше булып чыкты. Юлда бер кранны туктатты, аннары бер грузовой машинаны туктатты. Безнең машинаның калдыгын йөк машинасына салдылар. Мине йөк машинасының кабинасына күтәреп керттеләр.

---

*Дәвамы. Башы 2011 елның 1нче санында.*

Ул машинаның шоферы әйбәт керәшен егете (Валерий) булып чыкты. Монда кайтаргач, тагын бер кран табып, машинаны төшереп гаражга кертеп куйдылар. Дүрт сәгатьләп вакыт үтте. Валерага шул мәшәкатьләре өчен көчләп кенә бер ярты аракы биреп җибәрдек, алмый маташты әле.

ГАИ безне бәргән машинаны эзләргә уйламый. «Аны табудан сезгә ни файда. Ул үзен аклар өчен әллә нинди дәлилләр һәм шаһитләр табачак, ә сезнең бер шаһитыгыз да юк», — ди. Шулай итеп, безне үзебез, үз теләгебез белән тәгәрәгән кебегрәк итеп акт язып куйган. Без дә аңа әллә нинди таләпләр куймадык. Исән калган сөенеч җиндеме, шоковый хәлдә булдыкмы — аптыраш.

Машинаны страховать иткән идек, страховка күпме чыгар. Дүшәмбе, ягъни 15ендә госстрахка килергә куштылар. Шундый-шундый хәлләр. Язмыш тагын безнең ныклыкны сынап карыйм дигәндер инде. Машинасы да ул кадәр жәл түгел, җәй көне беркая чыга алмый өйдә ятуым жәл. Җәй көне әз булса да көч туплап, ял итеп калына иде.

Нурсөя дә бик каты тетрәнү кичерде, ныклап чирләп китмәсә ярар иде дип торам.

Социаль тәэминат министр урынбасары Зөфәр Сәйфетдиновка авария хәлләрен аңлатып: «Миңа машинаны чиратсыз сатып алырга ярдәм итә алмассызмы?» — дигән идем: «Юк, мин андый рөхсәт бирә алмыйм», — диде.

Прокатка алып торырга да юк бит бездә машина. Хәерче илнең мескен бәндәләре без.

**17 июль.** Моннан 33 ел элек, ягъни 1958 елның 17 июлендә мин муенны сындырган идем. Июль ае миңа бәхетсезлекләр китерә торган ай булып чыкты.

12 июль көнне Татарстан Республикасының президенты Шәймиев исеменә хат язып җибәрдем. Хатта миңа чиратсыз гына «Жигули» яки «Москвич» сатып алырга мөмкинчелек бирә алмыйсызмы дип язган идем. Кичә Шәймиевкә шалтыратып караган идем, ул бүген килмәде диделәр. Ә минем хат аның канцеляриясенә кергән, канцелярия ул хатны укып хатлар бүлегенә тапшыра икән. Бу хәлләр ничә көннән һәм нинди нәтиҗә белән урап чыгар. Үз акчаңа машина сатып алу өчен дә шушы кадәр нервы бетерергә кирәк бит. Шәймиевнең ярдәмчесенә шалтыраткан идем, мөмкинлек юк, диде. Неужели, мин әйтәм, бөтен Татарстанга бер машина кайтмый инде. Машина бит минем өчен аяк та, саф һава да, иҗатым өчен яңа тәэсирләр дә бит дип сөйләп матaштым мин моңарга. Бер сүз эндәшмичә генә тыңлады. Хатың безгә килеп кергәч җавап бирербез, диде.

Машина белән бәрелүләрен Нурсөя бик авыр кичерде. Мин җебегән аркасында җәйнең кызу көннәрендә син өйдә ятасың, ди. Бәрелүдә Нурсөя гаепле түгел. Бездән алда бара торган КамАЗ 40-50ләр белән генә бара иде. Без аны узып китәр өчен поворот утын яндырып обгонга чыктык. Без обгонга чыгуга ул безне уздырмас өчен кинәт безнең якка чыга башлады, тизлеген дә зурайтты. Аның машинасы прицеплы озын машина. Без обгон ясап бетерә алмадык, ул безне сул як юлга кысты. Нурсөя хәзер бу машинадан артта калу өчен тормозга басты. Шулвакыт теге КамАЗ прицепы белән безнең уң якка китереп чәпәде. Без юлның сул ягындагы кюветка очтык. Анда эре каенлык иде, шулар арасына барып челпәрәмә килдек. Ярый әле каешларны бәйләп утырган идек, шул коткарды.

Хәзер Госстрах артыннан чаба инде Нурсөя. Анда ГАИдан акт сораганнар. Чәпәлгән машинабызның фотокарточкасы һәм эксперт заключениесе кирәк икән. «Азат хатын»га шалтыратып фотограф китерттем. Ул кичтән төшереп, иртәнгә карточкаларны китереп тә бирде. Кичә Госстрах инспекторы белән автосервис эксперты килеп, машинаны карап киттеләр. Күпме түләрләр, әлегә билгеле түгел. Хәзергә шундый нервы боза торган эшләр белән шөгыльләнәбез.

**19 июль.** Әйберләрнең бәяләре көннән-көн күтәрелә бара, кеше бәясе көнләп-сәгатьләп төшә. Кичә Шәймиевкә шалтыратып карадым, булмады. Минем хатны кемгә биргәннәр һәм нинди резолюция салынган икән дип хатлар бүлеге мөдире Ибниева Венерага шалтыраткан идем. Хатны һаман беркемгә дә бирмәгәннәр. «Шәймиевкә бирә алмыйбыз без аны, ул бөтен Татарстанга берәү генә», — ди. Мин аптырадым да калдым. Миңа йөзләрчә хатлар килә, җавап язам. Кайбер

көннәрне утызлап укучы килә — кабул итәм. Мин дә бит бөтен Татарстанга берәү. Президентны икенчене дә сайлап була, ә шагыйрь Фәнис Яруллинны икенчене сайлап куеп булмый бит. Аннары Шәймиевкә Татарстанның барлык гражданнары хат та язмый бит әле.

Көннән-көн үзеннең кадерсез икәненне ныграк аңлый барасың. Ә эшләгән кешенең кадерен белмәгән ил нишләп алга китә алсын ди ул?

Әгәр мин үз-үзем белән бер-бер хәл кылсам, кеше моны дөрес аңламаячак. Машинасын җәлләп шулай эшләгән диячәкләр. Ә бит мин андый эшкә барам икән, кешенең кадерсезлегенә протест йөзеннән эшләячәкмен моны. Мин урамга чыгып ачлык игълан итә алмыйм. Протестымны бары тик үлеп кенә белдерә алам. Ул очракта да әле минем протестым гаепле кешеләргә ишетелмәячәк. Чөнки зур начальствоны тигәнәктәй сарып алган вак чиновниклар үз хуҗаларының тынычлыгын бик каты саклыйлар. Армияне сугышып җиңәргә мөмкин, ә боларны җиңеп булмый. Боларның иреннәрендә елмаю, телләрендә агу. Югыйсә әнә шул хатлар бүлеге мөдире Венера мине яхшы беләм дигән була. Сезнең әсәрләрне укып елаганым бар, ди. Ай-һай, мондый кешеләр елый белә микән?

**27 июль.** Шәймиевкә язган хатка җавап юк әле. Венера Харисовна мина шалтыратып: «Хатыңны Верховный Совет председателе Фәрит Мөхәммәтшинга бирдем, ул резолюция салды», — диде. «Нәрсә дип язган резолюциясендә?» — дигән идем: «Изыскать возможности», — дигән, диде. Җавап хатында: «Машиналар бик әз кайту сәбәпле чиратсыз сата алмыйбыз», — дигәннәр. Үз акчана ике ел йөрүгә туктап кала торган «Жигули» яки «Москвич» ала алма инде. Ә мина килгән кешеләр: «Сезне хөкүмәт бөтен нәрсә белән тәэмин итеп торадыр инде», — диләр.

Машина эштән чыкканнан бирле Нурсөя бакчага электричка белән йөри. Бөтен нәрсәне күтәреп ташырга калды. Икешәр сумка белән кайтып керә мескен. Минем бакчага бара алмавыма да үзен гаепле санап, газапланып йөри...

Мин ашау-эчүдә дә, эштә дә бернинди режим сакламыйм диярлек. Режим бит ул үз теләгең белән үз иркенне кысу. Болай да кеше гомере буе төрле калыпларга кысылып яши. Зуррак әсәргә тотынсам гына һәркөн утырырга тырышам. Андый чакта шунсыз булмый. Алай да әле: «Их, бүген берәр кеше килсен иде дә, эшне ташлап торырга сәбәп чыксын иде», — дип куйгалаган көннәр була. Язу да туйдыра. Ләкин күңеленә Алла тарафыннан салынган сәләт бар икән, аны үз эчендә үтерү зур гөнаһ.

Менә әле үземнең «Шүрәленең авылда күргәннәре» дигән әкият нигезендә бер пьеса язарга дип күңелгә беркетеп куйдым. Гомуми планы да бар инде. Башлыйсы килми тора. Язган әсәрләрне басарга бер дә ашыкмыйлар, басылмагач, акча да юк. Нурсөягә мине караган өчен түләмиләр. Минем пенсия 51 сум иде, хәзер инфляция башлангач пенсия арта башлады. Ләкин әйберләрнең кыйммәтләнүе арткан акчаны гына түгел, тулаем кеременне «ашый» бара.

**18 сентябрь.** Беркөн радиодан Әхмәт Рәшитов шалтыраткан иде. Монда, студиягә артист Шәүкәт Биктимеров килгән иде, ди, синең яңа шигырьләренне укырга тели, давай, шигырьләр җибәр, ди. Озакка сузмый гына әзерләп җибәрдек. Шәүкәт Биктимеров элек тә минем шигырьләрдән бер ярты сәгатьлек тапшыру эшләгән иде инде. Әхмәткә, нишләп ул минем шигырьләрне укырга булган әле, дигән идем, синең шигырьләрең әйбәт бит, диде. Чын күңелдән әйтүе булгандырмы. Ну Биктимеровның минем шигырьләрне ошатуы хак.

Бу айда Резидә Әхтәмованың кульязма китабын укып чыктым. Булачак китабын нәшриятка тәкъдим итеп, сүз башы яздым. Аннары ул баланы телевидениегә, яшьләр тапшыруына тәкъдим иттем. Кайчанрак бирерләр. Анда редактор булып Хәйдәр эшли икән. Ул бер дә авырсынмыйча гына тапшыру эшләргә булды.

Бу айның 25ендә телевидениедән минем «Нәсел агачы» поэмасы буенча эшләнгән әдәби театр була, 25 минутлык, программада бар.

«Казан утлары»ның 9нчы санында «Коткарыгыз» дигән поэмам һәм Гөлзадә Сафиуллина турында очерк чыгып килә. Корректурасы килгән инде. Журналлар хәзер соңарып чыга. Әле август саны да килеп җитмәде. Эшләгән эшем кеше күзенә күренгәч, бәла-казалар онытылып тора.

**30 октябрь.** Поэма һәм очеркны укыгач та Ф.Гыйззәтулина һәм Г.Бәширов шалтыраттылар. Бик ошатканлыкларын әйттеләр.

Телевидение минем барлык әкиятләрне дә диярлек «Әлли-бәлли-бәү»дә биреп бара. Кайберләрендә авторын әйтми укыйлар, ә берсендә «бу әкиятне сезгә, балалар, Фәрит абыегыз Яруллин язган» дип укыдылар. Күп кеше мине шул Фәрит Яруллинның туганы дип уйлый.

Бу арада Резидә белән бик якынайдык әле. Берничә тапкыр бездә кунып та китте. Үзенең мәхәббәт тарихын сөйләде. Шул вакыйгаларга нигезләп, бәлки, берәр хикәя язып булыр дип торам. Резидәнең шигырьләрен «Соц.Татарстан»га тәкъдим иттем, кайчанрак бирерләр.

**23 декабрь.** Кичә Илгиз (бакча күршесе) шалтыратты. Бакча өйләренә кергәннәр. Сезнең ишекне каерып кергәннәр, диде. Шунда кадаклап кайткан булса да ярый иде бит инде. Мин барып кадаклый алмаганны белә ләбаса.

Тормышлар кыйммәтләнә бара. Базарда итнең килосы 50 сум. Өрекләр 40-45. Хәзер бер куртка алыр өчен бер китап чыгарырга кирәк...

**1992**

**15 апрель.** Бу ай минем өчен рәхимле булмакчы. 22сендә, Алла бирса, К.Тинчурин театрында «Сөембикә егет сайлый» дигән пьесамның премьерасы булырга тиеш. Музыкаль комедия инде бу. Музыкасын Фуат Әбүбәкеров язды. Режиссеры Илдар Хәйруллин. Болай, әйтүләренә караганда, әйбәт спектакль булырга тиеш. Үзем дә барырмын дип торам. Ләкин сырттагы яралар ачыла башлады. Перевязка ясарга рәтле май юк. Даруларның да бәясе коточкыч хәзер. Элекке 3 сум 50 тиенлек гөлҗимеш мае 156 сум булган.

Бу айда икенче шатлыгым — «Шүрәлене күр әле» дигән пьесам Культура министрлыгы уздырган конкурста 2нче урын алган. Әкият-пьесаларга узган ел конкурс игълан иткәннәр иде.

**25 апрель.** Менә, ниһаять, премьералар да булды. 22сендә үзебез дә бардык. Нindirәк хисләр кичергәнне дә әйтә алмыйм. Тамашачы бик әйбәт каршылады. Бик каты кул чабып утырдылар. Соныннан артистларга да, миңа да бик күп чәчәкләр бирделәр. Халык шыгрым иде. «Күптән безнең театрда мондый аншлаг булганы юк иде», — диделәр.

Премьерага бер көн кала бер курьез булып алды. Телефоннан Сөембикә Вәлиева шалтырата. Менә, ди, «Ватаным Татарстан» газетасында сезнең «Сөембикә егет сайлый» дигән пьесагыз куелачагын хәбәр иткәннәр. Сез беләсезме, Сөембикә бит ул тарихи шәхес. Ни өчен ул егет сайларга тиеш. Бүгеннән спектаклегезнең исемен алыштырыгыз, юкса мин сезнең белән «с позиции силы буду говорить», ди. Мин моның тарихи әсәр түгеллеген аңлатып карыйм. Юк, тыңларга да теләми. Мин әле, ди, концертлар куеп әллә каян яңа гына кайтып төштем, ди. Менә шунда бер Сөембикә дигән хатынны очраттым. Ул ике тапкыр иргә чыккан, өч баласы бар, ди. Менә аны да судка бирдем, ди. Ни өчен ул шундый исем йөртеп ике тапкыр кияүгә чыгарга җөрьәт иткән, ди!

**12 июль.** Быел июньнең 7сеннән июльнең 9ына кадәр авылда булдым. Баулыдагы «Алтынчәч» балалар бакчасына очрашырга алып бардылар. Анда «Сандугач» дип аталган татар балалары группасы бар. Менә шул балалар минем шигырьләрне сөйләделәр. Җырладылар, биеделәр. Үзебезнең Мәдәният йортында да кечкенә генә бер очрашу булды. Үзешчәннәр минем «Автомобиль»дән өзек куйдылар. Концерт күрсәттеләр. Быел безнең авылның фольклор ансамбле Россия беренчелегендәге ярышларда катнашып дипломнар алган. Шуларга дипломнар һәм значоклар тапшыру булды.

**18 июль.** Кичә бакчага барган идек. Бик каты чирләп кайттым. Температура 39,9 иде. 17 июль — ул минем егылган көн. Менә быел шул егылуга 34 ел булды. Бу елларның берсен икегә генә чутласаң да, 68 ел һәм шунарга егылганчы яшәп калган 20 елны кушсаң, минем организм ин кимендә 88 яшьлек була.

Базар экономикасына күчү үзен күрсәтә. Бөтен нәрсә кыйммәтләнә. Элек 16 тиен торган ипиләр — 4 сум. Элек 15 мең торган «Волга» машиналары — 1 миллион

300 мең. Суыткычлар элек (иң шәбе) — 400-500, хәзер 18 мең. Ә эш хакы алай йөз тапкыр артмый бит. Мисал өчен, Культура министрлыгы элек бер пьесага 2200 дән 4 меңгә кадәр түли иде, хәзер 10 мең сум түли. Елына бер пьеса да куйдыра алмавың мөмкин бит. Китап нәшриятында да шундый ук хәл: бер китап акчаң эшче халыкның бер айлык хезмәт хакына әйләнеп калды.

**1 сентябрь.** Бу ел безнең өчен бәхетле ел микән әллә дип уйлаган идем, тагын бер зур күңелсезлек килеп чыкты. 30 август көнне бакчадан кайтканда (Әхәт Гаффарны да утырткан идек) бер «Беларусь» тракторын узып киткәндә, без аның белән тигезләшкәч, бу кинәт кенә сул якка борыла башлады да, сул ягының алгы тәгәрмәче белән безнең уң якны изеп китте. Бер ун-унбиш метрлап баргач, без туктадык. Әхәт Гаффар төшеп трактор артыннан йөгерде. Трактор ат юлына төшеп сыпырды. Бернинди номеры юк. Борылганда борылыш утын да яндырмады, әз генә булса да әкренәймәде дә. Ә.Гаффар, әлбәттә, аны тота алмады. «Ул анда бер сазлыкка кереп китте», — дип килде. Шулай дигәч, без дә аны куа китмәдек. Икенче көнне Зеленодол ГАИсына бардык. Анда гариза яздырдылар, бер хезмәткәрләренә, Фәргать Галиуллин, кече сержант, бу «дело»ны тикшерергә куштылар. Аның белән трактор кереп киткән юлдан бардык. Анда бернинди сазлык юк икән. Бу юл «Әйшә» совхозына илтә икән. Тракторларын карап йөрдек. Ләкин безне бәргәне юк иде. Ул тракторларны каядыр яшерделәрме, әллә чынлап кая киткәнен белмәделәрме, һәрхәлдә, кая икәнен әйтмәделәр. Аннан «Васильево» тракторларын да тикшереп йөрдек. Анда бер шик тудырырдай тракторны әйттеләр. Как раз сабан сөреп йөргән. Безне бәргән трактор да артына өч төрәнле сабан таккан иде. Төсе дә яшел. Аннары шунсы бик шикле: ул тракторчы үзенең тракторы белән ашыгыч рәвештә (бер көндә) отпуск алып авылга кайтып киткән.

Көне буе бу тракторлар артыннан йөреп шул хәтле арыдым, үләм дип торам. ГАИның үз машинасы юк. Безнең машина белән йөрдек. Бер дә очы чыгарлык булмаса, ташларга кирәк булыр моны. 100 чакрым йөрдек, бензин өчен генә күпме кирәк. Ә машина күпме иләнә. Ә үзем җәфалану күпме?

Әлбәттә, без үзебез гаепле булдык. Әхәт «сазлыкка кереп китте» дигән сүзгә ышанып тракторның артыннан куа бармадык. Һич югы аның кереп киткән, яисә барып туктаган җирен күрер идек. Тракторын да ныклабрак караган булыр идек. Күрәчәк булгандыр дип тынычланырга кала инде. Нурсөя: «Нигә соң бу бәлаләр гел безгә генә килә?» — дип өзгәләнә. Башкаларга да киләдер инде, башкалар безгә килеп әйтмиләр. 18 ел ЧПсыз йөргән идек бит әле. Менә бу ике елда бәхетсезлек ныграк сагалый башлады шул. Хәзер бит төзәттерүләр дә коточкыч кыйбат.

**2 сентябрь.** Фәргать Галиуллин шалтыратты. Безне бәргән тракторны тапкан. «Әйшә» совхозыннан Харис Сәлахов дигән адәм икән. ГАИ кешесе белән совхозга киттек. Теге тракторчы юлга чыгып безне көтеп тора иде. «Гафу итегез инде», — дип, гаепле төстә каршы алды. ГАИ хезмәткәре: «Үзегез килешәсезме, әллә судлашасызмы?» — дигәч, мин: «Давай, 3 мең сумыңны бир дә, шуның белән расчет», — дидем. Теге бераз башын кашып торды да, каядыр китеп барды. Ярты сәгатьләп торгач, акчасын алып килеп бирде. Анда кешеләр: «Әз сорадың, күбрәк сорарга иде», — диделәр. Мин инде, машинаны күпмегә төзәтеп буласын да белмәгәч, тоттым да өч мең сорадым. Күп сорасаң, бирмәячәк иде ул аны. Эшне судка җибәрсәң, мәшәкате күп дип уйладым. Ә болай без аның белән дусларча аерылыштык. «Көз көне кишер алганда килегез, кишер биреп җибәрермен», — дип калды. Без дә ниндидер бер мораль канәгатьләнү кичердек. Машинаны ничек кенә ясасаң да элеккегә хәленә китереп булмый инде аны.

## 1993

**8 февраль.** 1993 елның җәе минем өчен вакыйгаларга бай булды. Июнь уртасында авылга кайткан идем, «Татнефть» берләшмәсенең генераль директоры Ринат Галиевләр килде. Миңа коляска, язу машинкасы, магнитофон бүләк иттеләр. Ә көз көне, дөресрәге, октябрьдә, шалтыраталар: сина «Жигули» бирәбез, килеп ал, диләр. Гомер буе Язучылар Союзында чиратта торып, Сабировларга, Шәймиевләргә язып үз хәләл акчама да ала алмаган машинаны болар почти бушлай бирделәр. Хәерле

булсын. Үз гомеремдә беркемнән дә бүләк алганым юк иде әле. Дөрес, ул миңа страховкалары, ГАИда теркәүләре, символически булса да түләп алулары белән 500 меңнәргә төште. Хәзерге бәя белән бусы хәер генә инде аның.

**1994**

**1 гыйнвар.** Яңа елга да чыктык. Бәйрәмне Нурсөя белән икәү генә каршыладык. Ул кич белән коймак пешерде. Мин бер рюмка салып, коймак белән чәй эчтек. Ашарга апельсиннар, алмалар бар иде. Узган ел кыйбатчылык булса да, кибетләрдә бөтен нәрсә булып торды. Әле бездә (Татарстанда) халыкның ачыкканы юк, минемчә. Хәер, ач кешеләр «мин ач» дип миңа килеп әйтми бит инде. Һәркем үзенә килгән бәлане үзе җиңәргә тырыша.

Кичә Гомәр абый Бәшировтан (без аның белән телефоннан еш кына сөйләшеп торабыз) көндәлек режимыгыз ничек сезнең дип сораган идем. Иртән 6да торам да чәйләр куеп эчәм. Һәм 8ләрдә яки 9нчы яртыларда язарга утырам, ди. 8дән 12гә хәтле яза икән. 12дән 1гә хәтле йоклап ала, аннары төшке аш. Төшке аштан соң кибетләргә чыгып сөт, ипи алулар. Өйгә кайтып береаз ял иткәннән соң 5нче яртылардан 6га хәтле тагын язу өстәленә кадаклану. Кичке 10да йокларга яту. 93 яшен тутырган кеше һәркөнне алты сәгать буе яза! Моның өчен рухи көч тә, физик көч тә кирәк бит. Быел ул роман тәгәлләп ята. Зур күләмле роман. Роман язу өчен хәтернең бик яхшы булуы да кирәк бит. Кайсы бүлектә геройларың нинди гамәл кылган. Нинди диалоглар әйтелгән. Барсын истә тотарга кирәк. Мин андый режим белән эшли алмас идем. Беренчедән, шигырьне режим белән язып булмый, икенчедән, моңа тазалык рөхсәт итми, өченчедән, үзем дә таркаурак кеше.

**3 март.** ...Бүген тагын бер яңалык әйттеләр: Марий Эл республикасы Бәрәңге районы Портанур авылы халык театры минем «Мәхәббәт янгыры» дигән пьесаны сәхнәләштергән. «Татарстан хәбәрләре»ндә эшләүче Мөнирә исемле кыз шул якларга барган булган, шул ишетеп кайткан. Моңа кадәр «Койрыксыз сандугач»ны Красноуфимск һәм Норлат халык театрлары куйган иде. Халык театрлары да минем әсәрләргә игътибар итә башлады.

**29 март.** Быел кыш салкын килде. Март ахырында да салкыннар ун градустан арта. Апрель җылы булыр төсле. Кинәт эретсә бөтен дөньяны су басачак инде. Март ахырында котырган бураннар аркасында Чаллы-Казан юлында автобуслар батып, берничәшәр тәүлек кар астында ятты, халыкны вертолет белән ташыдылар. Машиналарны тартып чыгарырга танклар җибәрелде. Россия радиосы бездәге бу афәттә 12 кеше үлде, 62 кеше яраланды дип хәбәр итте. Безнең газеталар бу хәбәрне кире кагып чыктылар. Үлү булды, ләкин карга батып түгел, ә юл транспорты һәлакәте нәтиҗәсендә, диделәр. Мин үзебезнекеләргә ныграк ышанам.

**10 май.** Соңгы вакытта Нурсөянең хәле дә бик шәптән түгел. Умыртка сөяге авырта дип зарлана. Мине көчкә күтәрә. Алай мине күтәрүдән зарланганы юк иде әле. Ана эш тә күп инде. Бакча, машина, мин һәм шулар өстенә барлык өй эшләре. Плюс һәр язган нәрсәне машинкада басу. Редакцияләргә, нәшриятларга илтү. Һәм, шулар да өстенә, һәр әсәрнең язмышы өчен миннән дә ныграк кайгыру. Инде хәзер картаябыз да. Ана да быел 55 яшь тула. Пенсияләре ничек булыр тагын. Ул хакта да борчыла. Эш акчада гына түгел, ул бит гомерлек постта. Ана көн дә, төн дә юк. Бәйрәмнәрне әйтмим дә инде. Бәйрәмнәрдә аңа берәм-сәрән килгән кунакларны сыйлау, кешеләр киткәч өй җыештырулар. Мондый режимда беркем эшли алмас иде. Нурсөя генә түзә, ул дөньяда бердәнбер.

**26 май.** Бу арада Саба районы укучылары иялəшеп китте әле. Менә быел Тимершык урта мәктәбеннән 16 укучы һәм ике укытучы килде. Минем берничә шигырьне сөйләделәр. «Иң гүзәл кеше икәнсез»не җырладылар. Бер-ике кызлары миңа багышлап шигырь дә язган. Аларны укыдылар. Кайчан яза башлавым, әти-әни, туганнарым турында сораштылар. Авыл күчтәнәчләре белән чәй эчәрсез дип үзләре салган ипи, сөт өсте һәм бер-ике чиләк бәрәңге алып килгәннәр. Алар киткәч, самавыр куеп күчтәнәчләре белән чәй эчтек. Бик тәмле булды. Каймак, бал һәм авыл ипие белән чәй эчкәч, Нурсөя: «Авылга кайткан кебек булды бу», — дип куйды. Безнең үзебезнең авылда да күчтәнәчкә кабарып пешкән авыл ипие

алып килү гадәте бар. Анын чүпрәсен үзебезнен әрәмәдә үскән колмактан ясыйлар. Исләре үк икенче инде. Бәрәнге дә бетеп килә иде, ярап куйды. Базарга чыгып йөрисе булмады. Шунсы кызык әле анын, Нурсөя базарга барырга дип тора иде, Гөлзадә Сафиуллина килү аркасында гына тоткарланып калган иде. Насыйп ризык теш сындырып керер диләр бит.

**2 июнь.** Иртәгә язучылар съезды. Миңа чакыру кәгазе җибәргәннәр. Тукай клубында була съезд дип. Баксан-күрсән, ул Актерлар йортында була икән...

Бу язманы кичә яза башлаган идем, кулның язмый торган көне булды. Кайбер көнне куллар әле болай, әле тегеләй сикерә.

Менә бүген **3 июнь.** Съездга барасыңмы дип ник бер язучы шалтыратсын!

**13 июнь.** Рәшит Әхмәтҗанов шалтыратты. Китабынны («Җан авазы»н) укып чыктым, элекке китапларыннан бер баш өстен, ди. Ну күп эшлисең инде, ди...

Бу китап минем үземә дә хәзергә ошый. Ләкин вакыт нәрсә күрсәтер бит әле. Монда көрәш, халык, милләт, ирек һ.б.лар турында шигырьләр күп. Шуңа Рәшиткә ошагандыр, бәлки. Ул бит үзе дә көрәш, азатлык, туган тел темаларына яза...

Шигърияттә, минемчә, чын яшәү мәгънәсе, тормышның ачылмаган катламнарына үтеп кереп, аны үз йөрәгең аша ачу, милләтнең бөеклеген күрсәтү кирәк.

Мине, мәсәлән, хәзер шундый бер уй туктаусыз тинтерәтә: Ходай кешене ни өчен яратты икән? Ашап-эчеп, кәеф-сафа корыр өчен генә түгелдер бит. Эшләр өчен генә дә түгел. Бәлки, гомер буе Аллаһы Тәгаләне зурлап, аңа дога кылып яшәргәдер? Алай дисәң, шундый бөек затка безнең догалар ни бирә? Башка әллә нинди гөнаһлы уйлар килә. Бәлки, төрле милләтләргә аеруы да кайсыгыз акыллырак, күрсәтегез диюедер?!

Гүзәл шалтыратты. Иртәгә Әлфия килә ди. Туймазы театрыннан. Безгә өстәл алган. Шуны Туймазыдан бирле өстерәп йөри бит әле. Бар әйбәт кешеләр. Үз машинасы булса тагын бер хәл: поезд белән килә бит. Иртәгә өстәлен күрербез инде.

**16 июнь.** Өченче көн Әлфия белән Гүзәл килде. Әлфия Туймазыдан бирле сервировочный өстәл алып килгән. Акча да алмады, бүләк итеп алып килдем ди.

**17 июнь.** Минем «Мәхәббәт янгыры»н Әгерже районы Аккужа Мәдәният йорты үзешчәннәре куйган. Премьерасы февральдә булган. Режиссеры Мөршидә Шабаева, шул Мәдәният йортының директоры. Баш рольне — Тәнзиләне үзе уйнаган. Бу хакта мәгълүматны «Шәһри Казан» газетасының 16 июнь санында «Хыял канатларында» дигән исем белән язып чыктылар. Менә бит! Үзешчәннәр куя. Ә ул бит водевиль. Аңа музыка кирәк, җырлаучы, биюче артистлар кирәк. Димәк, музыка язучысын да тапканнар.

**5 август.** Төптәнрәк уйлап карасаң, Рәсәйдә, Татарстанда авыр промышленностьтамы, башка тармактамы — нинди генә уңышларга ирешмик, ул урысныкы була, төп уйлап табучылары татар булган хәлдә дә. Без бары тик әдәбиятыбызны, сәнгатебезне дөнья югарылыгына күтәрсәк кенә чикләрне үтеп чыгып, татарлыгыбызны күрсәтә алабыз. Монда инде авторлыкны танымый булдыра алмыйлар. Татар хәтта космик корабльнең иң яңа моделен уйлап тапса да, әгәр ул корабльдә урыс утырып оча икән, бу Россиянең дөньяга танылуы була. Татар исемен анда ялгыш та атамаячаклар. Безнең республика җитәкчеләре моны аңламыйдыр дип уйламыйм. Ләкин Мәскәү йодрыгыннан куркып мәдәнияткә, сәнгатькә акчаның йодрыктан сытылып чыкканын гына бирәләр.

## 1995

**3 декабрь.** Ниһаять, иҗат кичәм дә әйбәт кенә узып китте. Опера театры шыгрым тулы иде. Хәтта балконнар да. «Опера театрының күптән мондый тамашачы күргәне юк иде», — диделәр...

## 1996

**5 февраль.** Көндәлеккә кул тимәгәнгә дә айдан артык вакыт үткән. Ә вакыйгалар шактый булып тора. Беренчедән, үзем һәрвакыт тәнкыйтьләгән экстрасенслардан, дөресрәге, бер экстрасенстан, үземне дәвалап каравын сорадым. Алсу Мансуровна. Белемле врач. Кардиология үзәгендә эшли. Сәүиягә операция ясаган хирург Якуб

Хәмзиевичның хатыны. Икенчедән, ул кайбер экстрасенслар кебек кул болгап зур клубларда кешеләрне интектереп йөрми. Точечный массаж, догалар һәм үзе генә белгән, хәзергә миңа әйтеп бетермәгән методлар кулланып дәвалый. Мин инде аңа эчәкләрне әйбәтрәк эшләтә алмассызмы дип кенә әйткән идем, ул исә бармакларны да йөртеп булырга тиеш ди. Хәзер 9 сеанс алдым инде. 40 сеанс кирәк булачак ди. Биш дога ятладым инде. Картайган көндә анысы да бик кирәк.

**16 февраль.** Кичә Сәүиягә[1] икенче операциясен ясадылар. Янында торырга апасы Дания килде. Хәле әлегә бик авыр.

**22 март.** Сәүиянең аягына яңадан операция ясатырга туры килде. Сөяге ялганып өлгергән. Ялганган аягын яңадан сындырдылар, 20 мартта.

**2 апрель.** Мин бүгенгесе көнгә 26 сеанс лечение алдым. Бавырны чистартырга су эчүләрнең чуты югалды. Кич белән һәркөн аякларга ипликатор бәйлибез, корсакны кысып буабыз — эч мускуллары ныгысын өчен. Тагын әллә ниләр эшлибез. Мине аякка бастырмакчы булып тотынган врач бик тырышса да, эшләр алга бармый.

**13 апрель.** Камал театрында үз спектаклемне карыйсым килә иде. Кичә, ниһаять, шул бәхетле мизгелләрне кичердем. «Әнә килә автомобиль» шаулап-гөрләп 3 ел рәттән барганнан соң Камал театрына минем пьесаларны кертмәскә тырышучылар табылды. Зур уныш та кайчак үргә әйбәт кенә менгәндә аяк астына таш булып ята ала икән.

Минзәлә театрына быел 60 ел. Шул уңайдан 10 көнгә Г.Камал театрына гастрольгә килгәннәр. Минем «Мәхәббәт янгыры»н да алып килгәннәр. Кичә шуны карап кайттык. Зал туп-тулы иде. Рәт араларына урындыклар куелган, алай да басып торучылар бар иде. Артистлар бик тә илһамланып уйнадылар. Тамашачы һәр унышлы детальне хуплап кул чабып утырды. Соныннан бөтен тамашачы басып 10 минутлап кул чабып торды.

Бу спектакль белән Түмән якларында бер ай гастрольдә йөреп кайтканнар. «Анда да шулай һәр спектакль аншлаг белән үтте», — диләр.

Камаллылар спектакльләргә тамашачы йөрми башлады дип зарланалар иде. Йөриләр икән бит. Гел бер автордан туйганга гына йөрмиләр. Никадәр әйбәт язмасын, әгәр театр гел бер-ике авторга гына юнәлеш тота икән, ул аның сүнә башлавына китерә. Режиссерлар нишләптер шуны аңламыйлар.

Соңгы вакытта төрле мәктәпләрдән һәм ВУЗлардан килүчеләр ешайды. Бер кыз минем иҗатны тикшереп диплом язган. Дипломын миңа укып күрсәтәсе килгән. Нурсөя безгә чәй эчерде дә базарга китте. Теге кыз укый-укый кызды: кофтасының төймәләрен ычкындырып җибәрде. Мин дә бер як белән озак ятып арыган идем. «Гафу итегез, сез бер-ике минутка теге якка чыгып торсагыз, мин борылып ятар идем», — дидем. Ул: «Рөхсәт итсәгез, үзем борып яткырам», — диде һәм минем өсне ачып ташлады. «Ята-ята тәннәрегез оеп беткәндер, бераз массаж ясыйммы?» — дип, минем рөхсәтне дә көтмичә миңа массаж ясый башлады. Комачаулап торучы киемнәрне салдырды. Куллары йомшак һәм йөгерек иде. Ул кайбер нокталарга озаграк туктап, тәнем кызарганчы массажлады. Бу эштә тәҗрибәсе бар иде, күрәсең, кызның кулыннан тәнгә рәхәтлек йөгерде.

**16 май.** Кичә үзебезнең колхоз председателе Айдар Гафуров килде. Хатыны белән. Китапка спонсорлык итәргә уйлый. Балалар өчен шигырьләр, әкиятләр, поэмаларны туплап 12 табаклык кульязма әзерләп куйган идем. Айдар 20 миллионлык «Ак барс» чегы алып килгән. Нәшриятта Харрас Әюпов белән сөйләшкән идем. Бер табак шигырь 5 миллионга төшә дигән иде. Хәзер, договор төзи башлагач, мин ялгыш әйткәнмен икән, бу узган ел бәяләре шулай булган, хәзер 12 табаклык китап чыгару өчен 80 миллион кирәк, ди.

Туймазы театры быелтыр куйган «Язмышларны кабат язып булмый» әсәрен видеотасмага төшереп җибәргән иде, шуны карадык. Әйбәт куйганнар, бик фантазияле режиссер икән. Күздән яшьләр килде. Үзең язган әйберне үзең елап кара инде. Картайган саен күңел нечкәрә бара, ахры. Туймазы театры бу спектакль белән Бөтенроссия театрлары конкурсында катнашып икенче урынны алды.

**26 май.** Бу атна-ун көндә һава салкын тора. Төннәрен — 4ләр.

Алсу Мансуровнаның 18 апрельдән бирле килгәне юк. 27 сеанс үткәргән идек,

[1] Сәүия — Нурсөянең сеңлесенең кызы, шагыйрьне бик нык тәрбияләшкән кеше. Ред.

ләкин файдасы булмады. Ә ул да, мин дә күпме интектек.

23е көнне аларга кунакка бардык. Кызлары бик сөйкемле. Догалар беләләр, намаз укыйлар. Миләүшәсе быел университетны бетерә. Лилиясе мединститутның икенче курсын, Ләйсән гимназиянең 7 классын тәмамлый.

**29 май.** Бөгелмәдән Зөфәр шалтыратты. Бу төндә Һәнүзә сеңлем үлгән. Безнең — алты баланың төпчеге. 1942 елгы. Әткәй фронтка киткәч туган бала. Әҗәл безнекеләрне түбәннән чүпли башлады. Йөрәгенә, үпкәсенә операция ясатып интеккән иде бичара. Балаларының да рәте булмады. Рушанияләре урыска чыгып, аерылып, тагын кушылып йөрде. Маратлары маржага өйләнде. Төпчекләре Сиринә нинди булыр инде. Хәзергә медицина училищесында укып йөри. Аның да йөрәге таза түгел бугай.

**4 июнь.** Тышкы баскычлардан төшәр өчен пандус ясадылар. Безнең Яңа Савин районы администрациясе башлыгы Виктор Бударин бик шәп кеше. Былтыр бер сөйләшкәндә: «Яз көне монда пандус ясатырсыз әле», — дигән идем, шуны онытмаган. Кешеләрен җибәргән. Башта тәп-ләп кенә эшләп китгәннәр иде. Бударинга шалтыратып, начар эшләүләрен әйткәч, трест начальнигы Новицкийны җибәргән. Материал юк дип йөриләр иде, материалын да таптылар, эшләделәр дә. Төшәргә бик җайлы. Юкса төшкәндә бер, менгәндә икенче тапкыр кем ярдәм итешер икән дип көтеп тора идек. Хәзер Нурсөя выжлатып кына алып менеп китә. Ләкин кешеләр моңа каршылык күрсәтеп маташтылар, ясатмаска теләделәр. Хәзер үзләренә үк җайлы: балалар коляскасы белән менсәң дә әйбәт, арба тартып дачадан кайтучы да, аягын көчкә өстерәп йөрүче карт-коры да шуннан йөри. Тик аскы этаждагы хатын гына: «Барыбер сүттереп ыргытам мин аны, балкон төбенә үк китереп куйдыгыз», — дип шаулап йөри. Ә үзләре балкон төпләренә баз казып куйдылар, без берни дә әйтмәдек. Һәркем өенең нигезенә баз казый башласа, өен аварга да күп сорамас. Болай да саз өстендә утырабыз.

**10 июнь.** Башкортстанның Илеш районыннан бер автобус укучы-шәкертләр килде. Мәчеткә йөрүче балалар. Имам хатиплары Рәшит мулла. Мәктәп балалары укулардан тыш мәчеткә йөреп догалар өйрәнә, гарәп язуын үзләштерәләр икән. Монда Казан мәчетләре һәм мәдрәсәләре белән танышырга килгәннәр. Муллалары минем әсәрләрне яратып укый икән. Минем ике томны алган булган. Өченче томны биреп җибәрдем.

**13 июнь.** Бүген төнлә әни вафат булган. Күңелем сизгәндәй, кичә авылга да, Чаллыга да, Бөгелмәгә дә шалтыратып, әнинең хәлен сорашкан идем. Бик авыр, менә-менә өзелер дип торабыз дигәннәр иде. Кайтырга үзебез генә юлга чыга алмыйбыз. Килеп алучы таба алмадым. Өчесен, җидесен уздырырга кайтып, хәерләр биреп, кабере өстенә чардуган кордырып килеп булса иде дип торам. Үземнең дә хәл мөшкел. Анда кайткач кем карар? Нурсөя белән дә кайтып булмый. Сәүияне шушы көннәрдә больницадан чыгарырга тиешләр. Сәүия дә үзе генә киенә дә алмый. Һәнүзә үлгәнгә ике атна дигәндә әни китеп барды. Урыннары оҗмахта булсын. Әни мескен безне, алты баланы, нинди авыр елларда ач-ялангач итмичә тырышып-тырмашып дөнья көтте. 89 яшендә китеп барды. Соңгы ике елы бик авыр булды. Сукырайды, хәтере бетте. Бер ападан икенчесенә йөрде. Бер ай берсе, икенче ай икенчесе карады. Кулдан кулга йөрү таза кеше өчен дә бик авыр хәл. Һәркемгә яраклашырга кирәк.

Заманында безнең әни Димтамак авылының иң бай кешесе Галимнең яраткан төпчеге булган. Галим бабайның таш кибете, түбәсе яшел калай белән ябылган ике катлы ике йорты, ат көтүе, хезмәтчеләре булган. Егерменче елларда аның өен һәм барлык байлыгын алып өеннән куып чыгарганнар. Галим бабай кеше мунчасында үлгән. Әни безгә бу турыда сөйләргә яратмый иде.

Ә әтиләр уртача муллыкта яшәгән. Ярулла бабай бик тырыш. Үзе ташларны яраткангамы, бөтен нәрсә гомерлек булсын дипме ихаталарын таш койма белән әйләндереп алган. Йортның да аскы катын таштан, өске катын агачтан салган. Без Ярулла бабайның шул йортында яшәдек. Кыш көннәрендә аскы, ә җәй көннәрендә өске катка менеп яши идек. Мин Ярулла бабайны хәтерләмим. Әти 1942 елда сугышта үлгәч, әкрен-әкрен өебез таркала башлады. Утын юклыктан өйләрнең

почмаклары юешләнә иде. Бер мәлне өске өйнең түшәмнәре чери башлады. Һәм әни өстәге агач өйне сугыш вакытында сыерын сатып аска төшертте. Биек өйгә утын күп кирәк була дип астагы ниргәләрне алдырып ташлатты.

**3 сентябрь.** 1 сентябрьдән Сәүия пединститутка укырга йөри башлады. Әле ул ике култык таягы белән көчкә-көчкә йөри. Кичә студент билетлары тапшыру булган.

**11 сентябрь.** Бүген төшемдә гел әни белән саташтым. Болай озак итеп төшкә кергәне юк иде әле.

Төшләр — серле нәрсә. Төштә безнең кылган һәм кылырга тиешле булып та кылынмый калган гамәлләр; гомер юлында күрәчәк мәшәкать, шатлык-кайгыларын; дөньяны яраткан Бөек Затның безне нәрсәләрдәндер тыелырга кушып кисәтүе; безнең аң төбендә ятып та көндезләрен дөнья мәшәкатьләре астында калып уяна, өскә калка алмаган фикерләребез... Кыскасы, ничек кенә булмасын, төшләрдә безнең реаль чынбарлыгыбызның күпмедер чагылышы бар дип уйлыйм. Ләкин төшләр турында бу әле минем соңгы фикерем түгел.

**5 октябрь.** Минем бер генә китабым да җинел генә чыкмый. Хәтта спонсор ярдәме белән чыкканы да. «Яз гөлләре» дигән балалар өчен әзерләнгән шигырь китабын 14 майда Татарстан китап нәшриятына тапшырган һәм шул ук көнне 20 миллион акча түләп куйган идем, әле корректурасы да юк. Өч айда чыгарырга вәгъдә иткәннәр иде. Тоткарлык шунда: нәшриятның типографиягә 500 миллионнан артык бурычы бар икән. Хәзер типография нәшрият аша кергән һәр акчаны шул бурыч өчен тотып кала...

**1997**

**2 гыйнвар.** Бүген иртүк Әлмәттән Ринат Галиевләр шалтыратты. Яна ел белән котлап. Р.Галиев йөрәгенә операция ясатып чыккан булган икән. Бәйрәмнәр үткәч бер килеп чыгарбыз әле диделәр.

**26 февраль.** 23ендә Әхмәт Галиевләр мине туган көн белән котларга килделәр. Алар һәр елны шулай үзләре барлык сыйларын күтәреп 23ендә киләләр. Кайчандыр мин аларга әнинең язуы буенча туган көн 23е дип әйткән идем.Әхмәт абыйны эшеннән алсалар да, ул һаман элек якын иткән кешеләрен ташламый. Аны гына элекке «дуслары» ташлады. Элек һәр язучы, һәр артист үзенең юбилеена беренчеләрдән булып аларны чакыра иде, хәзер бар да аны онытты. Хәзер алар үзләре билет сатып алып андый юбилей кичәләренә йөриләр. Элек һәркем анардан сүз әйттерергә тырыша иде, хәзер сүз әйтергә теләсә дә ана «вакыт калмый». Кеше кешене түгел, анын урынын гына ярата шул.

**5 март.** 81нче мәктәптән укытучылар килде. «Чәчәкләр моңы» повесте буенча ачык дәрес уздыралар икән. Минем тавышны яздырдылар. Бу әсәрнең язылу тарихын сораштылар. Гомумән, бу соңгы вакытларда минем иҗат буенча дәресләр уздыру ешаеп китте.

**20 апрель.** Тормыш графигым тыгыз төзелгән. Иртән биштә торып бер чынаяк кофе белән юка гына киселгән бер телем ипигә май ягып 10 минут эчендә капкалап алам да эшкә тотынам. 1-2 сәгать эшләүгә эт булып арыйм һәм икенче иртәнге ашка тотынам. Монсында инде ашауны 40-45 минутларга сузам. Шул вакыт эчендә ял ителәә. Ә кайвакыт зур күләмле повестьлар язганда шундый нык арыта. Их, башка кайбер шагыйрьләр кебек шигырь генә язып ятасы иде дим. Күләмле әсәр язганда чын-чынлап шигырьгә сусау башлана. Зур әсәренне бер кат ерып чыккач, суына торсын, андагы геройлар сагындырсын дип ераккарак куеп торып шигърияткә тотынам. Перевязкалар ясау, үземне тәртиптә-чисталыкта тоту һәм кешеләр килү генә мине эштән бүлеп тора.

**15 май.** Балтачның Чапшар авылында яшәүче Вәгыйз белән без башта хат аша танышкан идек. 1972 елда аларга кунакка бардык. Балтачта халык бик кунакчыл. Һәр кеше кунакка чакыра. Без барганда Вәгыйзнен җингәсе Салисә авырлы иде. Без киткәндә: «Малай туса — Фәнис, кыз туса Нурсөя кушабыз», — дип калганнар иде. Кыз бала туган. Нурсөя кушканнар. Балтач Нурсөясе бик зиһенле бала булып чыкты. Мәктәпне алтын медальгә, институтны кызыл дипломга тәмамлады.

**7 октябрь.** Бүген ЧП булды бездә. Нурсөя кибеткә чыгып киткән иде. Ипи,

каймак, кефир алырга. Ачкычын югалткан. Ә электр плитәсендә аш калган. Дөрес, бик әкренгә куелган. Шулай да тора-тора ашның ите яна башлар дип мин милициягә шалтыраттым. Хәлне аңлатып бирдем. Бәлки, сездә отмычка ише нәрсә бардыр, дидем. «Юк, отмычка каракларда гына була ул», — диделәр. Алар белән сөйләшә торгач, «Служба спасения» дигән нәрсә барлыгы беленде. Аларга шалтыраттым. Аннан егерме минут эчендә килеп җиттеләр. Өстәге күршеләрнең балконыннан бау белән төшеп безнең балкон пыяласын һәм тәрәзәнең ике кат пыяласын алып эчкә керделәр. Иң беренче итеп ашны сүндерделәр. Аннары ишекне ачарга киттеләр. Ләкин безнең ишек йозагы ачкыч белән генә ачыла торган, өйдә ачкыч юк. Нурсөянең ачкычларын сумкасын ярып алганнар. Йозакны алып ишекне ачарга маташканнар иде, ача алмадылар. «Ишекне бераз ватмыйча булмый инде», — диде берсе. Мин ваттырмадым. Нурсөя тышта калды. Болар тәрәзә пыяласын аннан-моннан кадаклап чыгып киттеләр. Балкон тәрәзәсен дә кадакладылар. Нурсөя керә алмый. Өстәвенә һаман җылы бирмиләр. Тәрәзәләрнең пыялаларын да алгач, өй бик суынды. Күрше Әлфия апаларда да ачкыч бар иде барын, ләкин ул да өйдә юк. Хәзер менә ике тула. Дер-дер калтырап ятам.

Теге коткаручылар плитәдәге ашны сүндереп чыгып киткәч, деканатка шалтыратып Сәүияне чакырттым. Декан Мансур Зыятдинович аны чакырып бик тиз кайтарып җибәргән. Башта ук шулай иткән булсам, баш әйләндермичә генә бу хәлдән чыга идем. Без тормышта еш кына бик гади мәсьәләләрне катлаулы юл белән чишәргә маташабыз. Соңыннан аның гап-гади чишелеше барлыгын беләсең дә, үзеңнең аңгыралыгына аптырап каласың. Аннары икенче юл: коридордагы электр щитыннан электрны гына сүндерергә дә мөмкин иде. Соңрак мин моны әйтеп күршегә шалтыраткан идем, ләкин ул вакытта тәрәзәдән кереп киләләр иде инде. Ярый өйдә телефон бар. Ә телефон югында мин 3-4 тапкыр мондый хәлдә калып, үлә язган идем инде. Берсендә, Волгоград урамында яшәгәндә газ плитәсе өстендә пешерергә куелган аш калган. Нурсөя кибеткә чыгып киткән иде. Ә совет чорында һәр нәрсәгә чират. Нурсөя сөткәме, майгамы чират торып, вакыт үткәнен дә сизмәгән. Ул кайтып кергәндә өйдә төтен, мин идәндә ятам. Бөтен тән сыдырылып канга баткан. Мин күкрәгә белән амбразура каплаган батырдай ятам. Нурсөя кайтып керүгә мине күтәреп урынга салды да елап җибәрде. Икенчесендә үзем караваттан тәгәрәп төшеп, кухняга кадәр шуышып бардым. Ул чагында кырыйда озын таяк тора иде (телевизорның кнопкасын басып кабыза торган) шуның белән плитә өстендәге төтен чыгарып януы ашны бәреп төшергән идем. Беркемгә хәбәр итеп булмый, телефон юк. Телефон керттерә алмый 15 ел интектек. Әгәр мин шунда төтенгә тончыгып үлсәм, Нурсөяне гаепләрләр иде. Ярый әле ул чагында читтән торып телевизор кабыза торган пульт булмаган. Совет «пульты» — озын таяк үлемнән коткарып калды.

Йортларда инвалидлар өчен унайлыклар булмау әллә нинди «батырлыклар» эшләргә мәҗбүр итә.

**9 ноябрь.** Эшнең берсен бетереп өлгермисең, икенчеләре чиратка баса. Әле бит сызлаган йөрәк, авырткан бөер, гел канап торган яралар да бар. Аларны гел бәйләп, бөтен тәнне гел чистартып тормасаң эшләп булмый. Башта Нурсөя мине эшләрлек хәлгә килгәнче дәвалый. Шуннан соң мин тотынам. Йокламаган төннәр дә күп була.

**23 ноябрь.** Бераз шигырьләрне исәпләмәгәндә, язган нәрсә юк. Бу арада язасы да килми нигәдер. Кешеләр кебек әллә кайларга барып ял итәсе, тауларга менәсе, диңгезләрдә дельфиннарга атланып йөзәсе, урманнарның чәчәкле аланнарында балачактагы кебек чабасы, каләмне ташлап балтага тотынасы килә.

Балта эшен яратам мин. Ләкин корал һәм такталар гына юк иде. Шулай да алтынчы класста укыганда буровой тирәләрендә аунап яткан такталарны берәм-берәм ташып тавык кетәге ясап куйдым. Абзарның тәз лапасы юк иде. Ыкның аръягында чуерташ ташучылардан бер бүрәнә сорап алдым. Аның өчен әни аларга үзебезгә дә бик кадерле булган бер чиләк бәрәңгене пешереп бирде. Ә теге бүрәнәне тәз лапасның аркылысына куйдым. Өстенә әрәмәдән чыбык ташып, сыерлардан калган саламны түшәгәч, тәз лапас булды. Тәз лапас өстенә куыш ясап, җәй

көннәрендә эштән качып йоклап та алгалый идек. Тора-бара шуны аңладым: эшләгән саен эш арта икән. Бәрәңге бакчабызның озын ягы тыкрыкка чыга иде. Ә тыкрыкта көтүдән качкан кәҗәләр, чирәм чүпләүче казлар тулып ята. Тыкрык ягының читәне тузган. Көн саен Ык елгасын берничә кат йөзеп чыгып, әрәмәдән таллар кисеп, аны суда йөздереп алып чыгам да тыкрыкка читән үрәм. Бер җәй дигәндә 25 метрга сузылган бакчаны читәнле иттем. Юкса бердәнбер ризыгыбыз булган бәрәңгене маллар таптап, казлар йолкып бетерә иде.

**30 декабрь.** Быел шигырьләр шактый күп язылды. Юбилейга һәрбер журналга яна шигырьләрне җибәрдем һәм барсы да: «Шәп шигырьләр җибәргәнсең!» — диделәр. Ә бит без каләмдәшләребезгә мондый сүзне бик сирәк ычкындырабыз.

## 1998

**27 гыйнвар.** Иртәгә 2нче гимназиядә минем хикәяләр буенча ачык дәрес уздыралар. Барлык районнардан белемнәрен күтәрергә килгән укытучылар да шунда катнаша. Мине дә шунда алып барырга ниятлиләр. Кыш көне йөрүләре бик авыр, әлбәттә. Калын киенергә кирәк. Барырга ризалык бирдем инде.

Татарстанның барлык мәктәпләрендә «Иң яхшы хикәя язучы» дигән конкурс үткәргәннәр. Күпчелек тавышны мин җыйганмын. Шуңа белемнәрен күтәрергә килүче укытучыларны 2нче татар гимназиясенә җыеп, мине чакырганнар.

**10 февраль.** Кичә миңа 60 яшь тулды. Гади халык тарафыннан телефоннан шалтыратып котлаучылар да, килүчеләр дә күп булды. Көне буе телефон тынып тормады. Иртән радиодан да, телевизордан да котлаганнар. Үзебез ишетмәдек.

9ы көнне, ничек булгандыр, Язучылар союзыннан Ринат Мөхәммәдиев тә шалтыратты. Өйгә килеп котласам, артыкка китәр моның өчен дигәндер инде. Өйгә Әхмәт һәм Гөлчәчәк Галиевләр килде. «Татнефть»тән Рәфикъ Кәбирович, 22нче заводтан Өлфәт Хаҗиев килгән иде. Мәктәпләрдән, гимназияләрдән укытучылар, укучылар күп килде инде. Ярый әле укучыларым күп, иҗатымны яраталар.

**5 март.** Шөкер, юбилей әйбәт үтте. Камал театры халык белән шыгрым тулы иде. Минем иҗат кичәләрендә, юбилейларда буш урыннар булганы юк әле. 50 яшьлек юбилейны уздырганда Камал театрының иске бинасын халык ике-өч кат уратып алган иде. Ишек-тәрәзәләрне ватмасыннар өчен милиция дә килгән. Беренче бүлек беткәч, ишекләрне ачтылар. Түземлеге житеп сәгать ярым көтеп торучылар залга керә алды.

Ринат Галиев егет икән. Авырып яткан җиреннән килде.

**13 апрель.** Мәктәпләрдә рус балаларына татарча укытулар күпмегә барыр. Ансын инде Алла гына белә. Хәер, кайбер детальләрне язып үтсәм, ике теллелекнең нилектән бетә баруын чамалап булыр. Бу ике теллелек дигән нәрсә халык суверенлык таләп итеп демонстрацияләргә чыгып, депутатларны Республикага ирек таләп иткән халык коридоры аша гына үткәреп, аларга шундый таләпләр куеп кертә башлагач кына башланды. Барлык завод-фабрикаларга татар хәрефләре куелган «Ромашка» дигән язу машинкалары кайтартылды. Безнең күрше Тамара авиазаводта машинистка булып эшли иде. Нурсөя янына кереп татарча язарга өйрәнеп йөрде. «Исәнмесез» дип татарча исәнләшеп керә башлады. Кызлары Наташа өйгә бирелгән эшләрен эшләргә ярдәм сорап миңа керә иде. Элек ул миңа «дядя Фанис» дисә, хәзер «Фанис абый»га әйләндем. Чибәр Наташа ярыйсы гына татарча сөйләшә башлаган иде, ләкин Президентның татарчаны ун ел эчендә өйрәнергә дигән карары чыгу белән Тамара татар хәрефләре куелган язу машинкасын складка тапшырды, кызы Наташага мин янадан «дядя Фанис»ка әйләндем.

## 1999

**27 гыйнвар.** «Чәчәкләр моңы» повестендагы Минсылу апаны (чыны Минлегөл) Америкага җибәреп кайтардык. 2нче гимназия директоры Кәмария Зиннуровна да бик тырышты, кулдан килгәнне мин дә эшләдем. Миңлегөл апа ятимнәр йортында эшләгәндә тәрбияләнгән биш баланы Америкага уллыкка-кызлыкка алганнар иде. Ул шулар чакыруы буенча барды. Андагы тормышка, балаларга булган мөнәсәбәткә исе китеп кайткан. Ул сөйләгәннәрне көндәлеккә язып тормыйм. Повестьның икенче кисәге итеп язарга исәп. Хәзер шуны язарга хәзерлек эшләре алып барам.

Минлегөл апаның көндәлекләрен укыйм. Кайбер белешмәләр туплыйм.

**4 март.** 155нче мәктәптән 3нче класс укучылары килде. 26 укучы, 4 укытучы. Кызык, бик пөхтә балалар. Мәхәббәт турында да сораулар бирәләр. Укытучылары: «Кемнәрнең яраткан кызлары бар, кулларыгызны күтәрегез әле?» — дигән иде, малайларның шактые кулын күтәрде. Кызларга да шул ук сорауны бирде, кызлар кимрәк кул күтәрде... Минем шигырьләрне сөйләделәр. Җырларны җырладылар. Аннары икегә бүленеп чәй эчтеләр. Чөнки берьюлы аның кадәр кешене кая утыртасың? Пирогларын үзләре алып килгәннәр иде.

**19 июнь.** Кичә Кызылъяр мәктәбенең чыгарылыш кичәсенә бардык. Ике сәгатьтән артык утырып кайттык. Биш бала укып бетерде. Дүртесе егет, берсе кыз. Башта укытучылары тантаналы кичәне ачып җибәрде, аннары директорлары һәр баланы мәктәпне тәмамлавы һәм тормыш юлына аяк басуы белән котлап аттестатлар тапшырды. Беренче класска кергәндә болар тугыз бала булган, тора-бара бишкә калган. Алары да яңа килгән балалар өстәлү исәбенә генә. Берсе бөтенләй диярлек татарча белми. Ничек укып чыккандыр ул. Хәзер авылда Үзбәкстан, Казакъстан һәм башка яклардан кайткан кешеләр күп. Аларның балалары рәтләп татарча белми. Элек авыллар татар милләтен саклап торучы нигез иде, хәзер, киресенчә, телне ярлыландыручы, милләтне таркатучыга әверелеп бара.

**25 июнь.** 24ендә Камал театрына бардык. Анда быелгы сезонда «Сөембикә» соңгы кат уйналды.

Спектакльнең икенче пәрдәсе башлангач, пәрдә яна башлады. Ут лампа кызу аркасында чыккан. Мин икенче бер бүлмәдә диванда ятып тора идем. Пожарный машиналар чакырганнар. Ләкин алар килгәнче утны сүндереп өлгергәннәр. Унбиш минут тоткарланганнан соң, спектакль яңадан башланды. Ә пожарниклар директор ярдәмчесе Рушаниягә һәм тагын берәүгә (пожарник бугай театрның) 5 әр мең штраф салганнар.

Көне дә бик кызу иде — 32 градус. Пожарниклар нигә халыкны залдан чыгармадыгыз дип бәйләнгәннәр.

Халык тып-тыныч утырган. Күп кеше бу янгын спектакль буенча шулай булырга тиеш дип уйлаган. Янгын җайлы гына сүндерелгәч, спектакль әйбәт дәвам итте... Халык таралмады. Банкет та матур үтте. Банкетта Марсель Сәлимҗанов: «Безнең июньдә премьера чыгарганыбыз юк иде, чөнки җәй көне халык театрга бик йөрми. Ә безгә җәй көне дә халык йөри торган спектакль кирәк иде. Һәм без Фәнис Яруллинның шушы әсәренә тукталдык. Моның белән без ялгышмадык. Һәр спектакльдә халык шыгрым тулы», — диде. Бер ай эчендә сигез тапкыр уйналып, һәрберсендә тулы зал булуы артистларның да, театр җитәкчеләренең дә күнелен бик күтәргән. Моннан 25 ел элек, ягъни 1974 елда шушындый ук эссе июнь аенда «Әнә килә автомобиль»не куйганнар иде. Анда да халык агылып йөрде. Банкетта артистлар: «Безнең театр хәзер кризис кичерә.Гел бер автор әсәрләреннән халык туйды. Шуңа күрә театр элек куелган популяр әсәрләргә ташлана. Менә әле «Әни килде»не әзерлибез», — дип тордылар. «Әни килде»нең авторы Шәриф Хөсәенов рак белән чирле икән.Операция ясау да файдасыз дигәннәр. Ашказанын, бөтен эчен рак бизләре баскан ди. «Шушы премьераны күргәнче генә торырмын инде», — дип әйткән Марсель Сәлимҗановка.

**12 июль.** 7нче июльдә Шәриф Хөсәенов үлеп киткән. 30 июньдә премьерасы белән котлап мин ана шалтыраткан идем. Бик кәефсез сөйләште. «Премьера мина бернинди шатлык китермәде. Мин бетеп барам инде, — диде. — Син гомер буе чирләден, гомер буе яздың. Ә мин кинәт кенә чирләдем дә, беттем дә», — дип көрсенде. Мин аның авыруын белмәмешкә салышмадым. Киресенчә: «Мин сезне юатыр өчен түгел, ә премьерагыз белән котлар өчен шалтыраттым», — дидем. Ә ул: «Юаткан кешегә ачу килә минем, юата башласалар, сразы трубканы ташлыйм», — диде. Мин: «Барыбыз да финишка бер килеп житәбез инде, моннан котылып булмый», — дидем.

Бик күнелсез сөйләшү булды бу. Кайчандыр, без бакча төзеп кергән елны, ягъни 1975-76 елны, ул безнең бакчада шактый салып, кызып-кызып бәхәсләшкән идек. Мин аны өйләнмәве белән үртәгән идем. Ул төрле язучыларга язылган пародияләрен яттан сөйләп, мине шаккатырган иде. Ул пародияләре экспромтом гына уйланылгандырмы, язып куелгандырмы — әйтә алмыйм. Язып калдырылмаган булса бик кызганыч. Талантлы кеше иде, ләкин никтер бик әз язды.

## 2000

**20 апрель.** Җыелган газета-журналларны укып ятам. Быел 12 исемдәге газета-журнал алабыз. «Литературная газета», «АиФ», «Вечерняя Казань» һәм татарныкыларның барсын да диярлек.

**12 май.** Кичә Сабага бардык. Иртән 8 тулырга 20 минутта өйдән чыгып киткән идек, кичке 5ләрдә генә әйләнеп кайттык. Яшьләр үзәге дип йөртелгән ике катлы биналары бар икән, очрашуны шунда уздырдылар. Заллары 250 кеше сыйдырышлы. Тулы иде. Залга керә торган ишекләр артында да басып торучылар күп иде.

Бик әйбәт әзерләнгәннәр. «Җилкәннәр җилдә сынала»дан бер өзекне — Фәниярның армиягә китү өлешен сәхнәләштергәннәр. Өлкән класс укучылары гармуннар белән авыл урап, Фәүриянең Фәниярга кульяулык бирүләрен уйнаганда янадан армиягә киткәндәй булдым. «Ата тавык» дигән юмористик хикәяне бәләкәй балалар сәхнәләштереп күрсәтте. Халык яратып карады.

Без килгәндә сәхнәдә бер кечкенә генә өстәл тора иде. Мин: «Карале, бу өстәл янында Нурсөя белән икәү утырып ашарга шәп икән», — дип уйладым. Ул өстәлне чынлап та безгә бүләк итәр өчен Рөстәм Миннехановның атасы Нургали Миннеханов ясаткан икән. Ул, концертлар беткәч, калтырый-калтырый гына сәхнәгә менде һәм: «Менә бу өстәлне сиңа дип ясаттым. Элегрәк булса, үзем ясаган булыр идем, алыгыз, рәхәтен күрегез», — дип сәхнәдән төшеп китте. Халык котырып кул чапты.

**9 август.** «Сөембикә» журналында «Кулымдагы йөзегемнең исемнәре ...» дигән рубрикасына Нурсөя турында язуымны күптән сорыйлар. Һаман шуңа кул җитми. Иң якын кешеңне гел азакка калдыра киләсең икән ул. Якын кешең турында язу да авыр. Вакыйгалар күп, һәммәсе тормышта ни беләндер бәйле. Кыска материалга сыйдырып бетереп булмый.

**29 август.** Нурсөянең хәле әйбәтләнүгә бармый. Кан басымы бик уйный. Кыяфәте бер дә шәп түгел дип кайтты Әнисә. Аяклары зәп-зәңгәр ди. Уң кулы күптәннән авырта иде инде, хәзер әйбер дә тота алмый башлаган. Паралич сукмаса ярый ла. Әнисә дә 31еннән соң кайтып китәргә булыр дип йөри. Сәүия 1 сентябрьдән укый башлый. Медсестра мине карарга килергә җыенмый.

«Акчаң булса бөтен нәрсәне хәл итеп була», — диләр кайбер танышлар. Ә туалет эшләрен, юындыру, перевязка ясауларны әйтә башласаң, акчаң да, үзең дә кирәкми дип кача башлыйлар. Нурсөянең больницада икәнен белсәләр, телефоннан хәлне дә сорашмыйлар. Кеше буларак әйбәт кенә бәндәләр дә, авырганыңны белсәләр, кинәт кенә үзләре авырый башлый. Яки аның тиз арада эшләп бетерәсе эше була...

Язарга уйланган әйберләр дә язылмый. Нурсөянең кырыйда бөтерелеп йөрүе кирәк. Юкса мин аны язганда үз янымнан икенче якка чыгарып җибәрәм. Аның рухы кирәк икән барыбер.

**25 ноябрь.** 21 ноябрьдән «Казан» санаториенда ял итеп, дәваланып ятабыз.

Монда килгәч, Гакыйль Сәгыйревнең «Кабатланмас моң» дигән шигырьләр китабын укып чыктым һәм шуна рецензия яздым.

Гакыйль талантлы егет. Минем кебек бөтен нәрсәсе урын өстендә. Бик күп яза алмый. Шуңа тәки Казаннан фатир бирмәделәр. Союз председательләренең берсенә мин: «Гакыйльне Казанга китерергә иде бит», — дип мөрәҗәгать иткән идем. Ул: «Язучылар союзы инвалидлар йорты түгел, үзеннең монда килүенә сөен әле», — диде. Бу сүзләре аның мине кимсетергә теләве булгандыр инде. Мин аңа: «Син минем хәлдә булсаң, авызыңа бер кашык су да салучы булмас иде», — дидем. Ул шапылдатып трубкасын куйды. Сәламәт кеше бер дә чирләмәс, җитәкче дә булса — мәңге төшмәс кебек тоеладыр. Талантлы гына кешеләр дә еракка карый белмиләр. Җитәкчеләр кунаклаган чыбыкларыннан очып төшәләр, тазаларны — авыру ега. Бер егылгач, талантың булса да янадан аякка баса алмыйсың. Бездә система шундый.

*Ахыры бичы санда*

Зиннур
Мансуров

# ИЕЛГӘН БАШТА ТАҖ ТОРМАС

## II

• Изге Китапның кадерен белмәгән илне китап ятучы илгә санап булмый.

• Әдәбе чамалы кешедән яхшы әдип чыкмас.

• Бары бер генә китап мөхәррир кулы тиюгә мохтаж түгел: ул да булса — Коръән-Кәрим.

• Кайбер китапларның эчтәлегенә караганда, аларның азактагы искәрмәсе кызыклырак.

• Кайчак шагыйрьнең һавадан алып сөйләве күктән ингән вәхине ишеттерүгә бәрабәр.

• Кечкенә Апуш зуп-зур Тукайга әверелеп, коточкыч дәрәҗәдәге тәвәккәллек гамәлен кылган.

• Мантыйксыз юнан олуг шагыйрьләрне пәйгамбәргә тиңләгән чакта, ирләрне генә күздә тотып, олуг шагыйрәләрнең булуын ихтыярсыз шик астында калдырган.

• Парнас тавына шерплар ярдәмендә күтәрелергә маташучы шагыйрь-шогара да булгалый.

• Үзләре даһи булса да, сүзләре вәхи булмас.

• Салкынрак кыйтгада яшәүче халыкларның әдәбияты башкаларныкына караганда гамьлерәк булып тоела.

• Каләм әһеле үзенең әсәренә иң кирәкле сүзләрне гаувас-аквалангчыдай интегеп эзли, әмма дингез төбендә табылган кабырчыкларның да һәркайсында котелгән энҗе булмый.

• Хикмәтле сүзне үтә җентекләп эшкәртелгән кыйссага тиңлиләр икән, мәкальләрне күздә тотып әйткәндә, безнең халык бихисап кыйсса иҗат итүче булып чыгадыр.

• Ачыккан кеше икмәк кисәгенә үрелгән чакта хәтта Изге Китапка басарга рөхсәт ителгән кебек, шагыйрь Дәрдемәнднең югарыгы киштәдәге юка мәҗмугасын да кайбер күптомлыклар өстенә басып алырга мөмкиндер.

• Ирген җуйган каләм әдипнең авызлыгына әйләнә.

• Тел галимнәренең һәркайсына да тел-язу куәсе бирелмәгән.

*Ахыры. Башы 2нче санда.*

• Ялган тауарларны вакыйф[1] юк итә, ялган әсәрләрне вакыт юк итә.

• Әсәрдән суны сыгып чыгару алтын юу гамәленә бәрабәр.

• Алама тавышлы җырчының чыгыш ясавына караганда телсезнең ишарәт белән көйгә кушылуы тәэсирлерәк.

• Күңеленә ошаган китапны урлау себер китәрлек җинаять түгел.

• Укыганда йоклата торган китап язу да адәм баласы өчен үзенчә файда китерә.

• Мөтәтәнкыйтьче минем әсәрләрне сүгәргә азапланган очракта алардагы һәрбер җөмлә канатлы гыйбарәгә әвереләчәк.

• Кураның тамыры корган саен анын җыр-моны көчәя бара.

• Элгәрге шагыйрьләребезнең төп-төгәл санын белмәүгә артык гаҗәпләнмәскә кирәк — хәтта әле пәйгамбәрләребезнең дә ничә булуы билгеле түгел.

• Тәненнең гомерлек табибы бул, телennең гомерлек талибе бул.

• Актер халкы уйнаган рольләреннән чыга алмаган очракта безнең көндәлек тормыш беркадәр яхшырак булыр иде.

• Әгәр аерым мәшһүрләр белән эпохалар китеп барса, димәк, безләр һәрдаим нindидер вакыт бушлыгында торып кала.

• Һәркемнең үз күзаллавы: берәүләр шул ук мәһабәт арфада рояльнең эчкарынын, икенчеләр салават күперенә тарттырылган кояш нурларын күрә.

• Чынлыкта, һәрбер әдипне дә хәттат-каллиграф итеп санарга мөмкин, чөнки алар үз әсәрләрен күңел дәфтәреннән күчереп яза.

• Шундый өстәл китаплары да була, аларны таба астына куярга җайлы.

• Тәкъдир каләме язганның хакы төп-төгәл гомер бәясенә бәрабәр.

• Бала төшендә нинди телдә саташса, анарга шушы тел якынрак була.

• Үзләрен вәхи ирештерүчедәй тойган тәкәббер суфлерлар да булгалый.

• Ярым шәрә хәлдә алдырырга теләгән хатын-кызларга хиҗап кидерсән, алар сәләт дәрәҗәсе ягыннан бөтенләй тоныкланып калыр иде.

• Хәтта гали затлар да хатадан хали түгел.

• Кайберәүләр дөнья телләрендәге аерым сүзләрдә үзебезнең тамырны шулкадәр күрергә тели ки, алар хәтта каннибал кәлимәсен дә җинел генә татарга китереп бәйләргә мөмкин.

• Җырлаганда сакаулык онытыла.

• Матурлык бәйгесенең нәтиҗәләре бик шартлы, чөнки анда чын матурлар катнашмый.

• Күңел дәфтәрендә гарәп әлифбасында язарга күнеккәч, кисәктән генә кириллицага күчү шактый кыен.

• Әгәр Габдулла Тукай үз йортында гомер кичерсә, ул Иван Крылов рәвешлерәк шагыйрь булыр иде.

• Тирән мәгънәле чын-хак сүзләр артык уйлап тормыйча әйтелә.

• Язу осталыгы гына җитми, сызу осталыгы да кирәк.

• Кайбер «йолдызлар» сәхнәгә сихәтләнү өчен генә чыгадыр кебек тоела, чөнки җырлау сулыш юлының үпкәдәге тармакларын дәваларга ярдәм итә.

[1] Вакыйф — белгеч мәгънәсендә.

• Теге яки бу илнең дәүләт гимнын һәрбер халык үзенчә милли итеп башкара.

• Асылташка гади кыса килешүчән.

• Иманга соңлабрак килгәннәр арасында тәкъва булып кыланучы шундый затлар бар ки, гүя алар әле ана карынында чакта ук Коръән укып кына утырган.

• Гомер буе тунган Тукай мәңге күшегәчәк — дөньяның җылынуы кешелек өчен файдалы түгел.

• Сарыкны гелән кимсетмә: аның Коръән сүрәләре яза алырлык тиресе синең юк-бар сурәт төшерелгән тәнеңнән өстенрәк.

• «Кызыл китап»ның тулыландырылган басмалар җыелмасы кешелекне гаепләү томнарына әверелергә мөмкин.

• Соңгы могикан дип әйтү дөреслеккә бигүк туры килми, чөнки андый үзенчәлекле затлар һәрбер буында да була.

• «Син генә җитми иден», дип каршы алынган сабый еш кына халыкның газизанә мәшһүр заты булып үсә.

• Бу тормышта нәрсәнедер һәрвакыт истә тоту, нәрсәнедер оныту өчен дә зирәклек кирәк.

• Безнең музейлардагы мамонт теше пәйгамбәр чәченнән дә кадерлерәк.

• Әйтелмәгән сүз өчен үкенмиләр.

• Күңел киштәләрендә Һади Такташ шикелле шагыйрьләрнең китаплары сирәгәя барган саен, мәхкәмәләрдә «Һади Такташ» кебек оешкан җинаятьчел төркемнәрнең «эш-том»нары ишәя бара.

• Шәһвәтен тыя алмаган шөһрәт сынавына чыдамас.

• Төрле диварларга сызгаланган тегенди-мондый сүзләр шулкадәр эчне пошыра ки, бу язулардагы грамматик хаталарны кичекмәстән төзәтеп йөрисе килә башлый.

• Галәм гүзәлен билгеләгән чакта, хәттин ашкан инсанның олыдан кубуын күреп, бөтен җиһан куырылып куядыр.

• Ничек булып бетәр: кешедәге ат җенен машина җене, китап җенен компьютер җене кысрыклый.

• Пыяла өрүче: «Эчтән чыккан тының нинди уй-гамьнәр белән корылган булса, үзең күрергә теләгән бәллүр дә шундый рәвешне ала».

• Театр сәнгате әһелләре тамашачыдан бераз гына булса да, һич югы сәхнә биеклеге кадәр генә югарырак торырга тиеш.

• Безнең эстрада җырларын мәһабәт залларда түгел, ә җиңел автомобиль салоннарында тыңлау хәерлерәк.

• «Йолдызлар фабрикасы»н оештырырга Күкнең лицензиясе кирәк.

• Көйгә салынган мәгънәсез сүзләр җыелмасын ишетү икенче бер җырның кушымтасын искә төшерә: «Кому это надо — никому не надо; кому это нужно — никому не нужно».

• Сандугач сольфеджио үтмәсә дә, бик килешле итеп җырлый.

• Инде хәзер мәхлук көя күбәләкләре дә «Без Гоголь «Шинел»еннән чыктык», дип масаймакчы.

• Чын әдип һәрбер яңа әсәрен язганда үз-үзен тәмам яндырып бетерә төсле, әмма иҗат казанышы аша аңа өр-яңадан тернәкләнер өчен илаһи көч иңә.

• Гамәл дәфтәре җирлегендә языла торган булса, автобиографик әсәр нигезлерәк чыгар иде.

• Көлке көлә килер, артыннан куа килер, ә без анын саен алга ыргылырбыз.

• Начар рәсемнең кысасы яхшы булучан.

• Концерт алдыннан уен коралларын гына түгел, күңел кылларын да көйләү таләп ителә.

• Үзешчәнлек югары сәнгатьне таныр өчен яратылган.

• Классик җырларны башкарган «йолдыз»лар мине тавышлары белән түгел, ә элекке яхшы көйләрне искә төшерүләре белән хисләндерә.

• Үтә һаваланып киткән курай: «Синдә кул белән генә түгел, аяк белән дә уйнап була», дип органнан көлә ди.

• Күктәге йолдызлар җирдәге «йолдыз»лардан гарьләнеп атыла.

• Ярымшәрә кыяфәттә җырлаган хатын-кыз йөз-чәһрәсе белән хәтердә калмас.

• «Өч тиенлек» җырлар кайберәүләргә миллионнар китерә.

• Сәхнәдә кыз-хатын киемендә чыгыш ясаучы ир-атлар күбәя икән, димәк, инде тормышның үзендә дә хатыншалар мотлак арта бара.

• Хушавазлы оркестр чокырларының күбәюе халыкның биеккәрәк күтәрелүен күрсәтә.

• Гарештән әйләнеп кайта алган көй-моң илаһи музыка кебек кабул ителер.

• Әгәр җәмгыять Коръән буенча гына яшәсә, бәлки, башка китапларның кирәге дә калмас иде.

III

• Тәгәрмәч уйлап табучыларга караганда, тәгәрмәчкә таяк тыгучылар күпкә алданрак туган.

• Кайбер бәндәләр аналык чүбеннән гомер буена арына алмыйлар.

• Икейөзлелекне хиҗап астына яшерә алмассың.

• Күнелдә нөктә саклау низагка нокта куймас.

• Фәрештә канатына кул сөртеп кенә кара эшләрең ак итеп язылмас.

• Имансыз бәндәләрнең мәчет манараларын кисүе күктәге рәхмәт баскычларын кисүгә тиңдер.

• Үзенең нәсел шәҗәрәсен юньләп белмәгән кавем җиде бабаңны искә төшереп сүгенергә ярата.

• Бераз гына намусы булган бәндә мәчет манарасын кискән икән, ул ошбу манараны гомере буена җилкәсендә күтәреп барырга тиеш.

• Изгегә тарткан каләм гаепсезләрне чагар өчен кулланылганда тузбашның кара еланнан агу соравы гаҗәп түгел.

• Берсен-берсе күрә алмаган күзләр кылыйлаша башлый.

• Гыйффәт кадерен белми торган кызга ак яулык җилкән була алмас.

• Гомер озынлыгы безнең ихтыярда түгел, гомер киңлеге башлыча үзебездән тора.

• Тәнең тәгамнән тыелып торган чакта җан-рухың тансык азыгы белән туеныр.

• Кешенең иртән үк көйсезләнгән кәефе көннең хәерсез гамәлләрен йөзгә тапкырлый.

• Башның тышкы яктан түгел, эчтән зур булуы яхшы.

• Әфьюнчеләрнең кешелеккә китергән ин зур зыяны, киндер, мәк һәм шуның ише башка үсемлекләрне «Кызыл китап»ка керттереп, аларның бөтенләй юкка чыгуына сәбәпче булуындадыр.

• Кешеләрнең: «Ике куянны берьюлы ату», дип әйтүенә үч итеп, куян кавеме һәркайда гелән үрчергә генә омтылып яшидер.

• Бөтен жирдә дә үтә чисталык хөкем сөрсә, киләсе заман археологлары өчен бернинди табыш калмас.

• Әгәр минем фикер белән бик тиз килешсәләр, үземне алар алдында кызганыч итеп тоя башлыйм.

• Сынауга бәрабәр күтәрелү егылган урында башлана.

• Арканны мунчада фәрештә ышкыса да, аннан барыбер канат үсеп чыкмаячак.

• Һавалы булу оча торган шарга гына килешә.

• Бер үк елгада Иисусны ике тапкыр чукындырып булмый.

• Кешене шөһрәт тә, шәһвәт тә сыный.

• Мәхшәр көнендә атеистлар булмаячак.

• Ризыгың нинди — холкың шундый.

• Акселерат: «Ана карынында яралып яткан чакта мина олырак яшьтәге жан ингән».

• Без бит Аллаһка «Сез», дип мөрәжәгать итмибез ләса, ә нигә соң аның бәндәсенә «Сез», дип дәшәбез?

• Мәхәббәт хисе югалмый, тирәнгәрәк яшеренә генә.

• Үлеп ярату гомерне озайта.

• Жиде хатынга түзәрлек булсаң, аларның әниләренә дә чыдарга тиешсең.

• Саклый алсаң йөз аклыгын, ачык булыр зирәклегең.

• Романтик-мантыйкчы: «Бездә хәзер итәк астыннан эш йөртү кими төште, чөнки хатын-кыз өчен индерелгән итәк гамәлдән чыгып бара».

• Кара эчле бәндәләр кояш нурларын күбрәк «эчә».

• Авызына сыймаган телен каеш итеп теләрлек.

• Имансыз инсанның «Иманым камил», дип әйтергә хакы юктыр.

• Кәфенгә кесә текмиләр.

• Кәгазь житештерү барышында чыга торган яман ис әлләк язылган хатны укыганда янә аңкып куя.

• Кайбер адәмнәрне намусындагы тап түгел, затлы киемендәге тап күбрәк борчый.

• Гамәл дәфтәренә әлләк карасы йокмас.

• Индәге фәрештәләргә көндәшлек бирелмәгән.

• Учак та жырлый, пычак та жылый.

• Кайнар ризыкны өреп кабу гына авызны пешүдән саклый алмый, чөнки әлеге гайре табигый гадәт шәригать кагыйдәләренә туры килми.

• Җәннәт ишекләрен шапылдатып япмыйлар.

• Начар бәндәләр озаграк яшәүчән, чөнки дөньядан иртәрәк киткән яхшы затлар ахирәттә алар белән очрашуны бигүк теләми.

• Теге дөньяга лаеклы рәвештә барырга әзерләнү бу дөньядагы яшәү мәгънәсе түгелме икән?!

• Шушы тынгысыз җаныбыз аркасында тәнебез күпме кыен ашый.

• Уйнап башланган озын-озак гомер ахырында уйлап бетерә алмаслык гамьнәр җыела.

• Дөрес егылу ялгышка саналмый.

• Кочакка алу гамәле кайвакыт пычакка алу белән тәгәлләнә.

• Салам торхан җаны бал кортында кабатланмас.

• Хәрәкәтсез ятучы урын хастасы да Җир шарын кат-кат әйләнеп чыгар: кан йөреше белән...

• Хәсис бәндәнең эчендәге дегетне кашыклап карасаң, бихисап тәпәндәге балны пычратырга җитәр иде.

• Кабернең эше күп — ул бөкреләрне төзәтә.

• Җәннәт капкалары төбендә ачкыч ясаучылар утырмас.

• Арттагы күперләрне икеләнмичә яндырып баруыңа артык сөенмә, алдагы сират күперендә үзенне яну көтәргә мөмкин.

• Елан аягын кискән тәҗрибә әлләни ерак китә алмас.

• Тарак ыргытып кына урман үсеп чыкмас, көзге ыргытып кына күл пәйда булмас.

• Туган як былбыллары тәпи юган таңгы су юл аягы итеп эчәрлек әбелхәят суына тиңдер.

• Җәйге чилләдә ат тоягы эзеннән су эчмәгән бала туган җиренең бер яраттыру сихереннән гомерлеккә мәхрүм кала.

• Кешене яшәү түгел, ашау авыруга сабыштыра.

• Үренте ашарга гадәтләнсәң, торыннарың ач калыр.

• Орлыкның хәтере таркалса, тереклек хәтәргә тарыгыр.

• Ана карынында алган тәрбия аннан соңгысына караганда өстенрәк.

• Күк әниләрнең ялварулы теләген беренче нәүбәттә ишетеп ала.

• Ана карынында утыру тоткынлык мөддәтенә керми.

• Мактанчык: «Ана карынында тотып карагач ук мин үземнең башлы икәнемне белдем».

• Бала чакның таяк аты үсә төшкәч кыен ашата.

• Әгәр борын юеш булмый икән, димәк, ул үзенең вазифаи бурычын үтәми.

• Елмаюлы йөзләргә караганда елмаюлы күзләр ышанычлырак.

• Хатын-кыз битендәге мәхәббәт чокырында ничаклы ир-ат башын югалткан.

• Яраларны вакыт дәвалап бетергәч, беренче мәхәббәт тә онытыла.

• Кыз-хатынның бала төшерергә ниятләнүе, Ходаем, ялгыйның төшенә керә күрмәсен.

• Заманча көндәшлек тәҗрибәсен үзләштерү килендәшләргә әлләни кыенлык тудырмый.

• Җыештыручы: «Әйбәтрәк акчалы эш эзлим; власть коридорларын тәкъдим итмәскә...»

• Комнан бау ишкән шпагат ясый алмас.

• «Блин» сүзен ешрак кулланучы карап «белен» үзен горур итеп сизми.

• Су кушып сөйләүче судан коры чыга.

• Яна корабка бәреп ватылган шампан шәрабе кемнедер күнелсез мажарага тарудан саклап калыр.

• Акыл ияләре тормышны катлауландырып бетермәсен өчен җинел уйлап эш кылучылар да кирәк.

• Галәмне чүпли башлаган инсаният матурлык химаясеннән мәхрүм калачак.

• Башы йомры кавем шакмак карбыз үстерер.

• Сары матбугат басмаларын талымламый уку сине сары йортка кертергә мөмкин.

• Тормышта бәланең ялгызы гына килмәве кайвакыт балалы хатынга өйләнүне хәтерләтә.

• Көмәне беленеп торган хатын-кыз затына сез дип эндәшсәң дә урынлы.

• Чын гимнаст булып танылырга теләгәннәр күнегүләрне ана карынында ук башлый.

• Тома ятим баеса, туганнары тиз табылыр.

• Су корылмалары төзүче кайбер әһелләрнең кондызныкы кадәр дә акылы юк.

• «Сабыр төбе сары алтын», дисәң, байбичә аның пробасын сорар.

• Башның капкага туп кертүе житез аякка гарьлек китерер.

• Без юынгыч бүлмәсендә токтан суда хәтта филне коендырып булыр иде.

• Башың пеләш булса да, чәчне чәчкә бәйләргә мөмкин.

• Әгәр кеше шифоньер уйлап тапмаган булса, сөяркәләрне яшерү гадәте дә булмас иде.

• Үз-үзен кытыклаган кымырҗымас.

• Алтынлы сабыр төбе тирәнлекләренә төшәр булсаң, аннан чыгу өчен холык-фигылеңне үзгәртергә кирәк.

• Бәгъзе кешенең хәтта исемен хәтергә төшерү дә бик һәйбәт какырткыч дару сыман тәэсир итә.

• Шикаять: «Күршем канын тапшыра, әмма салым түләми».

• «Мин!» дип гайрәт оручы мөгезләрен сындырып салсаң, бер казанга ике тәкә башы да сыя.

• Шайтанның аяк-кулы богауланган айда азгын бәндәләр йөгәнсезлек күрсәтер.

• Мөселманнар яратмаган хайванга да Нух көймәсендә урын табылган.

• Галәм кояшы тотылу — кыска вакытлы күренеш, дөреслек кояшы тотылу — озакка сузылган фаҗига.

• Күккә ашып торган ярымай яшен кайтаргычка мохтаж түгел.

• «Алдан килгән — урын өчен», дип сөенгән, имеш, яңа зиратта беренче булып жирләнгән мәрхүм.

• Соңгы юлга сәфәрдәш кирәкми.

• Соңгы хөкем мәйданында «А судьи кто?» дип сораучы булмаячак.

• Оҗмахта ачык ишекләр көне үткәрелми.

• Кемдер ахирәттә җәннәтнең яхшырак катына эләгергә ымсына, кемдер сугышта югалткан аягына тиенү турында хыяллана.

• Инсанны химая итүче фәрештәләрнең асыл вазифасын бернинди дә тән сакчылары башкара алмый.

• Күзеңне йомып уйланган чакта эчтән киңәеп киткәндәй буласың.

• Гомер шәрабен насыйбынча эчте — кече теленә дә җитмәде.

• Таза ташпулат җиткерсән, җимерелеп беткәнче яшә.

• Халык тәкәллефсез рәвештә һәрдаим кочаклап сөя-сөя, үзенең якты талантларын каралтырга да мөмкин.

• Бөтен халык бәйрәмнәре вакытында күбәүләр ялгызакка әйләнеп кала.

• Елның үзенә дүрт фасыл да җитәдер, күңелгә исә бишенче фасыл да кирәк.

• Кысадагы алмаз үзен ирексез тойганга күрә, мондый кашлы йөзек монсу булып күренә.

• Әле яңа гына туган игезәкләр үзләрен иске карындашлар итеп тоя.

• Авылның бер исәре гомергә истә калучан.

• Ишегеңне тәбәнәк итеп ясасаң, имеш, өеңә баш иеп керерләр.

• Сай тәлинкәдән ашарга яратмаучы кешеләр яшәүнең тирән мәгънәсенә ирешә алмас.

• Кайвакыт мәгънәсез рәвештә шаяртуның аянычлы ахыры әтәч булып кычкырган тавыкның язмышын хәтерләтә.

• Әгәр Гиппократ исән-сау булса, ант бозарга гадәтләнеп киткән табибләр галәмен Аллаһ алдында вәгъдә бирергә чакырыр иде.

• Бакыр акча белән генә хаклык күзен яптырып булмый.

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кулъязма җибәргәндә түбәндәге документлар булу мәҗбүри:

1. Паспорт күчерелмәсе (титул, прописка бите).
2. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы күчерелмәсе.
3. ИНН күчерелмәсе.
4. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
5. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп).

# ШИГЪРИ ҖАНЛЫ ГАЛИМ

Әдәбият галиме, шагыйрь һәм публицист Нурмөхәммәт Хисамов, гомерен татар әдәбиятының тирән катламнарын өйрәнүгә багышлаган шигъри җанлы талантлы шәхес буларак, киң җәмәгатьчелеккә яхшы таныш. Аның күпсанлы монографияләре, әдәби әсәрләре, тәнкыйть һәм публицистик хезмәтләре фактик дәлиллеге, объективлыгы, заманчалыгы белән аерылып тора һәм алар, казаныш буларак кабул ителеп, үз вакытында ук җитди бәхәсләргә, яңа эзләнүләргә юнәлеш биреп килә. Филология фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, ТР Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге премиясе лауреаты Н.Хисамовның тормыш һәм иҗат юлы үз эшенә бирелгәнлек, намуслы хезмәт, халык язмышы өчен борчылып, җан атып яшәүнең үрнәге булып тора.



Нурмөхәммәт Шаһвәли улы Хисамов 1937 елның 24 мартында Татарстанның Чүпрәле районы Мунчәли авылында туып-үсә. Туган авылында җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Яшел Үзәндәге 5 нче һәм Чүпрәле мәктәпләрендә укып урта белем ала. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем алганнан соң (1955-1960 еллар), хезмәт юлын Чүпрәле районында чыгып килгән «Коммунар» газетасында бүлек мөдире буларак башлап җибәрә. Хезмәт тәҗрибәсе туплаган егетнең күңеле фәнгә тартыла һәм ул 1962-1965 елларда аспирантурада укый. Бераз вакыт Казан оптика-механика заводының «Җиңү байрагы» газетасының мөхәррире булып эшләгәннән соң, Н.Хисамов 1969 елда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына эшкә күчә һәм шуннан соңгы хезмәт юлы әлеге фәнни оешма белән бәйле: ул анда кече фәнни хезмәткәрдән институт директорына кадәр юл үтә. Хәзерге вакытта әлеге институтның директор урынбасары вазифаларын башкара.

Н.Хисамовның фәнни кызыксынулары киң һәм төрле булса да, ул урта гасырлар татар әдәбияты ядкарьләрен өйрәнүне, аларның әдәби-эстетик кыйммәтен, халыкның рухи тормышына йогынтысын ачуны үзенең төп тикшерену өлкәсе итеп ала. Урта гасырлар татар әдәбиятының гүзәл үрнәге булган «Кыйссаи Йосыф» һәм аның авторы Кол Гали сигез гасырдан артык халкыбызның рухи таянычы булып тора, шуңа да тикшеренүчеләрнең игътибарын даими җәлеп итә. Н.Хисамов әлеге әсәрне озак еллар дәвамында системалы өйрәнеп, әдәбият фәнен җитди казанышлар белән баета. Каләмдәше Т.Галиуллин язганча, «икенче мәхәббәтенә, юлдашына, күңел юанычына, шатлыгы-кайгысына әверелгән Кол Гали әсәренең әхлакый-фәлсәфи тирәнлегенә, рухи дөньясына үтеп керү юлларын эзли, ишарәкинаяләрдә татар халкына хас милли сыйфатларны күреп, шигъри энҗеләрне күтәреп ала». Н.Хисамовның 1970-1980 еллардагы эзләнүләре нәтиҗәсе буларак Мәскәүдә рус телендә «Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул Али» (1979) һәм Казанда татар телендә «Бөек язмышлы әсәр» (1984) исемле монографияләре дөнья күрә. Автор моңа кадәр гомуми планда гына күрсәтелеп килгән мәсьәләне — поэманың сюжет чыганакларын җентекләп барлый, шуларга нисбәтле Кол Галинең иҗади яңалыгын, табыш-үзенчәлекләрен ача.

Алдагы еллардагы эзләнүләре нәтиҗәсе буларак галимнең «Сюжет Йусуфа и

Зулейхи в тюрко-татарской поэзии XIII-XV вв. (Проблема версий)» (2001) хезмәте басылып чыга. «Кыйссаи Йосыф»ның төрки әдәбияттагы тәрдәшләре белән чагыштырылуы, поэма авторының сәнгати фикерләвен, мәңгелек кыйммәтләргә караш-мөнәсәбәтен тагы да тирәнрәк аңлауга җирлек тудыра.

Н.Хисамовның соңгы еллардагы тикшеренүләре «Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә» (2006) китабында чагылыш таба. Урта гасыр төрки шигърияте тарихчыларда, фәлсәфәчеләрдә, телчеләрдә зур кызыксыну уята. Шундый шартларда бөтен урта гасыр шигъриятенең яки аның тарихындагы озын бер дәвернең тулы панорамасын һәм логик контекстын бирерлек гомумиләштерүче хезмәтләргә ихтыяҗ булу аңлашыла. Йосыф һәм Зөләйха турындагы сюжет күпсанлы әдипләрне һәрвакыт үзенә җәлеп иткән һәм нәтиҗәдә төрки телләрдә дә берничә әсәр язылган. Н.Хисамов сюжетны төрләндерүнең бер тибын гәүдәләндерүче, тулы мәгънәсендә тәрдәш, ягъни версия тәшкил итүче әлеге дастаннарны чагыштырып өйрәнеп, төрки шигърият үсешендәге үзенчәлекләрне ачыклауга килә. Аерым алганда, урта гасыр төрки әдәбиятларда традицияләр дәвамчанлыгы һәм яңачалыклар бигрәк тә Йосыф сюжетын эшкәртүдә калку чагыла, дип билгели автор. Монографиядә тәрдәшләр ясалуның өч ысулы аерып чыгарыла: шигъри ысул, шигъри-структур ысул, шигъри ярыш ысулы. Аларның эчтәлек-асылы ачыклану, әдипләрнең нинди максатта әлеге ысулларның берсенә мөрәҗәгать итүен билгеләү дә хезмәт авторының бай фәнни-теоретик чыганаклар белән эш итүен, уңышлы гомумиләштерүләр ясавын, анализ һәм синтез алымнарына иркен мөрәҗәгать итүен күрсәтә. Ә инде төрки шигъриятгә йосыфнамә үсешенә бәйле тәрдәш ясаучы алты компонентның аерып чыгарылуы җитди яңалык булып кабул ителә. Алар түбәндәгеләр: 1) укмаштыру; 2) детальләштерү; 3) мотивлаштыру; 4) катлауландыру; 5) психологик баету; 6) метафоралаштыру. Хезмәтнең аерым бүлекләрендә чыганакларга һәм текст фактурасына, төп геройларга һәм идея-фәлсәфи проблематикага, шигъри тасвирлауга нисбәтле әлеге тәрдәш ясаучы компонентларның чагылыш үзенчәлеге, функциясе, гомумән, әһәмияте җентекле һәм күпсанлы мисаллар ярдәмендә ачыклана. Гомумән, Кол Гали, Шәййад Хәмзә, Сули Фәкыйһ, Әхмәди, Дүрбәк, Хәмдуллаһ Хәмди һ.б. төрки шагыйрьләрнең әсәрләре җентекле тикшерелеп, тәрдәшләрнең өч төре билгеләнә һәм Урта гасыр төрки шигъриятенең үзәк проблемасын хәл итүдә кулланылган тәрдәш ясаучы иң мөһим элементлар аерып чыгарыла. Әлеге тикшеренүләренә нигезләнеп, Н.Хисамов «Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасының бөтен эзлекле төрки йосыфнамәдә фундаменталь әһәмияткә ия» булуы турында нәтиҗә ясый. Шулай итеп, Н.Хисамовның әлеге монографиясе, фәнни нигезенең ныклыгы, чагыштырма анализ алымнарына, дөнья фәнендә бу өлкәгә караган ачыш-нәтиҗәләргә уңышлы таянуы белән зур кызыксыну уята һәм җитди казаныш буларак кабул ителә.

Н.Хисамов тикшеренүләре фәнни-теоретик нигезе, бай фактик материалы белән аерылып тора. Автор, татар әдәбиятының нигез чыганакларын барлау белән бергә, актив рәвештә Шәрекъ классикасына мөрәҗәгать итә, шулай ук күпсанлы тарихи, мәдәни ядкарьләрне әйләнешкә кертә. Аларда татар әдәбиятының үсеш-үзгәреше ислам дине идеологиясе белән тыгыз бәйләнештә карала һәм аңа Шәрекъ мөселман дөньясы, аерым алганда, гарәп, фарсы һәм төрек телендәге әдәбият йогынтысы ачыклана. Авторның игътибар үзәгендә халык яшәешенең чагылышы булган сүз сәнгатенең үз җирлегендәге яшәү шартлары һәм рухи байлыгы, тарихи вакыйгалар йогынтысында эчке закончалыкларына бәйле әдәби процесс буларак яшәве тора. Шуңа да Н.Хисамовның урта гасырлар әдәбиятына караган хезмәтләре тугандаш төрки һәм рус галимнәрендә дә зур кызыксыну тудырып, алар тарафыннан бик югары бәяләнә.

Күпсанлы тикшеренүчеләрнең тырышлыгы белән һәм Н.Хисамов мөхәррирлегендә дөнья күргән «Средневековая татарская литература (VIII-XVIII вв.)» китабы (1999) борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбиятының үсеш тенденцияләрен, аерым авторлар иҗатындагы табыш-яңачалыкларны чагылдырган, төрле чорлар сүз сәнгатен үзара тыгыз бәйләнештә, традицияләр дәвамчанлыгында бәяләгән җитди фәнни хезмәт булып тора. Н.Хисамовның әдәбият тарихының төрле чорларына,

аерым шәхесләренә, шулай ук үз дәвере татар шигъриятенә бәйле күпсанлы фәнни һәм тәнкыйди мәкаләләре, публицистик язмалары «Бәрәкәтле чишмәләр» (1987) һәм «Хәтер сагында» (2004) җыентыкларында урын ала. ХХ йөз башы татар шигърияте — галимнең даими игътибар үзәгендә торган мәсьәләләрнең берсе. Күпсанлы хезмәтләрендә ул әлеге дәвернең күренекле классиклары Г.Тукай, Дәрдемәнд, С.Рәмиев һ.б. иҗатының идея-эстетик һәм фәлсәфи-этик катламнарын ача, заман биеклегеннән торып бәяли, шәрехли, башка халыклар әдәбияты белән чагыштыра, традицияләр дәвамчанлыгы һәм яңачалыкларга мөнәсәбәтле тикшерә һәм шуның белән әдәбият тарихын яңача өйрәнүнең теоретик һәм методологик мәсьәләләренә ачыклык кертә, аларны баета, үстерә.

ХХ гасыр ахырында, җәмгыятьнең төрле өлкәләрендәге җитди үзгәрешләр йогынтысында, татар әдәбият белеме сүз сәнгате тарихын яңача өйрәнүнең фәнни-теоретик нигезләрен эзләү юлына чыга. Әлеге гаять җитди мәсьәләләргә беренчеләрдән булып мөрәҗәгать иткән галимнәр арасында Н.Хисамов та бар. Татар әдәбият фәне традицияләренә, тупланып килгән казанышларына таянган хәлдә, дөньякүләм әдәбият белемендәге яңалыкларга йөз белән борылу кирәклеген тирән аңлап, Н.Хисамов «Яңача фикерләү һәм татар әдәбияты тарихы концепциясе» дигән мәкалә белән чыгыш ясый. Әдәби мирасны яңартып өйрәнүнең магистраль юлын галим түбәндәгеләрдә күрә: беренчедән, «әдәби дәверләр күпкырлы идея-эстетик эзләнүләрдән торган, эзлекле, кануниятле һәм бердәм процесс рәвешендә яктыртылырга тиеш. Ул аерым күренеш һәм ядкарьләрнең бер-бер артлы тезелгән эзлекле гади хронологик чылбыры гына булмаска тиеш»; икенчедән, «әдәбият үсешен дөньяви һәм дини-рухани эчтәлекнең бердәмлеге рәвешендә тикшерергә кирәк»; өченчедән, әдәби күренешләрне объектив-тарихи бәяләү, ягъни «әдәбият тарихының борынгы катламнарын тикшергәндә аларны безнең заманга хас сыйфатлар тагудан, ә яңа чор әдәбиятын анализлаганда субъективлыктан һәм дәшми узудан качарга» тиешбез.

Күпгасырлык татар сүз сәнгатен эзлекле, бердәм күренеш буларак өйрәнеп, галим ХХ гасыр ахыры — XXI гасыр башы татар шигърияте белән дә тирәнтен кызыксына. Аның Х.Туфан, С.Хәким, Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Миңнуллин, З.Мансуров һ.б. турындагы мәкаләләре тәнкыйтьтә яңа сүз буларак кабул ителә һәм әдәби барышка уңай йогынты ясый.

Әдәби җәмәгатьчелек Н.Хисамовны шагыйрь һәм тәрҗемәче буларак та яхшы белә. Аның интим хисләрне чагылдырган яисә милләт гаме урын алган лирик һәм иҗтимагый яңгырашлы шигырьләре даими рәвештә вакытлы матбугатта чыгып килә. Ә инде Кол Гали поэмасының хәзерге татар теленә тәрҗемә-күчермәсе һәм үзе иҗат иткән «Йосыф-Зөләйха» драмасы Н.Хисамовның талантлы шәхес булуын тагын бер кат раслый.

Н.Хисамов бүген дә актив иҗатта. Татар әдәбиятының төрле дәверләренә хас әдәби-эстетик, әхлакый-фәлсәфи үзенчәлекләрен ачкан хезмәтләре, халык язмышы өчен тирәнтен борчылу белән сугарылган әдәби-тәнкыйди, публицистик язмалары киң катлау укучыларда гуманистик карашлар формалаштыруга һәм милләт гамен кайтыртып яшәүгә хезмәт итә. Замандашыбызның хезмәт нәтиҗәләре, иҗат уңышлары чын мәгънәсендә тирән хөрмәт һәм горурлык хисе уята.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ**

**Редакциядән:**
*Каләмдәшебез Нурмөхәммәт Хисамовка 2012 елның 24 мартында 75 яшь тулды, аны олы юбилее белән ихластан тәбрик итәбез, иҗат уңышлары теләп калабыз.*



*Балалар шагыйрәсе, журналист Йолдыз (Йолдыз Әдип кызы Шәрапова) 1962 елның 10 апрелендә Татарстанның Буа районы Яңа Тинчәле авылында укытучы гаиләсендә туа. 1984 елда Казан дәүләт университетының филология факультетын тәмамлый. «Ялкын» журналында, Биектау район газетасында эшли. 1986 елдан – «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасы хезмәткәре. Балалар өчен язылган алты китап авторы («Антенналы бәрәңге», «Зоопарк-әлифба», «Шигырьле чәй» һ. б.) 1995 елдан – Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Татарстан Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге әдәби премиясе, Республика журналистларының «Бәллүр каләм» бүләге иясе.*

*Шагыйрә бу айда үзенең юбилеен билгеләп уза. Әлеге бәйрәме белән без аны ихлас котлыйбыз, исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

# Йолдыз

## Ә ХАКЫЙКАТЬ ҺӘРЧАК КИРӘК БИТ УЛ

### Шагыйрь үлеменә

**Бүген кояш чыкмаска бит тиеш иде...**
**Ә ул чыкты.**
**Чыкты да безне күргәч,**
**Йөзен чытты.**
**«Нинди милләт соң сез,**
**Нинди халык?**
**Болай булса, тарих чоңгылында**
**Бетәсез бит тәмам югалып...»**
**Ни үкенеч, милләтемнең**
**Шагыйрьләрен саклый алмавы,**
**Гаҗәп түгел тагын берәр елдан**
**Хакыйкатьне күзгә бәреп әйтер**
**Кешеңнең дә инде калмавы...**
**Ә хакыйкать һәрчак кирәк бит ул**
**Уятырга гамьсез җаннарны.**
**Кирәк милләтемнең моны хәзер,**
**Соңга калмый бүген аңлавы.**

### Җан һәм Тән

**Әллә чын, әллә уйнап,**
**Баш әйтте: «Туйдым уйлап».**
**Күзем: «Туйдым елап», — ди.**
**Йөрәк: «Булмый чыдап», — ди.**
**Тел әйтә: «Туйдым, билләһи**
**Буш, ялган сүзләр сөйләп».**
**Колак әйтә: «Туйдым, чынлап**
**Ишетеп нахак, гайбәт».**

Аяк әйтте: «Юк артыннан
Һай, туйдым йөреп, чабып».
Беркөн гәүдәм баш күтәрде:
«Бу дөньядан туйдым, гарык
Рәхәтләнеп ял итәсем килә».
...Күңелнең иң төпкелендә
Бер аваз ишетелә.
Әллә елый, әллә көлә.
Җан икән, иңри мескенкәй:
— Минем яшисем килә!

## Таң алды

Төн. Дөнья — дөм караңгы
Күңелемне берәү какты,
Йокымнан уятты —
Илһам икән.
Хәл белергә килгән,
Икәү учак яктык,
Хисләр ташты, акты,
Очты чаткы.
Ул чаткыдан
Җиһанга ут капты.
Инде дөнья якты —
Таң атты!

***

Әбиләр чуагы.
Көзнең иң ямьле чагы,
Агачлар күлмәге — алтыннан.
Сөенми агачлар
Кышларга якын бит,
Көттермәс салкыннар.
Яз башы —
Тамчылар
Кар ашый.
Агачлар шәп-шәрә
Сөенеп башларын күтәрә.
Алда җәй бар әле көтәргә.

## Көз — илһамчы

Җылы якка китүләре —
Кыр казлары тезелгән.
Җәй үзе дә юлга чыккан
Шушы казлар эзеннән.
Иярергәме исәбе —
Сары яфрак өзелгән.
Каен-әни башын иган —
Аерылуны сизенгән.

## Елгалар һәм диңгезләр

— Агалар да агалар,
Кая бара елгалар?
— Дулкыннарын кага-кага,
Вакыт кебек ага-ага,
Диңгезгә бара алар.
— Ә диңгезләр ник акмый?
Шуңа һич җавап тапмыйм.
— Диңгезләрме? Алармы?
Әниләрдәй сабыр гына
Көтәләр елгаларны.

***

Казан. Кремль.
Яшерен гашыйк төсле
Кол Шәрифкә
Сөембикә тора карап.
Усал ата кебек зәңгәр чиркәү
Тәреләре белән
Тора бармак янап.

# КЫСАГА СЫЙМАС КАНАТ

*Синнән өркә көзгедәге чагылышың —*
*Канатларың кысаларга сыймый калган.*
Ләис Зөлкарнәй

Шагыйрьлекнең төп хикмәте нидә? Беренче шигырьләрендә үк игълан иткән мәсләгенә гомер дәвамында тугры калудыр ул, мөгаен. Тугрылык бер үк сүзне өзлексез кабатлап тору түгел. Еллар белән бергә шагыйрь дә үзгәрә, олпатлана, әверелешләр кичерә. Хәтта Ләис Зөлкарнәй кебек шактый еллар дәвамында матбугатта тавышы-тыны да ишетелмәскә мөмкин. Поэзия тарихында гайре табигый хәл түгел. Унтугыз яшендә шигырь язудан туктап, Гарәбстанга сәүдә эшенә киткән Артюр Рембоны искә төшерик. Хакыйкать шул — шагыйрьләр элекке була алмый! Кайчагында тынлык та шагыйрь иҗатында серле бер музыка булып яңгырарга мөмкин.



*Сулдан уңга: Л. Лерон, Л. Зөлкарнәй, Г. Морат, Р. Зәйдулла. 1986 ел.*

1979 елның июле. Без — университетка имтиханнар бирергә әзерләнеп йөргән ике үсмер — Кызыл Позиция урамында, ул вакыттагы каләм әһелләре өчен атаклы чал өянке төбендә танышкан идек. Атаклы — чөнки аны Роберт Әхмәтҗан «О, яшел генератор!» — дип эндәшеп шигырьгә әвереллдергән булган. Кайчандыр иң өске ботагына Равил Фәйзуллинның чөелгән кәпәче дә эләгеп калган дип сөйлиләр иде. Без Казанга килгәндә өянкедә кәпәч юк иде инде, әллә җил алып киткән, әллә берәр студент үзләштергән... Безнең өчен әле дә тарихи урыннар — студентларның бу шәһәрчегендә күпме яшь шагыйрь яшәп киткән, бөеклеккә имтихан тоткан...

Ләис Зөлкарнәйнең исеме миңа таныш иде — нәкъ бер ел элек «Яшь ленинчы» газитендә аның шигырьләр бәйләме дөнья күрде. Фотосурәте белән. Мәктәп укучыларын болай сирәк нәшер итәләр, моның өчен Зөлфәтнең дикъкатен җәлеп итү кирәк иде. Чыннан да, Ләис шигырьләре ихласлык белән дә, сурәтле фикерләве белән дә башкалардан аерылып тора. Болынны сәнәк очына элэктереп офык читенә аткан малай әле дә күз алдымда. Менә шул ук малай бәйгегә чыга:

*Учлап-учлап туфрак ата*
*Тояклар кыеп кына.*
*Тезгеннәр зыңлап тартылган,*
*Киләбез тыеп кына.*

Шәһәрдә ничә еллар гомер кичерсәк тә, без барыбер авыл малайлары булып калабыз, анда алган тәэсирләр, тойгылар беркайчан да югалмый. Күзнең төсе унса да, без дөньяга, табигатькә авыл малае булып карыйбыз, анынча гажәпләнәбез: «болын кебек сусыл болытларда сутлы сусән үсә, нәзек тары...» Шагыйрь шәһәр өстендәге болытны шулай күрә, аның да үзен тануына, күңелен сихәтләп китүенә өметләнә:

*Бу тарылар мине таный бугай.*
*Бу сусәннәр коча мине төреп.*
*Болыт түгел лә бу, болын бит бу —*
*Ык буеннан килгән күтәрелеп.*

Әлбәттә, шагыйрьнең баш өстендә күкләр дә бүтәнчә күкри, яшеннәр дә башкача яшьни: әйтерсең лә, «авылдашлар күктә печән чаба, ялт-йолт килә үткер чалгылары»...

Беренче китабын Ләис «Жилкәнле утрау» дип атарга теләгән иде. Нәшриятта бу исемне артык катлаулы, дәгъвалы дип исәпләделәрме, алмаштырдылар. Яшь-яшь егетнең китабы, — өстәвенә, андагы шигырьләрнең күбесе мәктәптә укыганда язылган, — ничек аталырга тиеш? Әлбәттә, «Балачак күге!» (Минем дә беренче җыентыгым «Давыл күләгәсе» урынына «Кояшлы күзләр» дип нәшер ителгән иде). Ләис «Кар өстендә алмалар» китабының беренче бүлеген барыбер «Жилкәнле утрау» дип атады. Әйе, аның утравы гади атау гына түгел, ул комга терәлгән караб булып күзаллана. Монда инде ничек Дәрдемәнднең атаклы шигырен искә төшермисең?! Яшь шагыйрь шулай ассоциатив рәвештә укучының уен Ватан язмышына китереп тоташтыра. Ул аның аянычлы язмышы өчен әрни:

*Борынгыдан, Болгардан ук килгән караб*
*Комга утырып калган мәллә утрау булып?*
*Өянкеләр давыл даулый,*
*Китсен өчен*
*Сәях атау*
*тоткынлыктан кубарылып.*

Дәрдемәнднең карабын упкыннар сагаласа, Ләиснеке бөтенләй тоткынлыкта икән ич! Аныкы гына түгел, безнеке... Торгынлык елларында үз язмышларыбызны нәкъ шулай кабул иттек тә. Безне нәрсә коткара ала иде соң? Комга терәлгән көймәбезне ни генә кузгата ала иде? Шигырь, әлбәттә! Яшь шагыйрь, ышанып, нәкъ менә аңа мөрәҗәгать итә:

*Синдә икән дәверләрне кичәр көчем.*
*Тормыш заман комнарына терәлгәндә,*
*Давыл даула*
*Кубарылып китәр өчен.*

Ул елларда без барыбыз да давыл теләдек.

Давыл купса, гасырлар дәвамында халкыбыз хыялланган ирек килер сыман иде. Ул сүз Ләиснең «Кояш оясы» әсәрен укыганда бертуктаусыз колакта сулкылдап тора. Батыршаның өзелгән теле кычкыра аны: «Киерелеп сукты тавыш — зинадан да иске зиндан бер таш аска китте иңеп — И-И-РЕК!» Әлеге әсәрендә шагыйрь Тел, Ил язмышыннан Жир язмышына (менә ни өчен «Кояш оясы!») күчә. Телеңне, илеңне югалтканда, барыбызга да уртак бу жир шарында бәхетле яшәп буламы? Шәҗәрә агачың корыганда, тоkымыңның гомерен санаучы Кәккүк тынып калганда, шагыйрь җанында нинди шигырьләр туа? Халкың комга терәлгән көймәдә, язмышына риза булып, җырлап-көлеп сабантуй (сабанның ни икәнен белмәгән килеш) үткәргәндә, шагыйрь җанында шигырьгә урын бармы? Әллә трюмга төшеп, юеш нуештә (почмакта) ул тын гына сулкылдарга тиешме?

Җанына дәваны шагыйрь үткәннәрдән таба. Үзәк Азия далаларына барып чыккач, аның күңелендә тагын өмет уяна:

*Дәште Кыпчак, бәлки, таныр безне —*
*Киләчәкне эзләп табу өчен*
*Узганнарга китә арба эзе.*

«Дүңгәләк»

Ничек инде монда Акмулла арбасын искә төшермисең? Милләтнең шагыйре берәү генә, ул тик тарих дулкыннарында төрле исемнәр белән калкып кына чыга. Тик... «Өркәч-өркәч калкулыклар монда — коммы күмгән кәрван дөяләрен?»

Бу урында шуны да әйтеп үтәргә кирәк: Ләис Зөлкарнәй шигырь төзелешенең ислахчысы, шәкел җәһәтеннән төрле алымнарны куллануччы шагыйрь. Ул мангайга бәреп әйтми, аның фикерләре катлаулы метафораларга (шигырь белгече метаметафоралар дип әйтер иде) төрелгән. Шуңа күрә аның әсәрләрен үз вакытында аңлап җиткермәүчеләр дә булды. Мансур Вәлиев, мәсәлән, аларга: «томанлы «мин» исеменнән сөйләүче, гомуми төстә генә сүз алып баручы шигырьләр», — дип бәя биргән иде. Янәсе, «Дүңгәләк» һәм «Тәңге бизмән» шигырьләре (боларның беренчесе шигырьләр циклы, икенчесе «әйтеш» формасында язылган — *Р.З.*) мәгънәви бушлык белән бигрәк тә аерылып тора».

Эпик киңлек белән иҗат ителгән, шигырь калыбында бәргәләнгән ихлас хистойгыларны өзлексез бер стихиягә әйләндергән әсәрләрне «мәгънәви бушлык»ка тиңләр өчен чыннан да чын тәнкыйтьче булырга кирәк, мөгаен. Әлбәттә, Ләис Зөлкарнәйне укыр өчен күпмедер әзерлек зарур. Ул еш кына дөнья мифологиясеннән файдалана, татар фольклорына мөрәҗәгать итә.

Шагыйрьнең «Түбәсез остаханә» шәлкеме дә туксанынчы еллар татар поэзиясендә үзенә лаек урын тота. Хатын-кызга мәхәббәтнең төрле әверелешләрен мондый поэтик югарылыкта сурәтләгән әсәрләр бездә сирәк. Әлеге шәлкемне хасил иткән биш шигырьне Ләис «цикл» дип атаса да, миңа калса, бу әсәр поэма жанрына да дәгъва итә ала. Гомумән, шагыйрь әсәрләрен «поэма» дип атаудан саклана, аларны йә цикл, йә әйтеш, йә мозаика дип исемли. Соңгы елларда кайберәүләр «поэма» дип озын шигырьләрне дә атый башлады. Бу җәһәттән Ләиснең жанрларны билгеләү мәсьәләсендә сак булуы шулай ук аның шигърият алдындагы җаваплылыгы турында сөйли.

Ләис Зөлкарнәй прозада да үзен сынап карады. «Кыргын», «Сафа», «Ком сәгате», «Ая» һәм башка хикәяләре аның әлеге жанрда да үзенчәлекле автор икәнлеген раслап тора. Болар гадәти хикәяләр түгел, болар — шагыйрь прозасы.

Әлбәттә, илле яше тулган елда шагыйрьнең барлык әсәрләрен туплаган китап нәшер ителсә әдәбият сөючеләр өчен бер вакыйга булыр иде.

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА**

## Итле колбаса

**Ирләр ничек көчле булсын? –**
**Колбаса итсезләнә,**
**Ә шуның нәтиҗәсендә**
**Хатыннар... ирсезләнә.**

## Бердәмлек

**Көн саен эчеп кайтасың.**
**Бу инде тагын ни эш?.. –**
**Әй, хатын, мин халкым белән**
**Бердәм булырга тиеш!**

## Юлым уңмады

**Бүлнискә еш йөри идем,**
**Ник язмыш йөри үртәп?!**
**Табиб юк!..**
**Йозак элгәннәр –**
**Депутат булган, мөртәт!**

## Эчкече тормышы

**100 граммнан соң – сөйләшә,**
**200 дән соң – көлә,**
**300 дән соң ул җырлый,**
**400 дән соң – күп белә.**
**500 дән соң ул бии,**
**600 дән – ызгыша.**
**700 дән – сүгенә,**
**800 дән – сугыша.**
**900 дән – ул елый,**
**Ә 1 литрдан – йоклый.**
**Үз нормасын ул белә –**
**Алтмышка җитми... үлә.**

***

**Бәйрәмнәр –**
**Мөбарәк,**
**Түрәләр –**
**Түгәрәк.**

**Ринат МӘННАН**

### БАЛАЛАРГА ОЛУГ БҮЛӘК

1 март көнне башкалабызда күптән көтелгән «Әкият» мәдәният үзәге ачылды. Тантанада ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, мәдәният министры Айрат Сибагатуллин катнашты.

«Без балалар ата-аналары белән бергә килә алырлык урын булсын дип күптәннән хыялландык. Монда балалар ял итеп кенә калмасын, үсеш тә кичерсен. Бу бинаның идеясе беренче Президент тарафыннан эшләнгән иде. Башкарып чыккан эшебез уйлаганнан да яхшырак булып чыкты. Балалар өчен бик яхшы сарай барлыкка килде. Без балаларыбыздан берни дә жәлләргә тиеш түгел. Бу — безнең балаларыбызга бүләк», — дип белдерде Рөстәм Нургали улы.

Бина әкияти сарай кебек төзелгән. Ул ак таш манаралар, үрелгән колонналар, декоратив бизәкләр белән баетылган. Тышкы яктан халык әкиятләрендәге скульптор композицияләр белән бизәлгән.

Бинаның беренче ташлары 2008 елда салына башлаган иде. «Әкият» мәдәният үзәге бинасының проект бәясе 1 млрд 300 миллион сумга төшкән. Аның мәйданы 21,7 мең квадрат метр. Шуның 7 мең квадрат метрын «Әкият» дәүләт курчак театры били. Калган урыннар балалар сәнгать, музыка мәктәпләренә һ.б.ларга бирелгән. Биредә 250 һәм 100 урынга исәпләнгән ике зал, балалар кафесы, уйнау урыннары һәм сәүдә галереясы урнашкан.

Тантана көнне кунакларга «Камыр батыр» белән «Буратино» спектакльләре күрсәтелде.

### ТАРИХ ЕЛЫ БАШЛАНДЫ

Быелгы ел Россиядә Тарих елы дип игълан ителде. ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Указы белән 2012 ел Татарстанда Тарихи-мәдәни мирас елы буларак үтәчәк. Шул уңайдан Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында Татарстанда Россия тарихы һәм тарихи-мәдәни мирас елын ачу тантанасы уздырылды.

«Тарих — үткәннәр турында гомуми хатирә ул, аны белү һәм саклау — безнең изге бурычыбыз. Тагын шунысы да мөһим: тарих фәне мифлардан азат булырга тиеш, чөнки сәяси һәм икътисади вакыйгалар кайчак аңа артык көчле йогынты ясый. Тарих елы — күптән чишелеш көткән мифлардан котылу өчен менә дигән мөмкинлек» — КДМСУ ректоры Рифкат Юсупов үз чыгышында нәкъ менә шул теләкне җиткерде.

### ТУКАЙ ПРЕМИЯСЕНӘ КАНДИДАТЛАР

**Г.Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премияләре буенча ТР Президенты каршындагы комиссия хәбәр итә**

Комиссия, 2012 елда Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясен дәгъва кылуга тәкъдим ителгән әсәрләр һәм хезмәтләрне карап тикшергәннән соң, түбәндәге кандидатларны тәкъдим итү турында карар чыгарды:

Салитова Фәридә Шәриф кызы. «Музыкальные драмы Салиха Сайдашева: роль жанра в становлении татарской профессиональной музыки» (Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1988 ел), «Салих Сайдашев. Жизненный и творческий путь» («Бриг» нәшрияты, Казан, 2011 ел) китаплары өчен;

Шаһиева Розалина Гомәр кызы. «Кара мәрҗән» (Татарстан газета-журнал нәшрияты, Казан, 1997 ел), «Ниса» («Мастер Лайн» нәшрияты, Казан, 2003 ел) шигъри җыентыклары өчен;

Булатова Клара Гариф кызы. «Келәү» (Казан, 2011 ел), «Каурый канат — җил атым» (Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2006 ел) китаплары өчен;

Кәримов Камил Әдһәм улы. «Ком сәгате» (Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2000 ел), «Телсез күке» (Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2005 ел) романнары өчен;

Гыйззәтуллина Флера Сабирҗан кызы. «Башкаемда — дөнья исәпләре» (Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2007 ел) китабы өчен;

Бикчурова Нәбирә Миңнәхмәт кызы

(Н. Гыйматдинова). «Парлы ялгыз» (Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2003 ел), «Мәхәббәттә гөнаһ бар» (Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2008 ел) китаплары, «Хатыннар сагышы» (Н.Гыйматдинова. Повестьлар. Беренче китап. «Идел-Пресс» нәшрияты, Казан, 2010 ел) повесте өчен;

Мир-Хәйдәров Рауль Мирсәет улы. «Пешие прогулки», «Двойник китайского императора», «Масть пиковая», «Судить буду я» романнар тетралогиясе һәм «Черная знать» сериясеннән «За все — наличными» («Идел-Пресс» нәшрияты, Казан, 2006 ел) романы өчен;

Кузьминых Софья Даниловна. Г.Тукай истәлегенә багышлап традицион милли күн мозаикасы техникасы нигезендә башкарылган хезмәтләр циклы өчен (2009 — 2010 еллар);

Сәйдашева Земфира Нурмөхәммәт кызы. «Песенная культура татар Волго-Камья» («Матбугат йорты» нәшрияты, Казан, 2002 ел) китабы өчен;

Фәйзрахманов Айдар Фәйзрахман улы. 2002 — 2010 елларда ТР Дәүләт фольклор музыка ансамбленең концерт программалары сериясе өчен;

Якупов Илдус Дәүләт улы. «Синяя птица» ораториясе (2009 ел) һәм төрле еллардагы вокаль әсәрләре өчен;

Салаватов Ренат Салават улы. Опера-балет сәнгатен саклау һәм үстерү эшенә зур өлеш кертүе, Көнбатыш Европа, рус, татар композиторлары әсәрләрен югары дәрәҗәдә башкаруы, М.Мусоргскийның «Борис Годунов», Ж.Бизеның «Кармен», Р.Ахиярованың «Шагыйрь мәхәббәте», Г.Доницеттиның «Лючия ди Ляммермур», В.Гаврилинның «Анюта», Н.Жиһановның «Җәлил» әсәрләре һ.б. премьера спектакльләрен куюы өчен;

И.Ф.Сәйфуллин, С.П.Шәкүров, А.В.Головин, З.М.Садыйков, А.Г.Саттаров, А.К.Даишева, З.Ш.Галиуллин, Р.М.Зәбиров. «Кол Шәриф мәчете» архитектура комплексын иҗат иткән өчен.

## УДМУРТИЯДӘ ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ

Удмуртия Республикасында татар мәдәнияте көннәре үткәрелде. Ул Ижау каласындагы 6нчы татар гимназиясендә язучыларның укучылар белән очрашуыннан башланды. Аннары Халыклар дуслыгы йортында түгәрәк өстәл янында Удмуртия мәдәният, матбугат һәм мәгълүмат министры урынбасары Н.Собина, милли сәясәт министры урынбасары О.Царегородцева катнашында Татарстан һәм Удмуртия Язучылар берлекләре арасында төзелгән килешүнең үтәлеше турында сөйләшү булды. Шуннан соң шул ук бинада әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Тантана барышында Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары И.Шәрипов Удмуртиядәге иҗат көчләренә Татарстан мәдәният министры А.Сибагатуллинның котлавын укып ирештерде. Шушы төбәктә яшәп иҗат итүче Р.Баттал, И.Биектаулы (Ижау), Г.Галиев, Ч.Мусинга (Татарстан, Әгерҗе) Риза Шәфи исемендәге әдәби бүләкләр тапшырылды. Әлеге кичә Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары И.Биектаулыга — 75, Г.Исхаковага — 55, шушы төбәкнең популяр җырчысы Ш.Таҗетдиновага 75 яшь тулу уңаеннан бәйрәмдарларны котлау тантанасына да әверелде.

Удмуртиядә татар мәдәнияте көннәре кысаларында үткәрелгән чараларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары В.Нуриев, эзтабар-язучы, «Сүз» нәшриятының баш мөхәррире Ш.Мостафин, «Идел» журналының бүлек мөхәррире, яшь шагыйрә Э.Һадиева, Удмуртия Язучылар берлеге каршында оештырылган татар язучылары бүлеге җитәкчесе Р.Баттал, Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары Г.Сафин, И.Биектаулы, Г.Исхакова, Ә.Низамова, Татарстан Язучылар берлегенең шәрәфле әгъзасы З.Нуретдин, Удмуртия Язучылар берлеге рәисе Б.Загребин һ.б. катнашты.

Аннары татар мәдәнияте көннәре Воткинск шәһәрендә дәвам итте.

## КОРЪӘН — РЕКОРДЛАР КИТАБЫНДА

Татарстандагы иң зур басма Коръән Гиннесснең рекордлар китабына кертелде. Гиннесс рекордлар китабы комиссиясе сертификатында: «Дөньядагы иң зур басма Коръән: аның биеклеге—2 метр, киңлеге — 1,52 метр, калынлыгы — 0,17 метр. «ARC Group s.r.l» компаниясе (Италия), осталар Неджан Братасевеч, Андрей Чернатич (Словения) һәм Мауро Лоче (Италия) тарафыннан эшләнде. ТР тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен торгызу фонды (Россия) тарафыннан 2011 елның 17 ноябрендә Кол Шәриф мәчетенә (Казан) тапшырылды», — дип язылган.

## КАДЫЙРНЫ ЧАЛЛЫДА ЗУРЛАДЫЛАР

Чаллының «Энергетик» Мәдәният сараенда Балык Бистәсе районы якташлары очрашуы булды, ул күренекле шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинның тууына 70 ел тулуга багышланган иде.

Балык Бистәсе районыннан килгән кунакларны һәм әлеге төбәктән чыккан чаллыларны сәламләргә сәхнәгә менгән Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе Вахит Имамов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев, шагыйрь Ләбиб Лерон, прозаик Марат Закир һ.б. Кадыйр Сибгатуллинның шигъриятен югары бәяләделәр.

Очрашуга Балык Бистәсе районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары

Рашат Хәбибуллин һәм мәгариф идарәсе башлыгы Илсур Садыйков житәкчелегендә Балык Бистәсеннән зур делегация килгән иде. Зал тутырып килгән тамашачыга әлеге районда туып-үскән сәнгатькярләр А.Сафин, Ф.Бәдретдинова, Р.Жәләлова, Р.Исламов, Л.Федорова, Р.Зарипова, З.Хәсәншина, Татарстанның атказанган артисты Илдус Низамов, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Дания Сибгатуллина, Шамил Ногманов катнашында концерт программасы тәкъдим ителде.

Фойеда шагыйрьнең китаплары, газета-журналларда басылып чыккан язмаларыннан күргәзмә оештырылган иде.

Кадыйр Сибгатуллинның жәмәгате, «Ләйсән» әдәби берләшмәсе житәкчесе Роза Хәмидуллина һәм «Көмеш кыңгырау» газетасының баш мөхәррире Факил Сафин белән берлектә, шагыйрьнең әдәби мирасын барлауда, киң жәмәгатьчелек игътибарына ирештерүдә гаять күп көч куйган Фәния ханым Хамматова да кичәнең үзәгендә иде.

Чаллының мактаулы гражданнары — якташлар жәмгыятьләре ассоциациясе рәисе Гөлзадә Рзаева һәм Балык Бистәсе якташлар жәмгыяте рәисе Рахман Шәфигуллин тарафыннан оештырылган кичәдә Чаллының югары уку йортларында белем алучы студентлар, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, шәһәр мәгариф идарәсенең милли бүлек белгечләре катнашты.

### ХЕЗМӘТТӘШЕБЕЗ БӘЙРӘМЕ

17 февральдә Актаныш район Мәдәният йортында танылган язучы һәм драматург Ләбиб Леронга 50 яшь тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Анда районның сәнгать әһелләре чыгыш ясады, Ләбиб Лерон ижат иткән жырлар яңгырады, спектакльләреннән өзекләр күрсәтелде. Юбилей кичәсендә «Мәйдан» журналының баш мөхәррире, язучы Вахит Имамов, журналның бүлек мөхәррире, язучы Айгөл Әхмәтгалиева, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары, язучы Вакыйф Нуриев, «Мәдәни жомга» газетасының баш мөхәррир урынбасары, шагыйрь Газинур Морат һәм Актаныште яшәп ижат итүче шагыйрьләр чыгыш ясады. Аннары Ләбиб Леронны «Казан утлары»нда бергә эшләүче хезмәттәшләре — язучылар — Камил Кәримов, Алмаз Хәмзин һәм Марат Закир тәбрикләде.

Әдипнең юбилей тантаналары шулай ук узган ел азагында Казанда К.Тинчурин исемендәге театр бинасында һәм Мөслим районы Мәдәният йортында уздырылган иде.

### ЯЗУЧЫ ҺӘМ РЕЖИССЕР

«Инновация» нәфис фильм студиясендә яна фильм төшерелде. Ул Салават Юзеевның «Он, его муза и одноклассники» дип атала. Күптән түгел ул «Мир» кинотеатрында тамашачыларга күрсәтелде.

Салават Юзеев — Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Автор һәм режиссер буларак, байтак еллар телевидение һәм кино сәнгатендә эшли. Татар халкының дистәләгән бөек шәхесләре турында документаль фильмнар ижат итте. Журналыбызның алдагы саннарында С.Юзеевнең яңа әсәре дә дөнья күрәчәк. Фильмны кино белгечләре югары бәяләде.

### ӘДИП БӘЙРӘМЕ — ТОМЛЫКЛАР БӘЙЛӘМЕ

Танылган язучы, Татарстанның Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Марсель Галиевнең 6 томлык әсәрләре басылып чыкты. Жыентыклар жанр ягыннан төрле: әдипнең 40 еллап ижат гомерендә язган шигъри әсәрләре, сайланып, ике томга туплап бирелгән. Чәчмә әсәрләрдән «Ерак урман авазы» романы һәм «Ак абагалар», «Нигез», «Алтын тотка», «Ул чакта» кебек, заманында жәмәгатьчелек фикерен кузгаткан повестьлар һәм лирик-фәлсәфи-психологик хикәяләр, юморескалар да ике томны тәшкил итә. Исеме халкыбызның күз уңында торган язучы-әдипләр, сәнгать осталарының кадере хакында язылган, «Догалы еллар» дип аталган гомер сәхифәләре аерым бер томда урын алган.

Мәжмуганың соңгы — 6нчы томы публицистик уйланулардан, тарихыбыз, халык язмышы, бүгенге заман вакыйгаларына фәлсәфи карашлардан һәм авторның каләмдәшләре хакындагы гыйбрәтле мәзәк-истәлекләрдән тора.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казандагы «Әкият» мәдәният үзәге.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Альбина Әпсәләмова**.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Республикабыз җәмәгатьчелеге зур югалту кичерде. 26 февральдә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры **Шамил Зиннур улы Закиров** 67нче яшендә кинәт вафат булды.

Ш.Закиров 40 елдан артык гомерен Татарстан Республикасы мәдәнияте һәм сәнгатенә хезмәт итүгә багышлады.

Шамил Зиннур улы 1945 елның 15 мартында Чистай районының Нарат-Елга авылында дөньяга килгән. С.Киров исемендәге Казан химия-технология институтын һәм Н.Крупская исемендәге Ленинград дәүләт мәдәният институты аспирантурасын тәмамлаганнан соң Казан дәүләт мәдәният институтының мәдәни-агарту эше кафедрасында укыта. 1979-85 елларда «Энергетик» мәдәният сарае директоры, аннары халык депутатларының Чаллы шәһәр Советы башкарма комитеты мәдәният бүлеге мөдире булып эшли.

Шамил Закиров 1985 елның 4 февраленнән Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры итеп билгеләнде. Әлеге вазифада 27 ел эшләү дәверендә ул үзен талантлы җитәкче, чын мәгънәсендә профессионал, иҗади шәхес итеп танытты. Шамил Зиннур улы репертуарга, театрда яңа юнәлешләр эзләп табу, квалификацияле кадрлар сайлауга зур әһәмият биреп, яшь актерлар һәм режиссерларны аерым игътибар үзәгендә тотты. Аның театрның матди-техник базасын ныгытуга керткән өлеше дә бәһаләп бетергесез.

Ш.Закиров бик күп театр фестиваль-бәйгеләрендә, бөек татар артистлары, режиссерлары, язучыларының истәлеген мәңгеләштерү буенча чараларда башлап йөрүче һәм оештыручы булды. Халыкара «Нәүрүз» төрки халыклар фестивале, «Яңа татар пьесасы» бәйгесе, Сәйдәшкә багышланган сәнгать бәйрәме, «Гаяз Исхакый укулары» кебек иҗат проектлары әнә шундыйлардан.

Ш.Закиров җитәкчелегендә Г.Камал театры Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләре, Латвия, Әзәрбайҗан, Үзбәкстан, Финляндия, Германия, Бөекбритания, Колумбия кебек илләр буйлап гастрольләрдә йөрде, фестивальләрдә катнашты. Шулай итеп, татар диаспорасы вәкилләре генә түгел, сәнгать сөюче барча халык ин өлкән татар театры тамашачысына әйләнде.

Мәдәният өлкәсендәге казанышлары өчен Шамил Закировка «Татарстан ССРның атказанган мәдәният хезмәткәре» һәм «Россия федерациясенен атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемнәр бирелде.

Талантлы, иҗади фикер йөртүче, зыялы кеше арабыздан мәңгегә китте. Аның якты истәлеге күнелләребездә һәрчак сакланыр.

**Р.Миннеханов, М.Шәймиев, Ф.Мөхәммәтшин, И.Халиков, Ю.Камалтынов, А.Сибагатуллин, И.Метшин, Ф.Бикчәнтәев, Т.Миңнуллин, Ш.Биктимеров, Р.Тажетдинов.**




Альбина Әпсәләмова

**КАЗАН УТЛАРЫ**
**QAZAN UTLARI**
**ОГНИ КАЗАНИ**

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)